# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зиннур МАНСУРОВ. Борынгылар сүзен барлаштырам... *Шигырьләр.* ....................................3
Әлфис ГАЯЗОВ. Кайсы яктан чыга соң бу кояш? *Роман.* ..........................................................10
Чулпан ЗАРИФ. Синең күк янам мин, әй кояш! *Шигырьләр.* ....................................................82
Нурания ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА. Мөнбәрле мөгаллим. *Повесть.* .................................................87
Энҗе ХӨСӘЕНОВА. Бер сөйләшик әле... *Шигырьләр.* ..............................................................116
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Хикәяләр. ........................................................................................................120

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Рөстәм УЗДЕНОВ. Дүртьюллыклар. *Шигырьләр.* .......................................................................134
Фатыйма КАРАБАШЕВА (УЗДЕНОВА) Начар бала диярләр. *Шигырьләр.* ..........................136
Шамил УЗДЕНОВ. Ватансызлык. *Шигырьләр (Рафис КОРБАН тәрҗемәләре).* ..................137

ЯҢА ИСЕМНӘР

Айдар НУРИЕВ. Тавык эше. *Хикәя.* ...........................................................................................139
Айгөл БАҺАВИЕВА. Кояш элдем мин күгемә бүген... *Шигырьләр.* ......................................147

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлнара ГЫЙЛЕМХАНОВА. Парлы бию. *Хикәя.* .......................................................................150

*Әдәби тәнкыйть:* Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. «Дөрес чорда» тугансың, шагыйрь!
*(Зиннур Мансуров иҗатына бер караш).* ....................................................................................155

*Фотоархив:* «Казан утлары» архивыннан. ..................................................................................162

ХӘТЕР

Тәэминә БИКТИМЕРОВА. Онытмадык сине, Зөһрә апа. ..........................................................164
Луиза ЯНСУАР. Шундый төрле һәм шундый бөтен... язмыш
*(Фәйрүзә Мөслимова турында кайбер истәлекләр).* ................................................................ 169
Чыңгыз МУСИН. Сукаланган җир башы... *Шигырьләр.* ...........................................................174

*Әбүгалисина мәгарәсе:* Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Нәсел шәҗәрәсе кайларга китә...
*(Каюм Насыйриның 200 еллыгын каршылап).* ..........................................................................178

*Хатлар яздым утырып:* Әнгам Атнабай, Разил Вәлиев, Сибгат Хәким, Нажар Нәҗми һәм
Вәзих Исхаковның Рәдиф Гаташка язган хатлары. ....................................................................183

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* ...................................................................................187

*Газиз тавышлар:* Бибидән Бибинурга кадәр иҗат юлы
(*Фирдәвес Әхтәмованың тууына – 85 ел).* ...................................................................................188
Еракка китеп кара... (*Надир Дәүләтнең тууына – 80 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* .....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..........................................................................................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 7 (1221) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---


★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.06.2024, график буенча 28.06.2024, басылып чыгу вакыты 04.07.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1455. Тираж 4446.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Зиннур
Мансуров

# БОРЫНГЫЛАР СҮЗЕН БАРЛАШТЫРАМ...

## Көлеп карау

*Нух пәйгамбәр (г.с.) хатыны*
*иренең көймә ясавыннан көлгән...*
Хәдистән

Тынгылыксыз дөнья шавын тыңлаганда,
үз-үземне тылсымчыга иш итәм, –
каһкаһәләп көлүләрнең кайтавазын
еллар аша аермачык ишетәм.

Күптән мәгълүм: җанны тәмам кисә башлый
гүзәл затның авыз ерып үртәве.
Мондый хәлдә үтеп чыкмас киртә кебек
сиземләнә җирнең һәммә үр-тавы.

Елаганда ихлас хисләр актарылса,
көлүләрдә байтак үт тә чагыла.
Самимилек җитми тормыш сәхнәсенә –
күзләреңне текәп бакчы чак кына.

Нух пәйгамбәр юкка гына ясаганмы
һәлакәттән йолып калыр көймәсен?!
Җәберсенеп дәшәм хәләл җефетемә:
«Игелекле ниятләрдән көлмә син!»

Сынык рухлы гамьсез егет йолкып ташлар
кальбендәге ашкындыргыч атын да.
Адәм углы хәтта тауны тауга бәрер,
сөеклесе хуплап торса артында.

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе; «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Дөреслек икегә төрләнмәс», «Тукай белән әңгәмәләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Көлү белән чикләнмәүче усал зәүҗә
аждаһадай зәһәрләнеп ут өрсә;
ачы мыскыл ешрак явар безнең башка,
кухаркалар хаким булып утырса...

Багындыргыч җиде җәннәт бакчасыннан
сөрелүдә бардыр бөек гыйбрәт тә.
Бәндә өчен һәрчак хаҗәт изге сүзләр
каңгырашып йөри төсле горбәттә.

Сабак алмас җиһан буйлап сибә вакыт
туфан ише сынауларның шау комын.
Кешеләрем, ай-яй, авыр кичерәсез
һәрнәрсәгә көлеп карау шаукымын!

...Минем уйлар әллә кая кереп китте –
бисмилласыз тоттым бугай каләмем.
Рәнҗетмәсәм ярар иде әнкәемдәй
рәхим-шәфкать ияләре галәмен.

## Фигълият төрлелеге

Кешене чуп-чуар яшәеш,
төрлечә тәкъдири юл көтә.
Берәүләр ат менеп узышса,
бәгъзеләр таракан йөгертә.

Дөньяны иңләгән кавемнең
җәһәтрәк агадыр каны да.
Тик менә кирегә тарткалый
зиһенне чуалткан кай нида[1].

Тынгысыз иҗтиһат әһеле
ачарга омтыла көн дә сер.
Эчкерле адәмчек сөйрәлеп
йөрүче еланнан көнләшер.

Ак яллы паровоз алдыннан
ашкынып чапмыйдыр кем генә!
Югыйсә җиһанда һичбер зат
соңгармас Кыямәт көненә.

Вундеркинд яктылык тизлеген
иярләү хакында уй йөртә...
Ил-җирләр утырып янганда,
бәгъзеләр таракан йөгертә.

## Шикләнү

*Кешесыман роботларны камилләштерү*
*юнәлешендә эшләүче якташым Р.га*

Алай ансат кына ясап булмас
безнең ише бәндә сыңарын.
Күрә торып, бидгать чиген узма –
иманыңа сыймас омтылыштан
әүвәл мөэминнәрчә син арын.

Коеп куйган камил кеше, имеш,
өстәвенә байтак тел белә...
Вакламыйкчы Ходай вәкаләтен –
узынулы ошбу үзешчәнлек
көфер гамәл кебек тоела.

Уятасың даһи уйларыңны,
колак артын тиз-тиз кашып та.
Ниятеңнең нинди нәтиҗәсе –
әйләнмәсме homo sapiens
җиһандагы артык кашыкка?!

Ымсындыргыч сонгый[2] интеллект...
Нидер җитми, нидер ким монда.
Кәттә робот гөнаһ кылмый калмас –
аның өчен кем соң җавап бирер
ташламасыз Хисап көнендә?

[1] Нида – рәсми чакыру мәгънәсендә.
[2] Сонгый – ясалма.

Хозыр-Ильяс сезләр хозурында
ихтирамлап имәс ак башын.
Кисеп әйтү һич тә мөмкин түгел –
кешесыман затлар киләчәктә
көчәйтмәсме иблис әгъвасын?!

Алай ансат кына ясап булмас
безнең ише бәндә кәмәшен.

Шатлык белән кайгы барсын ачар –
җансыз курчак, бәлки, көлеп туймас,
әмма түгә белмәс кан-яшен.

Габед шәкүр[3] төсле шиккә төшәм:
барырлармы алар хак юлдан?..
Олылауга, кардәш, өметләнмә –
мәрхәмәтле Аллаһ үзебезне
аермасын аек акылдан.

## Югалтулы алгарыш

Хәзер дөнья тиз-тиз ыргым ясый
якты тәрәккыят ягына.
Авыздагы телләр күзәнәктән
күпләп үстерелә җай гына...

Үкенечле төстә үткәннәргә
әйләнгәләп кайта бар уйлар.

Ничә кавем өчен бетү булып
төгәлләнгән алга барулар!

Алгарышны даим олылаган
милли телләр үлеп ятканда,
авыздагы телне күзәнәктән
үстерәләр тоташ... ят канда.

## Үрнәк була алмау

*Куш мәләкләргә,*
*җиһаныңны тазартсыннар...*
Г.Тукай

Чыкта даим коенулар мөмкин түгел,
моны инде бик күптәннән аңлый Җир.
Мәләкләре ташлап киткән мәмләкәттә
гомер сөрү үрнәк була алмыйдыр.

Күкләр безне, хаким мотлак[4], гелән күзли –
кавемнәрне җәберләүдән ерак тор!..
Хәер,
мәләкләре ташлап киткән мәмләкәттә
гомер сөрү гыйбрәт өчен кирәктер.

## «Птичьи права»

Кинәт шундый тәгъбир искә төште:
«Ил өстендә чыпчык үлми лә...»
Борынгылар сүзен барлаштырсам,
бәгыремне төрле уй телә.

Ваемсызлык белән авырганда,
файда итми икән кай имнәр.
Иман сеңмәс җирдә чыпчык түгел,
юкка чыкты күпме кавемнәр!

Чү, гадәти кошның хокукыннан
көнләшерлек вакыт килгән ич.
Хаким көчнең Аллаһ аңлар телгә
каныгуы бик тә кызганыч...

Югалтуга гына китерәдер
«Чыпчык үлми» диеп юану.
Гамьсезлекләр кылып башланмыймы
инкыйразга таба юл алу?

[3] Габед шәкүр – шөкер итүчән кол.
[4] Хаким мотлак – хокукы чикләнмәгән идарәче.

## Санаучылар аклануы

Чуалыша терек зиһен чаткылары,
нидер чикли бездәй затның ис-аңын.
Акъәбиләр кайчак төгәл күзалламый
сөеп туймас туруннары исәбен.

Бәни адәм инде ерак чордан бирле
уяу тора чын-хак хәтер сагында.
Әмма гавам анык итеп әйтә алмый
яшәп киткән пәйгамбәрләр санын да.

Чиксез галәм киңлегендә ничә йолдыз –
моны белми хәтта гыйльме нөҗүм[5] дә...
Татарларның җанисәбен тәгаенләү
мөмкин түгел ошбу дөнья йөзендә.

Терлек башын берәмтекләп терки дәүләт,
чыгартмыйча кирле-мырлы өнен дә.
Милли зурлык санга гына бәйле булмый,
ачыкланыр барсы Хисап көнендә.

## Гаҗәбә

*Егет кешенең эчендә иярләнгән ат ятар.*
Татар халык мәкале

Япь-яшь яугир сыман акыл йөртәм,
егет сүзе һәрдәм бер икән, –
татар аты, әйе, гаярь кавем
бәгыренә ныклап береккән.

Әлмисакта, ахры, элгәрләргә
асыл малкай җене кагылган;
алар бергә дөнья йөген тартып,
күпме яуда бергә кан койган.

Күккә якын торып, ничә тапкыр
ат өстендә намаз укылган!

Шулай юрыйм: насыйп язмыш юлын
Аллаһ хөкемдарча уң кылган.

Ахак кашлы ияр ир-ат өчен
сихри тәхет булып күренә.
Кайчак башка гаҗәп уйлар килә,
җайдак халәтенә кер генә.

Әллә инде, Раббым, безнең эчтә
утырамы тере кентавр?!
Тиңдәш затлар кебек сынау үтү...
Мондый хәлнең серен кем табар?

## Кысыр вәгъдә

Берәр мөһим мәсьәләне чишү өчен
барып керсәң олы түрә янына,
күрер күзгә ышанычлы хуҗа сине:
«Иртәгә», – дип озатачак җай гына.

Хәтта Мәнди анасына яхшы мәгълүм:
кем – бар, кем – юк, кем – бар, кем – юк иртәгә.
Изге булып саналырдай тәҗел эшне
кичектерү сыймас һичбер киртәгә.

[5] Гыйльме нөҗүм – астрономия фәне.

Кыйтгаларда кайтавазы кабатлана
кысыр сүзне яңгыраткан бу өннең.
«Иртәгә»ләр хәттин ашып киткәнгәме –
борчулары артып тора «бүген»нең.

## Курку эчендәге әҗер

Нинди була иң зур курку хисе?
Малай чакта шушы уй төшсә,
шүрләтүчән төрле шомлыкларны
санап китә идем үземчә.

Авылдагы тәкъва әбекәйләр,
үсә төшкәч, миңа хак әйтте:
«Барысыннан зуррак, балакаем,
Раббыбыздан курку халәте...»

Алда олуг әҗер көтә кебек,
җаным тыныч шуның өчен дә.
Мәрхәмәтле Аллаһ ятуы
бардыр ошбу курку эчендә.

## Үкенечле соңгару

Әнкәемнең раслап әйтүенчә,
мин бит чынлап кырда туганмын.
Шушы мәлдә, ахры, җанга кучкән
арыш камылына тулган моң.

Ерак чорга күчте әүвәл тапкыр
елап аваз салган ул җомга.
Төгәл белеп булмый: кендек каным
тамды икән кайсы урынга?!

Малай чакта тәмле йокы теләп,
назлавыңны ничә кич көттем!
Үзем исә, әни, сөю хисен
белдерергә инде кичектем.

Әллә нинди сәер ният кылып,
шагыйрь углың керә кай язга –
җиргә сеңгән кендек каны белән
язар идем ап-ак кәгазьгә:
«Я-ра-там!..»

## Мөкатдәс ышаныч

Тымык күктә аллы-гөлле җәйгор чыкса,
җетеләнеп күзаллана балачак.
Газиз әнкәй тәгълим кыла: «Коръән безне
кыяматкә кадәр әйдәп барачак...»

Менә шулай тәүге ваем иңә икән
уйнап туймас шаулы гомер башында.
Инде хәзер уйга чумган йөрәк аша
үткәзергә туры килә барсын да.

Искитәрлек: аналарча искәртүдә
тынгы бирмәс гамь-хәстәрле хикмәт бар.
Аһ, тормышның ашкынулы арбасыннан
төшеп кала күпме асыл кыйммәтләр!

Нишли ала Җирне иңләр төрки кавем,
мәхрүм булса тугрылыклы атыннан?!
Тел-төркемем, инкыйразга юлыкмыйча,
барса иде Изге Китап артыннан.

## Дөрес егылырга өйрәнү

Үсмер чакта тормыш һәркем өчен
бөтенләе белән өр-яңа.
Чарыс малай, бакчы, алга карап,
дөрес егылырга өйрәнә.

Барыс сымак өскә ыргым ясап,
җиргә килеп төшә җай гына;
аннан җитди төстә караш ташлый
күккә ашкан баскыч ягына.

Бабакае гаярь балакаен
авыр мәлдә гелән юатмас.
Бөеклеккә тәңгәл биеклекне
яулар егет башын югалтмас...

Япь-яшь башта йөргән һәрбер ният
нурга коенгандай өр-яңа!
Чарыс малай, бакчы, алга карап,
дөрес егылырга өйрәнә.

## Кичеккән кайтаваз

***(Сүз уйнату түгел)***

*Башың әйбәт эшли,*
*Равил, акылың гына юк...*
Шагыйребез әнисе Әминә ханымның
яшүсмер улына әйткән сүзләре

*Миңа без дә үсеп җиттек, әни!..*
Р.Фәйзуллин

Һәнүз сизәм, әнкәй, синең сүздә
миңгә чакырулы оран бар.
Алгысытып акыл өләшкәндә,
йоклап калган миндәй оланнар.

Бала килеш җиде иләк аша
ничек үткәрергә барсын да?!
Киңәйткәләп фәһем офыкларын,
җил дә уйнагандыр башымда.

Дәвачыдай куйган диагнозың
буенча мин җирдә бер идем.
Башым җитте: шуңа ачу итеп,
акыл хезмәтенә бирелдем.

Кылтакланып ният кылмадыммы?!
Әүвәл булды бераз шигем дә.
Яшьлегемдә артык тырышканмын –
фикер ягы басты шигырьдә.

Хасиятле хәят хаталанмый,
акыл теше чыкты миңа да.
Шуннан бирле аңга гамен өстәп,
тамырлардан гүя моң ага.

Насыйп төстә иңгән хәтер кузы,
әйдә, сүрелмичә көйрәп тор!
Җанга тансык хикмәт чәчәр өчен
уйлый белгән йөрәк кирәктер...

Хатын-кызның сихри хозурында
ничә тапкыр зиһен чуалды.
Җефетләрнең саны ишәйгәннән
име табылмаслык чир калды.

Башны ташлап сөю җиңел үтми –
гомеремдә күпме ут йоттым.
Мондый хәлләр хәттин ашар мәлдә,
ярый әле, акыл утырттым.

Вакыт юа садә малай чакның
күңел төбендәге каруын.
Ашкынулы тормыш агышына
инде фәйләсуфча карыйм мин.

Өзлектерә алмас үзаңымны
башка йөгерерлек сыйлар да...
Күп нәрсәм бар, әни, син генә юк
«Акыллым!» дип баштан сыйпарга.

## Белми кылган гөнаһ

Үткәннәргә карап үкенгәлим,
миннән башка тагы кем аһлар, –
җанны артка табан сөйри кебек
белми кылган төрле гөнаһлар.

Балачакта мәктәп бакчасыннан
алма чәлеп эчне күптердем;
шуның ише гаеп гамәл өчен
өйнең почмагында күп тордым.

Инде хәзер, сизәм, хәрәм булып
төпкә язылгандыр ул ашым...
Беркатлылык күчте егетлеккә –
кордашыма кыз да урлаштым.

Көрсиемә сеңеп көрсенгәндә,
капылт әйтеп куям: «И яшьлек!»
Азындырып һаман әзәрлекли
малайларча ихлас иләслек.

Башбаштакка хастыр ыругбашның
кисәтүле өнен ишетмәү.
Нинди генә кыек юлга кертми
анык тәдбир белән эш итмәү.

Ярый әле, милләт хакын ваклап,
күрәләтә язык җыймадым.
Газиз җиргә бәхет иңсен диеп,
һомай-кошка гелән җим салдым.

Кайчак тынгы бирмәс шикле фигыль
савап китергәли – ис китәр!
Һәрбер адым туры килеп чыкмый,
кат-кат тәүбәлимен: «Истигъфар!..»

Узганымның барсы үземнеке,
миннән башка тагы кем аһлар?!
Ахыр чиктә уңга тартсын иде
галәлгомья[6] кылган гөнаһлар,
Ярабһым!..

[6] Галәлгомья – сукырларча, аны-моны уйламастан.



Әлфис
Гаязов

# КАЙСЫ ЯКТАН ЧЫГА СОҢ БУ КОЯШ?*

РОМАН**

## 1

Әллә төш, әллә өн булды бу берничә көн, аңлавы авыр. Әллә килмәгән йокыны көтеп ятумы, һәм шул чакта берничә минутка йокыга талганда, ачык күзләрнең нидер күрүеме, кем белә.

Вагон тәгәрмәчләре текелдәве, паровозның кайчак җан өшетерлек кычкыртуы, кайчак ата каз кебек ысылдап сызгыруы, йокы аралаш ишетелгән сөйләшүләр, кирәк-кирәкмәгәнгә атылган мылтык тавышлары – барысы да буталып бетте. Һәм ничәнче көн шушы буталышлар, бер-берсенә ялганган буыннар булып, бербөтен чылбырга әйләнеп бара. Аның иң куркытканы да шул: бу хәлләрнең очы-кырые күренми иде!

Мәскәүдән авырлык белән чыгып китү, поездда чак-чак утырырлык кына урын табып урнашу, бер күз, бер колак белән генә йоклау, пычак, обрез тотып, кеше талап йөрүче явыз адәмнәр белән сүз көрәштерүләр, ул гына да түгел, бәрелешләр – болар артта каламы, әллә мәңге озата киләчәкме?

Җитмәсә, йөрәк тибешенә кушылып, каш өстендә нәрсәдер сулкылдап ала. Монысының сәбәбе бик тиз искә төште. Кичә төнлә күршедә тын гына йоклап утырган мыеклы абзыйның биштәрен тартып алырга маташучы өч кешегә берүзе каршы чыкты бит ул! Бу хәлләр төрлечә тәмамланырга мөмкин иде, хәер, анысын кем уйлаган ул чакта! Беркем дә ярдәмгә килмәде,

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2023 елда уздырылган татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Роман» номинациясендә беренче урынны алган әсәр.

** Журнал варианты

Әлфис ГАЯЗОВ (1956) – *галим, язучы, педагогика фәннәре докторы; РФ мәгариф академиясенең мөхбир-әгъзасы, Россиянең һәм Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе. «Мин бәләкәй бит әле», «Бәхет дагасы», «Актирәк, күктирәк» һ.б. китаплар авторы. Уфада яши.*

барысы да булган әйберләрен кочаклап йоклаганга салыштылар. Кулындагы пычагын бәреп төшергәч, теге өчәүнең башлыгы: «Встретимся ещё мы с тобой, солдат!» – дип ыжгырды, һәм алар икенче вагонга үтеп киттеләр. Маңгай ярасын исәпләмәгәндә, бу бандитларны бик уңай гына җиңеп чыга алды Ильяс. Абзыйның хәлләре күпкә авыррак иде, аның яраларын, булган чүпрәкләрен ертып, фронттагыча бәйләде ул. Бераз баш-күз алгач, алар төннең калган вакытын сөйләшеп үткәрделәр.

Менә шушындый күңелсез уйлар эчендә Ильяс тагын йокымсырап киткәнен сизми дә калды. Халыкның дәррәү кубып, берьюлы башлаган хәрәкәте тәэсир итте бугай, күзләр шунда ук ачылды, оеган куллар янда гына торган биштәрне әләктерде, колакка «Казан! Казан!» дигән сүзләр килеп керде. Булган кием-салымын җыеп маташкан күрше абзый, Ильяснең кузгалганын күреп, көлемсерәп эндәште:

– Тор, шәкерт, җиттек Казанга!

Инде йокы челтәрен бөтенләй ачып, алып ташлаган зиһен, каравылда торган солдат парольга җавап биргәндәй абзыйның сүзләрен дәвам итте:

– Алдыбызда бит Казан!

– Әйе, алдыбызда!

– Берничә ел окоптан чыкмаган җанга Казанны бер урап чыгу шатлыктан яну була дип хыялландым. Менә бу бәхеттән, нәкъ Тукай әйткәндәй, янсын җаным!

Ильяс вагонның төтеннән ысланып беткән тәрәзәсенә борылды.

– Әйе. Менә шулай. И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан! Казан... Казан тән яраларына да, күңел яраларына да дәва булыр.

Юлдаш абзый, тукталып, Ильяска игътибар белән карап тора иде.

– Ә кайдан Тукаев иҗатын шул тиклем яхшы беләсең?

– Мин бит «Галия» мәдрәсәсендә белем алдым. Хыялым шушы белемне Казан университетында дәвам итү иде. Әле дә ул хыял сүнмәгән. Тик... Кирәкмәгән кешеләр белән йөргән өчен, аларның тыелган эшләрендә катнашкан өчен полициядән шелтә алдым. Шуннан миңа, үзем теләп, сугышка китәргә туры килде, «вольноопределяющийся» була инде бу.

– Ә-ә-ә! Мин шулайрак дип сизгән идем шул аны тел төбеңнән! Әйе. Милләтнең язмышын даны бар дөньяга таралган мәдрәсәләребездән башка күз алдына китерү мөмкин дә түгел.

Белем турында сүз чыккач, күзләре янып китте Ильяснең. Юлдашының елмаеп торган карашында хуплау да, шатлану да, соклану да бар кебек.

– Ә башта кайда укыган идең?

– Үзебездә. Гафу итегез, мин таныштырып та тормадым үзем белән. Мин Ильяс Муллаяр улы Ягафаров булам. Үзебездә дигәнем – Казанлы мәдрәсәсендә. Аның да тарихы җиде йөзенче еллар уртасына китә. Безнең мәдрәсәдә Гали Чокрый үзе укыган.

– Чокрый татар әдәбиятында ныклы урын алган шагыйрь инде ул. Димәк, син Танып буеннан булып чыгасың?

– Әйе, Танып буеннан, Бөре өязе, Казанлы волостеннан. Нәселебез муллалардан, сугышчылардан. Шулар арасыннан бер әти игенчелек һөнәрен сайлаган. Урта хәлле.

– Сугышчылар дигәнең башкорт-мишәр гаскәреннәнме?

– Әйе.

Бушап калган вагоннан чыгарга кузгалдылар. Вокзал алды мәйданында терекөмеш бәйрәме. Бер-берсен таптардай булып, халык йөгерешә, аларны әле төтен, әле пар булып, әллә кайдан күтәрелгән болыт урап ала.

– Ни эшләргә исәбең, туган? Кая барасың хәзер?

– Университетны барып карыйсым, залларыннан бер үтәсем килә, әгәр мөмкин булса. Дөнья тынычланса, бәлки белем эстәп, шунда килермен дип уйлыйм, иншалла!

– Ә нигә Казан университетын сайладың?

Ильясның иңбашларында канатлар үсеп киткәндәй булды.

– Бу бит данлыклы Казан университеты!

– Әйе, Казан – мәгърифәт ягыннан да, мәдәният ягыннан да барлык татар халкының мәркәзе инде ул. Тик укуны дәвам итү дигән сүзләргә ышану бик кыен әлегә, туганым! Дөнья шул тиклем үзгәрде, кичәге бүгенгә ярамый. Сугыш дөньяны сүтеп-җимереп ташлады. Бәлки кайчандыр тигезләнер дә ул тормыш... Тик кайчан?

Икесе дә, моның дөреслеген аңлап, тын калдылар. Шунда Ильяс сүз катты:

– Казан университеты белән минем бер якташымның язмышы бик тыгыз бәйләнгән.

– Йә-йә, кем инде ул?

– Шәркыять белгече Саблуков. Гордий Саблуков.

Иптәше барган җиреннән туктап калды.

– Са-аблуко-ов? Гордий Семенович Саблуков? Менә сиңа тагын!

– Аның Аскын заводы белән бәйләнгән туган җирен ачыклау буенча бәхәсләр күп тә ул. Ике авыл әле дә көрәшә.

– Ничек кенә булмасын, Саблуков – шәркыять дөньясында да, рухият дөньясында да бик тирән эз калдырган кеше. Шундый якташың кебек зур, укымышлы кеше булырга язсын сиңа да. Һәм шулай булыр да бу, иншалла!

Вагоннан төшкәч, бер минутка туктап калдылар. Тирә-яктагы ыгы-зыгыга карамыйча, тын гына чыгып килгән зур кызыл кояш кына елмаеп каршы алды кешеләрне. Бар да һәр көндәгечә, кайдадыр канкойгыч сугыш бара дип тә уйламассың, ничә еллар илне тотып килгән тәртипнең дилбегәсе йомшарган-ычкынган дип тә әйтмәссең. Бары кешеләрнең йөзендә ниндидер читләшкәнлек, ниндидер чит-ят тәвәккәллек чагыла иде.

Ильяс юллар аерылганчы бирергә теләгән, тел очында торган соравын әйтмичә булдыра алмады.

– Гафу итегез, сорарга кыенсынам, тик сорамый да булдыра алмыйм. Сез үзегез кем буласыз соң?

Юлдаш көлеп үк җибәрде.

– Безнең якта, Самар губернасы, Бөгелмә өязе Әбдекәй авылында, бәйрәмнең икенче көнендә хуҗа кунагына: «Саумы, кодагый!» – дип эндәшкән дип көләләр. Без дә шулай. Бер тәүлектән артык юлда бергә булдык, башкисәрләр белән сугыштык, инде якынрак танышырга да вакыттыр, иншаллаһ! Мин – Камил Лотфыйрахман улы Якубов. Синең

кебек сугышны үткән кичәге солдат. Хәзер Казандагы Мөселман социалистик комитетында.

Абзый, кесәсеннән кәгазь кисәге тартып чыгарып, аның кош теле кебек кенә кисәген ертып алып, каләм белән нидер язып, Ильяска тоттырды.

– Менә нәрсә. Казанда февраль ихтилалыннан соң бик көчле сәяси җилләр исә. Безгә синең кебек дөнья күргән, Идел кичкән кешеләр бик кирәк. Син менә шушы адрес буенча миңа керми кайтып китмә! Университет ягына барасың бит, барыбер шул тирәдә йөрерсең! Тап бераз вакыт, сөйләшербез! Мин сине бүген иң билгеле булган татар зыялылары белән таныштырырмын. Алар – милли сәясәтне алга алып баручы кешеләр, һәм бу исемнәр тарихта әле яңгыраячак!

Инде туганлашып беткән юлчы киң итеп елмайды.

– Монысына инде иманым да камил, исемем дә Камил!

Юллар икегә аерылды. Мыеклы абзый, мәйданны чыгып, озын аяклары белән аршын салгандай, инде вокзал яны урамын үлчи башлады. Ильяс әллә нигә туктап калды, нидер аны вокзалдан чыгармый тота иде. Поезд тавышлары, ыгы-зыгы, кешеләрнең төрлелеге, җиргә төшеп җәелеп-сылашып барган төтен, аяк астында уралып, кешеләр белән бергә йөгергән пар, Казанның биек манараларына эләгеп китә алмый торган кургаш болытлар, тагын якын да, ерак та булган әллә нәрсәләр. Тора торгач аңлады Ильяс: хәтер шушы ыгы-зыгы аша ярты ел элек булган хәлләргә алып кайта иде.

Ә ярты ел элек нәрсә булды соң хәтердән чыгармый саклана алырлык?

**2**

Йокы... Кеше табигатьнең шундый баласы шул инде. Нәрсәдер барда, аның кадерен белмибез, юкка чыкса, шунда ук яна-көя башлыйбыз. Бер дә юкка бабайлардан калмагандыр тазалык теләү. Шул теләк эчендә тагын да бер мөһим әйбер бар, һәм ул әйбер – йокы. Ильяс моны фронтта яралангач, контузия алганнан соң бик яхшы аңлый башлады. Йокысыз озын газаплы төннәрдә берничә мизгелгә йоклап киткәндә, бер үк төшләр керә иде аңа.

Әйе, нәрсә булды соң ярты ел элек көн саен төшкә керерлек, шулай хәтердән чыкмый тота алырлык?

Ә ярты ел элек уналтынчы елның сентябрь ае иде.

Тиле сугышның әллә нинди кануннары меңләгән ир затын көчләп окоп казытты да шунда кертеп тутырды. Ул гына да түгел, дошман җире синеке, син аны басып алырга, кайтарып алырга тиешсең, ә моның өчен андагы җан ияләрен үтерергә, юкка чыгарырга тиешсең дип өйрәтте. Кагыйдә шул тиклем гади: син моны эшләмәсәң, каршы яклар һичшиксез шулай итәчәкләр. Ә бу инде яшәү белән үлем арасындагы җепне өзү икәнен барысы да яхшы аңлый. Сугыш өчен барысы да бер: солдатмы, генералмы, мобилизацияләнгәнме, ирекле булып килгәнме. Бүген барсың, ә иртәгесен Алла үзе генә белә.

Икенче-өченче ай бер-берсенә каршы торып, кайчакта шактый көчле атышып алып, разведкага йөреп, ике як та арып бетте. Ни әйтерсең, позицион сугыш шулай була инде ул. Әллә сугышның максаты, файдасы, кирәге булмауданмы, әллә командирларның булдыксызлыгыннанмы

шулай килеп чыкты. Тик начар ягы бар мондый хәлнең – гамьсезлеккә, тынычлыкка өйрәнәсең, ә монысын сугыш беркайчан да гафу итми, төзәтеп булмаслык нәтиҗәләргә китерә. Монда да шулай булды.

Фронтның бу өлкәсендә үзеннән-үзе килеп чыкты аркадашлану.

Бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган берничә көн сизелми дә үтеп китте. Иртәнгә әллә ниләр булыр кебек иде. Туып килгән таң солдатларны соры томан белән каршы алды. Төн белән көнне аерып булмаслык томанда, шушы сорылыкта ак белән кара бер-берсенә кереп чумып, эреп беткән кебек иде. Тынып калган табигатьтә иртәнге салкынлык хөкем сөрә, җирдә ара-тирә яткан сулар бозга әйләнгән, һәм көмеш бозның очлы уклары, әллә кайдан яктылык табып, шул яктылыкта ялтырап кала...

Фронттагы хәлләр солдатлар өчен әлегә начар түгел иде. Үзара мөнәсәбәтләр акрынлап кичә генә дошман булган солдатларның аралашуын якынайтты, алыш-биреш башланды. Кем тәмәке тәкъдим итә, кем – кәгазь, кем – ашау-эчү. Ярым-ярты рус һәм немец сүзләре, бөтен кешегә уртак булган кул белән ишарәләү – барысы да мөнәсәбәтләрне тизләтте һәм тирәнәйтте.

Дошманлык, күрәалмаучылык, аз гына булса да, артка чигенде. Тик сугыш нәтиҗәсендә барлыкка килгән ышанмаучылык кала килде: теге якка берьюлы берничә кеше йөри. Кесәдәме, итек кунычындамы – үткен хәнҗәр ята. Туганлашуга этәргән сәбәпләрнең зурысы: якын арада һөҗүм булмаячагы ике якка да ачык иде. Озакка сузылган сугышның буыннарга кереп утырып сызлатуы да читтә калмагандыр монда. Шуңа да командирлар бу хәлгә бармак аша карадылар.

* * *

Ах, бу төшләр!

Сугыш алып барыр өчен яралтылган фронт туганлашу кебек стихияле күренешкә түзеп тора алмый шул. Кайчан да булса, моңа чик куелачагы аңлашыла. Хезмәт урынын калдырып китү, дезертирлык очраклары, боерыкларны үтәмәү, солдатлар арасындагы чуалыш-буталулар, ризасызлык бу хәлләргә чик куюны якынайтты. Җәй айларында һәр көнне диярлек оештырылган демонстрацияләрне атып таратып, ике властьлылыктан котылгач, Вакытлы хөкүмәтнең куллары чишелеп китте. Һәм әле генә бәйле булган куллар вазгыятькә ярашлы ныклыкны күз ачып йомганчы кабаттан кайтарды. Солдатларның туганлашуы, агитаторларның эшчәнлеге тукталды.

Сентябрьнең соңгы көннәре җитте. Кичәге җылы көннәрдән соң кинәт яңгыр катыш кар күренүе, шул карның йә җиргә төшәр-төшмәс эрүе, йә салкын җирдә бер урынга җыелып ятуы табигатьнең кышка борылуына ишарә булды. Окопларда аякка үтеп кергән пычрак, бөтен булган тишек-тошыктан агып, тамып төшкән салкын су тамчылары җанны кыя, салкын, юешлек, туктый белмәгән тамчылар болай да соры төстәге көнне караңгылык белән аралаштыра, күңел күтәренкелегенә койма булып баса.

Туганлашуның иң кирәкле ягы шунда күренде: ул ачыктан-ачык, курыкмыйча учак ягу булды. Солдатлар учак тирәсенә җыела, җылына,

бөтен дөньяны, югарыда торган хакимиятне иң тәртипсез сүзләр белән тирги...

Тик язмаган икән тынычлык та, солых та. Солдатлар сугыша, ә солыхның язмышын югарыда, өстә утырган сәясәт кешеләре хәл итә шул! Атна да үтмәде, кичкә табан инде җанга тигән кар туктап та бетмәде, учак янына дагалары белән җир актарып, пычрак чәчеп, берничә җайдак килеп туктады. Алар арасында солдатларның котын алган полк командиры һәм башка офицерлар бар иде. Килгән уңайга кылычларын тартып алып, учак янындагы берничә немец солдатын турап ташладылар, кыска нагайка сызгыруы солдатларга ишелгән сугу тавышы белән кушылды.

Немецлар шул ук минутта ут ачты. Юньләп әзерләнмәгән окоплар, коралның чамалы булуы үзенекен эшләде – батальоннан санаулы кеше калды, немец ягында калган солдатларның язмышлары билгесез иде.

Ильяс өчен шушы көндә сугыш тәмамланды. Икенче көнне башка бик күпләр кебек окоп төбендә яраланган муенынннан аккан кызыл кан эчендә яткан Ильясны, иптәшләре табып алып, госпитальгә озаттылар...

Ах, бу төшләр!

Нигә сездә гел бер үк хәлләр, шул сугыш, тагын шул кызыл кан! Иртән чыгып, кич баеган кояшның кызыллыгы да шул кан, кояштан сузылган нурлар да канга манчылган төсле иде...

**3**

Казан, бернигә карамыйча, үзенчә кайный иде. Ашыгып атлаучы кешеләр, төркем-төркем булып җитез атлап баручы шат гимназисткалар, олылары да, яшьләре дә, тояклары белән ут чәчүче атлар, манарадан намазга чакыручы азан, калын йә нечкә чылтыравыклы җиз кыңгыраулар, тагын да әллә нинди, әллә нинди таныш та, ят та булган тавышлар... Казан үзенә тарта, үз эченә алып, сине дә үзенеке итәргә тырыша. Казанның дәрте, моңы, нуры гына түгел, бар булмышы, шаулы дөньяга алып кереп, сине бөтенләй яңа кеше итеп, алга таба этә, юл күрсәтә.

Искереп, кояшта уңып беткән хәрби киемдәге яралы солдатка университет бинасына керергә рөхсәт итмәделәр. Ильяс бер дә үпкәләмәде моңа, шул кертмәгән кешеләрнең урынына үзен куеп карады да, ул үзе дә шулай эшләр иде дигән уй аны тынычландырды.

Барыбер урап чыкты ул тыштан гына булса да университет биналарын. Февраль инкыйлабыннан соң университет исеменнән күптән түгел генә алып ташланган «император» сүзе, бик тырышып буялуга карамастан, ярылып ята, һәм бу кешеләрдә елмаю уята иде. Биредә укучы бәхетле яшьләр, дөньяның катлаулы булуына игътибар да итмичә, үз көенчә яши бирәләр. Йә узып киткән кошлар көтүе кебек күз ачып йомганчы очып үтәләр, йә, матур формаларына сокландырып, җиңел генә атлап узалар, йә, университет бинасы алдында урын табып, китапка текәләләр. Ишек төбеннән үк аңкып торган китап исе, типография буявы исе башны әйләндерерлек булып урап ала, китап эчендә булган белем һәм зиһен хәзер үк үзе белән танышырга чакыра. Салмак кына басып, мәһабәт кыяфәтле укытучылар узып китә, әле генә көлгән, әле генә бер-берсенә әллә ниләр сөйләгән студентлар аларны еракта ук олы ихтирам күрсәтеп озатып

калалар. Монда, чынлап та, икенче төрле һава, икенче төрле тормыш – монысын инде Ильяс үзе яхшы белгән «Галия» мәдрәсәсе шәкертләренең тормышы белән чагыштырып карады. Бу аның шушында укырга килергә булган теләген тагын да көчәйтеп җибәрде.

Булды, күрде Казанны, университетны Ильяс. Казан ничек кенә тартмасын, туган якка кайтырга кирәк. Алда яңа гына Казаннан Екатеринбургка тикле сузылган Казанбург тимер юлы үзенең халык тулган станцияләре, вагоннары белән көтә. Күп дигәндә, бер тәүлек уңайсызлыклар булыр, ә аннан соң инде – туган яклар! «Казаннан – Казанлыга!» – дип көлеп куйды Ильяс.

Аяклар инде вокзал ягына борыла башлаганда, келт итеп кесәдәге язу искә төште. «Миңа керми китмә!» – дип әйтте бит ул Ильяс исемен дә сорарга кыймаган абзый. Тиз генә язуны алып карагач, ул анда язылган адресның каршы йортка эленгән урам исеме белән туры килгәнен күрде. Мәскәү урамы, 37 адресында урнашкан бу бина, классик формалары, калку бизәкләре белән башка биналардан күпкә аерылып, әллә кайдан үзенә чакырып-тартып торгандай булды. Аның тирәсендә тезелеп киткән бәйләп куелган атлары, бертуктаусыз йөгереп йөргән кешеләрнең ыгы-зыгысы, сакта торган озын винтовкалы солдатлары, берничә телдә яңгыраган сөйләшүләре, өске каттагы кайсыдыр бүлмәдә өзлексез шалтыраган телефоны – болар барысы да бу бинаның бик мөһим булуына ишарә ясый иде.

Сакчы солдатлар Ильясны бернинди таныклык та сорамыйча үткәреп җибәрделәр. Үзеннән-үзе усал сакчылары белән университет искә төште, Ильяс моны уйлап елмаеп куйды. Бер кешегә сүз катарлык түгел, бар да ашыга. Кайдан табарга иртәнге танышны? Коридор тулы халык, барысының да кулында нидер бар, барысының да чырайлары борчулы, тынычсыз; татар һәм рус телләрендә сөйләшкәннәре ишетелә. Кинәт бер бүлмәнең ишеге ачылып китте, һәм аннан төрле киемдәге кешеләр чыга башлады. Очрашу бик кызу баргандыр, күрәсең: йөзләрендә кызыллык, хәрәкәтләрендә тизлек, телләрендә әле генә кабатланган җөмләләр. Ә халык агыла да агыла, алга барырлык та түгел. Ильяс, читкәрәк тайпылып, биек тәрәзәле диварга сыенды. Халык агымы кими төште, ә бераздан инде бөтенләй тукталды, коридорда берничә минутка гадәти булмаган тынлык урнашты. Алга атлаган Ильяс, бүлмәнең ишеге төбендә иң соңыннан булып чыгып килүче өч кеше белән бәрелешә язып, тагын туктап калды. Шул арада өчәүнең берсе – бер кочак кәгазь тотканы буш кулын җәеп җибәрде.

– Илья-яс! Дускаем! Син әллә Казанны шәхси атың белән урап йөрисең инде? Ни арада монда ук килеп җиткәнсең! Булдыңмы дәрелфөнүндә?

– Кыен булса да, әйтим инде, университетка кертмәделәр бит!

Игътибар белән карап торганнарның тагын берсе сүзгә кушылды.

– Ничек инде кертмәделәр? Илне саклау изге бурыч дип лаф органда, солдат беренче урында, ә инде мәгърифәт мәркәзе булган университетка кичәге солдатны бусагадан да уздырмыйлар!

– Камил, бу солдат син иртәннән туктамый сөйләгән батыр егет буладыр бит? – диде икенчесе.

– Әйе, нәкъ үзе!

– Көн буе сөйли шул, чынлап та. Әйдә, таныштырып үт!

Камил шунда ук таныштыра башлады.

– Ильяс Муллаяр улы Ягафаров. Танып буеннан, Бөре өязе, Казанлы волостеннән. Нәселләре белән муллалардан, сугышчылардан. «Галия» мәдрәсәсендә гыйлем тәхсыйль иткән. Хыялы – белемен Казан университетында дәвам итү. Әйтүенчә, әлегә ул хыялы сүнмәгән. Кирәкмәгән кешеләрнең тыелган эшләрендә катнашкан өчен полиция тарафыннан куылуга дучар булгач, вольноопределяющийся булып, сугышка китәргә мәҗбүр булган.

Алар ниндидер бер бүлмәгә керделәр.

Бүлмәдә ачык тәрәзәләрдән үзенә генә хас тавышлары белән Казан эндәшә иде. Кояшлы көннең җәйгә борылуы, талгын искән җилдәге җәй сулышы күңелгә дәрт бирә, бер мизгел дә тик тотмаслык әллә нинди көчләр алга чакыра иде.

Бүлмәгә кергәч тә, Камил таныштыруын дәвам итте.

– Менә, Ильяс, әйткән сүземне үтим. Мин сиңа иртән генә билгеле зыялылар белән таныштырам дигән идем. Монысы – Мулланур Муллаҗан улы Вахитов. Монысы – Мәхмүт Габделвахит улы Алиев. Алар – Февраль инкыйлабыннан соң Казанда Мөселман социалистик комитетын оештыручылар, «Кызыл байрак», «Сугыш сафы» дигән гәзитләрне җитәкләүчеләр. Мәхмүт – синең кебек үк сугышта, Төньяк фронтта, Казанга җае чыкканда кайтып-китеп кенә йөри әлегә.

Вахитов, Камил сөйләгәндә, игътибар белән Ильяска карап торды да Алиевка табанрак борылып әйтеп куйды:

– Без Икенче Бөтенроссия мөселман съездына делегатлар таба алмый җәфа чигәбез. Ә монда бар ягы да килгән делегат бар икән!

Алиев, килешмәүдән түгел, бу эшнең барып чыкмаячагына көрсенеп, үз фикерен әйтте.

– Соңладык! Соңладык шул! Делегатлар составы каралган, тәкъдим ителгәннәре инде расланган. Берни дә эшләп булмый!

– Ә ул чакырылган кунак булып катнаша ала бит?

– Ай саен Казанга килеп йөри алмый бит инде ул.

Мулланур Вахитов тагын сүзгә кушылды. Ильяс аның башкалар алдында аеруча ихтирамлы булуына игътибар итте. Ул сөйләгәндә, барысы да шунда ук тынып кала, ул әйткән күрсәтмәләрне шунда ук кабул итеп алалар.

– Сезнең турыда, чынлап та, күп ишеттек бүген. Кунак ашы – кара-каршы, дигәндәй, бездән сезгә бер үтенеч бар. Безгә Уфа губернасының татарлар күпләп яшәгән Бөре өязендә бер оештыручы, әйдәп алып баручы кеше кирәк. Анда әлегә мондый кеше булмады, һәркем үзенчә эшли. Дөресен әйткәндә, эшләми. Оештыручы юк! Менә эш нидә.

Ильяска карап, Камил да сүзгә кушылды:

– Синнән аерылып киткәч тә, мин бу турыда бик күп уйладым. Һәм башка келт итеп шушы уй килде бит! Шуннан иптәшләр белән киңәшләшергә дигән карарга килдем. Чиксез шатмын, алар минем фикерне хуп күрделәр. Әгәр син каршы булмасаң, сиңа шушы эшне йөкләргә иде исәп.

Алиев, нидер исенә төшереп, үз фикерен әйтте:

– Без татарларны башкортлардан аеру турында сөйләмибез. Алар – бер ата-бабаның баласы. Әгәр алдагы планнарыбыз уйлаганча барып чыкса, без

ике милләт тә тарихка исемнәребезне алтын белән язарбыз әле. Ул турыда алда тирәнрәк сөйләшербез әле.

Ачык тәрәзә челтәрләре буйлап җил йөгереп үтте. Ильяска сораулар ява торды.

– Маркс тарафыннан язылган, бездә Владимир Ленин тарафыннан үстерелгән социалистик тәгълимат белән очрашкан булдымы фронтка хәтле?

– «Галия»дә, ай-һай, ул булырмы икән? Анда мөмкин дә түгел инде.

Ильяс уйга калды.

– Әйе дип әйтергә була. Безнең Казанлыда сөргенгә җибәрелгән Яков Константинович Никонов яшәде. Бәлки, ул әле дә андадыр. Без аның белән авылга кайткан саен очраша идек.

Алиев кузгалып куйды:

– Кем, кем? Яков Константинович Никоновмы?

– Әйе.

Мәхмүт иптәшләренә борылды:

– Ул бит Георгий Валентинович Плехановның уң кулы! Аның мәкаләләре әле дә алтынга бәрабәр! Кара әле, кая җибәргәннәр аны, ә!

– Без аны бик зур игътибар белән тыңлый идек. Күп нәрсә аңлашылмый иде аңлашылмавын.

– Ничек кенә булмасын, дустым, бу бик шәп очрашу. Кайткач та, әгәр сөрген вакыты чыгып, Питерга-Мәскәүгә китеп бармаса, бар син аның янына. Өйрән, тыңла, ул әйткәннәрне хәтереңдә калдыр!

– Ә фронтта сәяси эш ничегрәк барды? Партияләрнең сүзләре солдатлар арасына барып җитә алдымы?

– Килеп җитте дә ул! Тик һәркем үз көен көйли. Ә менә большевиклар үткәрерлек итеп сөйләделәр, сәясәтне солдатларга аңлата алдылар. Тырыштылар дип әйтер идем. Иң дөрес сүз большевикларда икәнен мин күптән аңладым инде.

– Әлегә партиядә түгел инде син, алайса?

Ильяс башын иде.

– Юк! Госпитальдә аларның берсе белән яттык, тәүлек әйләнәсенә сөйләшмәгән сүз калмады. Ул миңа: «Партиянең ишекләре синең өчен киң ачык», – дип әйтте һәм тизрәк партияле булырга өндәде.

Вахитов көрсенеп куйды, иптәшләренә борылып, фикерен әйтте:

– Әйе, әгәр Ильяс партия әгъзасы да булып кайтып китсә, бу, һичшиксез, файдалы булыр иде безнең инкыйлаб эшенә, ә?

Ильяс та түзмәде, әллә кайчаннан бирле башында йөргән соравын бирде:

– Ни эшләп була инде бу минем өчен бик уңай булмаган вазгыятьтә?

Мулланур Вахитов та, башкалар да уйга калдылар, ә ул уйның барысында да бер үк икәне бер авыздан әйтелгән сүзләр аша яңгырады:

– Гадиләштерелгән юл! Гадиләштерелгән юл – язылу аша партиягә!

Бу сүзләрнең серен Камил ачты:

– Февраль инкыйлабыннан соң бик актив рәвештә партиягә язылу хәрәкәте булып алды. Аның иң күп чагы апрель аена туры килде, язылу әле дә тәмамланмаган. Гадиләштерү ул гомуми җыелышта тикшереп, карап тормыйча партиягә кабул итү була. Димәк...

– Димәк, әгәр теләгең булса, син дә партия Уставының беренче параграфы буенча аның сафларына языла аласың.

– Башка төбәкләрдә тәҗрибәле партия әгъзалары тарафыннан тәкъдим сорала, ә Казанда бу эш Уставка таянып кына эшләнә.

Ильяс мондый тизлекне көтмәгән иде, шуңа бераз югалып калды.

– Мин... мин риза, әгәр мөмкин булса инде шулай...

Камил аны кочаклап ук алды:

– Мөмкин, мөмкин, туганкай!

Мулланур Вахитов биргән сорау бу сүзләрдәге өмет чаткыларын аз гына сүндереп җибәрде:

– Ә нинди оешма аша? Уставта берничә оешма күрсәтелгән: «партийные группы, заводские ячейки; городские, подрайонные и районные комитеты; военные организации». Кайсысы безгә якынрак?

Мәхмүт Алиев җавабында өлгеррәк булды:

– Уйлыйсы да юк – соңгысы! Камил, син бүген үк Ильяс белән бергәләп барып кил гарнизонга. Язылуны рәсмиләштерергә кирәк!

– Аңлашылды! Хәзер үк китәбез. Менә бу кәгазьләрне кертеп кенә чыгам да кабинетка.

Уйчан, акыллы күзләрен Ильяска төбәп, Вахитов тагын сүзгә кушылды:

– Бер-ике көнгә Казанда калырга синең мөмкинлегең бармы?

– Бар, әлбәттә!

– Бусы әйбәт. Партиянең эшләре буенча хәбәрдар булу кирәк. Аның соңгы айда чыккан документлары белән, бигрәк тә Ленинның «Апрель тезислары» белән якыннан яхшылап танышу мөһим. Камил, монысын хәстәрләүне дә сиңа йөкләргә туры килер.

Камил бер сүз белән җавап бирде:

– Аңлашылды!

Вахитов сүзен дәвам итте:

– Садри Максудов әйтүенчә, Казан белән Уфа арасы большевиклаштырылмаган, моның өчен мөмкинлек юк, чөнки анда партия әгъзалары юк! Ә, Пермьне дә кушып, бер өчпочмак ясасак, анда, ни кызганыч, большевиклыкның эзе дә юк дип әйтергә була. Син ул якта партия кешесе буларак мөҗәррәд, ә ялгызлык – бик начар эш!

Камил, шаярып, Вахитовны бүлдерде:

– Ялгызлык Аллага гына килешә ул диләр!

Елмаеп, Вахитов Ильяска карады:

– Шуңа да сиңа авырга туры килер, тик халык ярдәме белән ул авырлыкны җиңеп чыгарсың дип ышанам. Ә без һәрвакыт синең янда, синең белән! Безнең белән син ялгыз түгел, шәкертләрчә әйтсәк, дәгел мөҗәррәд!

Кузгалдылар. Шул вакытта Мулланур Вахитов, килгән юлында тукталып, Ильяска мөрәҗәгать итте.

– Ярар, алда матур очрашулар көтсен безне, бирсен Ходай! Кара әле, Ильяс туган, бер сорау бирми булдыра алмыйм.

Ильяс аптырабрак калды.

– Мин җавап бирерлек булса, рәхим итегез!

– Бирерлек дип уйлыйм. Без бит сезнең белән якташ дип әйтерлек, якын араларда якты дөньяга килгәнбез. Минем туган яклар – Пермь губернасы

Көнгер өязе, Казай авылы. Сезнең Казанлыда да булганым бар. Өч мәчетле бик зур авыл, волость үзәге булып китте бит инде гасыр башында.

– Әйе, бу бик җылы сүзләр минем өчен.

– Сөйләсәң, бик озын тарих бу. Ярар, мин кыскарак тотармын. Туксан тугызынчы елга тиклем без Көнгердә яшәдек, шул елда Казанга күчәргә дигән карар чыгардылар безнең таралып баручы гаиләдә. Әни, әти белән икесе ике якка аерылып китәр алдыннан, үзен сезнең Изге чишмәгә күз сырхавын дәваларга алып баруны сорады. Әти үзе бармады, әлбәттә, ат һәм бер кеше бирде. Сезнең авылга ничә чакрымдыр, белмим. Чишмәгә барганчы, кайтканчы булган юллар әле дә күз алдымда тора. Арбадагы мин аунаган хуш исле, мәтрүшкәле печән исе әле дә исемдә. Әйтеп кенә бетереп буламыни безнең якларның шул тиклем матурлыгын! Исәнме әле ул Изге чишмә?

– Яхшы чишмә. Яхшы чишмә диләр аны бездә. Исән, әле дә Сабантуй булып, халык дәваланырга килә.

Һәрвакыттагыча дәвалану турындагы сүзләр бер кешене дә битараф калдырмады, шунда ук сораулар туды.

– Нинди чишмә инде ул? Нигә без белмибез аның турында?

Чишмә турында бик күп сөйли алса да, Ильяс сүзен кыска тотты.

– Тирән тарихлы чишмә ул. Хаждан кайтып килүче бер олы яшьтәге мулла шул урында мәрхүм була. Берничә көннән анда чишмә бәреп чыга. Халык аның дәвалау мөмкинлекләрен белә, файдалана башлый. Ә инде күзләрне дәвалауга килгәндә, бер землемер шунда туктап күзләрен югач, алар ачылып китә, чынлап та, әйбәтрәк күрә башлыйлар.

– Менә бит нинди изге урыннары бар безнең туган якларның!

– Киләчәктә анда Каф таулары ягындагы кебек әллә нинди дәвалану йортлары төзербез әле, иншалла!

Бар да тынып калдылар. Һәркем үз ягының матур табигатен күз алдына китерде, нindидер күңелгә якын булган сәхифәләр искә төште, үзенә чакыручы мизгелләр, күз алдына килеп, күңелне хушлады. Шунда барысы да, вакытның чамалы булуын искә төшереп, очрашуны тәмамларга ашыктылар.

– Изге юллар сиңа, Ильяс туган! Тагын да очрашырга язсын!

– Якын арада тынычлык көтәсе юк, Россия бүген таяк тыгып буталган кырмыска оясы кебек. Синең урының бу вазгыятьтә билгеле, уңышлар сиңа!

– Мөмкин кадәр хәбәрләшеп торыйк! Иң беренче чиратта – гәзитләребезне мәкаләләргә тилмертмә, хатлар җибәреп тор! Мәктүбләрең күп булсын, барысын да гәзиткә урнаштырырбыз!

Ильяс мондый җылы кабул итүдән уңайсызланып калгандай булды. Шулай булса да, ул саубуллашу вакытында үз сүзен әйтергә өлгерде.

– Хәзер чуен юл бар, «ә» дигәнче хәбәрнең кош теле хәтлесен дә, зурын да китереп җиткерерләр. Исән-сау булыгыз, очрашканга хәтле!

Ильяс белән Камил бинадан чыгарга борылдылар, Мулланур белән Мәхмүт, туктап, аларга карап тордылар. Кыю итеп алга атлаган егетнең яңа дуслары бераздан үзләренең фикерен бер-берсенә җиткерделәр.

– Ильяс алдагы эшләрнең уртасында булачак. Монысына минем иманым камил, – дип елмайды арттарак калган Камил.

– Әйе, уртасында. Кызганыч, Уфа губернасының ул төньяк төяге безнең йогынтыдан читтә кала килде, килә. Моның тискәре яклары бер килеп чыгар әле кайчан да булса. Шуңа да менә мондый белемле, кыю, тәвәккәл егетләр кирәк безгә!

Алиев әйткән сүзләрен, утын ярган балта суккандай, кулы белән куәтләде.

– Тагын бер мөһим нәрсә. Менә бу әйткәннәрне искә алып, Ильясны бәлки без Милли Идарәгә тәкъдим итәрбез? Бу да бит Максудиның бер хыялы.

– Ә миндә икенче тәкъдим. Бөтенроссия мөселман Корылтаеның көн тәртибендә 27 июльдә Милли Мәҗлес оештыру каралган, аның урнашуы да Уфада булачак дигән сүзләр бар. Әгәр барып чыкса, аны шунда тәкъдим итәргә кирәк.

– Ә нигә итмәскә? Уфада «Галия»дә укыган. Белеме бар. Сугышта булган, тормыш тәҗрибәсе аз түгел. Бик кулай кандидат!

– Иншаллаһ, ничек кенә булмасын, кирәкле кеше табылды. Элемтәне югалтмаска, ныгытырга кирәк. Аны ул үзе дә аңлый, әнә ничек итеп чуен юлны файдаланырга кирәк дип әйтте бит! – Монысын инде Мулланур Вахитов өстәде.

Камил, тиз-тиз атлап, ишек төбендә көтеп торган Ильясны куып җитте.

– Әйдә, туган, безгә әле Казанны бер-ике урыйсы бар!

Кичкә авыша башлаган көн Казан тормышына берничек тә тәэсир итә алмады. Шул ук тавышлар, шул ук гудоклар, урамнан-урамга чапкан атларның тимер дагалы тояклары тыпырдавы, трамвай җырлары, кеше сөйләшүе, ара-тирә ишетелеп киткән тавышлар, намазга чакырган азан моңы...

**4**

Мишка этисе белән Таныпның Тукмай дип аталган матур бер тугаенда берничә ел элек Матусовның ярдәмчеләре кушуы буенча кечкенә аучылар йорты салып куйды. Бу йортта яшәргә кирәк булган бар нәрсә дә бар: кирпечтән чыгарылган мич, өстәл, стенаның ике ягында йокларга урыннар, учак ягу урыны, алдан хәстәрләгән утын һәм тагын әллә ниләр.

Танып өстеннән караганда, бу өй күренми дә, ә башка яклардан сазлыклар белән уратып алынган бу урынны кешеләр бик яратмый, ул гына да түгел, куркып искә алалар. Чөнки анда Аждаһа үзе яши диләр. Авылларда була торган гарасатны китереп чыгаручы да шул Аждаһа инде.

Мишаның Аннага боларның барысын да бик матур итеп сөйләгәне бар. Күңеле романтика белән тулы кызга ниндидер яңалык кирәк, монда кайткан җәй саен ул шушы урман эчендә яткан авылда дөньяны таң калдырырлык күренешләр көтә иде. Шуңа да ул Аждаһа турында сөйләүне үтенә башлады.

– Ну, Мишенка, сөйлә инде Аждаһа турында! Синең аны күргәнең бармы? Нинди ул?

– Син нәрсә? Аны күргән кеше исән калмый бит! Куркыныч бит ул Аждаһа!

– Бер кеше дә күрмәгәч, юк инде ул!

– Аһа, булмас! Әнә, Казанлыда Галлямка карт күргән, аңардан сорарга кирәк. Тик бу иртәгә генә, иртәгә базар бит. Казанлыга чыгарга сәбәп була. Алып барырмын.

– Сөйләштек! Ә бүген теге урман өен күрсәт, алайса!

Мишка бөтенләй коелып төште. Ничә көннәр Аннаны шунда алып барырга сәбәп эзләде ул, ә монда кыз тозакка үзе килеп кереп килә! Мишка үзен кулга алырга, тынычланырга тырышты.

– Ярар! Барырбыз. Тик анда барып кире кайтканчы таң ата. Җылы киен! Көтү кайтып узгач та чыгабыз!

Монысын махсус вакытны сузар өчен дә әйтте Мишка. Көтүчеләр кирәккәнне дә, кирәкмәгәнне дә бик күп күрәләр, елгада балыкчылар барыбер була инде ул, тик аларның телләре көтүчеләрнекеннән күпкә кыскарак. Тиз генә өйдән берничә пешкән бәрәңге, тоз эләктерде, сало кисеп, икмәк сындырып алды. Чәйне урында кайнатырга дип уйлады. Ул барыбер тынычланырга өлгермәде. Куллары, бармаклары вак кына калтырау белән дерелдиләр, тавышы бөтенләй балаларныкы кебек булды, әтәч тавышына якынайды, күзләрендә моңа тикле булмаган әллә нинди утлар кабынды.

Мишка елга ярындагы көймәләрнең иң җитезен сайлап алды да кызны көтә башлады. Менә инде көтү дә кайтты. Көймә, буадан төшкән агымның өске ягыннан урап кайткан дулкыннарга ияреп, талгын гына тибрәлә. Мишка шул тибрәлүгә ияреп йоклап китә язды. Аны кызның кыңгырау чылтыравы кебек көлгән тавышы сискәндереп җибәрде.

– Егет! Йоклап, кызлардан колак кагасың бит!

Бик тиз уянды Мишка, шунда ук җавабын да тапты:

– Ә мин йокламыйм! Кояш нуры күзгә төшә бит. Шуңа аларны йомып утырдым.

Мишка көймәнең борынын ярга китереп терәде. Анна бер сикерүдә аның төбенә басты, чайкалып киткән көймәдән чак кына икесе дә елгага егылып төшмәделәр. Мишка мәче җитезлеге белән кызны тотып алды, тик барыбер тигезлекне югалтып, көймә төбенә ауды, аның өстенә Анна да егылды. Мишка Аннаны кочаклаган кулларын ычкындырмый торды. Ул болай кич буе ятарга да әзер иде дә, тик Анна аның колагына:

– Җибәр! Кеше күрә бит! Ни әйтерләр? – дип пышылдады.

Мишка батыр булып кыланды:

– Күрсәләр тагын! Ә мин беркемнән дә курыкмыйм!

– Син курыкмыйсың да ул! Ә минем турында ни әйтерләр? Ә әти белеп алса?

– Ул бит йоклый!

Мишка шулай да тиз генә аңа торырга ярдәм итте, көймәне баудан ычкындырып, ишкәкләргә тотынды һәм агымга каршы ишә дә башлады.

Таныпны бер дә юкка гына Җитез Танып дип атамаганнар шул! Агым бер караганда гына тыныч күренә, ә инде йөзеп, аның белән ярышканда, һич баш бирә торган түгел. Тик усак агачыннан чокып эшләнгән елгыр көймә бирешмәде. Анна сораулар бирә башлады.

– Ә без Таныпның теге башына тикле барабызмы?

– Соң, аучылар өе авыл янында гына булмыйдыр бит инде. Мин сине кисәттем ерак дип. Түз!

– Ярый, мин түзәм. Тик черки ашый!

Мишка көлеп җибәрде.

– Мин аларга, барып җиткәч тә, синә тимәскә кушармын. Болары мине тыңламый, болары – су черкиләре. Урманныкылар мине тыңлый!

Анна, барган шәпкә яфраклы чыбык сындырып алып, черки куа башлады. Төшеп килгән эңгер-меңгердә аның җиңеннән чыгып торган ак беләкләре уйнап алалар, чыбыкны тоткан бармаклары гүя пианинода уйный. Мишканың шул бармакларны, шул ак беләкләрне тотып күкрәгенә кысасы килә. Аның пианиноны күргәне юк, ул бүлмәгә керү аңа да тыелган. Тик сөйләгәннәре бар, пианино яткырып куйган тальянка кебек, тик басмаклары гына бик күп.

– Ә син ничек итеп шул тикле матур итеп пианинда уйныйсың?

– Пианин түгел, пианино. Озак кына укыдым, өйрәттеләр. Хәзер инде үзем уйныйм.

– Ә кайдан беләсең нинди көй уйныйсын?

– Анысы ноталар аша. Шуны укыйм да уйныйм.

Монысын Мишка берничек тә аңлый алмый. Ничек итеп инде көйне язып була? Аның уйларын сизгәндәй, Анна җавап бирде:

– Була шул язып. Ул «нота» дип атала.

Мишка тагын көлде.

– Нута дигән сүзне беләм. Ул тезмә дигәнне аңлата. Салларны җибәргәндә: «Нута артыннан нута булып киттеләр», – ди безнең Пётр Алексеевич Ташкинов.

Җитез Танып һәм елдам көймә күптән инде берсен-берсе аңладылар булса кирәк, икесе ике якка тын гына актылар. Елганың биек ярлары аның борынгылыгына ишарә итә – меңәр, ә бәлки миллион еллар елга җирне кисеп, үзән ясап, аска төшкән, һәм бу эле дә дәвам итә. Язгы ташкыннар җиткән саен Танып яңа җирләр яулап ала, юлын кыскартып, яңа үзәннәр яра.

Ниһаять, Мишка «Килеп җиттек!» диде, көймә сөзәк ярга таба борылып, ком өстенә менеп туктады. Кинәт тукталудан алар тагын егылып киттеләр – моны инде Мишка махсус эшләде. Тик Анна бу юлы җитезрәк булып чыкты, Мишка егылып яткан арада ул көймәдән ярга сикереп төште, яңгыравык тавышы белән көлеп, Мишкага эндәште.

– Ну, егет, йә йоклап, йә егылып ятасың, ә!

Бер сүз әйтмичә, Мишка көймәне тагын бераз ярга өстерәп мендерде, көймә башында яткан төргәкне эләктерде дә комга басты.

– Ну, кайда инде синең ул өең?

– Ә менә син аны эзләп кара! Ул якында гына!

Кая карама, урман, бер эз дә юк, бер юл юк. Аннаның тирә-ягына каравыннан Мишка көлеп җибәрде, агачларга табан ике адым атлап, чыршыларның калын ботакларын күтәрде. Шунда ук зур булмаган өйнең почмагы күренде. Анна, балаларча кул чабып, өйгә таба атлады.

– Әкият! Әкияттәге кебек бит бу, Мишенька! Кара, нинди куе, матур чыршы ботаклары! Чын урман! Тылсымлы урман!

Мишка бу сабыйларча шатлануга читтән көлеп карап торды. Анна ишекне ачарга тырышты, тик булдыра алмады.

– Тукта, алай түгел, ашыкма! Башта менә шушы биген ычкындырабыз, шуннан ишекне ачып була. Ишекне ачкач та, өй белән исәнләшәбез, шулай тиеш.

– Әһә, шаяртасың! Кем белән исәнләшергә инде?

– Ну, шулай кушылган.

Мишка ишекне ачып, эчкә башын тыгып: «Саумы, ызба!» – дип эндәште дә алга атлады. Аның артыннан курка-курка гына Анна да керде.

– Кызы-ык! Монысы – мич! Монысы – өстәл. Монда йоклап йөрисеңме сунарда? Ә кайда мендәрең?

– Әйе ди сиңа, мендәр, ди! Мичне ягып җибәрәсең дә йоклыйсың. Тик төнлә торып өстәргә кирәк, утын янып беткәч, суына. Ашыйсың киләме?

– Ә нәрсә бар?

– Бар да бар. Башта чәй куябыз. Мин мичне ягып җибәргәнче, син елгадан су алып кил.

Учакта янып, кап-кара булган бәләкәй генә чиләкне тотып, Анна елгага атлады, ә Мишка мичне ягып җибәрде. Анна килеп кергәндә, өйдә янган чыршы ылысыннан тәмле төтен исе таралган иде. Анна бу тикле күп яңа мәгълүматны башына сыйдырырга тырышты, бигрәк тә шушы төтен исе аны сабыйларча шатландырды. Тиз арада чәй дә кайнап чыкты, Мишка карлыган яфраклары алып кереп чиләккә салды, алып килгән нигъмәтләрен өстәлгә чыгарып тезде.

– О, бәрәңге! О-о, сало! Вот здорово!

Мишка бәрәңгеләрне чистартты, кайдандыр чүпрәк табып, өстәл өстен җир идәнгә сыпырып төшерде.

Өй эче караңгыланды. Мич авызыннан төшкән ут яктысы каршыдагы стенада, яшьләрнең йөзендә уйный, болай да сихри булган бу урынга тагын да ныграк сихрилек өсти, күңелне дулкынландыра. Өйгә таралган төтен исе борынны кытыклый, тын артыннан тын алырга чакыра.

– Миша, ә син нигә шәм кабызмыйсың?

– Бар ул, бар. Таба алсам.

Мишка, тәрәзә төбеннән шәм калдыгы табып, мичтән ут алып, аны кабызып җибәрде һәм шунда ук караңгы өйгә уйнап-селкенеп торган тагын бер яктылык килеп керде. Яктылык дип тә әйтмәссең моны, бу тын алу дулкынында чайкалган яктылык кисәге өй эченә сөйләп бетергесез нур алып кергәндәй итте.

Чәй эчәргә бернинди савыт та таба алмады Мишка. Шуңа ул чиләкне уттан алып читкә куйды:

– Савыт-саба юк, суынгач, чиләгеннән генә эчәрбез.

Шунда Анна тагын теге Аждаһаны искә төшерде, сөйлә дә сөйлә дип, аның тәкатен корытты. Мишка белгәннәрен исенә төшерергә тырышты.

– Ну, тыңла, алайса. Мин моны Казанлыдан Галлямка карттан ишеттем. Минем хәтер яхшы, картның һәр сүзе истә, хәзер түкми-чәчми сөйлим.

– Тукта әле! Син аны ничек аңладың? Ул бит татарча сөйләгәндер?

– Ә мин бит татарча ару гына сукалыйм! Син тыңла башта! Очы-кырые күренмәгән сазлык булган Тукмай дигән яланда. Монда кош та очмый дип сөйлиләр иде элек.

– Ә нинди булган инде ул Аждаһа? Дракон?

– Аждаһамы? Ул елан инде, зур дию ул. Елгаларда, күлләрдә, сазлыкларда йөз ел яшәгән елан аждаһага әверелә. Биш йөз, мең ел яшәсә, аждаһа юха еланга әйләнә, матур кыз кыяфәтенә керә ала. Ул кешеләргә су бирми, су алу өчен аңа яшь кызларны корбанга бирүне таләп итеп куя. Ә корбанга тәгаенләнгән кызны әкиятләрдә батыр егет кенә коткара ала.

– Ә нигә аны үтермәгәннәр?

– Әһә, үтерерсең! Аждаһага каршы чыккан бик күп батырлар һәлак булган.

– Кара әле, без бит шул тугайда бүген! Син мине корбанга алып килдеңме әллә?

– Әлбәттә! Минем бит Аждаһа белән килешү бар! – Мишка бик усал булырга тырышып әйтте бу сүзләрен, тик елмаюы ирен читләреннән барыбер китә алмады. – Син тыңла башта! Аждаһаның яшәгән урыны сазлыкта, баткаклыкта булган, бу урын шомлы, анда караңгылык, яңгыр, боз ява, болытлары җиргә тиеп тора. Тукмайда да шулай.

– Галләм карт шулай сөйлиме?

– Әйе! Казанлы җирләрендә борын заманда шат, киң күңелле эшчән кешеләр яшәгән, ди. Җир сөргәннәр, икмәк үстергәннәр, сунар иткәннәр, балык тотканнар, туганлашканнар. Тик алар һәр ел саен җәй башында Аждаһага иң чибәр кызны корбан итәргә тиеш булганнар. Зар елаганнар казанлылар.

– Ә нигә иң чибәрен?

– Ну, яраткан инде ул чибәрләрне. Тыңла! Менә берчак Казанлыда бер малай туа. Бәбине кулга алгач та, бу батыр егет булачак ди әйтә кендек әбисе. Ә сабый – аңа Гали дип исем бирәләр – ел үсәсен ай үсә, көн үсәсен мизгел үсә, егет чорына кереп бара, оста сунарчы була. Галинең әнисе аның Тукмайга бармавын үтенә. Егет моның сәбәпләрен сораша да авылны якларга карар итә.

Мишка, тәмле итеп, өстенә тоз сибеп, бәрәңге ашавыннан бүленеп, мичкә бер-ике утын ташлады.

– Ә авылда бик чибәр Зөһрә исемле кыз яшәгән.

– Әһә, иң кызыгы башлана!

– Болар икәү берсенә-берсе карарга да кыймый йөриләр, ялгыш кына карашлары очрашканда да, бит очлары кызарып китә. Менә шунда чибәр Зөһрә кызның да чираты килеп җитә корбанга. Гали, Зөһрәне урманга озатып барып, Аждаһа белән алышырга ниятли. Моның өчен ул көмеш саплы хәнҗәрен генә ала. Корбан көне килеп җитә. Иң матур ак киемнәрен кигән Зөһрә Тукмайга атлый, авыл халкы аны елап озатып кала. Зөһрә урманга барып җиткәндә, аны Гали көтеп ала һәм Аждаһага каршы чыга.

Аждаһаның авызыннан ут бөркелә, егет Аждаһаны, анысы егетне җиргә күтәреп бәргәли, көн төнгә авыша, яшен яшьни, күк күкри, Аждаһаның үкерүе җирне тетрәтә, алыш берничә көн туктаусыз дәвам итә.

– Ух, ты! Син бит чын сказочник!

– Гали җиңә алышта. Аждаһаның сөякләрен кара болыт Каф тавының аръягына алып китә. Шул вакытта сөйрәлеп барган койрык берничә өйнең түбәсен алып ыргыткан... Казанлы халкы бу җиңү хөрмәтенә җәй башында

ел саен бәйрәм оештыра, ул Сабан туе дип атала. Зөһрә кызның чибәрлеге йолдызларга тиң. Шуңа күрә дә күктә Зөһрә йолдызы яна, Айда Зөһрә кызның сурәте бар. Галинең исеме дә мәңгегә торып кала: әле дә, әгәр берәүнең пычагы-балтасы үткен булса, «Гали пәкесе кебек» диләр.

Аждаһа да онытылмаган. Әгәр берәрсенең явызлыгы чиктән ашып бара икән, аны Аждаһага тиңлиләр: «Азма, азма, очынма, болыт килеп алып китәр үзеңне Каф тау артына», – дип кисәтәләр.

– Матур әкият!..

Инде сүзләр кирәкми иде аларга. Анна әллә иртәнге салкыннан, әллә Аждаһадан куркып, Мишкага сыена төште. Ул әллә нинди уйларга бирелеп, әллә булган, әллә булмаган, тик ничек кенә булмасын, таң калдырырлык матур дөнья хәлләрен тагын-тагын башыннан үткәрде, шул заман кешеләренең саф мәхәббәтенә сокланды. Мишка аны нык итеп кысып кочаклады, кипкән иреннәре белән аның иреннәрен эзләде. Анна аның иреккә чыккан кулларын туктата килде, үзе дә аның муенына сарылып, кипкән иреннәрен әллә кайдан килеп чыккан эссе күз яшьләре белән чылатты.

Мишканың туктарга бер дә исәбе юк иде. «Мишка, тукта! Я... я папке пожалуюсь! Азма, болыт алып китә үзеңне Каф тау артына!» – дип сөйли-сөйли, Анна Мишканың кочагында эреп югалды.

## 5

Фронт мәхшәреннән үзен кем, ничек алып чыкканын белми Ильяс. Белерлек тә түгел иде шул.

Тагын поезд. Бу юлы ул инде туган якларга чаба. Тәгәрмәчләрнең йә бер акрынаеп, йә бер тиле тизлеккә якынаеп текелдәвендә әллә нинди таныш сүзләр яңгыраган кебек. Ильяс инде күпме вакыт шул сүзләрнең аңлаешлысын эзләп баш ватты, тик әлегә бер сүз дә аңлашырлык булып яңгырамый иде.

Ә бит бу беренче кабат кына түгел. Ярты ел элек әнә ничек иде бит йоклатмый, әллә саташтыра, әллә тилертә торган бу хәлләр.

Ул чакта Ильяс, поезд сәндерәсендә яңа гына аңына килеп, бик озак аңламый ятты кайда икәнен. Аңламассың да: тирә-якта бөтен нәрсә селкенә, шыгырдый, караңгылык белән яктылык, берсе артыннан берсе куып, качыш уйный. Колаклар тәгәрмәч тавышына күмелгән сүзләрне аңлаганын аңлап, аңламаганын аңламыйча йота иде.

Поезд алга табан чабуын белде. Иң кыены – башны борып булмауда, күз алдында өске кат киштәнең такталары, кара яшелгә буялган уйнап торган дивар кисәге. Ә кемнеңдер бәхетенә тәрәзәдән карау төшкәнме, йокы һәм саташу аша гел бер сүзне кабатлый иде:

– Алга барабыз... Дөрес барабызмы икән? Кояш... Кояш кайда булган? Әле генә уң якта иде бит!

Аның бәйләнешсез сүзләрен беркем дә тыңламый, беркем аның белән сөйләшми. Хәер, сөйләшә алырлык кеше дә юк монда, ә берничә вагон арасында йөгереп, хәлдән тайган шәфкать туташларында сөйләшү кайгысы юклыгы күренеп тора.

Тынычсыз берничә көн үтеп китте. Поезд тимер юлның әллә нинди

тыкрыкларына кереп туктый да яртышар көн шунда тора. Тынычсызлыкның исеме дә бар – моны Ильяс үзе генә аңлап алды. Бернинди борчусыз, ваемсыз тынычсызлык иде бу. Төшенкелекме инде бу, дөньяга булган карашның «барыбер» рәтенә төшеп туктавымы, кем белә.

Тик әлегә Ильяснең үз хәле хәл: муенны борып булмый, ашау – бары тик ниндидер сыекча. Сөйләшергә тырышып карады, тик барып чыкмады. Шешенгән тел аңкауга барып ябыша, шунда ук тын алуы авырлаша. Ильяс, көч-хәл белән кулын күтәреп, телен аска төшерә, бары шул вакытта гына тын алуы җиңеләеп китә. Тик бу хәрәкәт бөтен хәлне ала, һәм ул ярты көн күз дә ача алмыйча, урынында тик кенә ята.

Менә поезд каядыр якынлаша, аның сызгыруы станциянең якын булуы турында сөйли иде. Тик... Тик нәрсә булганын аңлый да алмадылар. Нәрсәгәдер бәрелгәндәй, поезд туктап калды, яралылар бер мизгел эчендә идәнгә очтылар. Берни хәтерли алмады соңыннан Ильяс: өске сәндерәдән кемдер аның өстенә килеп төште, шул кеше астында калып, каерылган кул сөяге әллә сынды, әллә буыны тайды, шул ук мизгелдә поезд инерциясенә кушылып, алга тартылды һәм «шып» туктаган поезд артыннан калмыйча, вагон стенасына килеп бәрелде. Һәм бөтен дөнья юкка чыкты, упкында бөтерелгән су кебек каядыр аска очты Ильяс.

Ыгы-зыгы купты поездда. Кычкырыш, аллы-артлы йөгереш, төтен исе – боларны Ильяс ишетмәде дә, сизмәде дә. Кемдер әллә нинди ямьсез сүзләр белән кычкыра башлады, кемдер тынычландырырга теләп, йомшак итеп нидер сөйләнде.

– А-а-а...

– Нәрсә булды? Нә-әрсә булды?

– Йөрергә юл ачыгыз тизрәк!

– Тынычланыгыз... тынычланыгыз...

Якында гына бик хәлсез тавыш ярдәмгә чакыра иде.

– Монда... Монда, ярдәмгә килегез...

Тавыш вагонда булган мәхшәр эчендә бер көчәя, бер юкка чыга. Кычкыру, иң ямьсез сүзләр белән дөньяны актарганда, аны беркем дә ишетми иде. Тагын:

– Монда... Монда, ярдәмгә килегез...

Тавыш, кемнеңдер соңгы өметен өзеп, юкка чыга бара, төтен исе белән тула барган вагонда яралылар берсен-берсе ишетерлек хәлдә түгел иде.

– Янабыз! Күрәсезме?

Ильяснең күршесе калтыранган куллары белән сәндерә читенә ябышып, үзәкне өзә торган тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Ярдәм! Йа Ходай, бармы монда кешеләр? Ярдәм итегез тизрәк!

Бу тавыш Ильясны һушына кайтарганда, берничә кеше вагон идәнендә яткан яралыларны ашыкмый гына тышка алып чыга иде. Вагонның икенче башында чытырдап ут яна, тәмсез исле куе кара төтен яралыларга сылаша, яна башлаган киемнәрдән өскә үрмәли.

«Ишетәсезме, ишетәсезме?...» дигән тавыш чигә тамырларыннан бәрелә-сугыла йөгереп үтте, юклык белән барлык арасында яткан хәлсез аң бу сүзләрне кабатлый торды. Һәм тагын да, бу юлы инде бернинди ышанычсыз:

– Янабыз! Ишетәсезме? Кем бар, кем ишетә безне?

Вагонда кан исе, төтен исе белән кушылып, укшыта, пыяласы ватылган тәрәзәдән вагон эченә битараф кына булып кар бөртекләре төшә. Идәндә яткан солдатның башына уралган бинт аклыгын югалткан, аның аша саркылган кан бинтның соңгы ак өлешләрен йота барган кебек. Җылы канга төшкән кар бөртекләре, кан хуҗасы тормыш белән хушлашкандай, эреп юкка чыга...

Һәм тагын кайдандыр:

– Ишетәсезме? Ишетәсезме? Монда!

Кем бу? Кемне чакыра ул? Нигә? Нәрсәгә бу кешегә әллә кемнәр кирәк булган? Ильясның томан эчендәге зиһене, нигәдер башка хәлләрне онытып, шушы сорауга җавап эзли. Ә томанның таралырга исәбе дә юк...

– Ишетәсезме? Ишетәсезме? Монда!

Ильясның аңы бу халәткә каршы чыга, баш күтәрә, тынгылык тапмыйча әллә ниләр эшләргә тели, тик моның өчен мөмкинлекләр аз булуы җанны көйдерә, хәлсезлектән тешләр кысыла. Йөгергән уйлар, тәртипкә килеп, бер сызыкка тезеләләр. Ишетәсезме сез, ниһаять? Монда кеше дөньядан китте, башкалар мәрхүм була, калганнар да үләчәк бит! Ишетәсезме? Ярдәм итегез!

Ишетмиләр...

– Ишетәсезме? Ишетәсезме? Монда!

Вагонда ятучылар өстенә кара төтеннән дулкын булып караңгылык, тынлык төште.

– Ишетәсезме? Ишетәсезме? Монда!

...Калганы томанның иң куесы эчендә. Күпмедер вакыт үткәч кенә, тәнгә ябышып каткан бинтлар йомгагын сүткәндә барлыкка килгән әче авырту тойгысы Ильясны яңадан бу дөньяга алып кайтты.

– Йә, йә, туган, уян! Әйдә-әйдә! – дип әйтә иде кемдер, йомшак куллары белән Ильясның сакал баскан битен кытыклап. – Бәй, синдә бит гангрена башланып ята түгелме?

Ильяс ябышкан керфекләрен өзә-өзә күзләрен ачарга тырышты.

– Менә-менә! Булдырасың бит, теләсәң! – дип дәртләндерде Ильясны йомшак куллы кеше.

Ильяс алдында ак халатына кызыл тамчылар кунган, күзләре гел елмаеп торган озын буйлы табиб, ә аның янында арган күзләрендә зур игътибар чагылган олы яшьтәге апа басып тора иде. Кемне хәтерләтә соң бу йомшак куллы кеше? Ильясның аңы тагын икегә бүленде: беренче яртысы шушы сорауга җавап эзли, икенчесе табиб әйткән сүзләрне игътибар чикләрендә тотарга тырышты.

– Әһә, менә сезнең яра! Әһә, ярчык кисәген алганнар коллегалар, афәрин! Ә нигә яра төзәлми алай булгач? – Табиб бармаклары белән яра тирәсен баскалый башлады. – Йә, йә, түз чак кына! Карарга кирәк, бу хәлнең сәбәбен белергә кирәк бит!

Йомшак дигән бармаклар бер дә йомшак түгел икән шул! Салкынлыгы белән авыртуны баскан мамык кисәгенең шундый әче булуы да мөмкин икән – монысына инде күп авыртуларга түзгән Ильяс дөньясын онытып сикереп үк җибәрде.

– Йә-йә, тынычлан, шулай кирәк! Менә инде бүгеннән хәлләр әйбәтләнүгә таба, бирсен Ходай! Ике-өч атна ятарсың да фронтка!

«Аллам сакласын!» дип эчтән генә җаваплады Ильяс. Сугыш үзенең кара эчле асылын күрсәтте, иң якты уйларны һәм ышанычларны утка салды, көлгә очырды, иң якты хыялларны юкка чыгарды. Ерактан торып, сугыш турында сөйләү – бер, үзең шунда кайнау, көн саен үлем белән күзгә-күз очрашу, аның белән бер мәйданда бию икенче икәнен шул юлны үткәннәр бик яхшы аңлый иде монда. Ильяс башыннан бу уйлар узган арада табиб аның ярасына тагын иелде.

– Нигә эндәшмисең? Тә-әк, ач әле авызыңны!

Ә бераздан ул, борылып, артыннан килгәннәргә сөйли башлады:

– Тавыш ярылары да зыян күргән дип уйлыйм. Дәвалану – әйтелгәнчә, яраны көненә ике тапкыр юу мәҗбүри. Сөйләшә алырмы – монысы икеле!

Бу сүзләрне ишеткән Ильяс үзе дә сизмәстән талпынып куйды. Моны күреп, табиб, елмаеп, озын бармагын өскә күтәрде:

– Ә-әле-егә! Ай чамасы. Шуннан барысы да үз урынына кайтыр. – Тагын иптәшләренә борылды. – Ашау элеккечә. Гомум алганда, дәвалау юллары барлык тамак-бугаз яраларындагы кебек.

Барысы да чыгып киттеләр.

**6**

Ике көн эчендә Камил Якубов белән Казанны берничә кат урадылар. Гарнизонда да булдылар, очрашулар күп булды, күп итеп кирәкле сәяси әдәбият җыеп алынды, берничә митингта катнаштылар.

Өченче көнне, ниһаять, кайтыр юлга чыкты Ильяс. Казан нинди генә матур булмасын, ничек кенә үзенә тартып тормасын, Казанлы сагындырган: йә бер якынаеп, йә бер ерагаеп, күз алдыннан китми. Сәлимә сагындырган... Әгәр хәленнән килсә, Ильяс поездны артыннан этеп тизләтер иде, тик җитми шул моңа адәмнәрнең көче! Поезд күбрәк туктап тора шул әле.

Менә тагын поезд Казаннан ерак китә алмады, ахры, ялан уртасында туктады. Чалт аяз көннең уртасында эссе кояш астында бернинди саклаусыз-яклаусыз калган вагоннар, тимеренә су сипсәң, бу бөркелерлек булып кыздылар. Җитмәсә, кемдер тәмәке тарта, шуның тәмсез төтене дымлы үпкәләргә сылана, эссе тән буйлап аккан тир исе, көннәр буена юлда йөргән кеше исе укшыта, башны әйләндерә. Шушы туктауның күпмегә сузылырын беркем дә белми, бернинди җавап юк. Ишекләрнең ачыклыгыннан әллә ни файда юк – тыштан кергән җил озын вагонны үтеп, икенче ишеккә барып җитүгә, анда хөкем сөргән эсселекне үзенә алып, һава дулкынлануы белән тәмамлана. Вагон түбәсендә эссе калайда кояш астында утырганнар ни эшли икән?

Умарта кортлары кебек шаулаган халык тынып калды.

Бер нәрсәне яхшы аңлады Ильяс: монда аз хәрәкәтләнергә, кирәкмәгәнгә кузгалмаска, чәбәләнмәскә; шул гына бу эсселектән коткара ала. Чынлап та, шулай булып чыкты. Елга ярында яткан балык кебек еш тын алуын бер рәткә китерә алды, аккан тирдән әрнегән муен ярасының эзләре дә кибеп киткәндәй булды. Сәндерә читендә кысылып утырып, ул йокыга да китә башлады. Бер уянып, бер йокымсырап

утырганда, аңа яңадан шул ук төшләр керде: тагын фронт, тагын Мәскәүнең читендә урнашкан госпиталь, тагын хастаханә... Кайдадыр урамда тормыш бара, бик сирәк кенә, шул тормышның ярчыклары булып, госпитальгә тавышлар үтеп керә.

Табиб: «Бүгеннән хәлләр әйбәтләнүгә таба бара», – дисә дә, Ильяс өчен газаплы көннәр башланды. Ялгызлык, авырту, һава җитмәү – болар барысы да түзеп булмаслык газап төенендә иде. Бигрәк тә төннәр коточкыч озын газапка, ә иртән һәм кичен үткәрелгән яраны эшкәртү гади кешенең түземлеген бетерә торган җәзага әйләнде. Авыртудан бигрәк Ильясның күңелен гаҗизлек тойгысы ашый, кимерә. Урыныннан тора да алмый яткан, яше егермедән бераз гына өстәге егетнең хәлен аңларга була. Палатада авыр яралылар, бер тавыш-тын юк, бары тик саташу, ыңгырашу, теш шыгырдату. Озын төндә монысы бик тә куркыныч булып ишетелә, бөтен дөньяда бары тик шул куркыныч теш шыгырдату гына калган, һәм ул да акрынлап тына бара...

Бер атнадан хәлләр әйбәтләнә башлады, муен да борыла, тик сөйләшеп булмый иде әле. Ниһаять, ул шәфкать туташы ярдәмендә беренче мәртәбә башын күтәрә алды, тирә-якка күз салды. Палатада авыр тынлык урнашты. Ильясның кычкырасы, стенага тибәсе килә башлады. Бер генә теләк – аны ишетсеннәр, аны моннан кояшка чыгарсыннар. Аның үзенең исән икәнен белдерәсе килә, ул тын ала, ул бу дөньяны ташлап китәргә җыенмый әле... Тик тавыш юк, кычкырырга түгел, сөйләшергә тырышу да әллә нинди ямьсез мыгырдау булып ишетелә. Анысы да баш авырту, күз алды караңгылану белән бергә бара. Чынлап та, таш идәнгә егылып төшүең мөмкин, канга буылып, бу газаплардан котылганыңны беркемнең дә сизми калуы да бар.

Көн артыннан көн үтә. Ильяс акрынлап башкалар ярдәмендә ашый башлады, тик әлегә торырга рөхсәт юк иде. Бер мәртәбә торырга тырышып карады ул, тик бу егетлек начар тәмамланды. Һуштан язды, кан китте, әгәр вакытында кермәсәләр, ниләр буласын чамалау авыр түгел иде. Йомшак куллы табиб Ильяска ялгышуын бик дәлилләп аңлатты, тик эчтә янган яшьлек аны тыңламаска, аңа каршы дәшәргә, тупаслык, тәрбиясезлек күрсәтергә чакырды. Табибның тавышы шул тиклем йомшак, җылы, дусларча елмаюы үзенә тарта иде, Ильяс бер сүз әйтмичә, аны тыңлады.

Яңалыклар да палатаны урап үтми, чөнки яңа кешеләр килә, алар яңа хәбәрләр алып киләләр. Өзлексез хәрәкәт, яңалыклар әйләнеше яралыларны да битараф калдырмый, алдагы язмышны уйларга мәҗбүр итә.

«Барлык кешеләр дә бу партиягә киләчәк, эзлә, тап юлын. Тәкъдим була калса, йөгереп бар, шуны онытма», – дип киңәш бирделәр бар да.

Бу сүзләрне Ильяс, Казанда яңа танышлары тарафыннан әйтелгән сүзләр белән янәшә куеп, чагыштырып карады. Әллә ни аерма юклыгы әллә кайдан күренеп тора, юлында очраган кешеләрнең күбесе бер үк фикерне әйтә. Тик бармы икән андый фикердәшләр Казанлы якларында? Нәрсә көтә яралары да төзәлеп бетмәгән солдатны туган җирдә? Урман эчендәге тыныч кына яшәп яткан авылларга килеп җиткәнме икән инкыйлаб шаукымы? Чуен юл! Чуен юлның булуы бу авыллардагы тыныч кына аккан яшәүне уятуына һич шиге юк. Димәк, кешеләр бүген

көндез үзәктә кичә кич булган хәлләрдән хәбәрдар, бу авылларны инде билгесезлектә яши дип әйтү бөтенләе белән дөрес түгел, димәк, монда яшәеш гөрләп-шаулап тора. Кичәге солдатларның кайтуын да көн кадагыннан алып ташлап булмый. Яңа гына салынган чуен юлы бу хәбәрләрнең шул тикле тиз әйләнешенә тәэсир итүе дә билгеле. Димәк, дөнья алга бара, Ильяс та үз урынын табар әле!

Шуларны уйлап утыра торгач, аруның чикләрен үтеп баручы Ильяс, эссегә дә карамыйча, акрын гына йокыга киткәнен сизми дә калды. Йокы дип атасаң инде моны. Тора-бара бу йокыны ярата да башлады Ильяс. Ничек кенә булмасын, беразга тирән һәм борчулы уйлардан аерып тора шушы кыска гына черем итү мәлләре. Монысына Ходайга рәхмәт укырга кирәклеге дә тиешле.

Ә поезд, йә туктап, йә тирә-якны парга күмеп, алга баруын белде. Еш туктаулар хәрәкәткә, озын көн төнгә кушылды, шулай итеп аларның исәбе дә бер вакыт югалыр кебек иде инде.

**7**

Мөхәммәтҗан бай Фазылов Уфага мал төяп киткән улларын көтә. Соңгы елларда ул базар эшләре белән үзе йөрми башлады. Бер яктан, яше дә бар, икенче яктан, ул улларына мөстәкыйльлек бирергә тырышты. «Суга кермичә, йөзәргә өйрәнеп булмый, үз юлыгызны, дус-танышларны үзегез табыгыз, үзегез һәр адымга җавап бирергә өйрәнегез!» – дип, акыллы киңәшләрен бирә килде улларына. Атнадан артык вакыт үтеп китте, кичә кич үк кайтырга тиешләр иде, тик нигәдер күренмиләр. Алар белән бер тирәдә киткән Сәләхетдин бай күптән кайтып җитте. Сораугa бер җавап – чыгарга җыенып калдылар, юлдалардыр дип тынычландырды ул Мөхәммәтҗанны.

Яшь тә түгелләр инде Нигъмәтҗан белән Шаһимәрдән. Гаиләләре бар, менә дигән йорт төзеп куйдылар. Хәйриячелек юнәлешендә бик көчле эшлиләр. Әнә нинди мәчет төзеделәр авыл уртасында, авылның күрке булып утыра. Мөхәммәтҗан заманында, кибет ачып, сату-алу эше белән шөгыльләнә башлаган иде, уллары алга китте, алар иң уңышлы юлны – ашлык белән эш итүне сайладылар. Тора-бара аларның юллары Матусов белән дә кисеште – бу яктагы чиксез урманнарны тиз генә сатып бетерә алмаячакларын алар аңлый иде. Ике якның да акылы җитте, бүлештеләр бу өлкәне, башкаларны кертмәскә дип килештеләр. Кайчандыр урман сатып алганнар урманнарын кочаклап торып калдылар, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, байга баш иеп килергә мәҗбүр булдылар.

«Бер мизгел дә тик тору, бер мизгел эшсез үткәрелгән гомер йөзәр, меңәр сумлык зыян китерә» дигән сүзләр Мөхәммәтҗанның шигаре булып торды. Чыны да шулай: тик тору бит ул туктап калу гына түгел, ул башкаларга, бигрәк тә синең көндәшләреңә юл бирүне аңлата. Шул ук сату-алуны алганда – кибет белән генә калганда, алар бүген урта кул сәүдәгәр булып йөрерләр иде, авылда кибетләр саны уннан артык. «Алтыга ал, бишкә сат, исемең булсын сәүдәгәр!» дигән сүзләрне искә алып, Мөхәммәтҗан үзалдына елмаеп куйды. Әйе, шулайдыр да, тик исем белән генә яшәп булмый, эшне алып барырга акчасы да кирәк, эш

төшемле булырга тиеш. Бай булу башкаларга, үзеңнән түбәннәргә ярдәм итүне дә йөкли. Сәүдә эшендә бүген барсың, иртәгә юксың. Гел озын акча артыннан куып, сиңа карап, синнән ярдәм көтеп торган фәкыйрьләрне онытырга ярамый. Тик гел ярдәм итеп, аларны аздырып кына җибәрмәскә, ниндидер урталык булырга тиеш, чөнки Аллаһ һәркемгә үзенекен бирә, һәркемнең үз язмышы.

Бай кешегә дә бик күп таләпләре бар дөньяның. Тырышлыктан, һәр мизгелне эш белән тутырудан соң, Мөхәммәтҗан беренче урынга белем алырга, укырга, өйрәнүгә һәрвакыт әзер булуны куя. Ул бит үзе дә, инде танылып китүенә карамастан, ел саен Казанга барып, андагы танышларында яңа эш алымнарын өйрәнә, сәүдә эшенең тышкы һәм эчке үзенчәлекләрен үз тәҗрибәсенә кертә. Тагын һаваланып йөрүне яратмый Мөхәммәтҗан, бусын инде ул иң начар сыйфат дип саный. Мин бай кеше дип, башкаларга юл да бирми йөрү Ходай кушкан эш түгел. Тик яшьләр алай уйламый шул. Әнә, икмәк пешереп сатып, чак кына күтәрелә алган Василий нәрсә ди бит? Имеш, «Юлга чыксаң, йә атың, йә хатының матур булсын, шуларның берсенә халык егылырдай булып карап калырга тиеш». Бәлки шулайдыр, тик бу табынырлык сүзләр түгел инде.

Мөхәммәтҗанның уйлары тагын улларына кайтты. Сәүдә эшендә вакытны санап кына эш итеп булмый. Тик вакытның кадерен белү кирәк. Сиксәнне куган Мөхәммәтҗан караңгы төшкәндәрәк үз биләмәләрен урап чыкты да йокларга кереп китте.

* * *

Бу вакытта Бөре шәһәренең реаль училищесының актлар залында эсерлар фиркасенең кайнар утырышы бара иде. Көн тәртибендә иң мөһим сораулар – шушы болганчык заманда фирканең эш юнәлешләре, халык белән эш итү, партия казнасын тулыландыру, булачак җыеннарда сайланучылар санына керү. Зур залда ике йөзгә якын кеше, алар арасында сугышчы киемендәгеләре дә, зыялылар да күп иде. Тик чыгыш ясаучыларның гына бер дә рәте юк, аларның чын тормышны белмәве, аңардан бик ерак торуы күренә. Шуңа да чыгышлар өзелгән чылбырны хәтерләттеләр.

Реаль училищеның җитди укучыларны күреп өйрәнгән зур залы бүген кайнар бәхәсләр мәйданына әйләнер дип көткән кешеләр акрынлап кына сүрелә бардылар. Чыгыш ясаучылар бер үк сүзләрдән ерак китә алмады.

Берәүләр соңгы елларда бик билгеле булып киткән «крестьян социализмы» идеяләре тирәсендә йөрде, анысы да бары тик теориядә, «кирәк», «шулай итү дөрес» дигән сүзләргә бәйле. Икенчеләр Рәсәйдәге капитализмның кешегә йөз белән торган социализмга каршы булуын исбатлады; өченчеләр Учредительләр җыелышының кирәклегенә басым ясадылар; башкалар милли төбәкләргә милли автономияләр статусын бирүне хуп күрде. Иң кызыксындырганы җирне гомумиләштерүгә багышланган чыгышлар булды, тик алары да «кирәк» тирәсендә генә иде.

Фазыловлар, боларга үч итеп, үзләренең тирән мәгънәле сорауларын бирә башладылар, һәм шулай итеп, өстәл түрендә утырган җитәкчеләр, үзара сөйләшеп, аларга сүз бирергә мәҗбүр булдылар.

Беренче булып Нигъмәтҗан чыгыш ясады. Ул, бик җентекле итеп, өязнең икътисади хәленә анализ бирде. Башта ук ул чыгышта файдаланылган саннарның рәсми чыганаклардан алынган булуын әйтеп үтте, моның белән ул шик-шөбһәләргә бернинди урын калдырмады.

– Мөхтәрәм җәмәгать! Чыгышымны саннардан башлыйм, – дип, ул Бөре өязендә яшәүчеләрнең күпме мал асравын, терлекләрнең баш санын яшәүчеләр саны белән чагыштырып, җан башына күпме терлек туры килүен күрсәтеп сөйләп чыкты. – Мал-туарның күп булуына игътибар итик – бу саннар да шул ук статистик мәгълүматлар җыентыгыннан. Билгеле, авыл кешесенең төп ризыгы мал белән бәйле. Нинди нәтиҗәләр ясый алабыз без моннан? Бу якларда яшәүчеләрне, большевиклар раслаганча, фәкыйрь дип әйтеп булмый. Бернинди малсызларның саны бары сигез процент тәшкил итә! Бу – бер. Икенчедән, халыкның күплеге – монысы сугышка алынучылар санына күз салсак та күренә. Өченчесе, һәм монысы иң мөһиме:өяздә яшәүче халыкның бай булуы, хәлле кешеләрнең күп булуы безнең фирканең аларга таяну мөмкинлеген арттыра. Җәмәгать, резолюция әзерләгәндә, шушыларны онытмаска кирәк дип белдерәм.

Залда чебен очкан тавыш та ишетелмәде. Зур тәрәзәләрнең ачык өлгеләре аша искән җил дә бу тынлыкны өзә алмады, ә фирка әгъзалары телсез калгандай булды. Шуннан китте үзара сөйләшү, җыелыш рәисе кыңгырау шалтыратып тәртипкә чакырып карады да, булдыра алмагач, кулын селтәде.

Сораулар күп булды. Иң аптыратканы – залда утыручыларның статистик материаллардан хәбәрдар булмавы. Бусы күпләр өчен фирка эше, революция идеяләренең уен, буш сүз булуы турында сөйли.

Шуннан сүзне Шаһимәрдән алды. Ул да баштан ук саннарның рәсми чыганаклардан алынуы турында искәртте. Иң әүвәл ул крестьяннарның күпҗирлелектән баш тартуына игътибар итте.

– Бу нәрсә урында сөйли? Бер яктан, халык бары тиешенчә, җиткәнчә генә җирне эшкәртә. Икенче яктан, җир сатыла башлады, монысын инде соңгы саннар күрсәтә.

Бу сүзләрен ул Казанлы авылы мисалында исбатлады. Шуннан Шаһимәрдән җир эшкәртүдә яңа формалар юл яруын әйтеп узды – монысына инде тагын Казанлыдан Чәчрәтке яланын мисал итеп алды.

Аның чыгышының нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәре дә читкә какмаслык булды. Башка фиркаләр үзенеке дип игълан иткәнче бу яңалыкларны эсерлар фиркасе табышы дип атап өлгерергә кирәк. Шуннан менә шушы бай катламнарны фирка ягына аударыр өчен халык арасында аңлату эшен яңартырга, арттырырга кирәк. Моның өчен һәрбер волостьта бер-ике кешене җаваплы итеп билгеләп кую фарыз. Фирканең барлыгын авылда белмиләр, фирка әгъзалары шәһәр тирәсенә ябышып ята.

Тын калып тыңладылар бу сүзләрне. Кемнеңдер күңелендә аларга теләктәшлек, кемнеңдер күңелендә ак та, кара да көнчеллек утлары кабынды. Фирка әгъзалары өчен бу чыгышлар аяз көнне яшен яшьнәгәндәй булды. Гомер буе шәһәр тирәсендә яшәп, авыл турында сөйләүче кешеләрнең иң алгы сафында торучылары иде бу, тик алардан ниндидер яңалык көтү, ниндидер хәрәкәткә өмет итү мөмкин дә түгел – залда утыручылар моны бик яхшы аңлый. Чыгышлар шуңа да матур эз калдырдылар.

Ике бертуган тыштан караганда да әйбәт фикер уяттылар. Озын буйлы, шәһәрчә киенгән егетләр акыллы уй, чагыштыра белү, русча матур итеп сөйләшүләре белән үзләренә караттылар.

Җыен тиз арада киңәшләшеп алды да ике Фазыловны фирканең өяз җитәкчелегенә кертеп тә куйдылар.

Шул арада, ярты күкне кып-кызыл итеп, кояш офык артына кереп югалды.

**8**

Төзелеп бетмәгән бинасы белән каршы алды Ильясны Чернушка станциясе. Кая карама, тузан, эсселек, тимер юлы салынган өемнән вак таш коела, станция алдындагы мәйданда пешкән бәрәңге, йомырка һәм сөт тәкъдим итүче берничә сатучы хатын-кыз. Поездлар әллә ни еш йөрми, күрәсең, шуңа да кинәт станция булып киткән җиргә сеңеп барган кара өйләр тезелгән авылда тынлык.

Иң беренче игътибарны җәлеп иткәне – бер көтү чыпчыклар. Шаулашып, юл тузанында коеналар да, ниндидер үзләренә генә билгеле булган шомлы тавышка буйсынып, дәррәү күтәреләләр, үсеп китә алмый җәфаланган агачларга, станция бинасының ябылып бетмәгән түбәсенә кунып, тын калалар. Сирәк кенә үткән поезд тәгәрмәчләре тавышы, гудокның ачы сызгыруы аларны тагын һавага күтәрә. Чыпчыклар ялтыравык кара күзләре белән пар томанына очалар, шул томанның чыганагы булган кара паровозга карап, тагын көтүе белән зур тизлектә җиргә төшеп урнашалар. Каян килә шундый тизлек, бер караганда, бер уйсыз, гамьсез һәм ваемсыз күренгән кошларда? Аларны тагын нидер куркыта, кара-соры көтү тагын бер тында өскә күтәрелә. Кайсысыдыр ат тизәгендә нидер таба, шунда үзара низаг башлана, тавыш куба, гауга күтәрелә, иң көчлесе, тапкан бөртекне талап алып, үзен хаким итеп сизә башлый, ә җиңелгәне, кыерсытучыларга үпкәләп, рәнҗеп, читкә китә.

«Боларның тормышы да нәкъ кешеләрнеке кебек бит!» дип уйлап куйды Ильяс.

Кошларның кара күзләре кешеләрне дә игътибар белән күзәтә. Тик тынгысыз кешеләрнең эше кошларда түгел шул. Йөгерәләр, кычкыралар, көләләр, сугышалар, елыйлар, бер мизгел дә тик тормыйлар. Ильяс озак карап торды мәйданда кайнаган тормышка. Баш үзеннән-үзе кешеләр белән кошлар тормышын чагыштыра, охшашлыклар таба, кешеләрнең кайсыдыр гамәлләрен кошлардан алган күчермә кебек күрә. Тынгысыз уйлар кешеләр һәм кошларның рәхимсезлегенә, тик кешеләрнең явызрак һәм рәхимсезрәк булуына, җирдә хуҗа булырга тырышуына ишарәли.

Ә кешеләр авыр тормыштан чыгу юлларын эзлиләр, аны таба алмаудан авыл кешеләренең башлары ката, һәрберсе үзенчә, үз дөньясыннан чыгып эзли ул юлларны. Күренми шул ул юллар! Хыялларда, йокысыз төннәрдә, авыр эштә бер мизгелгә күзне йомып алганда күз алдына килә торган матур тормыш күзне ачкач та юкка чыга.

Ильяс Казанлыга атлый, алда егерме чакрым юл ята. Бара торгач, кояшның түбәнгә тәгәрәгәнен дә сизми калды. Ул юл буендагы үлән арасында чылтырап аккан кечкенә чишмә ярына барып утырды, уң кулы

белән бер уч су алып битен юды. Шунда ул җиңеләеп китте, күзләре ачылды, әллә салкын чишмә суыннан, әллә инде туган якка кайтып килүдәнме, күңеле күтәрелеп, җырлыйсы килә башлады.

Каршыга һәм юл уңаена йөк салган арбалар үтә. Кайберләренең ни алып барганын карамый да белеп була иде, чөнки анда крестьян тормышы өчен мөһим булган кирәк-ярак: оны-ашлыгы да, утыны, печәне, хәтта мунчаласы да бар. Тирләгән ат исе, эссе тирдән йомшарган күн каеш исләре, әле генә чабып алган печән тәме, арбалар артыннан күтәрелгән тузан, арба артына эленгән чиләктән таралган дегет исе – боларны әйтеп тә, сөйләп тә бетерерлек түгел, алар күңелдә хатирәләр тезмәсен кузгатып җибәрә.

Арбаларның күбесе станциягә табан юл тота, димәк, иртәгә базар көне. Казанлыга табан баручыларның аз булуы Ильясның атка утырып кайту өметен кыскартканнан-кыскартты. Болай барса, төнне кайдадыр уздыру мәсьәләсе дә кузгалачак. Ильяс, чишмә суында аякларын юып, инде ару гына туза төшкән итекләрен киеп куйды. Аяклар шешенгән, ә итекләр үлчәүнең бер зурлыгына бәләкәйләнә төшкән кебек. Ильяс сискәнеп китте, чөнки аңа кемдер исеме белән атап эндәште:

– Ильяс!

Ялгыштыр бу, ишетелгәндер генә. Кем монда аны танысын да аңа эндәшсен инде? Тик әлеге тавыш тагын ишетелде:

– Ильяс! Синме бу? Әллә төшемме?

Куып җитеп килгән бер ат туктады, арбадан урта буйлы, кыска кара сакалы йөзен матур түгәрәк итеп урап алган егет сикереп төште һәм Ильясны кочаклап алды.

– Ильяс! Дустым! Ниһаять! Син! Кайтып киләсең! Яраланганыңны ишеттем!

– Г-гәрәй! С-син!

– Мин, мин бу, Ильяс! Төн салкынчарак, атларга җайлырак булыр дип, юлга чыкмый тордым.

– М-минем б-бәхеткә бб-улган и-инде б-бу, а-алайса!

– Сине инде күпме көтәбез бит! Болай булгач, авылда хәзер без бөтенесен дә җиңәбез, Алла бирсә!

– Н-ничек и-инде җ-җиңәбез? С-сездә дә с-сугыш барамын-ни?

Гәрәй, шул сорауны гына көткәндәй, шунда ук сөйли башлады:

– О-оо! Бездәме? Бездә хәзер Уфа-Казандагы кебек. Бер көнне берне сөйлиләр, икенче көнне – икенчене. Чуен юл якын булгач, хәбәрсез калганыбыз юк. Урамда ак сакаллы картларына тиклем, ике якка аерылып, бер-берсе белән бәхәсләшеп, этешеп-төртешеп яшиләр! Патшаны куган айларда сугышып бетә язды халык, бер-берсенә эт көтүе кебек ябыштылар. Әле дә шулай. Базарда да шул ук сүзләр, волостьта да.

– Җ-җиңәрбез. Т-тик мин ә-әлегә б-бик х-хәлсез ш-шул! Җ-җил и-иссә, о-очарга т-торам.

– Монысы гына үтә ул! Иң мөһиме – исән-саусың, кайтып киләсең менә. Ярар, мин сине бик сорау биреп җәфаламам, бераз ял ит! Чынлап та, бик арыган кешедәй күренәсең. Тире дә сөяк!

Арбага менеп, чабылган яшел үләнгә аудылар. Тик туктатып буламы

инде ничә ел күрешмәгән кешеләрне? Сөйләшү таңга хәтле барды, Гәрәйнең бирмәгән соравы калмады. Ильяс берничә тапкыр үзенең сорауларын бирергә талпынып карады, тик кая ул! Тотлыккан тел белән уйларын бер җөмләгә җыеп әйткәнче, Гәрәй биш сорау биреп өлгерә.

Гәрәйнең беразга туктап торган мәлләрендә Ильяс җәйге кичнең соклангыч күгенә карап ята. Төпсез күк киңлекләрендә исәбе-хисабы булмаган йолдызлар әйләнә, Киек Каз Юлы балачактан ук хәтергә сеңгән томаны белән үзенә тарта. Кояш баткан якта әле шәфәкъ кызыллыгы юкка да чыкмаган, инде кояш чыгасы як аллана башлаган, таң йолдызы Зөһрә иртәнге нурга күмелә. Бары тик җәйге төннең йөзек кашы булган сандугачлар гына армый-талмый җырлап озатып бара юлчыларны. Бер мизгелгә туктап калалар да, берсен-берсе узып, ярышып сайрый башлыйлар, әллә нинди бормалар, әллә нинди йолдызларга тикле күтәрелә торган, җирдәге талларны урап әйләнә торган матур сызгырулар аша бар дөньяны ямьгә төрәләр...

Туган як дип сөйләгәндә, чишмәләр, таллар, таулар, елга-күлләр искә төшә, тик беркем дә әлегә алар белән бергә сандугачларны онытканы юк. Сандугач – халыкның күңел кыйбласы, аның сайравы кешеләрне көндәлек мәшәкатьләрне онытырга өйрәтә, күзләрне ачып, алга барырга өнди.

Йолдызлары да, көнчыгыш белән көнбатышның аерым кызыллыгы да, сандугачлары да, урап алган бу сихрилек тә юлчыларны әсир итте, үзе дә сизмәстән Гәрәй җыр көйли башлады, Ильяс булдыра алганы белән аңа кушылырга тырышты:

Сары сандугач тотаем,
Телен ничек отаем?
Сандугач, күгәрчен,
Гөлләр үскән, күрәмсең?

Ильясны иң аптыратканы шул булды: ул тырышып-тырмашып җырлаган чакта тотлыгу акрын гына әллә кая китеп югалганын сизде. Шунда ул бар дөньясын онытып – йолдызларны да, сандугачларны да – бу хәлгә сөенеп, яңадан-яңа җыр сүзләрен кабатлады.

Танып күперенең начар булуы да аптыратмады егетләрне. Ел саен була торган, ел саен кабатлана торган хәл, кеше эшенең табигать көчләре белән ел саен очраша торган мизгеле. Язның ярсулы сулары бу күперне йомычкага тиңләп күтәреп алалар да, шырпы кабын алып киткән төсле әйләндерә-әйләндерә, озын юлда бүрәнәләрен тарата-тарата еракка алып китәләр. Су тынгач, күпер урынында каккан субайлар гына берәм-сәрәм утырып кала.

Кайдан җыядыр бу Танып шул тиклем суларны! Ярларын «ә» дигәнче үтеп китә дә чакрымнарга сузылган урман-кырларны, болыннарны тутырып җәелә башлый. Ә агуы! Зур-зур бозларны, агачларны яшен тизлегендә алга куа, юлында очраган киртәләрне алып ташлый, элек тыныч кына борылып аккан урыннарда яңа юл ачып туры гына ага башлый. Кешеләр аның бу эшләренә, бай промышленник Данила Матусовның пристанендә биек салларга бәйләнгән агачларны җиңел генә алып китүенә карап, баш чайкап,

«Далинә картның бүресе улады быел да!» – дип баш кагалар. Матусов, мыек астыннан елмаеп, үз эшен башкара бирә, авыл кешеләренә тыныч тормыш биреп, үзенә байлык өстәп яшәвен белә.

Таныпның чоңгыллары су катламын уратып әйләндерә, елганың тирәнлеге кич төнгә авышканда бигрәк тә шомлы тоела. Елга буендагы агачлар, судагы иске күперддән калган ялгызак субайлар кеше куркытырлык әллә нинди кыяфәтләргә керәләр.

Күпергә керер алдыннан, арбадан төшеп, аның бүрәнәләрен тигезләделәр, калыкканнарын әйләндереп салдылар, кайберләрен балта белән суккалап, бер-берсенә якынайттылар. Гәрәй бер-ике урында хәтта сикереп тә карады, шуннан атны йөгәненнән тотып, алга әйдәде. Акыллы хайван, зур күзләрен әйләндергәләп, бик сак кына атлап, елганы узды, теге як ярга чыккач, арттарак калган Ильясны көткәндәй туктап калды.

Озын юлның икенче аяусыз урыны – кара яшелгә манылган Кәлтә урманнары. Алар – юлчыларның да, монда яшәүчеләрнең дә котын алып торган карурманнар, аларны үткәндә, малсыз гына түгел, исән калулар да икеле. Гәрәй, шуларны уйлап, ахрысы, тынып калды, Ильяс та торып утырып, янында яткан балтаны капшады. Чынлап та, явызлар өчен әзерләп куйгандай иде бу юл: үзе тар, үзе бормалы, үзе җәйнең иң коры көннәрендә дә пычрак, үзе шомлы, чык та атны башыннан әләктер. Беркая да китә алмыйсың, кирегә борылырга да мөмкин түгел. Җитмәсә, җәйге төннең якты караңгылыгында һәрбер агач, һәрбер куак басып торган йә яткан юлбасарга әверелә, кулларын бутый, өскә сикерер төсле тоела. Гәрәйнең дилбегәне урап тоткан кулларында кан тамырлары кабарып чыккан, ул башын борып, бертуктаусыз як-ягына күз йөртә, икенче кулындагы кыска чыбыркы сабы белән битне сыдырырга торган агач ботакларын читкә этәрә. Ильясның бөтен игътибары үз ягына һәм арба артына карау, ул, үзе дә сизмәстән, шомарып беткән балта сабын кысканнан-кыса бара.

Исән-сау үтеп киттеләр Кәлтә урманнарын. Киеренкелектә чакта ишетелмәгән сандугачлар тагын сайрый башлады, бу юлы инде аларга уянып баручы башка кошлар кушылды. Гәрәй, тирләп чыккан муенын сөртеп, дилбегәне кулыннан бушатып, Ильяска сүз кушты:

– Уфф! Аллага шөкер! Ике атна элек кенә базарга баручыларны талап киттеләр, ярый әле, исән калдырганнар. Югыйсә бит, үзең беләсең, нинди генә фаҗигаләр, җинаятьләр булмады монда. Сатарга алып барган бөтен малларын тартып алганнар.

– Б-болары де-дезертирлар, аларга к-кушылган башка ә-әтрәк-әләм эшедер. Ка-казанда да мин а-андый сүзләрне к-күп ишеттем.

– Яланга чыккач, бераз туктап, капкалап алырбыз. Шушы өч-дүрт чакрым урман бөтен юлга торырлык бит!

Ильяс Гәрәйдә булган үзгәрешләргә шатланып карап барды. Бергә уйнап үскән, инде егет булып киткән Гәрәй үзенең акыллылыгы белән, олыларча фикер йөртә белүе белән сокландыра. Шәкерт чагында кайтып-китеп йөргәндә күргән Гәрәй белән бүгенге Гәрәй арасындагы аерма җир белән күк арасына тиң, аның алдында үзаллы дөнья көтәрлек кеше булып, буйга җиткән, ир-егет чорына кереп баручы җитди авыл кешесе.

Кәлтә авылын чыгып, бераз баргач та, ул чишмә буенда атны тугарып, дилбегә белән арбага эләктерде, тәртәләрне өскә күтәреп бәйләп алачык эшләде, вак-төяк утын табып, казан асып җибәрде. Бераздан бәләкәй генә чиләктә су кайнап та чыкты. Кичәге Гәрәй белән бүгенге Гәрәй арасындагы аерма җир белән күк дип уйласа да, Ильяс аның шул ук басынкы холыклы, тыңлаучан, игътибарлы, һәрбер очракта шаяру кушып җибәрә белүче кеше булуын билгеләп үтте. Гәрәй озак та көттермәде, салкын чишмә суында битен юып, кулларын киеменә сөртә-сөртә, Ильяска эндәште:

– Әйдә, туган! Син ашый торган зиннәтле солдат ризыгы юк инде юклыкка, барыннан-булганыннан рәхим ит!

Барыннан дигәне аз түгел иде монда. Күпереп пешкән арыш икмәге, кисәкле ит, киптерелгән тозлы эремчек һәм чәй. Соңгысы инде иң көтеп алынганы булды, чиләкне бик тиз бушатып, яңадан чәй куйдылар.

**9**

Танып Көтмәс, Мута һәм Шидәле елгалары кушылган урындагы урманнар өстенә сихри моң агыла. Бу көй агымында бар да бар: шул ук елгаларның чылтырап аккан тавышы да, язгы ташкыннар шавы да, агачтан агачка очып йөрүче кошлар җыры да, яңгыр тамчыларының шыбырдап тамуы да, зәңгәр киңлектәге ак болытлар агышы да, шуларга карап, шуларны күреп, тыңлап әллә ниләр кичереп яткан кешенең йөрәк тибеше дә. Бу моң әле һавага күтәрелә, әле җиргә төшеп, тиз-тиз атлаган аякларны хәтерләтеп йөгерә, әле әллә нинди сихри дә, җиңел дә булган сары сагышны күңелләргә яга, әле алдагы киңлек пәрдәләрен шар ачып очарга чакыра, әле күңелнең түрендә яткан иң яшерен серле хыялларны-хисләрне уята, шушы хисләрне чабып барган аттай дулата. Моңның үзәгендә мәңгелек йөгерү ята, кайсы гына әсәрне алма, анда шул ук алымлы, омтылышлы йөгерү, алга бару гына түгел, йөгереп, очып бару. Кояш бар бу музыкада. Кеше күңеленең иң тирән төпкелләрендә яткан шушы кичерешләр аша кояш уйный, елмая-көлә, җылы нурларын сибә, алга чакыра, ышаныч бирә. Кояш бу аһәңле көйне табигать төсләре кушып баета, анда суда уйнаган нурлар, салават күпере төсләренә кушылган, күз явын алырлык зиннәтле җемелдәү, чагылыш бар. Бу – Фредерик Шопен музыкасы. Кайдан килгән урман эченә ерак Австриядә эшләнгән музыка коралы? Пианинода уйнаучы – урман промышленнигы Данила Матусовның кече кызы Анна. Анна апасы белән ерактагы Петербургта укыйлар, ә җәйге-кышкы ялны монда үткәрәләр. Алар өчен махсус буа өстендәге бозда ачык урын әзерлиләр, шунда кызлар, шаулап-гөрләп, тимераякта шуалар. Аларның өчәрләп җигелгән атлы чаналары, Казанлы белән йорт арасын кыңгырау чыңлавына күмеп, берничә мәртәбә узалар. Ә базар көннәрендә кызлар, Казанлыга килеп, үзләренә ошаган тәм-том алалар, авыл кибетләрен бер-бер артлы урап үтәләр, яшь сатучылар белән сатулашалар. Кызларның канәгать яңгыравык тавышы, алар киткәч, тә һавада эленеп кала кебек, алар кайтып киткәч, базардагы халыкка нидер җитми иде.

Казанлыдан ерак түгел матур Аккош күле болганчык, тиз агымлы

Танып белән саф сулы, салкын Көтмәс елгалары очрашып, меңәр еллар буена диңгезгә ашыгып, гаять зур ярымутрау барлыкка китергән. Эшлекле, эшмәкәр кешеләр күзе белән караганда, урман эшкәртүне алга җибәрергә бөтен уңайлыклары булган урын инде бу. Һәм эшлекле кешеләр кирәк вакытта урында булмаса, аларны Ходай читтән китерәдер, күрәсең.

Көтмәс елгасын буып алган урында ике катлы кызыл кирпечтән эшләнгән йорт, аның белән янәшәдә генә түгәрәклеге белән тәңкәгә тиңләрлек, кулдан казылган ясалма күл.

Йорт тирәсендә бихисап күп хуҗалык биналары, фин иленнән кайтарылган ике такта яру корылмасы, шунда ук ике су тегермәне. Тегермәннең триер дип аталган сортка бүлү, ашлыкны чүптән аеру җайланмасы бөтен тирә-як төбәге өчен яңалык булып исәпләнә.

Монда ук, бөтен тирә-юньне чыңлатып, ике тимерче алачыгы эшли.

Елганың каршы ярында табигать тарафыннан эшләнгән тагын бер уңайлы урын бар – анысы халыкта Гәвен дип атала. Менә шулай халык теленә кереп үзгәргән Пётр Беренче Нидерланд иленнән алып кайткан ят сүз Гавань. Өч яктан биек булмаган тау белән уратып алынган, дүртенче ягы белән Таныпка чыккан зур мәйданда кыш буе кызу эш бара – килгән агачны баркаларга туплыйлар, аларны монда ук мунчаладан ишелгән арканнар белән кысып бәйлиләр.

Буадан агып төшкән су тавышы, елгадагы көймәләрнең, салларның берберсенә тып та тып тиеп шаулавы, такта яру корылмасының шыгырдавы, тегермән ташының бер көйгә әйләнүе, авыр бүрәнәләрне тәгәрәтүче эшчеләрнең бертавыштан «Ух!» дип кычкырулары монда бик зур сәнәгать үзәге барлыгын искәртеп тора.

Бөтенесе дә хәрәкәттә. Әллә шуңа, тәкәббер кыз Анна яраткан композиторы итеп, Шопенны сайладымы икән?

Данила Матусов, Каф таулары артыннан Казанлыга килеп, урман эшен бик киң итеп ачып җибәрде. Ул агызган баркаларны Агыйделдә кабул итәләр, Иделдә дә аның эш маркасын беләләр, бөтен Россия төбәкләрендә ул җибәргән агачларга һәм агач әйберләренә сорау бар. Кайчакта, Танып буйлап китеп барган баркаларны озатканда, ул, канәгать елмаеп, бер уйны уйлый: бәлки, шушы агачларны ерактагы Каф тау якларында да файдаланалардыр? Бәлки, алар Даниланың туган җирләренә тиклем барып җитәдер? Нәрсә әйтер иде әтисе, әгәр исән булып, моны белә калса? Ул бит аны өйдән куып чыгарырга ашыкты. Бер уйлаганда, кызу канлы егет Данила үзе гасырлар буе яшәп килгән гореф-гадәтләрне бозды. Өйдән киткәндә, Данила әтисенең гомер буе саклап килгән хәстәрлеген бераз бушатырга уйлады. Барып та чыкмас иде монысы, әгәр шул ату булмаса. Тик хәзер инде кем гаепле, кем гаепсез икәнен аңлау мөмкин түгел, ничә еллар үтеп китте бит. Колачларын җәеп егылган атасы аша атлап чыгып китте бит ул.

Ничек кенә булмасын, чит якларга килеп, үз эшен башлап җибәрә алды. Ә аның белән ярышучыларны узып китә алу – үзе бер уңыш. Хәер, ул турыда сөйләшмәү яхшы, чөнки ниләр генә булмады ул чакта.

Табигате белән тирән акыллы, зиһенле, тиз арада эш итә алучы кеше буларак, Данила берничә ныклы кагыйдәсе белән башкаларның тез

астына сукты, ул гына да түгел, шуның белән ярышырга теләүчеләрне бәреп екты.

Башта ул иң уңайлы урынны сайлап алды, аны тагын да уңайлырак итеп көйләп җибәрде. Нәкъ шул урынга Гәвен килеп урнашты. Авыл кешеләре белән ачуланышмас өчен, ул буа суын саклап торырлык дамбалар төзеде. Гамәлият күрсәтүенчә, урман эшендә иң авыры – агач ташу. Монысының да әмәлен тапты Данила. Гәвенгә кадәр агач боз өстеннән килә башлады, ә урманнан елгага тиклем боз юллары түшәлде. Монысы эшне инде күпкә җиңеләйтте. Килгән агачны Гәвендә өй биеклеге баркаларга бәйләү кыш буе бара. Ә язын аларны ташкан Танып суы Гәвенгә кереп, җиңел генә күтәреп ала да кирәкле урынына агызып алып китә. Баркаларда ишкәк базасы, ашату һәм төнге ял өчен махсус оештырылган урыннарда мунчасына тиклем әзерләнгән. Бу эшне оештыручы итеп, бик күп эзләгәннән соң, күрше авыл ирләреннән берсен, Пётр Васильевич исемле кешене сайлап уңды Данила. Киңәш сорап, минут саен баш катырмый, үзе белеп, үзе юлын табып эшли торган алтын куллы һәм акыллы ярдәмче булып чыкты ул.

Башкалар да шулай эшләргә маташып карадылар. Тик Даниланың киңлекләре һәм мөмкинлекләре белән ярышу инде берсүзсез булмастай эш. Данилага өйрәнгән халык аның артыннан барды, аны яклады, аның карарларын хуп күрде, аңа сүз тидертмәде.

Матусов беренчеләрдән булып шөгыленең төрле якларын үстереп җибәрде. Урман урман инде ул. Бүрәнәләрне су буйлап куу төшемле эш булса да, ул төрле хәлләрдән бик зур бәйлелектә тора. Ә бу хәлләр исемлегендә карның мул булу-булмавы, ташуның ничек булуы, урман, җир хуҗаларының таләпләре һәм башкалар ята. Шуңа күрә дә Данила төзелештә кирәк булган юкә ботакларын әзерли башлады, монысы инде штукатур эшендә дранча итеп кагыла, Иделнең түбән ягында моны ике куллап алалар. Күзәтүчән эшкуар муел ботакларына кытлыкны сизеп, аны да хәзерләде. Монысы инде мичкә ясаучылар өчен кирәк, тиз бөгелүчән һәм, кипкәч, үз формасын саклый торган ботаклар мичкә кыршаулары ясаганда файдаланыла.

Даниланың тагын бер яңалыгы уңышлы булып чыкты. Ялланып эшләүчеләрне иртән каршы алалар, ашаталар, атлыларны ат кирәкле эшкә, атсызларны кул эшенә бүләләр, озаталар. Кич кайткач, тагын кайнар аш ашаталар, акчасын түлиләр. Беркем беркемне алдамый, алдарга да теләми, чөнки барысы өчен дә мондагы эш – яшәү чыганагы, Данила Матусов үзе – эш бирүче дә, ашатучы да.

Килгәч тә, татар, башкорт, удмурт телләрен ярыйсы гына өйрәнеп алды Данила. Монысы сәяси яктан бик кулай ысул булып чыкты: бердән, кайда, кем аның турында ни сөйли, Данилага шул ук мизгелдә билгеле, икенчедән, бу адымы белән ул җирле халыкның үзенә булган ышанычын бермә-бер арттырып җибәрде.

Боларның барысыннан да уңышлы файдалану Матусовта зур акыл барлыгын күрсәтте. Шуңа да ул җиңел генә, бернинди каршылыксыз, җирләр, урманнар сатып алды, киң колач белән төзелеш алып барды, ерактагы завод тотучылар белән бәйләнешкә керде, акрын гына «черегән байлар» исемлегенең иң югары баскычларына менде.

Тик бер нәрсәдә бәхете булмады Даниланың – варис булырлык улы юк. Еллар уза, җитмеш ел җыелган авыр йөк, алып ташлый алмаслык булып, иңбашларга ята. Кышның озын төннәрендә усал җилләр сызгырганда, Данила Матусов ач бүре булып улый, йортсыз-хуҗасыз эт кебек шыңшый, киң ятагында урын таба алмыйча, тешләрен кысып шыгырдата. Бернигә дә, беркемгә дә зарлану гадәте булмаса да, берүзен калдырып ташлап киткән хатынына зарын сөйли, ялгызлыгына зарлана. Даниланың төннәре бик озын, көннәре бик тиз үтә, бер калкып, бер басылып киткән шәм яктысында бүлмәдә әллә нинди шәүләләр чайкала. Төшләренә бик еш этисе керә башлады, ул берсүзсез, кузгалмыйча, карап тора да тора, бары тик күкрәгендәге ярасыннан кан тама. Төнге йокыны кинәт теге вакыттагы ату тавышы бүлә, Данила сикереп торып утыра, авыр уйлар аның башын тагын аска ия. Ул инде алда булачагыннан курыкмый, тик белә – булачагы әле соңгысы түгел. Нидер эшләргә кирәк, бәлки кайтып этисенең каберенә егылу зарурдыр...

Таң әтәчләре белән бергә тора Матусов, каты кофе эчә, трубкасына тәмәке тутырып кабыза да йорт-кура, хуҗалыкны әйләнеп чыга. Бөтен нәрсәне дә күрә, бернәрсә дә аның карашыннан читтә калмый. Шуннан ярдәмчеләрен җыеп, көн артыннан көн бер нәрсәне кабатлый-кабатлый, аларга күрсәтмәләр бирә, кисәтә, орыша, мактый.

Бары тик ике кешегә аз гына ышана Данила. Берсе – Пётр Васильевич, анысына бар да ихтирам белән шулай эндәшәләр. Икенчесе дә – Пётр, Петька, язмыш тарафыннан очраклы сайлап алынган ир уртасындагы кеше үзенең этләрдә генә була торган бирелгәнлеге белән шатландыра да, бер үк вакытта куркыта да. Данила, бу кешене малай чагыннан табып, эшкә өйрәтте, һәрвакыт аны башкалардан аерып билгели, эшләгән эшләре өчен буш итми, хезмәтен мулдан бәяли. Куркуы нидән икәнен үзе дә аңлый алмый Данила. Бер яктан, Петька барысын да эшли, аның карамагындагы кешеләр дә эшли. Баркаларның исән-имин кирәк җиргә барып җитүе дә алар өстендә. Ике Пётр да тырыш, күңелләрендә ни ятадыр, монысы, әлбәттә, билгеле түгел, ләкин кемгәдер чак кына булса да ышанырга да кирәк бит! Бер кеше башкарып чыга торган эш түгел. Шуңа да акча ару гына тама тора.

Халыкта бу ярдәмчеләрне дәрәҗәләрен түбәнәйтергә тырышудан түгел, өйрәнелгәнчә «Ике Петька» дип атыйлар.

Матусовның бар курыкканы – кешенең үзгәрүчән булуы, бер кешегә дә ышанырга ярамау. Барысы да хатыныннан башланды түгелме? Ул бит моннан егерме еллар элек кара урман уртасында яшәргә теләмәде, Даниланы да, балаларын да ташлап, зур шәһәргә китте дә барды. Шуннан бирле аны күргәне дә булмады Даниланың. Хәер, хатынында гынамы икән эш? Үзендә түгелме Даниланың? Ул дөньясын, туганнарын ташлап чыгып китмәдемени? Беренче булып туган ягына, туганнарына ул хыянәт итмәдемени? Болар бит картлык якыная барганда күңел яндыра, өтә торган нәрсәләр! Әллә шуңамы ул төшендә бик еш кына тауларны, өй кырында, тәрәз каршында яфракларын койган таныш агачны күрә...

Данила үзенең бөтен ярату хисләрен, бөтен өметен кызларына баглап карады. Байлык бирде ул аларга, зур калаларда укып, белем

алырга мөмкинлек бирде. Ә алар... Ярты ел шушы караңгы авылда яталар, ярты ел Уфага, Петербургка барып, акча туздыралар. Бу хәлләрне аңлау үтә дә кыен иде. Баштарак Данила кызларга шундый холык биргән әниләрен гаепли, соңыннан үзенең монда китереп батырган язмышын каргый иде.

Барысы да көлгә әйләнеп ята. Күз алдында! Байлык белән тынычлык берсен берсе якын итә алмадылар, яшьлек хыялының йолдызы якты итеп яна алмады. Байлык килде, тынычлык китте. Ялгыз бүре кебек яшәү, ялгыз бүре кебек барысын да күралмау, барысына да нәфрәт хисе генә калды. Данила бер нәрсәгә төшенә алмый: яз көне, баркаларның беренче партиясен озатканда, Гәвенгә йөзләре шатлыктан янучы эшчеләр гаиләләре белән киләләр, бәйрәм ясыйлар, җырлыйлар, бииләр. Нигә? Үзләренә тиене генә төшә бит агач сатканнан кергән озын акчаларның. Ә алар шунысына да канәгать, шул да аларны шатландыра, бәхетле итә, шуның өчен дә алар Данилага рәхмәтле. Баркалар, Таныпны үтеп, Иделгә табан баралар, алар Даниланың көндәшләренеке кебек таралмый. Эшчеләр, Данила артында: «Аның түбәсе борчак саламы белән ябылган!» – дип әйтсәләр дә, хуҗа өчен җаннарын фида кыларга әзер, аны яклыйлар һәм саклыйлар. Ул да аларга ярдәм итәргә һәрчак әзер тора, кирәк булса, берниен дә жәлләми, беренче булып килә.

Тик... Тынычлык юк! Тынычлык булмагач, шатлык та, бәхет тә юк... Алдагы көннәргә ышаныч юк... Уфа белән Бөре юлын таптаганда ишеткән хәбәрләре бу утны дөрләтеп җибәрде.

**10**

Казанлы бер көйгә генә яши бирә килде вакыйгаларга бай булган бу озын елларда. Атналарны, айларны артта калдырып, көн үтә, кич була, борчулы, шомлы таңнар ата. Урмандагы, авылдагы агачлар яшелләнеп тә өлгермәгән кебек иде, инде тагын сары, кызыл төскә манылдылар. Ашлыктан бушап калган басулар өстендә җир белән күк арасын бер итеп йөргән җилләр генә сызгыра, улый, җырлый, әллә нинди хәбәрләр бирә, нидер турында кисәтә.

Вазгыять сугыш, инкыйлаб, җир турындагы сүзләрдән куера бара. Тыштан караганда, берни үзгәрмәгән кебек. Шул ук һава, шомлы һава, эшче куллар җитми. Тормышның иң авыры, иң начары, иң җирәнгече кешеләрнең иңбашына төшә, аларны баса. Казанлы тарихында моннан да кыен елларны беркем дә хәтерләми иде.

Казанлыларның ата-бабалары бирегә бик борынгы заманнарда килеп урнашкан. Җәнлек белән тулы кара урманнар, киеккә, балыкка бай елгалар, уңдырышлы туфрак, яңгырларның мул, кояшның җылы булуы туктаткандыр монда килгәннәрне. Шушы хозурлыкка карап, бу кешеләрнең иң акыллысы: «Менә шундый оҗмах матурлыгына тиң булган урында минем варисларым яшәргә тиеш», дип уйлагандыр. Тик матурлыктан алда яшәрлек урын кирәк бит әле. Урманнан арчып-яндырып, басулар хәстәрләгәннәр, матур, төзек авыллар корганнар. Читтән килгәннәрне кабул иткәннәр, үз иткәннәр, алар белән бер сынык икмәкне бүлешкәннәр, тора-бара туганлашып киткәннәр. Вакыт елгасы кайчакта тыныч кына аккан, кайчакта туган илне, туган җирне яклап, сугышларга китеп барганнар казанлылар.

Һәркемгә шәхсән үлчәүләрдә бирелгән вакыт кысаларына сыеп-сыешып туганнар, яшәгәннәр, мәңгелеккә китеп барганнар.

Җир күп бу якларда, һәркемгә теләгәненчә җитә. Тора-бара кешеләр арасында шул күп булган җир белән сату итү аркасында аермалык килеп чыкты, кемдер үзе дә сизмәстән, кояш астындагы җылы урынны яулады, кемдер, ач-ялангач калып, алтын эзләп, Урал шахталарына юл алды. Тик берсенең дә ат башы хәтле алтын табармын дигән хыяллары тормышка ашмады, җир үзенең байлыкларын сайлап кына бирә шул!

Ничек кенә булмасын, матур, бай, тыныч, яшиләр иде бу якта. Тыныч тормышны бозган һәрбер вакыйга тарихка кереп калды, җыр булып, бәет булып, дастан булып, әкият булып яшьләрне дә, олыларны да тәрбияләде. Ул гына да түгел, монда яшәгән халыкларның уртак тарихына, мәдәният өлгеләренә әйләнеп, аларны тагын ныграк якынайтты, берләштерде, туганлаштырды.

Татлы хисләр, зәңгәр хыяллар белән тулы бу якларның тарихына көмеш яктылык сибә торган риваять тә бар.

Алты йөз еллар элек булган бу хәл. Аксак Тимер Кондырча елгасы буенда Туктамыш ханны җиңгәч, гаскәр башлыкларына, шул исәптән, аларның берсе булган Казанлы бигә очы-кырые булмаган җир бирә. Яшь гаскәр башлыгы бу җирләрне ни эшләтергә белми, тик шулай да барып җитә алган иң җайлы урында ныгытма төзи, аңа үз исемен бирә. Ул вакытта уйламаган дадыр ул шушында килеп, үзенең соңгы көннәрен үткәрермен дип... Аксак Тимер вафат булгач, һәрвакыттагыча дөнья бүлешү, Тимернең тугры кешеләрен юкка чыгару башлана. Казанлы, күп булмаган ышанычлы сугышчылары белән меңәр чакрымнар үтеп, монда чигенергә мәҗбүр була.

Риваятьтәгечә, урындагы халык аларны дустанә каршыламый. Алар белән гел сугышып яшәргә туры килә бигә – авыл уртасындагы борынгы зират бу турыда истәлекләр саклый. Урындагы Шаһгали ханның хакимлек белән бүлешәсе килми. Шул чакта Шаһгали хан кызы Җәмилә белән Казанлы би арасында мәхәббәт утлары кабына. Тик бөтен дөнья, бөтен галәм каршы чыга ул мәхәббәткә! Ә сөюне җиңәрлек көч бармы соң дөньяда! Бернигә дә карамыйча, үзенең зур гаскәр башлыгы булуын онытып ярата Казанлы би кызны. Җәмилә язгы ташкын вакытында, көймәгә утырып, сөйгәне янына юл ала.

Төн караңгы, айсыз була. Елга ургылып ага. Җәмилә көймәне борып өлгерә алмый, кыяга килеп бәрелә дә һәлак була. Казанлы би моны белгәч яшәргә теләми – ул да кыядан упкынга ташлана. Бу кыя әле дә бар иң тирән урыннары да төбенә хәтле күренгән, елга агышында яшел су үләннәре тибрәлгән Көтмәс елгасында.

Шунда алар ике аккошка әйләнәләр. Ел саен кыя янында пар акккошлар оя кора. Монда яшәүчеләрнең аларны куркыту гына түгел, якын барганы да юк. Йөз елга якын элек бер тапкыр андый хәл була – бер явыз җан табылып, аккошка ата. Халык өчен, бөтен дөнья өчен бу хәл бик начар тәмамлана – сугыш башлана... Бу хәлләрдә Казанлыда яшәгән поляк абзыен – Хорошкевичны гаепли халык.

Яшьләр дөнья куйгач, кыяның бер өлеше ватыла. Еллар буена кыяның

ике өлеше җил һәм су тәэсирендә бер-берсен яраткан һәм үбешеп торган ике гашыйкны хәтерләткән сынга әверелә. Әле дә алар шундый матур булып басып торалар, ә аларның аяк очында – ике аккош. Аккошларның муеннары бер-берсенә уралган, канатлары гашыйклар кулы кебек бер-берсен кочаклаган. «Гашыйклар кыясы» дип атаганнар ул кыяны казанлылар.

Ул чаклардан күп еллар узган, күп сулар аккан. Ул кыяга ялгз бармыйлар бу якта. Кешеләр инде нигә бармаска дигән сәбәбен онытып бетергәннәр, ә сүз калган. Гашыйклар кыясына бары чын гашыйклар гына, аерым очракта гына, киңәш сорап, икәүләп кенә баралар. Анда күргәнне беркемгә дә сөйләмиләр. Ярамый, диләр. Ә инде барган кешеләр, бик бәхетле булып, озак еллар бергәләшеп, пар аккош кебек гомер итәләр.

Менә шундый матур риваятьләр яши бу якларда. Булгандыр, монысы да булгандыр, ышанмый мөмкин түгел. Икенче елга – Мута ярында зур ташларны тигезләп, турыпочмак хәленә китереп эшкәртеп эшләнгән дивар бар. Һәрбер ташта гарәп графикасында чокып язган сүзләр... Бәлки, ул ташлар артында Казанлы бинең һәм аның сөйгәне Җәмиләнең соңгы очрашу урыныдыр?

Кем белә...

**11**

Данила Матусов, таң әтәчләреннән дә алдарак торып, биләмәләре буйлап китте. Бар да тәртиптә, ярдырырга әзерләнгән бүрәнәләр иртән пычкы астына кертеп җибәрергә җайланып куелган, бөтен җирдә чисталык-тәртип, эш урыннары себереп чыгарылган. Иң канәгатьләндергәне – Петька да йокыдан иртә торган, бөтен йорт-кураны карап йөри. Аны эшкә өйрәткәндә, Данила, берничә кагыйдәне ятлап алып, аларны беркайчан да бозмаска кушты. Беренче кагыйдә – иртән иртүк торып, бөтен нәрсәне күздән кичереп, эшчеләрнең һәрберсенә нәрсә эшләргә кирәген алдан ук белеп, хәстәрләп кую. Әйе, нәкъ иртә торып. «Мин сине көндез йоклап ала дисәләр, бер сүз эндәшмәм. Әгәр инде иртән тора алмаган, таңны йоклап каршы алган дисәләр, миннән юньле сүз көтмә!» – дип өйрәтте аны.

Әнә ул озын арбага салып берничә бүрәнә алып килгән мескен генә киенгән ирне рус, татар сүзләрен кушып тирги иде:

– Син бит хорошо знаешь, без нинди агач принимать иткәнне? Или бельмес? Может, синең өчен тагын бер повторить? Строевой агач должен быть зрелым, ә-ә-ә, җитешкән, җитлеккән: озынлыгы 13 аршиннан да мало түгел, толщ… ә-ә, юанлыгы өч карыштан да не менее. Ә син что привез?

– Кара әле, Петька. Син мине беләсең бит, мин алдаша торган кеше түгел. Башка бүрәнәләр арасына тыгып җибәр дә инде, кем күрә, кем белә? Мин боларны кирегә алып китиммени?

– Это синең эш! Больше не будешь хитрить!

Авыл кешесе белә: Петька әйтте икән – бетте. Аның карарын берничек тә үзгәртереп булмый. Шуңа да хәйләкәр абзый җәлләтергә тырышып карады.

– Балаларны ашатырга кирәк. Нужа, понимаешь? Ал, пжалысты, ә?

– Юк, и ещё раз юк! Не дело.

Абзый, башын иеп, тезгенне кыска гына итеп тотып, атын килгән юлына бора башлады. Бу хәлләрне күреп торган Данила якынрак килде.

– Хуҗалык эшләренә бәлки ярар, ал булмаса, Петя. Ә син болай итеп тагын бер алдашырга уйласаң, Кара дәфтәргә эләгүеңне көт тә тор! Понялмы?

Соңгы сүзен ике телне кушып әйтүе бөтенләй бу яклардагыча килеп чыкты.

– Юк-юк, что син, Данила әфәнде! Понял! Рәхмәт зур итеп! Спасиб!

Аның коты очуы бер дә юкка түгел. Бөтен кеше дә уттан курыккан кебек курыккан Кара дәфтәрдә алдашучылар, бурычлы кешеләр, сүзендә тормаучылар бар, ә алар инде Даниладан бернинди дә миһербанлылык көтә алмыйлар.

– Петя, эшләрең беткәч, мостикка мен әле! – диде дә Данила ашыкмый гына өйгә кереп китте.

Мостик дигәне – әллә «капитанский мостик», әллә «мостки» сүзеннәнме, моны беркем дә ачык хәтерләми, тик ике сүзнең дә су эшләре, су техникасы белән бәйләнгәне күренеп тора. Данила яшәгән зур өй кыегының бер башына манара кебек итеп салдырган корылма ул – мостик. Бөтен яктан да пыяла, бөтен тирә-як уч төбендәге кебек күренеп тора. Кем кайда ни эшли, кайда эш бармый, кем ялкаулана – барысы да күз алдында. Шушында утырырга ярата Данила. Менә бүген дә ул, ничәнче мәртәбә табигать хозурлыгына сокланып, тел шартлатып куйды.

Аккош күле томан эчендә, анда кошлар уяна башлаган. Су өстендә озын муеннарын уйната-уйната, салмак кына пар аккош йөзеп бара. Таныпның теге ягындагы карамалар елдагыча соңлап кына яфрак ярдылар, алар арасында үскән муеллар чәчкәләрен әллә кайчан койса да, шомырт исе һавада эленеп тора. Ничә тәгәрмәчне әйләндергән Көтмәс буасының ярларын да томан каплаган, улактан аккан артык су буаның нинди куәткә ия булуын оныттырмый – җырлап түгел, вакыты-вакыты белән үкереп ага. Биек буадан шарлап акккан суга карап тору төрле уйлар уята. Бер яктан, табигать алдында кешенең көчсезлеге, икенче яктан, бу корылманы үз куллары белән кора алган кешенең акыл көче турында. Теләсә, агызып җибәрә ала, теләмәсә – юк. Әнә бит, язгы ташу вакытында суның ташкын көчен дә учында кысып тота кеше. Икенче яктан, бу көчнең хуҗасы булу, шул көчләр белән идарә итү өчен синең бер сүзең җитүе күңелне кытыклый, тормыш баскычларының ару гына биеклегендә утыруыңны күрсәтә.

Елгаларга башын салган куаклар агымга буйсынып агып киткәндәй итәләр дә кабаттан үз урынына кайталар. Таныпта уйный агымы белән: йә тын гына ага, йә бөтерелеп ала, йә әллә кайдан килеп чыккан дулкынын ярга бәрә, төбендә яткан әллә ниләрне өскә күтәрә, йөзеп барганнарын төпкә алып төшеп китә.

Куаклар дигәч, Данила яр буен агачлардан арындыру вакыты җитеп килгәнен исенә төшерде. Монысы инде – ярдәмчесенең эше. Елганы карап тору да кирәкле эш, баркалар үз юлын бернинди тоткарлыксыз үтәргә тиеш. Бу эшкә Данила бер вакытта да җиңел карамады, артыкка санамады, махсус кешеләр тәгаенләп, елга үзәнен һәр көз саен чистартып торды. Пётр

Васильевич та эшне җиренә җиткереп башкара, кушканны көтеп тормый, үзе белеп эшли.

Тынгысызлар яр буенда балык тотарга маташа. Әйе, бу елгалардагы балыкның тәмлелеген бернинди пайтәхет рестораннарында да тапмады Данила. Танып яздан үзе хәстәрли балыкны. Җәелгән су чакрымнарга тарала, Казанлыга килеп җитәрәк бик озак тора да, ярларына кайта башлый. Менә шул вакытта инде вак балыгы да, балык булырга әзерләнгән уылдыгы да җылы күлләргә кереп кала, көзгә ару гына зур балык булып, елга буенда көн күрүче кешеләрнең өстәлләрен баета.

Боларын уйлап бетерүгә баскычтан югарыга атлаган Петьканың аяк тавышы ишетелде. Ул килеп керү белән биләмәдәге хәлләр буенча хисап бирә башлады, тик Даниланың кызыксынмавын күреп туктап калды, куркыбрак сорау бирде:

– Даниел Геворкович, берәр хәл килеп чыктымы әллә? Әллә мин берәр хата ясадыммы?

Бөтен биләмәдә бары тик ике Петяга Даниел Геворкович дип эндәшергә рөхсәт, калганнар өчен ул Данила Георгиевич. Бераз тынып торгач, Данила кулын селтәде.

– Юк, эш синдә түгел, Петя! Күңелем ниндидер шом сизә... Ай, күңелем минем бер дә ялгышмый шул! – Шул вакытта Даниланың колагында кинәт теге ату тавышы яңгырады. – Петя, бер-ике соравым бар...

Тик туктап калды.

Петька, зур гәүдәсенең авырлыгын бер аяктан икенчесенә күчереп, тик кенә басып тора бирде.

– Уфада да, Бөредә дә бер үк хәбәрне сөйлиләр. Патшаның төшерелүе бу хәлләрнең башы гына, диләр. Яңадан инкыйлаб әзерлиләр икән. Монысы инде беренчесеннән усалрак булырга охшаган, ди. Җирне бүлеп, милекне тартып алу көтелә, ди.

Петька, бу сүзләрдән коты очып, Матусовка карады.

– Булмас, Даниел Геворкович! Булса да, кешеләр сезне ярата, «Ah!» итеп торалар. Нинди милек бүлү, ди, монда?

– Эх Петька, Петька! Ничә ел өйрәтәм сине, ышанма бер кешегә дә дип! Әнә, Казанлы картлары ничек ди: «Билеңнән түбән үзеңә дә ышанма!». Ходай сакласын! Кеше исәбенә баерга теләсәләр, ата улны, инә кызны белми ул! Андый кешеләр азмы бездә? Ун еллар элек ни булганын оныттыңмы?

Юк, онытмады аны Петька. Ул елда авылларның берсендә агач төялгән олауларны аударып, эшчеләрне кыйнап ташлаганнар иде. Становойга да, урядникка да әләкте, бөтен Россиягә китте, таралды даны. Чак чыктылар бу хәлләрдән.

– Дөрес аңласам, ышанычлы кешеләр булуы кирәктер, ул-бу була калса.

– Дөрес аңлыйсың, дөрес. Тик ул гына түгел. Корал да кирәк. Шуннан. Кешегә сиздермичә генә мөлкәтнең исәбен алып чык әле. Шуның нәтиҗәләреннән чыгып, эш кылырбыз алга таба.

Петька тәмам аптырады. Аптырамаслык түгел иде шул. Аның шушы матур итеп барган шәхси дөньясыннан бер дә колак кагасы килми.

– Э-э, аңладым, Даниел Геворкович, аңладым.

– Кара әле, Петя. Элекке старшина Гаязетдин унбишенче елда сугыштан кайткач, меңнәрчә десятина җирен саттымы әле?

– Тап шулай, Даниел Геворкович. Ундүртенчедә старшина эшен ташлап сугышка китте, унбишенченең азагында яраланып, сугыштан кайтты. Уналтынчының башында җирләрен сата башлады.

– Сизәсеңме, нинди бәйләнешләр барын монда?

Петькага Ходай табигый акыл биргән, ул шунда ук җаваплады.

– Сизмичә. Сугыштан нindидер хәбәр белән кайткан ул!

– Так-то, Петя. Без аптыраган, көлгән булдык ул чакта. Йомгаклау кирәк бу хәлләрне. Һәм очрашырга кирәк аның белән. Очрашырга, сөйләшергә. Атны әзерләргә куш!

Һәркем үз уенда иде. Данила тагын сөйли башлады:

– Тик син телеңне бикләп куй! Мин сине кеше иттем, эшләргә өйрәттем, дөнья белән таныштырдым, буш итмәдем, кеше арасына керттем.

– Даниел Геворкович, минем нинди рәхмәтле икәнне беләсез бит!

– Беләм, Петя. Шуңа да сиңа ышанам. Алдамассың дип ышанам, Пётр Анисимович.

Пётр Анисимович Даниланың аягына егылырга, антлар итәргә әзер иде. Тик карт, бераз тынып торгач, сүзен дәвам итте.

– Тагын... Әйт әле, Петя... – Калган сүзләр бик зур авырлык белән бирелде Данилага. – Анна Мишка белән очрашамы?

Петя инде күптән Даниладан бу сорауны көткән иде.

– Очраша, Даниел Геворкович, очраша. Мин Мишканы кисәтеп тә карадым, тик аларның хисләре көчлерәк булып чыкты, ахыры...

– Соң, нигә син миңа әйтмисең бу турыда? Мондагы хәлләр турында мин беренче булып, синнән ишетергә тиеш дип сөйләшкән идек бит!

Авыр тынлык урнашты.

– Даниел Геворкович, мин... мин сезгә җиткермичә генә бу мәшәкатьне чишеп чыгармын дип уйлаган идем. Сезне борчымыйча гына.

– Борчымыйча гына. Ул бит минем бала, мине борчымыйча, кемне борчырга тиеш син? Ярар, Петя. Мин сиңа аталарча булган мөнәсәбәтемне беләсең. Тик син мине бүген бу очракта алдадың, син мине саттың дип әйтергә мәҗбүрмен.

Әгәр Данила эттән алып эткә салып тиргәсә, сүксә, камчы белән сыдырып алса да, җиңелерәк булыр иде Петькага.

– Аңладым! Гафу итегез, Даниел Геворкович! – дип кабатлады Петя, бер аяктан икенчесенә күчүен дәвам итеп.

– Ни эшлибез? Бармы киңәшең?

– Бар, Даниел Геворкович, бар, – дип кабаланып җавап кайтарды Петя, аякларында биюен туктатып.

– Йә?

– Мишканы соңгы барка белән Әстерханга җибәрик.

– Мунчала беләнме? Ә нигә, шәп идея! Тик... тик син аңа әйтми тор бу турыда. Китәр алдыннан гына әйтерсең! Йә Анна белән бергә чыгып качарлар...

– Аңладым, Даниел Геворкович, аңладым. Барысы да сез әйткәнчә булыр!

– Бар, алайса. Тик беркем дә белергә тиеш түгел моны!

Петя тиз генә чыгып китте. Данила, йомшак урынында атына биреп, башын иеп утыра бирде.

Өске катта пианино клавишаларында берничә тапкыр бармаклар йөгереп үтте, Шопенның тылсымлы музыкасы агыла башлады.

Данила авырлык белән торып чыгарга атлады, тик өлгермәде. Күзен алган кигәвендәй йөгереп, Петька килеп керде.

– Даниел Геворкович, волостной старшина үзе!

– Ярар, мин аска төшәм, чакыр кунакны! Һәм өстәл әзерләргә куш тиз генә!

Тышта түшәлгән такта өстендә тукылдап, старшинаның кулындагы таяк тавышы ишетелә иде.

**12**

Гасыр башындагы Казанлы волостен оештыру турындагы карар бу якларның, Казанлы авылының бик мөһим сәяси, икътисади үзәккә әйләнүен күз уңында тота иде. Чынлап та, төбәкнең соңгы еллардагы үсеше, мәдәни һәм иҗтимагый торышы, халык санының бермә-бер артуы, яңа сәнәгать оешмаларының барлыкка килүе – болар барысы да бу карарның вакытлы һәм дөрес булуын исбатлый, бу якларның тарихында яңа мөмкинлекләр ача.

Дәүләт хакимият органнарына булган ихтирамны арттыруда волостьның зур бинасы да мөһим роль уйный: таш фундаментлы, карагай буралы, зур тәрәзәле һәм ишекле, калай белән ябылган түбәле булуы авылның төсен баетып җибәрә, бинаның матурлыгы дәүләтнең дә бөеклеген күрсәтә.

Ун елдан артык яшәү дәверендә сайлап кую тәртибе булганлыктанмы, сугышлар булып торганлыктанмы, өч старшина алышынып өлгерә волостьта. Әлегесе – сугыштан сул аягына аксап кайткан, тик моңа карамыйча тере, хәрәкәтчән, һәрчак кызыл йөзле, яшертен акыллы булуы белән билгеле Ибраһим Хаҗиев, писарь булып, Семен Зуев эшли. Волостьта Вакытлы Хөкүмәт тарафыннан юкка чыгарылган вазифа да булган: соңгы урядник булып Николай Дедухин утырган, аңа кадәр эшләгәнен каравыл астыннан качкан ат карагы төнлә суеп китә. Волость хуҗалары белән иң тыгыз бәйләнеш-мөнәсәбәтләрдәге Казанлы авылы старостасы булып Хәмит Җиһаншин куелган.

Нигә килде икән, ни кирәк икән Даниладан старшинага? Бик сирәк очраша торган иде алар. Данилага алар кирәкми, Ибраһим Хаҗиевның Данилада эше юк. Тиешле акчалар дәүләт казнасына кереп бара, җирле халык белән ызгыш юк – тагын нәрсә кирәк власть кешеләренә? Очрашуга старшинаның үзе килүе хәлләрнең үтә мөһим һәм кичектергесез булуына басым ясый, димәк.

– О-о, старшина галиҗәнаплары! Хуш килдегез! Утырыгыз менә бирегә, чәй эчәрбез!

– Рәхмәт, рәхмәт, Данила әфәнде! Утырабыз, сөйләшәсе бар!

– Сезнең нинди йомышлар төште безнең кебек урман кайрысы коңгызларына?

– Сезләр урман кайрысы коңгызлары түгел, урман хуҗалары бит! Дөнья

тотып килгән бер сәнәгатьче, кешеләргә эш биргән, аш биргән миһербанлы кешебез!

Данила, күпне күргән, күпне ишеткән, сүзнең икенче мәгънәсен белгән кеше буларак, боларына игътибар да итеп тормады, тик җавап итеп бер-ике сүз өстәде:

– Бар инде аз-маз шунда...

Йөгертеп чәй чыгардылар, аның янына тәм-томы килеп өстәл өстен тутырды.

– Йә, рәхим итегез булганыннан, старшина әфәнде! Кирәксә, мәен дә тәкъдим итә алам?

– Юк, юк, Данила Георгиевич! Вакыты ул түгел.

Яратмыйлар икесе дә төп сүзгә күчкәнче була торган юк-барны. Тик кая барасың, монысы гадәт, монысы йола, ансыз төп сүзне башлау – ул сүзнең бәһасен-бәясен төшерү, кадерен югалту.

– Быелгы уңышлар ничек, Данила Георгиевич? Су бик ару булды, кыш салкын килде. Урманны ташып өлгергәнсездер?

– Өлгердек, Аллага шөкер. Өлгердек! Уңышлар ни, елдагыча...

Аңламассың бу старшинаны: гел мактарга тырыша Даниланы.

– Өяздә безнең якларның икътисади хәлләрен карап, хисапнамә әзерләгәннәр. Шунда пристань урыны мең дә биш йөз алтмыш сумга унике елга арендадан дип язылган. Монысы инде сезнең шәхси мөмкинлегегез, бирсен Ходай! Халыкны да онытмыйсыз: агач ташуда мең ярым сумга тиклем эш хакын алып була икән! Так что, без сезләргә бик рәхмәтле!

– Тырышабыз инде, старшина әфәнде, тырышабыз үзебез өчен дә, халык өчен дә. Үзебез дә көнен-төнен эштә, эшчеләр дә эшли, шулай итсәң генә, тормыш алга бара. Гаиләдә тынычлык, тагын ни кирәк?

– Аннаның пианинода уйнаганын бөтен тирә-як сокланып тыңлый, күз тимәсен!

Тидерде йөрәк ярасына, кыек атып, туп-туры тидерде бит, карт шайтан! Аңа нигә кирәге бар инде? Шулай уйласа да, Данила татар, рус сүзләрен бутый-бутый, башканы әйтте:

– Да, махсус укыттым бит мин аны уйнарга. А то монда ведь, теге, күңелсез. Пущай уйнасын дидем.

– Матур уйный. Безгә бит, тальян гармун, скрипка, мандолинадан башканы белмәгән кешеләргә сезләр ерак чит илләр мәдәниятен күрсәттегез.

Кайчан сүзен башлар бу төлке? Даниланың кызын мактарга килмәгәндер бит?

– Ярар, исәнлек һәм иминлек өйләрегезгә, эшләрегез уң булсын, иншаллаһ! Тик мине, Данила Георгиевич, икенче мәсьәлә алып килде бит монда. Яңа гына өяздән кайттым, төрле хәбәрләр йөри анда. «Керенскийның власте озакка түгел» дигән сүзләр куркыта.

– Революция артыннан революция буламы әллә?

– Шуңа табан котырталар. Шуңа табан. Большевиклар бик нык эшлиләр икән. Тагын җир бүлү турында фикерләр күп, азатлык вә хөррият дип авыртмаган башны катырып, тимер тарак әзерлиләр. Монысы бер. Икенчесе безгә кагыла, турыдан-туры сезгә, Данила Георгиевич. Ничә кеше эшли әле сезнең белән?

– Йөз тирәсе даими эштә, ялланып эшләүчеләрнең, көнлекчеләрнең саны ике йөздән артык.

– Менә, менә шулар борчый да инде өязне. Большевикларча әйтсәк, болар бит инде эшчеләр сыйныфы. Алар куркыта, аларны һәрчак карап торырга кирәк. Кайбер очракта, юл куеп, кайберләрендә яман эшләрдән туктатып, кирәк булса – куркытып. Хәер, сиңа сөйлисе юк, үзең дә беләсең!

Ибраһим старшина майлы «сез» дигән сүзләрен ташлап, тавышына тимер өстәп «сингә» күчте.

– Шул иде минем йомыш.

– Вакыты да билгелеме?

– Юк. Вакыты билгеле түгел. Көз белән куркыталар.

– Так инде почти көз бит!

– Именно, именно шулай, Данила Георгиевич!

– Ярар, Алла сакласын дибез дә алны-артны карап эш итәрбез!

– Шулай, әлегә хушыгыз! Эшчеләрегезне тимер кулларда тотарсыз дип ышанам. Өязгә дә шулай әйтермен.

– Ә чәй? Шул тиклем ашыгычмыни соң?

– Ашыгыч!

Старшина Ибраһим Хаҗиев таягы белән идәнгә кагып чыгып китте. Данила, эчтән генә көлеп уйлап куйды: ничек йөгерә, артына нашатырь кыстырганнар бит моның! Бөредә ул үзе ишеткәннәр белән старшинаның сүзләрен чагыштырып карады, шунда ул ничә көннәр буена тынычлык бирмәгән шомлы уйларының очына чыккандай булды, берничә сорауга җавап таба алды. Беренчедән, «мал кыйммәтме, әллә җанмы?» дигән сорауга әтисе мисалында ул күптән бер карарга килде инде. Икенчедән, нәрсә тота аны бу кыргый урман илендә? Өченчедән, бу яктагы халыкның сугышыр өчен сәбәпләре күп тәдер. Ә Даниланың? Аңа нәрсә калган? Дүртенчедән, монда булган, күренеп торган малы җыелган һәм күренмәгән алтын-көмешләр янында чүп! Шулай булгач, югалып калмас!

Әгәр инде, чынлап та, көймәгә су керә башласа, бөтенесен дә ташлап китәргә була, бернинди дә кайгыру юк! Җәлләрлек мөлкәт бар да ул... Тик, чынлап та, мал түгел, баш кыйммәт!

Чәен читкәрәк куеп, ат җигәргә кушты – элекке старшинаның сүзе монысыныкыннан күпкә кыйммәтрәк иде. Шуңа ул уйланылганча Казанлыга Гаязетдинга юл алды.

* * *

Гаязетдинны берни белән дә аптырата алмассың хәзер. Дөньяда үзгәрешләр бармы-юкмы, старшина ни уйлый, Матусовны ни борчый – болары бөтенләй башка, бөтенләй икенче иде аның өчен. Шуңа да Матусовның капка алдына чаптырып килеп туктавын, этләрне өрдереп, капка аша ихатага үтүен ул тыныч кына карап торды. Кул бирешеп исәнләштеләр, хәл-әхвәлне сораштылар. Берничә мәртәбә ул иң усал, иң нык өргән этне тынычландырды:

– Йә, йә, Сокол, булды! Тынычлан! Бу бит безнең кеше, булды сиңа!

Гаязетдинны буаның су тәгәрмәчләре кызыксындырды. Әллә кайчан,

старшина булып сайланганчы ул тәгәрмәчләрне бер төркем булып, Матусовка әзерләгәннәр иде. Менә бит, Алланың рәхмәте, алар ун елга якын әйләнәләр, башка җиһазларны әйләндерәләр. Бу ун ел эчендә тупланган тәҗрибәгә таянып, Гаязетдин тәгәрмәчләрнең сызымына үзе генә белгән үзгәрешләр кертте, бу инде аларның әйләнеш тизлеген күпкә арттырып җибәрде.

– Так что, Данила дус, алыштырып та ташларбыз ул искерә башлаган тәгәрмәчләрне, бирсен Ходай! Гәрчә, ул череми суда – үзенең сагызында кояшта кайнаган чын карагайдан аның такталары.

– Мин риза. Һичсүзсез алыштырырбыз!

– Тик, күрәм, бу турыда сөйләшер өчен килмәгәнсең бит син?

Урта өйгә кереп утырдылар – монысы инде бу якларның кунакларны чакыра торган аерым бүлмәсе, бер ишеге аша тыштан кереп булса, икенчесе зур өй белән, аның ашау-эчү әзерли торган өлеше белән бәйләнгән. Утыргач та, Матусов чишелеп китте:

– Гаязетдин, урап тормыйм, нигә килгәнемне турыдан әйтәм. Дөнья бозыла бит! Күз алдында барсы да җимерелә, юкка чыга. Уфада, Бөредә ишетеп кайттым – әллә ниләр әзерләнеп ята бит безнең башка! Тагын инкыйлаб, тагын сугыш, тик бу юлы әтисе улына каршы, туган туганга каршы. Шуннан шәхси милек булмаячак, диләр бит. Нигә дип җыйдым инде мин малны, әгәр ул минеке булмаса? Нәрсә, иртәгә ярлы-ябага килеп, минем бөтен мөлкәтне тартып аламы? Ул ярлылар арасында бит күбесе ата ялкау! Әдним словом, ярдәм, киңәш кирәк миңа! Шул шифалы сүзеңне җәлләмә, зинһар өчен!

Гаязетдин ул сөйләгән арада акыллы күзләре белән Матусовка карап утырды. Озак еллар белә ул аны, ничек монда килеп чыкканын, ничек тырышып-тырмашып, кеше булганын, ничек буш урында бербөтен сәнәгать оештырып җибәргәнен. Дус дип әйтмәсәң дә, бик яхшы танышлар инде алар, бер вакытта да бер-берсенә каршы сүз әйткәннәре дә, каршы чыкканнары да булмады. Гаязетдинның җиңел кулыннан әйтергә бик үк уңайлы булмаган Даниел Данила булып китте.

– Нәрсә әйтим инде сиңа, Данила. Син үзең дә хәлләрне бик яхшы беләсең. Бездә бүген яшенле яңгыр алдыннан булган күренеш: болытлар берсен-берсе таптый, изә, җиле давылга әйләнеп бара, яшен чаткылары ялтырый, күк күкрәгәне җанны куркыта. Һәм шул бар җан кайда урын таба, шунда кача, яшеренә, тын кала. Кояшның кайдалыгын күреп булмый. Менә нинди хәлләр бездә, Данила. – Гаязетдин авыр сулап куйды. – Тик бу башы гына әле.

– Әгәр бу әйткәне башы булса, азагын күз алдына китерүе дә читен. Син шуны әйт: болай булса, мөлкәтне акчага әйләндереп, койрыкны сыртка салырга соң түгелме әле?

– Турыдан-туры әйтәм, инде соң булып бара. Ишеткәнсеңдер, мин шуңа да җирне сатып ташладым бит.

– Ишеттем, как же. Монда сүз бик тиз йөри.

– Ә мин артык яшеренеп тә эшләмәдем. Кемдә кемнең эше бар?

– Анысы шулай инде.

– Данила, син беләсең, малга ябышып яткан булып, яшәүдән ваз кичәргә

дә була. – Гаязетдин тагын бик озак карап торды Матусовка. – Мин монда тагын бер нәрсә күрәм һәм анысыннан инде берүк Алла сакласын! Әгәр бу хәлләр шулай барып чыкса, шәхси милек, чынлап та, юкка чыгачак! Хәер, моны син үзең дә әйттең бит.

– Дөньяны тотып килгән шәхси милек?

– Әйе. Менә нәрсә сугыш-кырылышның нигезендә ятачак. Кырылышның нигезе хөррияттә түгел, милек бүлешүдә. Тик тиз генә аңлый алмабыз әле моны без! Кызганыч!

– Болай булгач, дөнья, чынлап та, бетәчәк.

Данила башын иеп, сүзсез утырды, шуннан калган соравын бирде:

– Шулай булырына нәрсә күрсәтә соң? Нинди билгеләр бар инде безне куркыткан?

– Бар. Бар. Большевиклар фиркасе – бу бер. Әллә ниләр сөйләп, алар тарафыннан илне тарату сәясәте – бу ике. Властьның йомшаруы, бернинди кыю, тәвәккәл карар кабул итә алмавы – бу өч. Властьтагы урлашу, алдашу гамәлияте – бу дүрт. Россияне көне-төне хурлау, Ватанны яратуны иң түбән дәрәҗәгә төшерү – бу биш. Иң соңында – үземдә булган эчке сиземлек. Менә болар. Күпме бәхәсләшергә буладыр, тик зыялыларның өчтән икесе менә шулай булачагын күз уңында тота.

– Артка барырга юл калдырмадың, Гаязетдин! Һәрвакыттагыча, башкалар кебек юкны сөйләп тынычландырмадың, уйлаганыңны әйттең. Барысына да рәхмәт! – Матусов сүзсез калды. – Бәлки, безнең юллар аерыладыр, тик ничек кенә булмасын, миннән сиңа олы ихтирам! Ә алга таба юлны сайлау бездән, һәрберебездән! Рәхмәт сиңа!

Гаязетдин аны атына тиклем озатып куйды.

**13**

Ибраһим Хаҗиев Казанлыга килеп җитү белән волостька кереп тормады, атын туры өенә борды. Тынгылык бирми иде Матусовның эшләре. Шунда барган саен көнләшүдән чатнап янардай булып кайта. Читтән килеп, дөньяны басып алып ни эшләп ята, килмешәк, ә! Бөрегә, өязгә еш йөргәч, белә шул староста аның нинди акчалар белән эш иткәнен. Ничек итеп туктатырга, туктатырга гына түгел, ничек аның эшен тартып алырга?

Бер карарга килде Ибраһим. Беренче – ышанычлы кешеләр табарга. Икенче – буага зыян китерергә. Аннан күрербез! Килеп керү белән улын дәшеп алды:

– Сәйфи, бар, бик кеше куркытып кабаланмыйча гына, Тамырбулат абзаңны һәм Ярмине алып төш монда. Тик аерым-аерым, кешегә бик күренмәгез.

Үзе чәй эчәргә утырды, эссе көндә тастымал белән битен сөртеп, чынаякларны бер-бер артлы каплаганда, ул үзен елга хуҗасы да итеп, пристаньнар башлыгы да итеп тоя башлаган иде инде.

Чакырылганнар бер-бер артлы килде. Тамырбулатның бите шадра, Ярми дә бик үзенә тартып тормый, ак төшкән бер күзе генә ни тора!

Ибраһим, аларның тыңларга әзер торган буйсынулы йөзләренә берничә кабат ныклап карап чыккач, сүзен башлады.

– Ерактан башлыйм. Һәрберегезнең язмышына мин ару гына өлеш керттем. Тамырбулат, мин булмасам, син әле дә Новониколаевскида каторжан булып йөрер идең, онытмадыңмы? Ярми, унынчы елда юлбасар булып йөргәнеңне онытмагансыңдыр? Кәлтә урманнарының карама төпләрендә син күмештергән сөякләр череп бетмәгәннәрдер әле?

Тегеләр башларын иде. Булган хәлләр, булган ярдәм. Ни әйтәсең?

– Мин бер эш уйладым, ярдәм кирәк. Сезнең кебек кыю да, усал да егетләр кирәк.

Тыңлаучылар, бер кашын күтәреп, игътибар белән аңа карадылар.

– Ничә ел караштырып йөрим Матусовның эшләрен. Читтән килгән килмешәк дөньяның тезгеннәрен кулына урап тоткан! Безнекеләргә бернинди дә мөмкинлек юк. Урманны сатып алып бетерде, елганы буып куйды, эшчеләрне үзенә тартып алды. Сату аңарда, урлау аңарда. Хәтта әнә безнең хак мөселман Мөхәммәтҗан да аны узып сата алмый урманны. Бу ни бу? Нишлибез? Җир кемнеке? Безнекеме, әллә килмешәкнекеме?

Тегеләр, мондый хәлләрнең кая алып барырын белгән кешеләр, башларын иеп, тик кенә утырдылар. Күзләре янып киткән Сәйфи генә, чәчрәп, әтисенең сүзен бүлдерде:

– Ул бит, каты борын, чуен юлының төзелеп яткан ягындагы урманны да кисеп алырга килешү төзеп өлгергән, ди!

– Менә, менә! Нишлибез? Ул җирләр элек-электән Казанлыныкы, суд белән Петербургка барып җиткәннәр безнең бабайлар. Барыбер тешләрен сындырып кайтарып алганнар. Ә хәзер? Чуен юл дип тарттылар да алдылар!

Тынлык. Ибраһим басканнан басты күрекләрен:

– Менә нәрсә. Туктатабыз аны.

Тамырбулатның тәҗрибәсе Кәлтә урманнары белән генә бәйләнмәгән, ул – Себер күргән кеше. Шуңа да аның кире кагуы көчлерәк:

– Ай-һай! Барып чыгармы икән? Аңарда бит көч, акча!

– Бездә власть! Чыгар! Зурга-зур табыла, вагына-вагын табарбыз.

Ярми сүзгә кушылды:

– Яндырабыз и вәссәлам!

– Иртәрәк. Шуннан, яндыргач, безгә ни файда? Безгә аның эшләп утырган милкен кулга төшерергә кирәк!

Тамырбулат әллә ни уйлап чыгара алмады, шулай да, тик утыруны дөрес дип тапмады, күрәсең, тагын бер-ике сүзен кыстырды:

– Буачыларның иң курыкканы бер инде – чучка башы да терекөмеш! Бер атнада буасы Иделгә барып җитәр!

– Уйдырма! – Монысын Сәйфи кычкырып ук җибәрде. Тик әтисе аны хупламады.

– Уйдырма! Тик куркыта торган уйдырма, бусы хак! Кирәк! Син, Тамырбулат, монысы өстендә эшли башла, алайса. Ярми, сиңа махсус эш: алар анда Әстерханга мунчала әзерләгән баркаларга. Җепләрен бушатырга, өзәргә, кисәргә кирәк. Тиз арада!

Сәйфи тагын сүзгә кушылды:

– Әти, анда бер эшче, Мишка, Матусовның кызы белән чуала, диләр. Әгәр шуның аша эшләсәк?

– Ю-юк, ышанмыйм мин аларга! Сата бит ул! Бары тик үзебез эшлибез!

– Мин аны әйтмим. Чучка башы өстерәп йөрмәбез бит инде. Төртик бераз акча, ул ташлар. И вәссәлам!

Монысына иң шатланганы Тамырбулат булды – аның да, бик дингә ышанып бармаса да, ураза аеннан соң бер дә чучка башын ташыйсы килми иде. Ибраһим сөйләшүгә йомгак ясады:

– Тагын бер искәртәм, ләм-мим! Авызыгыздан сүз чыкса, сез дә Иделгә барып җитәчәксез бер атнада, бәлки, тизрәк тә. Буш итмәм. – Ул Тамырбулат белән Сәйфигә борылды. – Эшләр пешкәч, сезнең урыннар ике Петьканыкы! Сөйләшеп карагыз шул Мишкагыз белән. Ризалашса, безнеке булыр, әйдә. Кирәге чыгар әле. Бер кирәкмәгән балта тирес чабарга ярый, диләр.

Монысы әлегә зур вәгъдә икәненә бар да һичшиксез төшенәләр иде. Кашларын-күзләрен кысып, алган йөкләмәләрен үтәргә таралдылар.

**14**

Казанлы, иртә булуга карамастан, эсселек һәм Шопен музыкасы белән каршы алды Ильясны. Кайдан бу ят музыка, әллә тагын төшкә керәме ул дип, башын боргалаган солдатка карап, Гәрәй көлеп җибәрде:

– Түгел, төш түгел бу. Чынлап та, ят көйләр. Матусов кызларына каладан алып кайткан пианин дигән корал. Кече кызы Анна уйный анда. Белмим, бармаклары сөяксездер аның, шул тиклем тиз дә, җитез дә уйный, шайтан. Баштарак гармуннан ары башканы күрмәгән безнең халык егылып китеп тыңлый иде, өйрәнделәр, хәзер бик исләре китми тагы.

Тыңларлык та шул, төш тә дип әйтерлек. Бер елдан артык элек Польшада юлларыннан туктап калып тыңлаганнар иде бу коралның уйнавын. Польша нәрсә, үзебездә дә бар икән бит андый әйбер хәзер. Бу турыда ул Гәрәйгә әйтте. Тегесе бик җитди итеп сүзен дәвам итте:

– Чүп кенә ул Матусовка пианин. Син аның эшләрен, җитештерү ысулларын күрсәң, аптыраудан нишләрсең! Чит илләрдән әллә нәрсәләр алып кайтып куйды бит ул!

– К-кемгә с-сугыш, ә к-кемгә б-байлык т-табу ю-уллары!

– Шулай, шулай!

Арбаның таудан түбәнгә этүен тотып килгән ат биек тау итәгенә җитәрәк тәгәрмәчләргә ирек бирде. Көтмәс елгасы күперен чабып үтеп, алар авылга очып диярлек килеп керделәр.

Бик еш кайтып булмаса да, Казанлы – күңелләрнең иң нечкә кылларында урын алган туган як, талгын җылы җилләре, Чия тау артыннан чыгып килгән зур кызыл кояшы, иртәнең бер мәлендә генә була торган тынлыгы белән барлык хәсрәтләрне оныттырды, бушаган күңелгә җан өрде.

Ильяс бертуктамый тирә-якка карый, яраланган муены башын борырга ирек бирми, шуңа да ул бөтен гәүдәсе белән борыла. Моны күреп, Гәрәй тагын көлде:

– Шул тиклем әйләнмәсәң тагы? Артың белән арбаны тишәсең бит!

Ат, чабып килеп, аның туган урамына борылды да Гәрәйнең дилбегәне йомшак кына тартуын сизеп, Ильяслар капкасы алдына килеп туктады. Әллә кайдан сизгәндәй, беренче булып, Нәгыймә килеп чыкты.

– Балакаем! Көннәр буе күземне дә алмый олы юлга карап, сине көттем. Менә бит, Аллага шөкер, исән-сау кайтып та җиттең! Әйдә, балакаем, әйдә!

– Нәгыймә, Ильясны кочаклап алып, арбадан төшәргә ярдәм итте, төшкәч тә бик озак аны җибәрми тотты.

– С-саумы, ә-әнкәй! – Ильясның да күңеле тулып китте, шуннан ары берни әйтә алмады. – М-менә, к-кайттым, ә-әнкәй!

– Балакаем, рәхмәт, рәхмәт, әйбәт хәбәр белән шатландыруыңа. – Нәгыймә Гәрәйгә борылды. – Гәрәй улым, сиңа да рәхмәт! Станцадан ук бергәме?

Гәрәй Ильяс белән ничек очрашканнарын иркенләп сөйли башлады, тик аны Нәгыймә бүлдерде:

– Балакаем, анысын соңрак, әйдәгез, өйгә керик, капка төбендә тормабыз бит!

Нәгыймә, Ильясның бер алдына, бер артына төшеп, өйгә атлады, аның артыннан, бәләкәй генә биштәрен күтәреп, Ильяс кузгалды, атның тезгенен капка баганасындагы кулчага эләктереп куеп, Гәрәй алар артыннан иярде. Өйгә керү белән Ильяс, биштәреннән алып, әнисенең иңнәренә аллы-гөлле француз яулыгын салды. Нәгыймә, бала-чага кебек шатланып әйләнгәләп алды, шуннан үзенең балаларча шатлануыннан оялып, рәхмәт әйтергә ашыкты:

– Балакаем, синнән кем бүләк көтсен инде! Кайтуың – үзе зур бүләк! – Шушы сүзләрдән соң ул куллары белән Ильясның аркасыннан какты.

Очып диярлек өйгә килеп кергән Сәриягә дә шундый ук бүләктән өлеш чыкты. Сәрия аны ябынып биеп тә алды.

Бераздан, кунак кайтканын ишетеп, күрше-күлән, авылдашлар килә башлады. Иң беренче булып ут күрше Галләм карт керде, түгәрәк ак сакалын сыпырып, тиз генә дога кылды һәм сөйли дә башлады:

– Саумы, балакаем? Олылыр безгә әйтә торган иде: «Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр күрешә килер», – дип. Ишеткән идек, ишеткән идек синең дәваланып ятуыңны. Ысматри-матри, бик әйбәт, бик мәслихәт, дүрт саның да исән, калганы төзәлә ул.

– Б-бик ү-үк р-рәтле т-түгел әлегә хә-әлләр, Г-галләм а-абзый.

– Рәтле, рәтле, менә дигәнсең. Әйтәм бит, дүрт саның төгәл! Әнә, югары оч Галәветдин агач аяк белән кайтты сугыштан. Нишләсен инде, яшәргә тырышып ята, ысматри-матри! Ике аяклылардан да тизрәк йөгерә.

– Ә-әлегә т-төзә-әлеп к-кенә к-килә ш-шул я-аралар!

– Ысматри-матри! Сөяге булса, ит куна ул. Иншаллаһ, менә дигәнсең!

Берничә мәртәбә чәй дә эчелде. Өстәл яныннан торып китмәсәң дә була иде: бер-бер артлы туганнар, дуслар, күршеләр хәл белешеп кереп чыктылар. Ильяс үсеп киткән яшьләргә карап соклана, аларның кайберләрен танымаганда, әти-әниләрен искә төшереп, уртак сыйфатлар эзли, олыларның мең соравына белгәненчә җавап бирә. Иң авыр хәл әниләрнең «Улымны күрмәдеңме?» дигән соравына җавап эзләү булды. Ничек кенә аңлатып була соң авылдан ерак чыкмаган апаларга фронтның йөзәр-меңәр чакрым булуын, андагы кырмыска оясында таныш ике кешенең очрашуы очраклы һәм мөмкин дә түгеллеген?

Көн кичкә якынлашты, ә капка ачыла да ябыла торды.

Үзе дә сизмәстән, кемнедер көтүен аңлады Ильяс. Ничек кенә үзен дулкынландырмаска тырышмасын, исемен «кемдер» дип кенә атамасын,

көткән кешесе Сәлимә иде. Килгән-киткән кешеләр арасында ул юк... Хәер, башкача булуы да икеле инде. Нәрсә дип, ни дип килеп керә ала инде монда буй җиткән кыз кеше? Тәртиптән олы йола бар бит әле, алай өйрәнелмәгән дә, килешми дә. Тик шулай да күңелнең очканын туктатып буламы соң – капка ачылган саен эчтә, тирәндә яткан өмет кузгала, ачылып ябылган ишекләргә көткән күзләр белән йотлыгып карарга мәҗбүр итә.

Эңгер төшкәндә, гармун тартып, капка төбенә бер көтү яшьләр килеп туктады. Шунда тиктормас Гәрәйнең тавышы ишетелде:

– Солдат, сине Яшьләр тавында көтәләр! Әйдә, тизрәк!

Яшьләр тавы! Шидәле елгасы, текә ярларын артта калдырып, тигезлеккә чыккан урында борылып ярымутрау ясап, тип-тигез болын барлыкка китергән. Авыл барлыкка килгәннән бирле – ә бу хәлләргә дүрт йөз елдан артык! – яшьләр хуҗа бу аланга. Анда яшьләргә биерлек мәйданы да, сәхнә кебек калку урыны да, тәмле сулы Базан чишмәсе дә, җилфердәп искән җил кебек дулкынланырга торган яшь күңелләрне әллә кайларга алып китәрлек айлы кичләре дә бар. Анда тиле дә, акыллы да яшьлек дөньясы, анда сөю-мәхәббәт иле, анда «очрашу, вәгъдәләшү, кавышу» дигән тылсымлы сүзләрдән торган яшьләр иле! Елгага табан булган тигез урында үскән йөз яшьлек өянкеләр бу сүзләрне бик күп ишеткәннәр, аларны яттан беләләр төсле.

Кызык булып китте Ильяска. Ни генә искә төшмәсен, ул сагындырган, ни генә әйтмәсеннәр, ул әллә нинди бәйләнешләр аша берәр сәхифәне искә төшерә, кемне генә искә алмасыннар, ул кеше күз алдына килеп баса. Әле дә шулай булды. Яшьләр тавы – ул бит үзе бер дөнья, үзе бер галәм! Ә яшьләре – шундый ук шук, шундый ук өлгер, тере, шундый ук шат, әллә ниләр уйлап чыгаручы җитез егетләр,кызлар! Әнә бит, Ильяс кайтуга атап, такмаклар да чыгарып өлгергәннәр – монысын инде яшь гармунчы Әхтәмнең эше:

Каен агачы бөгелә,
Ничек түзә давылга?
Сугышларда җиңү яулап,
Солдат кайтты авылга,
Ильяс кайтты авылга!
Атлаганда, шинельләрен
Салып алган иңбашка.
Кызларның күзләре тала,
Карап безнең Ильяска,
Күз тимәсен Ильяска!

Әле генә бала-чага иде, инде буй җиткән; борын асты ару гына карала башлаган Әхтәм гармунда да беренче, җырда да алда, биюдә дә сынатмый. Бармаклары күз иярмәс тизлек белән төймәләрдән йөгерә, ә күзләре каршы якта җыелган кызларда, алар Сәрияне эзлиләр. Бер мизгелгә булса да якын килеп булырмы бүген аңарга? Э-эх, уйна, гармун, җырла, гармун, ела, гармун! Чакыр, гармун, сөекле кешене!

Яшьләр тавында Ильясны дәррәү кычкырып каршы алдылар. Ул егетләр торган якта һәрберсе белән кул бирешеп күреште, кызлар ягына карап исәнләште; тегеләре тыйнак кына баш кактылар.

Шуннан инде башланды! Кара-каршы җырлау, бию, каршы яктагы кызлар-егетләргә карап әйтелгән тапкыр да, матур да сүзләр, уеннар...

Безнең якларны мактыйлар –
Мактамыйча чара юк!
Безнең кызларны мактыйлар,
Бер сөйләшеп караек!

Бу җырга шул ук мизгелдә моңлы итеп кызлар җавап бирде. Егетләр дә җавапсыз калмадылар. Кызлар, аһ, бу кызлар! Шунда ук үпкәләрен белдерергә ашыктылар. Шаян егетләр дә сүз эзләп кесәгә кереп тормадылар:

Йөрәгемнән чыккан хисләр
Чишмә булып агыла.
Елама, кызлар, елама,
Солдат кайтты авылга!

Бик чакырсалар да, Ильяс биергә төшә алмады. Бу тиклем тизлек белән әйләнүче дөньяга ул сугыш яралары белән сыеп бетә алмый иде шул әле! Яшьләр дә, моны аңлап, аны кыстамадылар, шул ук вакытта ялгызын да калдырмадылар.

Бөтен авылдагы карт-корыны, ир уртасы булган абзыйларны, килен булган апаларны ак көнләшү белән көнләштереп, уен таң йолдызларына тиклем дәвам итте. Берничә тапкыр кайтырга кирәклеген искә төшереп тә карадылар, тик яшьләр аңа карыймы соң! Менә тагын шундый сүзләр, җырлар яңгырады:

– Әллә соң иртәгә без белмәгән бәйрәмме?

– Кайтырга теләгәннәрне тотмыйбыз!

– Йокы чүлмәкләре кайтып китә алалар!

Мондый сүзләр тагын кабатланды, тик көлешеп, аларны онытa тордылар. Кайтып киткәннәре дә булгандыр, тик күрер күзгә яшьләрнең саны кимегәне сизелмәде. Менә тагын кемдер, шаярып, җыр сузды:

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?
Әвен базарын сагынган,
Өенә кайта микән?

Тагын матур итеп көлештеләр. Шунда егетләрдән берсе Ильяска карады һәм, бөтен кеше ишетерлек итеп, аңа сүз кушты:

– Ильяс, җырла әле бабайлар башкорт-мишәр гаскәрендә йөргәндә, Ырынбурдан алып кайткан теге җырны!

– Җырла, Ильяс! Теге үзеңнең җырыңны. Аны син юкта беркем дә җырламады, сине көттек!

Ильяс аптырап калды. Станцадан төнлә арбада ятып кайтканда, беркем дә ишетмәгәндә җырлау – бер эш, ә монда халык алдында берүзең җырлау – икенче эш. Тавыш нишләр? Әгәр тотлыга калса? Кеше көлдерү генә булмасмы? Алай дисәң, кайтканда җырлаганда, бер дә тотлыгып тормады лабаса?

– Жы-ырлап к-карыйм, т-тик т-та-авыш нишләр! Ү-үзегез и-ишшетеп т-о-орасыз ми-инем с-сөйлә-әшүне. Б-булмаса, т-туктыйм, а-ачуланмагыз!

– Нинди ачулану ди? Авыр булса, ярдәм итәрбез! Әйдә, курыкма, җырла!

Ильяс бер мизгелгә туктап калды, күзләре белән Сәлимәне эзләде. Ул да кызлар артына кереп яшеренгән, Ильяс өчен дулкынланудан еш-еш тын ала. Менә аларның карашлары очрашты. Ни генә юк иде монда: сагынусаргаю да, юксыну да, очып килеп, кочакка чумарга теләү дә, ышаныч та, уңышлар теләп җан ату да. Сәлимәнең күзләреннән укыды Ильяс, алар: «Җырла, мин дә көтәм!» – ди иде... Башта бик акрын гына агылды җыр, тора-бара көчәя төште. Аның тавышы, елга буен уратып, кире кайтты, һаваларга менде, талларга уралды, елга агымына кушылып акты да акты, тыңлаучыларны таң калдырып, җырчыга якынайтты.

Чит җирләрдә йөреп, исән кайттым,
Әйтер өчен сиңа сүземне.
Илләр кичтем, күпне күрдем, сылу,
Бик сагындым нурлы йөзеңне.

Җыр туктагач, яшьләр озак кына сүзсез калып торды. Шуннан барысы да бертавыштан сөйли башладылар. Ул сүзләр арасында иң ишетелгәне «Афәрин!» булды. Барысы да бу җырның кемгә багышланганын аңлый иде.

Кичке караңгылыкта Сәлимәнең ут булып янган йөзе беркемгә дә күренмәде, ә менә йөрәгенең очып китәрдәй тибеше аңа еракларга ишетеләдер кебек тоелды.

Җырлаучылар тагын да бар икән. Кемдер шунда «Ә нигә безнең кызлар җырламый әле?» дигән сорауны бирде. Кызлар көлешеп киңәшләштеләр дә араларыннан Сәрияне алга чыгардылар. Ул кызарып-оялып торган арада гармунчы Әхтәм «Йә бүген, йә беркайчан да!..» дигәннең берсен сайлап алу вакыты килеп җиткәнен аңлады. Шунда ул, бөтен осталыгын салып, сукыр Ногман өйрәткән бормаларны исенә төшереп, бармакларын тальян төймәләреннән йөгертте. Ә Сәриянең яратып җырлаган җырын ул белә иде! Моны көтмәгән Сәрия башта каушабрак калды, шуннан тынычланып, җырлый башлады:

Иртә дә генә торам, юлга чыгам,
Иңнәремә шәлем ябынам.
Кемне сагынасың дип сорамагыз,
Күк күгәрченемне сагынам...

Йа, Хода, кайдан килә кешегә бу кадәрле моң? Таң беленә башлау кичке уенның бар хәрәкәтләрен, тавышларын туктатты. Сәриянең җыры туктагач, яшьләр тавындагы бар халык бер мизгел тын да алмый торды. Күңелләрдә уянган саф мәхәббәт тойгысы, йөрәк кылларына чирткән сагыш дулкыннары, яраткан кешеңне, олы мәхәббәтеңне, хыялларның тормышка ашуын көтү, алдагы матур парлы тормышка ышаныч – тагын әллә ниләр бар иде бу моңлы җырда.

Әйе, шулдыр инде ул – яшь чакта гына була торган сихри мәлләр,

парлашып дөнья көтә башлаганнарның ярлары күренмәгән бәхет диңгезендә йөзүе, олыларның сагышланып, хәтер чоңгылларына кереп, чыгар юлларын таба алмый уралып йөрүләре, картларның, нидер исләренә төшереп, фани дөньяның шул тикле тиз үтүенә аптырап, тел шартлатып, баш чайкап торулары...

* * *

Яшьләр үзләре генә белгән сукмаклар буйлап таралыша башладылар. Ильяс иптәш кызларыннан аерыла төшеп атлаучы Сәлимәне куып җитте.

– С-сәлимә! К-кич б-буе с-сине к-күреп тә си-иңа якын к-килә а-алмый и-иза чч-игәм! Н-ни хәл, С-сәлимә?

– Мин дә, Ильяс... Көндез сезгә керергә сәбәп таба алмый интектем!

Очрашкач, әллә ниләр турында сөйләшер кебек кешеләр тын калды, сүзләр онытылды, телләр аңкауга ябышты... Тора-бара сүзләре дә табылды, туктатып булмаслык көчле агым булып актылар да актылар йөрәктән чыккан ихлас сүзләр.

Көнчыгыш акрын гына яктыра башлады. Бер-бер артлы мәчетләрдә азан яңгырады. Сәлимә иртәнге салкында калтыранып куйды, шунда Ильяс шалт итеп үзенең маңгаена сугып алды:

– М-мин б-бит... О-оныта я-язд-дым... б-бүләкне!

Һәм шунда кесәсеннән кәшемир яулык чыгарды.

– М-менә!

Сәлимә яулыкны иңбашына салды, шуннан уйнап, әллә ничә төрле итеп бәйләп тә карады.

– М-матур!

– Рәхмәт, Ильяс!

Берьюлы өч манарадан намазга чакыру ишетелде. Сәлимә Ильяска карады:

– Ильяс, яктыра. Кеше йөри башлады. Әнә, азан да яңгырый. Әллә ни әйтерләр, мин өйгә киттем, – диде.

– Кичкә тиклем... – Ильяс үзе дә сизмәстән әйтте дә салды. – Кадерлем!

Бу сүз, икесенең дә башында матур уйлар булып уралып, аларга көне буе дәрт өстәп торды.

## 15

Унбишенче елның яңгырлы көзге кичендә волость капка төбенә ике жандарм озатуында арбалы ат килеп туктады. Озатучыларның берсе, чыланган киемнәрен каккалап, бинага кереп китте, ә арбада калганы, башын аска иеп, битараф кына утыруында булды. Жандармнарның юлдашы – Георгий Плехановның көрәштәше Яков Константинович Никонов – юешләнгән башлыгын өскә күтәреп, тирә-ягына карады. Өченче сөрген, ничәнче урын. Себере дә калмады, якынрагы да. Монысы авыррак булачагын ул сизде, чөнки килгәндә жандармнар аңа бу юлы аралашу мөмкинлегеннән мәхрүм ителәчәге турында әйттеләр. Озак утырдылар арбадагылар яңгыр астында, беренче жандарм, волостьныкылар белән тиргәшә-тиргәшә, кәгазьләрне рәсмиләштергәнче, аннан старостаны табып китереп, сөргенчегә торыр урынны билгеләгәнче. Ниһаять, чакырып

керттеләр. «Нишләп берни дә үзгәрми соң бу дөньяда? Себер ни, Урал ни...» дип уйлады Никонов, каләм сыныгы белән жандарм сузган язуга кул куйганда.

– Менә нәрсә, Никонов! – Жандарм үзен бик бөек кеше дип хис итте бугай, тавышын мөмкин кадәр югары күтәрде. – Сәясәт, сәяси эшләр булырга тиеш түгел! Без моны бик тиз белербез, хәтереңнән чыгарма! Моннан чыгып китү юк! Монысын үзең дә беләсең, тәҗрибәң зур! – Жандарм бераз туктап торды да, тавышына мыскыллау өстәп, сүзен тәмамлады. – Яшә менә шушында, пайтәхетләрдә яши алмагач!

Икенче жандарм да авызын ачты:

– Торыр урының, ярар, азрак җәлләдек, русларда булыр. Гәрчә татар гаиләсенә урнаштырырга дип язылса да. Әгәр безгә мәшәкать чыгарсаң, гаеп үзеңдә булыр. Безнең игелекне онытма!

Таза гына тормышлы Иван Суходеев өенә җитеп, хуҗа белән сөйләшкәч тә, саубуллашып та тормыйча, чыгып киттеләр.

Урта буйлы, коры сөякле, чәчләренә чал төшә башлаган Никонов йорт хуҗасына карады. Ул бернинди дә кичерешләрен күрсәтмичә, читкә карап кына, жандармнар белән саубуллашты. Ярты өйне биләгән зур мич янында тын гына, бәләкәй кызын кочаклап, чибәр хуҗабикә тора, унбиш яшьләр чамасы малай, егылып төшәрдәй булып, мич башыннан Никоновка төбәлгән. Шәм яктысында өй почмагына барып терәлгән өстәлдән биектәрәк торган ялгыз Мәрьям ананың йөзе ачылып-ябылып ала. Иван кузгалды. Мыегын сыпырып, сөргенчегә якынрак килде. Никонов аңардан алдарак сүз башлады:

– Танышыйк, бергә яшәргә, Ходай кушкач. Никонов Яков Константинович. – Ул алгарак атлады. – Социалист. Сәяси эшләр өчен сөргендә. Мәскәүдән. Ышанам, озакка булмас.

– Иван Семенович Суходеев мин. Болары – хатыным Антонина, балалар. – Ул хатынына борылды. – Табын әзерлә җәһәт кенә, кеше юлдан килгән!

Шул арада мичтән очып диярлек чүлмәк чыкты, өстәлгә тигез итеп, матур итеп туралган арыш икмәге ятты, май һәм бал салынган пыяла савытлар килеп утырды.

* * *

Менә шулай яшәп китте Никонов Казанлыда. Тулы ук булмаса да, университет белеме булгач, ул иң кирәкле кешегә әйләнеп китте. Фельдшерлык хезмәтен оештырып җибәрде, земство ачкан мәктәпкә ярдәм итә башлады. Муллалар фельдшерлык эшенә каршы чыгып карадылар каравын, тик халык нык торды: заманында Әхмәтгали хәзрәт сүзенә колак салып, авыл хастаханәсез торып калды бит инде. Менә шулай тора-бара Никонов бик кирәкле кеше булып китте, халык белән дуслашты, балаларны якын итте, өй хуҗалары да аны яратты. Җирле халык белән аралашу мөмкинлеге аз булачак, дисәләр дә, андый хәлләр булмады диярлек. Бу авыл кешеләренең күбесе рус телендә әйбәт сөйләшә, аңлашылмаучылык юк дип әйтерлек. Татарлар һәм башка халык аңа карата бернинди дә начарлык эшләми, киресенчә, аның белән әйбәт мөгамәләдә булырга тырыша.

Кышка Иванны сугышка алып киттеләр, тик озак та үтмәде, аның фронтта һәләк булуы турында хат килеп җитте. Никонов торган гаиләдә бик авыр көннәр башланды. Антонинаның күз алдында бәләкәйләнеп калуы куркыта, балаларны ашатырлык берни булмавы төшенкелеккә илтә.

Бәла үзе генә йөрми икән шул. Антонинаның бәләкәй кызчыгы Сима, урамда уйнап йөргәндә, бурасын алыштырып яткан коега егылып төште. Елау тавышын ишетеп, күләгәдә ашап утырган эшчеләр, кызчыкны коедан чыгарып, өенә илтеп куялар. Никонов урман юлыннан йөреп кайтканда, бала күзләрен шар итеп ачып, бер сүз эндәшә алмый урында ята, ә энисе ни эшләргә белми өзгәләнә иде. Хәлне бер сүздән аңлап, Яков шунда ук Антонинаның елавын туктатты, аннан аңа эш куша башлады.

– Син хәзер йөгер Сәләхетдин кибетенә, анда шешә белән серкә саталар. Шуны ал. Тик монда, үзебездә чыгарганын, Никольский химзаводында, әллә кайдан алып кайтканын түгел. Калганын карарбыз тагын.

Тиз әйләнде Антонина.

– Ә хәзер юка гына берәр киемне шул серкә кушып чайка, бераз җиллэтик тә юеш килеш киендерербез.

Монысы да эшләнде.

– Иртәнгә бөтен булган күгәргән урыннары килеп чыгачак. Ә хәзергә бакчадан җыеп кергән үлән-яфракларны кушып, бал тамызып, чәй ясап эчерт. Ә мин бераз сөйләшеп алыйм очучы кыз белән.

Яков баланы төреп күтәреп алды да йомшак кына сөйли башлады.

– Сима, син матур, син чибәр, син акыллы, син җитез, син – көтеп алган кадерле кеше, син – яраттыра торган бала, син сөйләшкәндә кошлар кушылып җырлый, син шаян, син шук, син өлгер, син... Ә син безне ташлап китәргә чамалыйсыңмы әллә? Юк, әлбәттә, юк!

Антонина, күз яшьләрен сөртергә дә онытып, аны тыңлады. Кайдан чыга бу тиклем матур сүзләр? Ә Яковның туктарга исәбе дә юк иде. Өйнең бер почмагыннан икенчесенә йөри-йөри, ул сөйләвен белде, баланың ачыла башлаган юрганын төзәтте.

– Сима, сине, бирсен Ходай, үстереп кияүгә бирәсебез бар әле. Шуннан синең безне оныклар белән шатландырасың бар әле! Син аларны ачык кое янында уйнамаска кирәклеген кисәтәсең бар! Шуны онытма! Менә бит синең күпме эшең бар бу дөньяда! Кайда әле безнең тәмле чәебез? Бер-ике йотым капкалап алыйк. Барысы да файдага!

Тагын йөрү, тагын йомшак кына, тыныч кына сөйләү.

– Сине алда нинди матур дөнья көтә, син бит моны үзең дә беләсең. Сине ничә кеше яратканын да беләсең. Әйдә, барыбызны да шатландырып, тиз генә аякка басабыз. Иң беренче булып, әниең шатланыр, аннан Андрейка, шуннан мин, тагын күршеләр, бу урамда яшәүчеләр, авыл кешеләре, аннан һавалардан карап торучы әтиең...

Антонина, шушы бәләкәй генә кызчык өчен җан атучы кешеләрнең шул тиклем күп булуына үзе дә аптырагандай, бер сүз дә әйтә алмыйча калтырап тора бирде. Ә Никонов өйне урады да урады, сөйләде дә сөйләде, арыганы да сизелми иде. Антонина берничә тапкыр баланы үзенә алырга теләп тә карады, тик Яков якын да китермәде. Иртәнгә кызчык, ниһаять,

күзләрен йомып йоклап китте. Никонов та утырган җиреннән башын иеп йокыга талды.

Иртән коп-коры булып кибеп киткән күлмәкне салдырганда, кызчыкның тәнендә учлап-учлап сыланган кара көйгән бихисап таплар күренде.

– Монысы әйбәт, тиз үтә торганнары. Иң мөһиме – эчтә ниләр икән? Авыздан-борыннан кан килми. Димәк, эчтә куркыныч юк. Сөякләрне капшап чыктым, сынганы сизелми. Тик башы, кул-аяклары авыртыр инде беркадәр вакыт. Ә хәзер баягы чәйне тагын яңартып җибәрәбез. Моңа менә нинди үләннәр кирәк була...

Терелде бер айдан Серафима.

– Синең исемең дә бит фәрештәнеке. Шуңа да син һәрвакыт кеше күзендә. Сак булу кирәк, үзең турында уйларга кирәк, ярыймы, Серафима?

Кыз инде шатлык нурлары йөгергән күзләре белән бер әнисенә, бер Яковка карады, ризалашып башын какты.

– Менә тагы бер сүзем бар, кызым. Кайчандыр минем... әнием кызларыңа өйрәтерсең дип, бик көчле дога ятлаткан иде... Кызларым-улларым булмады.

– Ә нигә булмады инде? – дип сорау бирде Сима борчулы тавыш белән.

– Тормыш, тормыш шулай икенче юлларга алып кереп китте шул!

Монысын аңлый алмый әле кызчык. Тик дога ятлауның нинди җаваплы булуын ул инде белә, шуңа да тагын сорады:

– Ә кайчан ятлый башлыйбыз?

– Нигә көтәргә ди әле? Хәзер үк! Әйдә, кабатла минем арттан:

Храни, Творец, меня, подруг,
Даруй им благодать!
Одних только лишь светлых дней
Хочу им пожелать!..

Серафима яңгыравыклы матур тавышы белән Яков Константинович артыннан доганы кабатлый да башлады. Бераздан инде ул аны бер хатасыз сөйли дә иде. Монысына Никонов тагын кысылмый булдыра алмады:

– Сима, доганы теләсә ничек, теләсә кайчан укымыйлар, аны эчтә генә тотып, кирәк чакта гына, Алла йортында йә Алланың йөзе каршында гына укыйлар. Син дә шулай ит, яме?

Кызчык, акыллы күзләре белән аңа карап, ризалашып баш какты.

* * *

Шушы хәлләрдән соң, беркөнне Яков Константинович Антонинага, игътибар белән карап, сүз кушты:

– Антонина, миңа монда сөргендә яткан өчен дәүләт акча түли. Ул акча, әгәр рәтен белеп кенә файдалансаң, барыбызга да яшәргә җитә. Шуңа күрә мин аны сиңа тапшырам, үзең белгәнчә сарыф ит.

Антонинаның кызара төшүен күреп, ул тиз генә аны туктатырга теләп кулын күтәрде.

– Ишетәсем дә килми. Мин – профессиональ революционер, ничек итеп башкача булсын, ди? Безгә бүгеннән бу хәлләрне ерып үтәргә кирәк. Соңыннан ни булыр, карарбыз!

– Яков Константинович, сез бит безнең өчен шул тикле күп изгелек эшлисез. Андрейны Мәскәүгә урнаштырдыгыз, менә хәзер Симаны коткарасыз...

– Алай уйлама, Антонина. Андрей укырга тиеш. Минем партия буенча коллегалар аны гел кайгыртып торалар, киләчәктә дә шулай булачак. Серафима инде ул күз алдында булган хәл, мин врач буласы кеше бит әле, ничек аңа кулдан килгәнне эшләмәскә, ди? Мин бу гаиләдән башка... синнән башка үземнең тормышымны күз алдына да китерә алмыйм!

Елады Антонина, тик яшьләрен күрсәтмәскә тырышты. Пешергән ашларының иң тәмлесен Никоновка салды, аның сүзен тыңлап кына торды, кушканын да көтеп тормыйча, аңа булышты. Яков та аңа бик зур игътибар белән караганын сизми дә калды. Беркадәр вакыттан соң Антонина да аңа ияләнә башлады, ахры, бик якын килмәсә дә, аның күзенә генә карап торган кешегә әйләнде.

Бу турыда бик еш уйланды Никонов. Революционерлар булып халыкка чыктык, халык арасында да йөрдек, халык тормышын өйрәндек, шул тормышны җиңеләйтерлек, яхшыртырлык юллар эзләдек. Таптыкмы соң? Һич югы Антонинаның тормышын җиңеләйтә алдыкмы? Монда әле ярый, зур авыл, кеше күп яши, хуҗалык мәдәнияте үзенә күрә оешып килә. Әнә бит, Марксны берни дип тә белмәгән килеш, Плехановны артта калдырып, күмәкләшеп, бер яланны эшкәртәләр. Ә бәхетлеме соң Антонина? Шунда ук күңелнең әллә нинди ерак нокталарында тискәре бер фикер уяна: ә син үзең, үзең бәхетлеме соң? Сөргеннән-сөргенгә йөрерсең, фатирдан-фатирга качып, күпме ятарсың икән? Яшең дә бара. Ә Антонина? Буйга да зур түгел, үзенә тартып торган йомшак тавышлы, күз алмаслык буе-тәне, озын коңгырт чәче урман кебек, сагышлы карашлары белән йөрәккә үтеп керә алган хатын. Соңгы вакытта Яков аның йөзен көне-төне шәм яктырткан почмактагы Мәрьям ана йөзе белән чагыштыра башлады. Әйе, шул ук бөтен дөнья сагышын үз эченә алган күзләр, башкалар өчен җанын да кызганмый фида кылырга, шулай ук тирәннән чишмә кебек ургылып чыгарга әзер торган наз, шул ук Ана буларак бөтен дөньяны сакларга, якларга әзерлек... Бер кешедә күпме әдәплелек, күпме түземлелек! Бу уйлар көннән-көн тирәнәйделәр, көчәйделәр, чыгарга юл эзләделәр. Тик уйлар гына түгел иде шул монда. Хисләр, хисләр – менә нәрсә иде бу! Яков бу хисләргә каршы тора алмаячагын инде аңлый башлады.

Ә Андрей бик башлы, акыллы һәм сәләтле укучы булып чыкты. Яков Константиновичны бер уй борчый иде: әгәр хәзер үк аны тиешле юлы белән җибәрмәсәң, соңга калабыз аның үсешендә. Акыллы, тик вакытында укымаган кешеләр азмы? Шуңа күрә ул, үзенең Мәскәүдә калган көрәштәшләре белән язышып, Андрейны тулы пансионлы берәр гимназиягә урнаштыруны сорады. Күп тә үтмәде, алардан уңай җавап та килеп җитте. Бу эштә иң авыры: малайны Мәскәүгә озату булды – монысын да чишә алды Яков. Екатеринбургтан кайтып баручы бер коллегасы Андрейны Чернушка станциясеннән башкалага алып китә алды. Сирәк-саяк килеп торган хатлар эшнең җайга салынуы турында сөйли иде.

Сөргендә яткан Яков Константинович авылда дошманнар да тапты.

Февраль инкыйлабыннан соң эшсез калган урядник күзләде аны, хатларны, җибәрелгән китапларны йә китереп җиткермичә югалтты, йә тоткарлады. Вакытлы Хөкүмәтнең бу революционерны төрле милләт вәкилләреннән тупланган халык кабул итмәс дигән фаразы гына тормышка ашмады.

* * *

Ильяс Казандагы сөйләшүне һич исеннән чыгармады. Мәхмүт Алиевнең белмәгән кешесе юк, ул Яков Константинович Никоновны да белә булып чыкты бит. Ул аның Россиядәге беренче марксист Георгий Валентинович Плехановның көрәштәше булуын да белә. Ул аңа, кайткач та, Никоновка барырга кушты. «Өйрән, тыңла, хәтереңдә калдыр ул әйткәннәрне!» – дип тә өстәде.

Тик ничек барып күрергә? Теге заманда болай кергәләштергәне бар иде дә, хәтерли микән әле ул Ильясны? Шуннан болай көпә-көндез барып керү аңа зыян итмәсме – кем белә аның хәлләрен? Элеккеге урядник, исерек баш, көне-төне сагалый дип сөйлиләр, кергән-чыкканнарның барысын да язып бара, диләр. Ничек кенә уйламасын, кичен Никоновны күрергә карар итте Ильяс.

Кич көттермәде, кызарып, кояш батуга караңгылык төшә дә башлады. Ильяс акрын гына, алдын-артын караштырып, урам буйлап килде дә Иван Суходеевның өе каршындагы түрбакчага борылды, биек муеллар кырыннан үтеп, өч-дүрт адым атлауга, өй алдына чыгып та җитте. Анда инде Никоновны эзләп торасы да юк: ул, сул кулына китап тоткан килеш, уңы белән оеган аягын уып, агач төбендә утыра иде.

– Хәерле кичләр, Яков Константинович! Мөмкинме?

– Ә-ә, солдат, кер, кер, әлбәттә! Мин сине күптән көтәм, син генә кермисең менә!

– Кайтуга бит өч-дүрт кенә көн, Яков Константинович, әле өйне төзекләндердем, башка эшләр булды йорт-курада. Шулай вакыт үтә дә куя.

– Мине үпкәләп әйтә икән дип уйлый күрмә тагы, аңлыйм барысын да. Ә керүең әйбәт, монда Россиядәге соңгы хәлләр турында хәбәрләргә кытлык, ой, нинди кытлык! Сөйләшик. Миңа өч сорауга җавап кирәк. Беренчесе, солдат халкының сугышка булган мөнәсәбәте. Икенчесе – партияләрнең активлыгы. Әнә бит ни эшли эсерлар фиркасе. Өченчесе – болай барса, сугыш бетерүне фронтны ташлауга кайтарып калдырырлармы? Меньшевиклар бик тирәнгә кереп баралар бит! Әлегә шул, калганын карабыз.

Никонов Ильясның җавапларын төпле дип тапты. «Яңалыкларга кытлык!» дисә дә, аның фронт хәлләреннән хәбәрдәр булуына игътибар итте. Сөйләшү сузылды, Антонина чыгып, аларга чәй ясап бирде, ниһаять, бертуктамый барган сөйләшү мондагы хәлләргә килеп терәлде.

– Яңа инкыйлаб булуы көн кебек ачык, Ильяс. Ул була калса, миңа да юл ачыла Мәскәүгә табан. – Никонов күзләре белән тирә-ягын урап чыкты. – Менә сезгә авырга туры килер. Большевиклар Учредительное Собрание турында ишетергә дә теләми, ризалашсалар – бары тик вакытлыча, тактик адым исәбендә генә.

– Ни белән тәмамлануы мөмкин инде моның?

– Гражданнар сугышы белән, гражданнар сугышы, Ильяс! Туган туган белән, ата ул белән сугышачак. Моның ни белән бетәчәген аңлап та булмый. Кыргыйлык булачак, илне харап итәчәкләр. Ленин моны аңларга теләми, ә Георгий Валентиновичны тыңламый да.

– Ә акыл белән эш итү кайда?

– И-их Ильяс, Ильяс! Син күпне күргән кеше, ә гимназистлар кебек фикер йөртәсең. Нинди акыл булсын власть өчен көрәшкәндә? «Башта власть, аннан карарбыз, аннан беркемгә дә бирмәбез!» Менә нинди фәлсәфә бит аларда.

Бер минутка тын калдылар. Казандагы очрашу искә төште. Анда бөтенләй башкача сөйләшү, башкача дәлилләр. Бәлки, бер үк сүзләр дәдер, аларны фикер баскычына менгерү башкача. Тик ничек кенә булмасын, Ильяс Казан егетләренең дә, Никоновның да белем, әзерлек дәрәҗәсен чагыштырып, үзенең әле бик артта булуын аңлый иде. Никонов соңгы соравын бирде:

– Син партия яклы гынамы, әллә инде әгъза дамы?

– Әгъза. Казанда чакта гадиләштерелгән юл белән үттем.

– Ике Бельгия хәтле җиргә бер большевик. Алга барачакбыз, болай булса.

Никонов көлгәндәй итте, тик шунда ук туктады.

– Юк, юк, мин көлмим. Бу – объектив вазгыять. Шулай булмыйча. – Никонов бер минутка уйга калды. – Ә миннән сиңа берничә киңәш, Ильяс.

Ильяс, армияне искә төшерепме, шунда ук аркасын турайтып утырды.

– Алдан ук үз яныңа ышанычлы кешеләрне җыя башла. Шуннан – корал. Коралсыз берни эшли алмаячаксыз. Тагын кайда, ничек яшеренеп ятарга урын бар, шуны карап куегыз. Сугыш тәртибен белгән кешеләр кирәк, ансыз авырга туры килер.

– Сез мине бөтенләй сугышка әзерли башладыгыз! – дип көләргә тырышып карады Ильяс.

– Мин вакытын да әйтә алам бу хәлләрнең. Көзгә большевиклар инкыйлабны ясаячаклар. Шуннан Учредиловка белән уйнау була, ә яңа елдан мин әйткән Гражданнар сугышы башлана, чит илләр һөҗүм итәчәк. – Никонов бер мизгелгә туктап калды. – Монда сезнең эшләр бик гади түгел, башка җирләргә караганда, күпкә катлаулырак! Милли мөнәсәбәтләр дә бар, бу якның бай булуы да бар. Соңгысы – эсерлар өчен менә дигән җирлек!

Монда кайткач яшәве җиңел булыр дип уйламаган иде Ильяс. Тик алда максатлар булмау, нәрсә эшләргә кирәклеген белмәү, фиркаләрнең эш юлларын аңламау – барысы да Ильясның әлегә бу эшләрне томанлы итеп күрүе турында сөйли иде. Үзе дә моны аңлый башлаган Ильяс Никоновка ярдәм сорап мөрәҗәгать итте:

– Яков Константинович, әзерлегемнең дәрәҗәсе бик түбән булуын мин аңлыйм. Андый кыю эшләр алда торганда миңа азрак булышмассызмы?

Никонов аңа көлеп җавап бирде:

– Данлыклы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган егеткә моны гына аңлау кыен булырга тиеш түгел! – Шуннан ул, җитдиләнеп, сүзен дәвам итте. – Яхшы, булдыра алсаң, көн дә кил. Аңлашырбыз. Икебез дә мөгаллимлекне сагынганбыз, бер очына барып җитәрбез ничек тә.

– Рәхмәт, Яков Константинович!

Ильяс кузгалды. Ул киткәндә, куаклар артында утырган ике кешене күрде, дикъкать белән карап, аларның авыл ирләре икәнен танышач, күрмәмешкә салышып, тыныч кына йорттан чыкты.

Никонов, урыныннан торып, куллары белән патша төрмәләрендә ятланган бер-ике хәрәкәт ясап, талган буыннарын яздырды, шәмне икенче ягы белән борып, китабына үрелде. Әле бер дә йоклыйсы килми иде аның. Менә бит нинди кыю егетләр үсеп килә, болар эшне азагына илтеп җиткерәчәкләр. Җәл, Плеханов белән Ленин гына килешә алмыйлар, уртак тел тапсалар, инкыйлаб та үз юлына тизрәк кереп китәр иде. Килешә алмау – әлеге дә баягы максатларда, үсү юлларында шул. Ә бусы бик гади нәрсә түгел. Елларның нинди кырыс булуына карамастан, Ленин армиядәге тәртипне бозган солдатларны яклап чыкты, фронттагы дуслашуны аклады, сугышның инкыйлаб белән тәмамланырга тиешлеген исбат итәргә тырышты.

Якында гына нидер кыштырдады. Никонов исерек урядникның караштырып йөрүенә инде күнегеп бетсә дә, аның шулай яшеренеп, монда килүенә ачуы чыга иде. Ул явыз кунакка бәрер өчен ару гына бер таяк та әзерләп куя башлады. Менә әле дә, яртысы язылган битне читкә куеп, сул кулы белән таягын капшады.

– Кем бар? Кем йөри караңгы төндә?

– Бу мин, Яша дәдә. Мин, Шакир!

Никонов лампаны кабызды.

– Кер, нәрсә таптанасың, килгәч? Ни булды?

Бакча капкасын тын гына ачып, уңайсызланып кына, нык гәүдәле, Шакир килеп керде.

– Бераз утырыйм әле синең кырда дип кердем, Яша дәдә.

– Тагын сүзгә килештегезме Сәләхетдин бай белән?

Шакир сул кулын селтәде.

– Аның белән шайтан да уртак тел таба алмый! Яз көне печәнлек бүлеп бирергә вәгъдә иткән иде. Бер атна исенә төшерәм, юк! Сәбәбе дә ни бит – имеш, быел җәй коры булган! Нишләп коры ди әле ул? Әнә, Чәчрәткедән халык печәнне ташып бетерә алмый!

Никонов урындыкны өстәлгә таба тартты.

– Әйдә, утыр, әле.

– Яков дәдә, өйдә ятып булмый бит. Балаларны ашатырга кирәк, алар миндә алтау, үзең беләсең. Менә кыш буе Сәләхетдингә бил бөктем. Ә ул? Имеш, быел печән юк, җәй коры килгән.

– Ну, җәйне коры килде дип әйтергә буладыр да, тик су буйларында үлән күп. Алдаша ул, хәйләле генә!

– Менә, менә! – Шакир туктап калды. – Яков дәдә, син гафу ит, мин үзем генә түгел бүген, Кәрам белән. Бераз әче бал да эчтек инде, – дип каушады Шакир. – Әнә ул, болдыр артында утыра.

Никонов елмаеп куйды.

– Чакыр соң, ник чакырмыйсың?

– Ю-юк, кыенсына ул сездән!

– Чакыр, чакыр, бар!

Шакир, борылып, тын гына утырган Кәрамга эндәште:

– Кер инде, Кәрам абзый! Нәрсә инде хәзер...

Тузанлы аякларын җиргә ышкып, эшләпәсен салып, кулына тоткан Кәрам килеп керде.

– Яков дәдәй, үзең кара: мин бит аңарда менә моның кебек чактан эшлим! – дип, Шакир кулы белән өстәл биеклеген күрсәтте. – Үземне белгәннән! Ә башкалар? Ярты авыл аңа бил бөгә!

– Ә мин? Ә без? – Кәрам урындыкка утырды. – Безнең нәсел дә көне-төне аңа эшли!

– Егетләр, без болай сөйләшсәк, таң әтәчләре уянганчы утырырбыз. Болар – гомуми сүзләр. Сез берничә сорауга җавап бирегез. Беренчесе – ничек алдады ул сезне? Хәер, бусына ишеттек җавапны. Икенче сорау – бу алдан ук килешенгән эшләр идеме, әллә бүген йә кичә сөйләшкән эшме? Үзегез генә сөйләштегезме, әллә шаһитлар да бар идеме?

Ирләр икесе бер тавыштан кычкырып җибәрә яздылар:

– Әллә кайчан, әллә кайчан! Эш башлаганчы ук! Ярты авыл ишетте безнең сүзне, ярты авыл!

– Менә монысы аяк терәп сөйләшергә мөмкинлек бирә, кирәксә. Тагын бер сорау. Бу эшләрнең вакыты билгеләнгән идеме?

Ирләр тагын уйга калды.

– Кем белгән инде анысы да кирәк икәнен... Вакыты ни – шул инде печән өстендә...

Менә шулай. Алдыйлар авыл кешесен, алдыйлар, аның кануннарны белмәвеннән файдаланып. Киләләр дә зарланалар. Сорауларга ачык кына, төгәл генә җавап бирә алмыйлар. Никонов тагын бер эзсез югалачак эшне күз алдына китерде:

– Нәрсә, жалу, гариза язып карыйбызмы? Хәл ителәсенә ышаныч бик чамалы. Кызганыч!

Ирләр дә моны яхшы аңлый иде. Кичке салкында балның кызулыгы да суына төште, вакыт та, бая әйткәнчә, әтәчләр уяныр чакка якынлаша иде инде. Беренче булып, олырагы – Кәрам урыныннан торды.

– Рәхмәт тыңлаганыңа, Яков знакум. Аңладык. Безне яклар бернинди нәрсә дә юк шул монда. Язудан ни файда?

Икесе дә урамга таба борылдылар, иелеп-бөгелеп, агачлар астыннан үттеләр дә тыныч кына чыгып киттеләр.

Никонов кәгазьләрен җыештырды, лампасын сүндерде. Өстәл өстендә иртәнге яктылык белән шәм яктылыгы ярыша иде. Шәм уты, җиңеләчәген аңлап, шәмдәлдәге эрегән балавызга сеңеп юк булды.

Ишек ачылды, шәлгә төренгән Антонина чыкты да Яков янына килеп басты. Аның уйчан күзләре аңа караган, әйтер сүзе юк, әйтәсе килгәне әйтелмәгән, килмәгәне – көн дә әйтелә торганы, көнкүреш сүзләре кызык түгел.

– Антонина, Тоня... Сиңа сүзем бар. Елдан артык бер өйдә торабыз. Минем өчен син бик кадерле кешегә әйләндең, моны инде үзең дә сизәсеңдер. Дөнья болганчык, буталчык заман, бераздан миңа да кайтып китәргә рөхсәт булыр. Тик мин кая кайтырымны да белмим. Ә син шуны белергә тиешсең – мин сине калдырып китә алмыйм. Син кайда – минем

өем, тормышым шунда. Каршы төшмә минем сүзләргә, зинһар, уйла: әзерсеңме минем белән тормышыңны бәйләргә? Ашыктырмыйм, тик сорау бирелде, җавап булырга тиеш!

Антонина, күз яшенә төелеп, ишек буенда торган урындыкка барып утырды.

**16**

Казанлы – өч мәхәлләсе булган, өч мәчетле авыл, Чияле тау астында, биш елга куенына кереп урнашкан. Зур авыл, бай авыл, күпмилләтле авыл. Вакытлы Хөкүмәт тарафыннан үткәрелгән хисап алулар авылда дүрт меңнән артык кеше яшәвен, меңгә якын хуҗалык булуын күрсәтә. Ул гына да түгел, авылның иң зур казанышы – шул тикле халык саны эчендә ярлы-ябагайның, хәерчеләрнең аз булуы. Җир күп, елга-урманнар бай, хуҗалыкларның эшче кулларга бай булуы мондагы тормышның ярлылык белән берничек тә тәңгәл килмәве турында сөйли.

Авылның үзенчәлеге – аның күпмилләтле булуында. Анда татарлар белән бергә тыныч кына башкортлар, руслар, поляклар һәм төрекләр, күп булмасалар да, удмуртлар һәм чувашлар яши. Гасырлар буена сузылган бердәм тормыш аларның телләрен шомартып бетергән, гореф-гадәтләрен якынайткан, милләтара татулыкны формалаштырган.

Кояшы нурларыннан, кар-яңгырлардан каралган өйләр, озын урам булып, төрле якка тарала. Кәтеринә вакытыннан калган, инде зур булып үскән каеннар һәм юкәләр яшеллегенә күмелә. Өйләрнең ике катлылары да, буялган, матур итеп ышкыланган такта белән тышланганнары да, калай түбәлеләре дә, сирәк кенә очраган бәләкәй, җиргә сеңеп барган салам түбәлеләре дә – барысы да авылның зурлыгын гына түгел, аның алга киткән тормышын күрсәтеп тора.

Биек мәчет манараларыннан төшкән күләгәләрнең иң кыска чагы – кояш баш өстендә, иң югары ноктада; авылда тирән тынлык хөкем сөрә. Бер тавыш, бер хәрәкәт юк. Бары тик кибетләр тирәсендәге күләгәләрнең кайнар тузанында арып-талып, телләрен чыгарып, чак тын алып яткан этләр генә күренә. Аларның танауларына кунган чебеннәрне куарга да хәлләреннән килми, ә ул бәйләнчек чебеннәргә чеилә эссесе берни түгел, этләр тирәсендә чуалып, аларны йөдәтәләр, теңкәләренә тияләр.

Июль тәмамланып килә, кояш чилләнең соңгы көннәрендә кинәнә.

Казанлы бушап калган.

Бөтен авыл печән әзерләүдә, малларга кышкылык азык хәстәрли.

Бөтен авыл өмәдә. Өмә – эш кенә түгел, бәйрәм дә, анда гармун, анда җыр-моң, анда ярыш, анда малайлардан башлап картларга хәтле эш белән мәшгуль; анда уен-көлке, анда яшьләр, анда мәхәббәт...

Кояш белән бергә торып, чалбар балакларын сызганып куйган малайлар, арбага җигелгән егермеләп атка халыкны утыртып, Чәчрәткегә юл ала. Олылар кулында чалгы уйнаса, ун яше дә тулмаган малайларның даны ат җиккәч башлана. Алла сакласын, юлда тугарылса? Камыт бавы сүтелсә? Аның бит ояты гына ни тора! Шунда ук җырлый башлыйлар: «Ат тугарып җигә белми, кызлар сайлаган була!»

Ул гына да түгел, бер колак белән булса да, олыларның сүзен дә тыңларга

кирәк бит әле! Алар ни генә сөйләми! Ә эше? Килеп җиткәч тә, абзыйлар сөйрәтке ясап бирәләр, арбаның артын ычкындырып, алгы күчәренә сөйрәткене беркетәләр. Шуннан китә ярыша-ярыша печәнне чүмәләләр янына ташу!

Ильяс өмәгә чыкмаса да, бер сүз әйтмәсләр иде, тик ничек итеп өйдә ятсын егет кеше уттай кызу печән өстендә?! Чыкты. Аның хәлен аңлап, егетне беренче болынга тәгаенләделәр. Чәчрәтке чишмәсе янында учак ягылган, анда әбиләр зур казаннарда ашарга пешерә, шифалы үләннәрдән ясалган чәй кайната.

Болыннарда шау-шу, ашыгу, күмәк эш тавышы.

Беренче болындагы чапкан печәнне әйләндереп чыкканчы кояш күтәрелә, печән шартлап кибә, корый һәм уала башлый.

Икенче болында – әзерлек. Кемдер чалгыларын үзе таптап чыга, кемдер, яшьрәкләр, гармунчы сукыр Ногман тирәсенә җыелалар. Ничек күрә икән берүзе алга-артка адым да ясый алмаган сукыр Ногман чалгының кайсы җиренә сугарга кирәклеген? Могҗиза!

Шуннан тезелеп басалар. Беркем дә кузгалмый, кулы җиңел Галләм картны көтәләр. Ул килә, бармагы белән чалгысының үткенлеген тикшерә, маңгаен сыпырып ала, дога укый һәм «Бисмилла!» әйтеп, чалгысын селтәп җибәрә.

– Аллага тапшырдык, егетләр! Изге сәгатьтә!

Бу юлы барысына да таныш булган «Ысматри-матри!» да әйтелми төшеп кала.

Һәм башлана! Ике болын арасында гармунчы Ногман йөри. Сугышта калган күзләре кайткан диярсең – җитәкләп йөрүче малае да кирәкми, аяклары үз юлын үзләре табалар. Ә җыры...

Ярман җире утлы күмер,
Ерак туган җиребез.
Шул яклардан хатлар язсам,
Сез дә җавап бирегез...

Чәчрәтке чишмәсе янында ашарга хәстәрләгән апалар, яулык очлары белән күзләрен сөртеп, йөгертеп, аңа чәй китереп бирәләр...

Төшке аштан соң кыска гына ял вакытында Ногман гармунда уйнаучы яшьләргә осталык дәресе үткәрә. Онытыла башлаган халык җырларыннан берсен ала да шул җыр көенең бар бормаларын, бөтен нечкәлекләрен ничек итеп уйнарга кирәген аңлата башлый. Кайбер тальянчылар бик тиз отып алалар, кайсылары өйрәнә алмый газаплана, кайсылары тыңлап кына вакыт үткәрә. Данлыклы гармунчыга алмаш булып калырга уналты яшьлек Әхтәмнең ышанычы бар. Ул Ногман өйрәткәннәрне бик тиз отып ала, кабатлый, икенче уйнаганда нәкъ аныңча уйный, үзенекен дә өстәп җибәрә. Шуңа оста ягыннан аңа аерым игътибар. Дөресен генә әйткәндә, Әхтәмнең бу эштә үз ихтыяҗы бар – гармунда уйнап, матур кыз Сәриянең игътибарын яулап аласы килә. Тик әлегә тормышка ашмый аның хыяллары... Сәрия аңа карамый да. Танавын өскә чөйгән дип әйтәсе килми Әхтәмнең, димәк, эш аның үзендә. Кызык түгел аның уйнавы Сәриягә, менә эш нәрсәдә!

Белерсең бу кызларны...

## 17

Лампададагы тыныч кына янган шәм уты тезләрендә торган Нинаның агарган йөзен яктырта, бу яктыда ул да дөньядагы барлык хатын-кызлар кебек галәм һәм җир тоткасы Алланың изге анасына охшап кала. Шул ук тын сагыш, шул ук юашлык, күндәмлек... Юка ireннәре Аллаһы Тәгалә генә ишетер сүзләрне пышылдый:

– Гафу ит мине, Аллам, гөнаһлы бер кызыңны, Синең дөрес юлда булмаган бер колың өчен догаларым белән мөрәҗәгать иткән өчен. Гомер бир Син аңа, ялынам! Яратам мин аны, Бөек Аллам! Яратам! Гөнаһлымындыр шуның белән, үкенәм һәм ярлыкау сорыйм! Яратам, башкача булдыра алмыйм! Ул да мине ярата бит! Нишләргә соң миңа?

Сизмәде дә кыз Степанның тавыш-тынсыз гына артына килеп басканын, күрмәде аның чөйдә эленеп торган каешны кулына алганын.

– Ходаем, бир мөмкинлек безгә кавышырга! Аерма юлларыбызны, ярдәм ит Син аңа барысында да! Мин... мин дә барысына да әзер!

Кыска гына сызгырып, кызу дуга ярымтүгәрәген сызып, каешның очы Нинаның кулбашын яндырып үтте.

– Ай-й!

Нина, сикереп торып, куллары белән йөзен каплады.

– Әле син онытмадыңмыни аны? Ә мин сиңа рөхсәт бирдемме? «Оныт шуны!» дип әйтмәдемме? – Степан сүзләрен суккан кулының җаена туры китереп кабатлый башлады. – Сиңа минем шул әйтүем җитмәдеме? Үтерәм мин сине!

Тавышка Егорьевна йөгереп чыкты.

– Атасы, атасы дим, нишлисең?

– Ә-ә, сез бер җырны җырлыйсызмыни әле? Мә сиңа да алай булгач! Мә! Икегезгә дә! Каһәр суккырлары, каргыш төшкерләре! Минем исемемне хурлыйсыз бит! Бөтен Михайловка көлә, тирә-як авыллар көлә! Бүгеннән дөньяны ташла да чыгып кач!

Егорьевна арык кулбашлары белән Нинаны капларга тырышты:

– Бар, бар кит, кызым, кач! Мин үзем сөйләшәм аның белән!

– Юк, әни! Үтерсен! Шулай әйбәтрәк булыр, ахры...

– Нәрсәәә? – Монысын ишеткәч, Степанның күтәрелгән кулы төшеп үк китте. Шуннан ул ачу белән каешын почмакка ыргытып, башын иеп чыгарга атлады.

Миләрне тишеп, сораулар кайный: «Нәрсә эшләргә? Кияүгә бирергәме? Кемгә? Берәр диванасынамы авылның? Юк, монысына кул күтәрелми инде, бердәнбер кызыңны утка салу була бит! Туй күтәреп ята торган вакыт та түгел бүген! Нишләргә?!»

Ул, шулай уйлана-уйлана, келәткә кереп китте, шунда яткан берничә башакны кулына алып, өлгереп килүче орлыкларын кулына уып төшерде. Учтан-учка өреп кибәген очырды, тулышып килгән орлыкны авызына кабып чәйни-чәйни чүгәләде.

Шунда ук икенче якка очты аның уйлары. Әйбәт, уңыш булачак быел. Тик туй түгел, башка уйлар иде аның башында. Сату, сату белән шөгыльләнергә кирәк бүген! Бөтен галәм сату итә, ул кешеләр генә бай да, әйбәт тә яши. Җир корты булып тырмашудан, җир ертудан файда аз шул! Менә шуңа да

ул, беркемгә дә әйтмичә, булган мөлкәтен төйнәп барды соңгы елда, әле дә карап кына тора. Нина елар-елар да туктар. Туй гына җитмәгән иде ди! Монысы – карар!

Нина гаиләдә берүзе үсте. Әнисе ул туып, өченче көнне якты дөньядан китте. Өйләнде Степан, берүзең яшәп буламы соң?! Тик... тик, Ходай тагын балалар бирмәде. Күпме какты ул яңа хатынын моның өчен. Тик ярдәм итмәде анысы да. Егорьевна бөтен булган җылысын, мәхәббәтен Нинага күчерде, Нина үз кызына әйләнде аның. Степан да яратты, тузан да төшермәде аңа бәләкәй чагында да, үскәч тә. Менә әле дә «Үтерсен!» дигән сүзләрен ишеткәч, кулларыннан каешы төшеп китте. Үтерәме соң?! Үзе аның өчен үләргә әзер бит ул Степан – моны Нина да яхшы аңлый. Авыл егетләрен барлый башлады Степанның хәтере. Берсе ярлы-ябагадан, берсе тәртипсез, берсе сөйкемсез, берсе ярымдивана, берсе шыр дивана... Ничек кенә булмасын, үзе яратмаган кешегә бирә алмый инде ул Нинаны. Мәңгелеккә йоклаган хатынының салкын кулын кысып, Алла каршында: «Мин бәхетле итәм Нинаны!» – дип сүз бирде бит ул. Ә Степан үз сүзен алыштырырга күнекмәгән, бу сүзләре башкаларга караганда күпкә изгерәк иде.

Тик аның бу Гәрәй белән булган бәйләнешләрен ничек кенә булса да өзәргә кирәк. Кирәк һәм тиз арада. Степан рус һәм мөселман кешеләре арасында мәхәббәт булуын күз алдына да китерә алмый иде шул.

Тик ничек ялгышкан ул – моны киләсе еллар исбатлады.

Әлегә ул үз уйларын тормышка ашырырга карар итте – моның өчен келәт ишеген тибеп ачып, йортта йөргән эшчеләргә кычкырды:

– Әй, кем бар анда? Миронны табыгыз тиз генә!

## 18

Өмәнең икенче көнендә ауды Ильяс. Шушы хәлләрдән соң гына исенә төшерде ул ак чәчле карт табибның сүзләрен:

– Синең алда берничә әйбердән курку тора. Беренчесе – салкыннан курык. Икенчесе – авыр эшләргә якын да килмәскә, авыр күтәрмәскә! Бугазның кан тамырлары бер-берсенә ябышып кына торгандай – аерылып китсәләр, эшләр хәтәр. Латынь әйтүенчә, «Instan mortem![1]» Өченчесе – тузаннан саклан, андый урынга аягың да атламасын! Монысы иң куркынычы – яраларның ялкынсынып китүе мөмкин. Әгәр мин кушканнарны үтәмәсәң, иң җиңеле – тавышсыз калу, иң әйбәте – җәннәтне якынайту. Һәм тагын – тәмәке тартма!

Э-эх, әйтүе генә җиңелдер – хуҗалыкта таркаулык, җимереклек хөкем иткәндә, тик кенә утырып буламы соң? Киртәләр авып беткән, өй кыегының такталарын давыл алып ташлый язган, әвендә тузан, чүп, абзар тулы тирес. Өмәдән тыш, атнага якын баш күтәрми эшләде Ильяс. Бер атнадан киртәләр, читәннәр ялт итеп тора иде, өй түбәсеннән тамчы да таммаслык итеп кагылган ап-ак такта ялтырап ята, йортның кунак ягы да, хуҗалык ягы да тап-таза итеп чистартылды. Өстәвенә – өмә, андагы тузан, анда эчкән салкын сулы катык...

Ауды Ильяс. Икенче көнне үк эсселек тәнне урап алып ятарга чакыра башлады, ашау үтмәве госпитальдә инде бер булган көннәрне хәтерләтте.

[1] Латинчадан «бер мизгелдә үлем» дигәнне аңлата.

Нәгыймә белән Сәрия аның яныннан китми утырдылар, аш ашатырга тырыштылар, Чияле тау чишмәсеннән бозлы су алып кайтып, тамагын чылаттылар. Тик ни файда белми эшләнгән эштән?!

Бары тик вакыты-вакыты белән килеп чыккан саташу гына Ильясның әлегә исән икәненә ишарә ясый иде. Бераздан анысы да юкка чыкты. Хәл белергә кергән картлар, борчулы карашларын идәнгә терәп, башларын ияләр, бертавыштан киңәш бирәләр – мулланы чакыртып, ясин укытырга...

– Сүземне авырга алма, Нәгыймә килен, чыгалмас Ильяс, чыгалмас. Сүземне авырга алма, ясин кирәк. Дога белән китсен Аллаһы алдына...

Якын туганы Гаязетдин Ильяс яныннан китмәде, сакалыннан тәгәрәп агып төшкән күз яшьләрен йота-йота, бал белән боздан үзе генә белгән дару ясап, аның тамагына сылады. Өченче көнне тотты да, андагы лекарьне алып килергә Чернушкага китте. Киткәнче Нәгыймәгә ныклап тукып куйды:

– Нәгыймә, кисәтеп куям! Ясин чыгарга уйлый күрмә! Терелә без!

Нәгыймә белән Сәрия үзләре дә алай итәргә уйламыйлар да иде. Ничек инде тере кешене озатырга?

Ю-юк!

* * *

Иртә белән кайтып та җиттеләр бу якларда киң билгеле булган халык табибы белән. Прохор табиб – олы яшьтәге, зур көрәк сакаллы, ярыйсы гына татарча да сукалый торган карт; күзләре йомшак, кешелекле булсалар да, аннан балалар курка, олыраклар да шүрли иде. Аның китек иреннәре – базар көн азагында еш була торган урамга-урам сугышларының эзе. Алар тәмәкедән саргайган сары тешләрен каплап бетерә алмый, ул урында сакалмыек та үсми, шуңа да куркыныч күренә – диңгез юлбасарларың бер якта торсын! Ә куллары – алтын, Рус-Төрек сугышын узып, күпме кешене яткан урыныннан күтәргән, терелткән, кеше иткән. Монысы белән бу якларда беркем дә бәхәсләшә алмый иде.

Килгәч тә эшкә тотынды. Кайдан белгән ул тамакта җыелган эренне тишеп чыгарырга кирәк булганын? Кайдан белгән ул моның өчен без кебек үткен пычагының очын утта тотып дезинфекцияләүне? Кайдан белгән ул кадарга кирәкле урынын? Кадап та бетерде, Ильясның башын борып өлгереп куе кара кызыл канлы эренне читкә агызды, шунда ук, Өреш аракысының иң бәләкәй шешәсен ачып, аның авыз эчен сөртте. Аракының әчелегеннән Ильяс ыңгырашып куйды, күз алдында битләре кызарып, җан да керә башлады.

Гаязетдин шатланып бетә алмый, күзен бер Ильяска, бер Прохорга йөртә, бертуктаусыз сакалын сыйпый.

– Кара әле, ә! Золотой бит синең ручки, ә, Проша!

– Золотой! Менә җитмиш җиди – җитмиш сигизенче елда Төрек билән алышканда булды ул, дааа! Кисилгән куллар-аяклар тау кебек, типкиләп диярлек йүртәләр. Шунда өйрәндек инде. Бик билгеле, от Бога хирург Николай Николаевич Пирогов бар иде, шул бизне үз яныннан җибирмәде, укытты, эшләтте. Тик озак тормады шул бизнин билән, анператор аны Болгарияга ярдәмгә узатты. Вот минә ул таби-иб!

– Элек булган соң кешеләр, ә! Это да!

– Тереләчәк! Үтә торган чир бу! Солдатны тегендәге шайтаннар җиңә алмаганны здешнийлары гына бер нирсә дә эшләтә алмас! Ә син, мамаша, давай, тавык суйдыр Гаяздан, аңа шулпа кирәк.

Гаязетдин шунда ук тавык суярга чыгып китте. Ильяс башта үзенең кайдалыгын, ни булганын аңламый иде дә бугай. Прохор аңа бал белән чәй эчерде, яңа суелган тавыкның пешкән итен турап бирде:

– Йута алмассың, пожалуй, ну итнең бөтен пользительныйларын тешең белән кысып чугарып глотай!

Гаязетдин да моңа көлеп куйды:

– Кул баласын да шулай ашатабыз бит!

– А что, кай җире белән биген ул кул баласы түгел? Менә иртәгә он все возвернёт, Худай бирсен!

Гаязетдин Сәриягә дә эш тапты – ул, тиз генә барып, бал балы алып килде. Кичкә табан сүзләрнең иң кызык җиренә җитеп килә иде. Прохор – Гаязетдиннан күпкә олырак, дөнья күргән кеше, узган гасырның бөтен сугышларында катнашып өлгергән. Иң кызыгы – алар икесе Казанлы волостеннан Япон сугышына бер көнне алынганнар, ярты Россияне паровоз теплушкасында бергә үтеп, бер урында хезмәт иткәннәр. Шуларга барып терәлделәр алар.

Прохор тәмәке артыннан тәмәке көйрәтә, тик моның өчен ул ишегалдына чыга. Бал балыннан аяклар авыр йөри башлагач түзмәде, Гаязетдинга борылып, үзенең фикерен әйтте:

– Карале, Гаяз, айда... теге... мал ызбасына! Мунда солдатны коптить... ыслатып битерәбиз, ә аңа бу ярамый бит.

Мал ызбасы дип, бу якта абзарны атыйлар. Кышкы салкын чакта, язның март айларында туган бәрәннәр, сыер бозавы җылы көннәрне шунда көтеп ала, яшел үләнне шунда каршылый. Миче дә була аның, капкалап алыргамы, берәр эш эшләргәме – өстәле, хуҗаның ятып ял итә торган калын итеп киез тышланган сәкесе була, авыл кирәк-ярагы – толыплар, туннар эленгән, идәндә билгеле урында чыпталар ята, кадак саен ат җигү әйберләре, кирәкле башка кораллар, бәләкәй генә булса да, дүртле-бишле лампа. Уңган хуҗабикәләр, яз җитеп, малны чыгаргач, йортны чистартып юып та куялар, менә дигән җәйге йокы урынына әйләнә дә куя үзенә генә хас исе булган кечәге мал ызбасы.

Өстәл җәймәсенә төреп, азык-төлек кыстырдылар, саклык белән генә бал балын, чуеннан бераз аш алып, бу икәү солдат чакларын искә төшерергә, очрашуны дәвам итәргә мал ызбасына киттеләр.

Анда чыгар алдыннан Прохор Ильясның авызын ачтырып карады, Нәгыймәдән юылмаган сарык йонын сорап алып, аны Ильясның муенына кысып урады. Күргәненнән риза булгач, аңа йокларга кушты:

– Помяни моё стариковское слово, спозаранку побежишь, пока биз турганчы йукудан. Гаяз ул йукуны бик ярата, мин аны йигирми йил биләм!

Иртәнгә тикле мал ызбасында сәяси темага сүзләр ишетелде, аларга ят сүзләр дә кушылды. Болардан башка авылда адмирал Зиновий Рождественскийны, Владивосток янында оборона тоткан Арцишевскийны,

Порт-Артур белән порт Чемульпоны, Дальний тирәсен, үзләре резервта яткан Раздольная станциясен кем белсен инде?

Йоклап киткәнче, Сәрия тагын бер кат Гаязетдинны карап килде. Ә бераздан Прохор һәрвакыттагыча татарча үзенең яраткан җырын ишеттерде:

Сары, сары, сап-сару,  
Сары пяки саплару.  
Сагинерсын, сиргаерсын,  
Килсә сугуш чаклару!

Аңа кушылып, Гаяз да үз җырын җырлый башлый:

В отставку с германского фронту,  
С далёких германских полей,  
Калека, солдат изнурённый,  
Плетётся к деревне своей...

Ильяс иртән барып, мал ызбасының ишеген ачып җибәргәндә, бу икәүнең тар гына сәкедә бер-берсенә артларын куеп гырлап йоклап ятканын күрде. Өстәлдә буш табак-савытлар, ипи кисәкләре, Прохорның дәваларга дип алып килгән Өреш аракысының бушаган шешәсе тәгәрәп ята. Басып куелган лампа уты кояш нурлары белән сугыша, куерган аш исе, үләннән борып ясалган бөкесен ябарга онытылган бал балы шешәсеннән чыккан ис идәндә яткан иске чыпталарның ат тиренә баткан исен күптән узып киткән иде инде.

Эчүдәмени хикмәт – очрашуда, очрашып, бер сөйләшүдә: монысын Туган илгә хезмәт иткән солдат ир-егетләр тулысынча аңлый, Аллага шөкер!

**19**

Ниһаять, эләктерде Петька Мишканы. Урыны да шәп – теләсәң дә, качып китә торган түгел. Көтмәс буасының аскы ягында Гәвенгә чыгып йөрер өчен җиңелчә басма салынган, шунда эләктерде ул аны.

– Син, Мишка, малай актыгы, нигә мин чакырганда килмисең әле ул?

– Вакыт юк бит, эш тыгыз, Пётр Васильевич!

– Эшлә, сүзем юк. Тик түрәләр чыкырганда, вакыт тап, кил! Немедленно! Алай ярамый ул!

– Аңладым, Пётр Васильевич, аңладым.

Биек буаның өч улагыннан үкереп агып төшкән су сөйләшергә мөмкинлек бирми, кычкырып-кычкырып та әйтәсе сүзне әйтерлек түгел. Шуңа Петя кулы белән «Теге якка чыгыйк!» – дип күрсәтте дә Мишканы куып дигәндәй, алга алып китте.

– Минем сүз бирәү генә – син кайчан Аннаны эзәрлекләвеңне ташлыйсың?

Чөгендердәй кызарып чыкты Мишка.

– Теге бит, Пётр Васильевич, эзәрлекләү түгел бу, бу ни...

– Мин сиңа бер әйткән идем бит. Аерманы кара: ул кем дә син кем? Раз тигез түгел икән ара, димәк, син аны эзәрлеклисең, аңа юл бирмисең, көн күрсәтмисең!

– Ай Аллам! Болай түгел бит! Ул үзе синсез яши алмыйм ди!

– Димәгәе. Туктат бу эшеңне! Туктамасаң, хуҗа үзе табар моның җаен. Аңладыңмы?

Мишка бер сүз эндәшә алмады. Ничек итеп туктатып була инде мәхәббәтне? Ничек?

– Белмим, Пётр Васильевич, белмим... Ни эшләргә дә белмим!

– Ярар, алайса. Син белмәсәң, мин йә хуҗа үзе белер. – Петька алга узды. Шуннан борынын салындырып басып калган Мишкага борылып өстәде. – Иртәдән соңга мунчала белән Әстерханга китәсең. Әзерләнә башла, әйберләреңне җый, кирегә юлның рәтен белеп куй, такелажны кара. Шул!

– Пётр Васильевич, Пётр Васильевич, соң бит минем бер мәртәбә дә суга чыккан булмады. Рәтен дә белмим. Куркам мин!

– Кыз кочакларга курыкмыйсың, биш йөз чакрым бер эшсез баркада ятарга куркам, имеш. Өйрән. Монда безне беркем дә өйрәтмәде, айлар-еллар буе. Кайчандыр, вакыты җиткәч, үзең утырасың да төшеп китәсең су буйлап. Шунда ук өйрәнәсең ул, көймәгә су керә башласа – Пётр Васильевич нидер искә алдымы, кыска гына итеп көлеп куйды.

Аерылдылар. Мишканың кулбашлары бөтенләй төшеп китте. Бар теләге – Аннаны күрү, аның белән сөйләшү. Бәлки, ул берәр җаен табар?

Пётр Васильевич, кабаттан басманы чыкканда, тагын улакларның үкерүенә игътибар итте. Тиккә түгел бу, бу кирәкмәгән куркыныч үкерү! Борылып, әле китеп өлгермәгән Мишкага сызгырып кул болгады. Тегесе, әйбәт яңалыкка өмет итептер инде, шундук йөгереп килде.

– Бар, тиз генә Пётр Алексеевич Ташкиновны тап и чакыр монда. Бер аягың – анда, икенчесе – монда, йөгер!

Тагын улаклар төбендә туктады. Нәрсә бу?

Ташкинов бик тиз килеп җитте, ерактан ук эшнең мөшкел булуын сизеп, кулларын колакларына куеп тыңлый да башлады. Шуннан, җиргә ятып, бик озак хәлне аңларга тырышты. Эш улакларда гына түгел иде – буаның биек, калын стенасы йөрәк суккан кебек акрын гына тибә, әлегә берәмләп агып төшкән су тамчылары аша елый иде. Монысы су афәтләре алдыннан була торган беренче кисәтү икәнен пристаньчеләр, буачылар, тегермәнчеләр бик яхшы күзаллый, аның булырлык нәтиҗәләрен еллар буена тупланган тәҗрибәдән чыгып, турыдан-туры күрә.

Пётр Васильевич торып басты, борылды.

– Кара, Петро, эшләр хөрти. Хуҗаны чакырыйк. Буа йөрәк каккандай. Танып, чыннан да, үкерә! Бу гел казага!

Петька, тагын тирә-ягына каранып, су кереп йөргән малайларның берсенә хуҗа артыннан йөгерергә әмер бирде. Тик Матусовны бераз көтәргә туры килде – карт инде күптән ашыкмый гына яшәргә өйрәнгән иде.

– Йә, нәрсә булды? – Тик соравын әйтеп тә бетермәде, эшне тиз аңлады тәҗрибәле кеше.

– Танып үкерә, Даниел Геворкович! Каза!

– Сиздем, нишлибез?

– Анысы гына нипочем, Даниел Геворкович! Буаны кага!

Матусов килгән уңаенда буага ятып тыңлады да бу сүзләргә бик тиз җавап кайтарды:

– Это плохо, очень плохо! Срочно нидер эшләргә кирәк!

Пётр Алексеевич, тын гына басып торган урыныннан уянып киткәндәй, сүзен әйтте.

– Бер көнне таныш булмаган кешеләр йөргән монда дип әйттеләр. Терекөмеш ташламадылар микән? Тикшерергә кирәк тиз генә!

Буа мәшәкатьләрендә терекөмеш ташлау – була торган эш. Үчләшүчеләр, елга ерылсын дип, дуңгыз башларына салып, буаның астына да, өстенә дә терекөмеш ташлыйлар. Алары инде, кушылырга теләп-ашкынып, буаны ералар. Дөрестерме, түгелдерме, төгәл белүче юк, тик бер тегермәнче дә, такта яру эшләре хуҗасы да бу ырымны игътибарсыз калдырмый.

– Ышанмыйм дип әйтә алмыйм, чөнки төрле хәлләр булды. – Матусов Петькага борылды. – Давай, куй кешеләрне, эзләсеннәр! – Шунда идарәченең тынычсыз йөзен күреп, аңа эндәште. – Пётр Алексеевич, тагын берәр нәрсәме?

Пётр Алексеевич сүзен дәвам итте.

– Әйе. – Ничек кенә кыю булса да, ул да Матусовка фикерен йомшаграк итеп әйтергә сүз эзләде. – Суны төшерергә туры килер, Даниел Геворкович. Башка юл юк! Нык кага, елга үкерә. Үзегез beләсез моның ни икәнен.

Даниел Геворкович күтәрелеп бәрелде:

– Син нәрсә? Бүген суны төшерү? Бер тамчы яңгыр юк! Безне партнёрлар үтереп, шушы су астына тыгачак бит!

Пётр Алексеевич сүзендә нык торды:

– Син мине беләсең, Даниел Геворкович! Уен түгел. Йә башны саклыйбыз, йә малны. Башка юл юк.

Даниел Геворкович үзе дә аңлый иде эшнең тирәнгә китеп баруын. Тик барыбер, авыр сулап, иң куркыткан соравын бирде:

– Күпмегә?

– Әлегә бер карышка.

– Бер карышка? Син мине чынлап үтерәсең, Петя! – Бар да тын калдылар. Шунда Даниел Геворкович, бер ныклы карарга килеп, соңгы соравын бирде. – Ә буадагы бер карыш Таныпта күпме булыр?

Пётр Алексеевич бер мизгелгә исәбенә чумды.

– Төрлечә. Иң биеге аршин тирәсе, чак кына күбрәк булуы ихтимал. Быел ярлар тар.

Матусовның йөзе яктырып киткәндәй булды:

– Бер карыш Гәвендәге баркаларны күтәреп җибәрерме?

– Җибәрә, ещё как. За милую душу!

– Ярар, бер карышка, әтеү. Тегермәнне туктатып торабыз, ачка үлмәсләр берсе дә. Ну агач эшенә туктау юк! Бер атнада кире кайтара алмабыз суны, шулай да... Кичкелеккә улакларны ябып торсак? Каравыл куеп?

– Була, почему булмый. Андый тәҗрибә бар безнең.

Матусов үз уенда.

– Тик Әстерханнарны шул күтәрелү булганда үткәреп җибәрегез тиз генә. Ходай үзе кушкандыр шуны эшләргә. Баркалар әзердер бит?

– Күптән әзер!

– Алайса, алга!

Данила – халыкта Далинә – карт акылының тирәнлеген кем үлчәгән?

* * *

Өч тешле сәнәкләр, ыргаклы багорлар белән коралланган кешеләр көймәләрдән, ярдан, саллардан, җәтмә тотканнары буа читеннән йөреп, суны сөзделәр. Аскы яктан, Көтмәс суы Танынка чыга торган урындагы чоңгылда таптылар беренче чучка башын, терекөмеше дә исән иде. Тик өстәгесендә берни дә юк, күпме генә тырышмасыннар, хәвефнең эзен дә тапмадылар. Беренчесен тапмасалар, юк дип баш кына кагарлар иде дә, эш, чыннан да, бик зурга китеп барды. Берсе булгач, димәк, икенчесе дә һичшиксез бар. Эзләргә, табарга!

Су, буа эше бергә-бергә башкарыла торган эш икәнен беркем дә инкарь итми. Көтмәс елгасында иң зур буа, аңа коя торган Мута елгасында Казанлыда гына да ике буа, әгәр аларның берсендә генә су ерылса да, өчесе дә шул мизгелдә юкка чыгачак. Ә су буендагы авыллар белән ни булырын күз алдына да китереп булмый. Шуңа мондагылар килешеп, эш итәләр, буаның хәлләрен күмәкләп тикшереп торалар, аның өчен махсус кешеләрне әзерлектә тоталар, елганы куак-агачлардан, баткан бүрәнәләрдән тазарталар. Матусов, үз буасының азакта торуын искә алып, аңа нинди хәтәр янаганын һәрвакытта да күз уңында тотып эшләде, булган хәтле ярдәм итеп, өстәрәк урнашкан иптәшләренә кул сузып торды. Дуңгыз башы, терекөмеш... Тик бу юлы? Алар эшеме? Кем авыллар язмышы белән шаяра? Кемгә кирәк җимерелү? Өстәгеләр түгелдер, ничек кенә булмасын, алар үз эшен башкара, Данила – үзенекен. Ярыш юк, димәк, алар түгел. Кем, алайса? Кем? Бу сорау, баш миен тишеп, бер яктан икенче якка йөри, тынгылык бирми, әллә нинди уйлар уята, утлы куздай кызуы белән җаннарны яндыра.

Бары икенче көнне тапты эшчеләр череп исләнә башлаган бәләкәй генә дуңгыз башын. Буа өстендәге вак дулкыннар аны агачлар арасына илтеп тыккан, ярым баткан үләксә шуңа күренмәгән дә икән.

Суны ашыгыч рәвештә бер карышка җибәрергә кирәк. Башкача булмый, куркыныч каза шәүләсе беркая да китмәгән әлегә. Танып үкерә дигән хәбәр авылларга таралды, кешеләр чынлап торып каза көтә башладылар. Мондый хәбәрнең беркайчан да казасыз калганы юк иде шул...

* * *

Бары кичкә таба гына хәбәр бирә алды Мишка Аннага. Очраштылар, сөйләштеләр. Иң көткәне дә, шатландырганы да – Аннаның бергә китәргә риза булуы иде.

– Миша, Мишенька, мин синсез яши алмыйм бит! Синең белән китәм. Итәш тугаенда барканы туктат, мин көймә белән Үле Танып аша синең арттан куып җитәм тиз генә. Аннан инде – бергә!

– Анна, бу куркыныч! Мин бит беренче тапкыр баркада. Таныпта суны күтәрәләр дип әйттеләр, буаны бер карышка төшереп. Андый чакта барканы туктатырга ярамый, тиз генә ычкынырга тырышалар. – Аннаның күзләре очкынланып китте, сүзендә каршы эндәшә алмаслык ялкын дулады:

– Яратасыңмы? Яратсаң, әмәлен тап! Туктат барканы бер мизгелгә, мин синең янга сикереп күчеп кенә утырам да алга талпынабыз. Ә анда инде без – бергә! – Анна бераз йомшарды. – Безгә шул кирәк бит, акыллым?

Мишка бу очрашудан бөтенләй төшенкелеккә бирелеп, боегып калды.

Ә бераздан тирә-юньне яңгыратып Шопен шашты, очты, әйләнде, тулганды, күккә менде, җиргә төште, су өстендәге вак дулкыннарны җыеп төреп, һавага күтәрергә тырышты...

* * *

Баркалар әзер, инде китәм, инде китәм дип, суда чайкала да башладылар. Тик су әлегә аз иде. Ташкинов тагын ике улакны ачарга боерды. Монысында инде су давылы буаның аскы өлешенә уйнап түгел, ашкынып килеп төште. Күтәрелеп киткән баркаларны шунда ук Таныпка юллый башладылар. Мишка өч барканың өченчесендә. Эшчеләр йөкне биек итеп төяп ныгытып куйганнар. Әнә шул биеклеге куркыта салчыларны. Бер яктан, ул яр буендагы агачларга тия, икенче яктан, тотрыклыгы аз. Чак кына дулкынлану булса – барка әйләнә дә китә, шуңа алардан осталык таләп ителә.

Гәвеннән мәшәкатьсез генә чыгып ычкындылар. Мишканың йөрәге куян йөрәге кебек тибә, шартлап, дөбердәп ала. Уйланылмаган сораулар аз түгел шул: Матусов сизеп калса, «Ә!» дигенче тотып алачак, Танып буендагы барлык пристаньнар дә аныкы, Кама-Чулманы да шул. Шуннан ни булыр? Кайда яшәрбез? Кирәк иде микән мондый карар? Бәлки Матусов та йомшарып китәр иде тора-бара. Ят кеше түгел, кызы бит!

Менә Үле Таныпка чыга торган Итәш тугаена да килеп җиттеләр. Мишка, барканы уңгарак алып, аның башын ярга төрттерде дә казыкны андагы тишек аша суктырып, ярга кадады. Ярдәмче абзый, коты алынып, бары кычкырырга гына өлгерде дә барка тукталу белән суга очты:

– Нишлисең, дивана, ярамый, ярамый! Харап булабыз! Сикер, сикер, тиз бул, барка әйләнә хәзер!

Бераздан аның ярга табан йөзгәне күренде.

Тик эшләнәсе эшләнгән иде шул инде. Кинәт туктау Мишканы биек урыннан бүрәнәләргә ыргытты, аның өстенә ниндидер юньләп бәйләнмәгән бүрәнәләр авып-шуып төшеп, кулларын кыймылдатырга да урын калдырмады. Барканың арткы ягы, су агымына буйсынып, теге як ярга барып ябышты һәм су юлын бүлеп куйды.

Үле Таныптан очып диярлек чыккан Анна хәлне тиз аңлады. Баркага күтәрелеп, Мишка өстендә яткан авыр бүрәнәләрне, чүп-чарны тарткалый башлады. Тик соң иде инде. Алар артыннан Ташкиновның бер карышы – Таныпта ул гөрләп, бөтен нәрсәне җимереп агып килүче дулкын, чыннан да, сажиннан биегрәк иде – килеп җитеп, су тегермәне ташын әйләндергәндәй, барканы чүп урынына әйләндереп тә җибәрде...

Бер минутта ике яшь йөрәк өчен дөнья бетте дә куйды... Кем кагылгандыр, әллә ни еракта да булмаган Матусов өендә пианиноның бер кылы яңгырап, чыңлап өзелде. Кеше сөйләвенчә, шул мизгелдә Танып та үкерүдән туктаган, диделәр…

**20**

Ике атналап сөйләделәр авылларда Таныпта булган бәхетсезлек турында. Матусовның икенче кызы башкалага чыгып китте, үзе бөтенләй күренмәс булды. Бары ике ярдәмчесе, тешләрен кысып, аның урынында бер җаен

алган эшләрне алып барды. Алар, авыр тын алып, мостикта утыручы кара күләгәсе генә калган хуҗага карыйлар иде.

Халык бу хәлләргә шунда ук бәет белән җавап бирде, кичләрен хәтерле кешеләр аны башкаларга илтеп җиткерделәр. Бәетнең башы – елатырлык, уртасы – үксеп елатырлык, азагы туйганчы елатырлык иде:

Кулымдагы шинелемне
Элеп куйдым кадакка,
Су астыннан китеп барам
Балыкларга азыкка...

Вакыт үзенекен итә. Барысы да акрынлап онытыла башлады.

Тормыш туктамый алга бара. Кешелек даимилеккә омтыла, бары тик шул даимилектә генә адәм үзенә кереп сеенып урынын таба, шунда гына ул бербөтен булып, бер үк вакытта шәхсән, аерым булып, гомер сөрә. Киләчәге борчый кешене. Кичәгесе – инде кирегә кайтмый торганы – кайгыртмый, анысы үтте, онытылды, ялгышлыклары да, уңышлары да артта калды. Бүгенгесе дә үтеп бара, кичәгедән нәтиҗә ясалдымы, әллә ясаласы бармы – монысы мөһим түгел. Ә менә иртәгәсе – ул тормышчан, ул кирәк, ул алдагы тормышның борылышларын югалтусыз үтәргә мөмкинлек бирә.

Даимилек тә куркыта шул кешеләрне.

Кинәт уяна башлады Казанлы үзенең мәңгелек йокысыннан.

Сәясәт белән икътисад, мәгариф белән мәдәният кушып алып барылган үзәк буларак, Казанлыга булганнарына һәм булачак хәлләргә алданрак каршы җавап бирү хас иде. Байлар, халыкның рухи халәте өчен Алла алдында да, җәмгыять алдында да җавап бирүче руханилар, мөгаллимнәр уяна башлады.

Әйткәннәрдән беренче булып Мөхәммәтҗан бай нык үрсәләнде.

Августның икенче яртысы бетеп килә, ә көннәр суынырга уйламадылар да. Һәркем үзенчә тормыш итсә дә, аңлаганнар алда әллә ни буласын сизми яшиләр дип әйтеп булмый иде. Менә Мөхәммәтҗан бай да көн саен ике улы белән планнар кора, кителеп барган дөньяның алдын-артын карап, нидер эзли, нәрсә булырын аңларга тырыша. Нидер буласы билгеле – көтеп алган патшадан котылу сәгатенең беренче сугуы ишетелде дә ул туктады. Димәк, алда булган эшләр эшләнмәде, димәк, тагын да нидер булачак. Менә шушы «нидер» нишләтер икән кешеләрне? Россия башка илләрдән аерылып тора, аның һәрвакыт үз йөреше, үз чишелеше, үз килеше. Һәм иң мөһим сорау – ни эшләргә?

Мөхәммәтҗанның ихтирам иткән киңәшчесе бар. Ул аңа бик сирәк, инде алга да, артка да юл калмаганда гына бара. Ул кеше – Гаязетдин, аның бабасы кеше итте Мөхәммәтҗанны. Узган гасырның алтмышынчы елларында Казан ягыннан кысулардан качып килеп чыккан иде ул монда. Торырга урын эзләп, эш эзләп килеп керде ул Башкорт-мишәр гаскәренең сотнигы Ягафарга. Тәртипле, итагатьле, Казан ягының көмеш тавышлы егете ошады сотникка. Ул чирүгә киткән чакта аның эшләрен эшләтүче кирәк иде, хуҗалыкны алып баручы. Бу эшкә коеп куйгандай булды Мөхәммәтҗан – бернәрсә сорамый, үзе белеп эшли, бу якта әйткәнчә, эшләгәндә йөрәге җилкенеп, ашаганда колагы селкенеп тора». Бер кайтуында

сизде Ягафар олыгаеп баручы кызы Фәния белән Мөхәммәтҗанның юллары очрашканын. Берни уйлап тормый өйләндерде, кияү итте, ул итте, башка чыгарды, байлыгын бүлеп бирде, ә эшкә өйрәтүен ташламады. Менә шунда үсеп китте Мөхәммәтҗан, алыпсатарлык аны бик тиз күтәреп, авылның гына түгел, төбәкнең билгеле кешесе итте. Иң кулай булганы – ашлык сату, шул ашлыкның хакы төшү-менүе иркен яшәргә, иртәгәге көнне артык хафаланып уйламаска өйрәтте.

Туганлашып яшиләр Гаязетдин белән алар. Бай кешенең бу якта бер туганы да булмавы да, бәлки, монда ниндидер әһәмияткә иядер. Мөхәммәтҗан аңардан олырак булса да, чыннан да, ихтирам белән карый Гаязетдинга, аның сүзен сүз итә. Чөнки Гаязетдин Япон сугышын, бу сугышның башын үткән, җитмәсә, унынчы елларда волость старшинасы булып та алган кеше. Урамнары да бер, Байлар урамы. Йорты да Мута елгасының Шидәле белән кушылган урынында, тегермән буасы буенда гына. Иң уңайлы урын дөнья көтәргә, монысы хак.

Бәлки аңарда берәр яңалык та бардыр? Дөнья бозылганда чынлап торып башны барып орыр урын да юк бит. Бүгенгесе кичәгечә түгел, иртәгә башкача булачак. Бармы бүген җир дип ябышып ятуның мәгънәсе? Әгәр иртәгә үк җирне бүлә башласалар, ни була?

Шушы уйлар белән барып керде ул Гаязетдинга. Хуҗа йортта, тик тормый, ниндидер эшләр белән мәшгуль. Өйгә кереп тә тормадылар, каен астына утырып, Рәфыйга китергән чәйне эчә башладылар. Башка чак булса, озак итеп дөнья хәлләрен сөйләрләр, төрле фаразлар кылыныр иде. Тик бүгенге көндә алар кайгысы читтә иде.

Гаязетдин, акыллы күзләре белән Мөхәммәтҗанга карап бер генә җөмлә әйтте, һәм җөмләнең сүзләре чишмәне ачып та салдылар:

– Урын таба алмыйсыңмы үзеңә?

– Юк! Беренче мәртәбә йөгәнсез ат кебек, кая барырга, ни эшләргә белмим. Бәлки, синдә берәр яңалык бардыр, ә? – дип өмет белән сорау бирде. Ә көмеш тавышы шул ук шайтанның!

– Нинди яңалык булсын инде, туга-ан! Утырабыз, ни көткәнне белми.

– Ишеткән идем, җирдән котылгансың икән?

– Бусы дөрес. Хәтереңдәме, патшаны алып ташлаган февральдә җир дип котырдылар. Хәзер дә, ул-бу була калса, җир дип тагын дулаячаклар. Шуңа күрә котыла башладым.

– Сер булмаса, күпмедән инде?

– Синнән серем юк. Күпме, азмы, ике ел дигәндә, биш мең десятинны җибәреп өлгердем. Үземә кешечә бары унберне калдырдым, Сары сазны. Сыйфаты әллә ни түгел, тик иң якын җир инде ул.

– Ару гына бит. Хакын сорамыйм, мул гына чыккандыр?

– Ару, тик күп түгел. Быелгы болганыш елларында сүз әйтерлек түгел.

– Монысында гына түгел бит әле эш. Ул акчаны кая куярга? Мин, булганын гел эшкә тыгып баргач, оекбаш тутырып куюны өнәп бетермим.

– Нишлисең инде? Оекбашны да яшерергә туры килмәгәе. – Гаязетдин кунакка якынрак күчеп утырды. – Мин монда гел Никон белән элемтәдә торам, бик еш сөйләшәбез. Ул әле чирләп ята, Мәскәүне сагынам дип елый.

– Терелә күрсен инде, Аллаһы, егерме ел өтөрмәдән чыкмаган, сөргеннән калмаган кеше бит ул!

– Әйе! Менә ул әйтә, большәвикләр киләчәк барыбер дип. Җирне бүләчәкләр – монысы хак, иң беренче булып. Шуннан Учредительное Собрание җыябыз дип алдаячаклар, анысы да булмас. Менә шунда эчке сугыш башланачак, ди ул. Гражданнар сугышы дип атады ул моны, атасы – улына, агасы энесенә каршы. Кырылачак халык, Мөхәмматҗан, кырылачак! Менә нидән куркырга кирәк безгә. Җитмәсә, интервенция булачак.

– Ходай, анысы ни инде тагын?

– Төрле илләр басып керәчәкләр!

– Ышанырлыкмы Никонга?

– Никон авыру. Бу хәлдә алдашу юк, үз хәле хәл аның...

– Кайчанга инде ул?

– Кем белә? Никон көзне сөйли, көтәргә куша.

Мөхәмматҗан башын иеп, бераз утырды да старшина килгәне турында исенә төшереп сөйләп алды:

– Теге атнада Ибрай килеп керде. Эшчеләрең күпме, тынычмы, сөйләгәннәре ни турында. Шуны, оялмыйча, миннән сорап утыра. Чак түздем, куып чыгарырга бер-ике омтылган идем дә.

– Аларны өяздән утлы табага бастырып кайтарганнар, шуңа йөри ул. Халыкны тынычландырыгыз дип инде! Ай-һай, алай гына тынычландырып булса ул кешене!

Уйланырга урын бар шул. Көз җитә, Мәкәрҗә ярминкәсе, сатып-алуның иң кызган чагы җитә. Мөхәмматҗанның ике улы, бәйләп куелгандай, монда яталар. Шулай килеп чыкты – ул аларны вакытында читкә җибәрмәде. Ә бит алар кайчандыр Парижга университетка юл сайлаганнар иде! Болай барса, ни булыр? Мөхәмматҗан сөйләшүдән соң берничә карарга килде. Беренчедән, улларны акрын гына читкә чыгарырга кирәк – монысы инде алар өстеннән җитәкчелек итүдән түгел. Алар үзләре инде күптән олы кешеләр, акыллары да, байлыклары да, тормышта тоткан урыннары да менә дигән, Мөхәмматҗан ягыннан бер ым гына булырга тиеш. Икенчедән, җыелган ашлык белән нидер эшләргә кирәк. Әгәр аны сатып булмаса, янә тартып алсалар – хәер сорашып китәргә генә кала. Өченчедән, хакы барда, җир белән азрак уйнап алырга кирәк. Аның да кадере китеп баруы ихтимал.

Озак сөйләшеп утырды алар. Тик әйтелгәннәрдән ерак китә алмадылар. Кем беләдер бу тормышның җаен, исәбен-хисабын...

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Чулпан
Зариф

# СИНЕҢ КҮК ЯНАМ МИН, ӘЙ КОЯШ!

***

Ак дөягә менсәң иде, сахралар кичсәң иде ул, сахралар кичсәң иде!
Сөю мәңге китмәсен дип, комнан бау ишсәң иде ул, комнан бау ишсәң иде...

Диңгезләргә төшсәң иде, энҗеләр тезсәң иде ул, энҗеләр тезсәң иде!
Бер генә коеп күз яшен, мең еллар көлсәң иде ул, мең еллар көлсәң иде!..

Оҗмахка кереп, алманы бер генә өзсәң иде ул, бер генә өзсәң иде!
Җиргә куылганнан соң да, Күкләргә түзсәң иде ул, Күкләргә түзсәң иде...

***

Кулларымны офыкларга суздым: син дип белдем күктә, кояш түгел!
Куллар идемени дөрләп янган? Юк, кояшка гаҗиз калган күңел!

Күктән иңгән бер йолдызга Җирдә назлы сүзнең иң назлысы – «гөлем»...
Җил-давыллар кубып Җирдән Күккә очты Күңел Җәнабемнең көле...

Учларыңда калды юеш эзе күз яшемнең... Нидер яшәү, үлем?!
Күпме елга гаип диңгезләрдә! Синең суларыңа мин күмелдем...

***

Кояшка юл тота кәрваным, аралар якынрак көннән-көн.
Әйләнеп кайтмасам, кичерерсең микән, илаһи сөеклем?

Талчыккан дөяләр янымда чайкалып баралар.
Көннән-көн ешая шатлыклар, кимиләр моң-зарлар.

Кояшның нурлары – күрәмсез, дөяләр! – эретәләр безне...
Синең күк янам мин, әй кояш!
Җылытырмын микән, кешеләр, мин сезне?!.

---

Чулпан ЗАРИФ (1969) – *шагыйрә, тәрҗемәче, галимә; Мәхмүт Кашгарый исемендәге халыкара премия, Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстан, Төркия һәм Евразия язучылар берлекләре әгъзасы. «Кояшка юл тота кәрваным», «Апельсиновая осень», «Lacivert yuhular» («Зәңгәр төшләр» – азәрбайҗан телендә) һ.б. китаплар авторы. Төркиянең Карст шәһәрендә яши.*

***

Мәрмәр диңгез буе – гөлләр...
Сезгә саксыз кагылдыммы?
Учымда – алтын тузан...
Тузаннан яңарып,
янә сиңа килгәнче, Истанбул,
Күпме гасырлар узган!..

Мәрмәр диңгез буе – гөлләр...
Сезне шашып үпкәнгәме,
Ирендә сутлы тамчы...
Тамчы гына өмет бирче,
синдә кияргә, Истанбул,
Илдә кимәгән таҗны!..

Мәрмәр диңгез буе – гөлләр...
Гасырларга сузылып та
Бу нинди бетмәс сусау?!
Сусавымны басмасмы дип
бу диңгезләрең, Истанбул,
Учларым сиңа сузам!..

Мәрмәр диңгез буе – гөлләр...
Сезнең язмыштан көнләпме,
Йөрәктә – тирән яра?..
Яралаган ярым булып,
гөлләр эченнән, Истанбул,
Минем йөзне арала!..

***

Хисләр анда төссез, уңган байрак кебек.
Әйтерсең лә кичкән дәүләтләрнең язы.
Әйтерсең лә менә чиксез Тупкапыда
Солтан ятагында кәнизәкләр назы...
Теләкләрем – көчсез, ялгыз илче кебек,
Кодрәтлегә яман хәбәр китерүче...
Әйтерсең лә суфый, намазлыкка ятып,
Теләкләре кабул булмый интегүче.
Җаным инде үчсез, җансыз тәңре кебек.
Каһәрләгән булды, инде җитәр, җитәр!..
Әйтерсең лә хисләр теләкләрем аша –
Бугаз өстендәге күпер тоташ челтәр!..

***

Истанбулда җәйнең соңгы мизгелләре...
Күңел котылгысыз көзне сизми әле.

Мәчет алларында гөрли күгәрченнәр,
Учлар әле тулы, хисләр әле җүләр!..

Хәрам фонтанында тәңкә-тәңкә теләк.
Үлем көчсез монда, яшәү – өметлерәк!

Күзләремне йомып бактым Үскүдарга.
Куллар рәхәт изри, алар сөеп арган...

...Истанбулда җәйнең соңгы мизгелләре.
Күңел котылгысыз көзне сизми әле.

***

Клеопатра! Сөйгәнеңнән сиңа бүләк –
Акдиңгезнең күз яшедәй тозлы суы.
Бу җирләрнең гүзәллеген синнән көнләп,
Яр буеннан карап торган күпме сылу!..

Ә мин бүген үзем – синдәй, хуҗабикә
Бер егетнең тәүге сөйгән йөрәгенә.

Көнләп түгел, көнләштерер бер халәттә
Яр буенда басып торам әле менә!..

Антонийга әйттең микән рәхмәтләрең?
Хәбәрем юк син сөелгән ул дәвердән.
Бүген – безгә ярым белән рәхәтләнеп,
Диңгез суын күз яшедәй эчү бергә...

***

Түбә буйлап йөзем үрмәләгән.
Баш очымда – пешкән, сусыл тәлгәш.
Бу җирләргә җаның теләп килгәч,
Үзең теләп китә алсаң әгәр!..

Юл читендә күккә сузган учын,
Нидер өмет итә хөрмә-агач.
Бу халыкның ашын бер ашагач,
Ничек юлга чыгып китсен юлчы?!.

Гашыйкларны илдән саклар өчен
Кыяларга уйган мәгарәләр.
Бу җирләрдә гашыйк булсаң әгәр,
Ничек онытылсын, ди, ул Кешең!..

Диңгез буйлап кояш тәгәрәгән –
Җиһан арбасыннан бер тәгәрмәч...
Бу җирләргә җаның теләп килгәч,
Үзең теләп китә алсаң әгәр!..

***

Җилле көндә диңгез буен иңлим...
Бармак арасыннан комнар илим.
Бу шәһәргә җәен килеп, көзен
Кайтып китми калган әллә бер мин?..

Ташлар ята – җансыз, хиссез, төссез...
Ә мин җанлы! Мин яшәргә телим!..
Уйлар уйлап, өметләрем төзеп,
Җилле көндә диңгез буен иңлим.

...Илдә калган, өйдә калганнарны
Башка төрле язмышларга көнлим.

***

Яңгыр явар, эрбетләрне чылатып,
Сәрбиләргә тагып тамчы-алкасын...
Йөрәгемне сулкылдатып, елатып,
Яңгыр явар... Айлар, еллар... Бер гасыр!

Яңгыр явар... Юк, җәлләмәс ул мине!
Әллә илдә, әллә читтә – барыбер...
Тик исемә төшерер дә илемне,
Яңгыр явар... Айлар, еллар... Бер гомер!

Яшь килен күк таулар өрткән бөркәнчек.
Зәйтүнлектә шашып-шашып кош сайрый...
Бурычка дип алган сулыш беткәнче
Явар яңгыр – сагыш кебек гел сары...

***

Таулар, чалма киеп, тәсбих тарта...
Теләкләрем кими, сагыш – арта…

Фирүзәдәй күктә – аппак болыт...
Тауга карап булсачы тау булып!..

Яшәү дигәннәре – яшел үзән...
Шул үзәннән тауга чыкмый түзәм.

Килер бер көн – тәсбих тарткан таулар
Үзәннәрдә агач булып шаулар...

Шул көн кояш кочагына кереп,
Аһ, мин түгел! – сагыш бетсә эреп.

***

Чит-ят күзләр күрмәгәндә генә, качып,
Битләремне күптән инде кояш үпкән.
Чәчләремдә – иртәнге чык тамчы-тамчы.
Иңнәремә болыт алып салдым күктән.
Ай юлында йөрим сине эзләп һаман,
Күзләремә җыеп йолдыз сагышларын.
Иңнәремдә – кара болыт... Киләм санап,
Тамчы кебек тамган мизгел агышларын...

***

Мин чакырган зәңгәр кыяларга
Туңам дипме, никтер менмәдең.
Җирдә калдың. Ә мин – югарыда...
Күрешербез микән бер мәлне?..

Җирдә калдың... Синең куллар түгел,
Кара болыт коча тезләрем.
...Зәңгәр кыялардан мин барыбер
Җиргә карап сөю эзләрмен.

***

Таулар томанда анда...
Күренми – караганда.
Шул тауларны эзли күңел
Кемнәрне уйлаганда?..
Таулар томанда анда...
Булса да салкын алда,

Тауларны күбрәк яратам
Кояшка караганда!
Томан да бер таралыр,
Таулар күреп хәл алыр,
Савыгыр минем дә күңел...
Әлегә – хәлем авыр.
Томанда калган тавым...

***

Язмыш ефәк булып сыйпамады
Ак тәнемне...
Үзем генә беләм ничә кабат
Үткәнемне
Күкләр белән мәрхәмәтсез җирнең
Тар арасын.
Ә бит шушы җирдә – күккә күчкәч! –
Бар каласы!..
«Уклар үтмәс калкан» дигән җаным
Яраланды...
Тәмугыңны кичтем. Сиңа, Оҗмах,
Тик бер адым!
...Җир убылды баскан җирдән.
Күкләр – ерагайды.

## Ак калфак

«Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы...»
Алларында тиңсез яры, –
Әле җылы кочагы...
Ләкин инде ак калфагы
Яткан ике арага...

Хәмдиягә сүз кушмагыз!
Кагылмагыз ярага.
«Ал мине дә үзең белән!» –
Талпынадыр кыз бала.
...Җаннар күккә ашканда, аһ!
Ак калфак җирдә кала.

***

Су биреп торсаң янымда,
Алтын саплымы кашык?
Мин синең мине сөймәгән
Җырыңа булдым гашыйк.
Белеп торам, артларымнан
Карап йөрерсең качып.

Китәсеңме? Бусагамнан
Имгәнмичә атлап чык!..
Йөрәгеңнән сызып, гамьме
Өзелә тамчы-тамчы?
Үкенмәм димә... Үкенү
Ишеге һәрчак ачык.

***

Кулымда кат-кат беләзек,
Беләкләрем – аһ! – нәзек шул,
Беләкләрем бик нәзек...
Бу төнне кем кочагында
Үткәргәнеңне, җаным ла! –
Килми генә беләсем...
Толымнарым кат-кат сүтәм,
Гомерләрем – аһ! – үтәр шул,
Гомерләрем тиз үтәр...

Нинди уйлар бу башымда,
Белсәң иде, кояшым ла! –
Беләсең килмәс бүтән...
Ишегемдә кат-кат келә,
Сөйгәнем – аһ! – бер генә шул,
Сөйгән ярым бер генә...
Ләкин ятлар кочагында.
Бәгыремне пычак белән
Әйтерсең чыра телә...

***

Айны болыт каплаганмы,
Күңелдәме ул болыт?..
Кемнәр сөйли шомлы төндә:
«Инде оныт соң, оныт!..»

Камышлыкка төшеп китте
Колагымдагы алкам...
Күл өстендә ай булырмын! –
Оныта гына алмам.

***

Оныттыңмы, әллә оныттыңмы? –
Яңгыр яудырмаган болытың мин...
Чәчәк атып, җәен тәлгәш-тәлгәш
Агачында кипкән шомыртың мин...

Күпме еллар үкси-үкси елап,
Яшәп килгән нечкә күңелең мин.
Шомырт булып инде чәчәк атмам...
Болыт булып, бәлки, түгелермен.

***

Шашып елый, үкси күкләр,
Җуйганмыни ялгысын!..
Чыккан юлдан кайтмас күпләр...
Кая илтә безне гасыр?!

Бүген кемнәр әйтә алыр
Алда тагын ни буласын?
...Җир-Ананың баш очында
Азгын җилләр чыга ясин.



Нурания
Гыйльметдинова

# МӨНБӘРЛЕ МӨГАЛЛИМ*

ПОВЕСТЬ

*Укытучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең
якты истәлегенә багышлыйм.*
Автор

## Кереш сүз

«1991 елның 2 сентябрендә улым университетка лекциягә киткәндә, балконга чыгып карап калдым. Безнең йорт бит университетныкы. Доцентлар, профессорлар пөхтә киенеп, кәс-кәс атлап, университетка киттеләр. Ә мин сәламәтлегемне терәп тотар өчен көндәлек гимнастикамны ясый идем. Аңлыйм: бу иртәдә мин университетка кирәк түгел. Татар факультеты миннән башка да яши ала. Студентлар минем лекциядән башка да яши алалар. Гантельләремне куйдым да, бүлмәмә кереп, үземә-үзем «сокланып», бер еламсырадым. Кырык алты ел эшлә дә бүген беркемгә дә кирәк булма әле!»

...Күзләрне каплаган яшь пәрдәсе аша укытучым Мөхәммәт Мәһдиевнең әлеге юлларын укыдым да, остазым белән беренче тапкыр килешмичә, шул килешмәвемне аның белән фикерләшә алмавыма бәгърем теткәләнеп елап җибәрдем. Үксеп, тавышланып, кайнар яшьләр агызып. Мин бит хатын-кыз. Җаны айкалганда, хатын-кыз еламсырап кына калмый. Юк, остазым, сез хаклы түгел! Сез әле студентларга кирәк идегез, сезнең гади дә, шул ук вакытта гаҗәп тирән мәгънәле лекцияләрегезне тыңлауга ихтыяҗ зур иде. «Мәһдиев дәресләрен тыңлау өчен генә мин университетның татфагын бетерер идем» дигән сүзләрне миңа күп тапкырлар ишетергә туры килде. Без бәхетле студентлар буыны булдык: киң амплуалы татар галиме Мәһдиевнең лекцияләрен тыңладык, тулай торакның кызыл почмагында әдипнең үзе һәм ул чакырган башка язучылар белән җанлы сөйләшүләр

* 2023 елда «Казан утлары» үткәргән «Сез – иң гүзәл кеше икәнсез!» конкурсында кызыксындыру премиясенә лаек булган әсәр.

Нурания ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА (1957) – *укытучы; «Нырсуар – Нырсы җире, шанлы изгеләр иле», «Йөз ел элек», «Үз өемдә – үз көем» китаплары авторы. Теләче районында яши.*

алып бардык, химкорпусның татар бүлеге урнашкан дүртенче катындагы аудиторияләрдә Мөхәммәт абый җитәкчелегендә «Әллүки» стена газетасын чыгардык, ул катнашкан һәм чыгышлар ясаган конференцияләрдә утырдык, төп корпусның актлар залы сәхнәсеннән укытучыбызның бары үзенә генә хас затлы торышын сокланып карадык, татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре буенча күп хезмәтләр, мәкаләләр, дәреслекләр авторы-төзүчесе Мөхәммәт Мәһдиевнең педпрактикада безгә биргән бик күп киңәшләрен тыңладык. Сез университеттан киткәч, шул бәхеттән мәхрүм булганнарга Мөхәммәт Мәһдиевнең нинди укытучы һәм остаз булуын сөйләп бирәсем килеп, мин шушы язмага алындым. Язмам повестьме, хикәяме, новелламы – минем өчен ул мөһим түгел. Аны язганда, мин гел сезнең лекцияләрдән әдәби әсәр нинди булырга тиешлеге турында, язучының иҗат процессы турында өземтәләр ишетеп торгандай булдым. Тик алар колакка ишетелсәләр дә, язганда йөрәктә калган, күңелдә сакланган вакыйгалар калкып чыга тордылар да кәгазьгә түгелә бардылар. Язмам тәгәлләнгәч, игътибар итсәм, сез кабатларга яраткан Толстой сүзләренчәрәк килеп чыккан: «...заманнар узу белән язучылар әдәби әсәр уйлап чыгарудан гомумән туктарлар кебек... Язучылар, әгәр инде алар булсалар, уйлап чыгарып язмаслар, бәлки тормышта үзләре күзәткән әһәмиятле яисә кызыклы нәрсәләр турында гына сөйләрләр». Болар – сез иҗатыгызда тугры калган сүзләр. Укучыларым игътибарына мин дә остазым турында «үзем күзәткән әһәмиятле нәрсәләр»не сөйләп үтим әле...

## Тулай торак та дәрес бирә

Әкрен генә ишек шакыдылар. Дүртебез берьюлы «Керегез!» дип эндәшүгә чыркылдап көлешә башлаган мәлдә, ишектән күзлек пыяласын ялтыратып, Нәҗип абый килеп керде. Кулында пөхтәләп бөкләнгән газета. Нәҗип абый – минем авылдашым һәм укытучым. Мин урта мәктәпне тәмамлап, ә Нәҗип абый инде шактый тормыш багажы белән икебез дә быел университет студентлары булдык. Без – бүлмәдә дүртебез дә бер төркемдә укучы кызлар. Шуның өстенә өчебез дә татар хорында җырлыйбыз. Уртак сөйләшер нәрсәләребез күп. Хәтта артык күп... Менә тагын бер төркемдәшебез кушылгач, сөйләшәсе сүзләр ташый да башлар әле. Тулай торакта шулай инде: бүлмә хуҗалары ник кердең дип сорамыйлар, керүче йомышын тиз генә әйтергә ашыкмый. Егет халкы үз төркеме кызлары яшәгән бүлмәләргә, лекцияләрдән кайтып, бераз хәл алгач керергә ярата. Бу вакытта бүлмәнең бүгенге дежур кызы чәй куеп, җиңелчә генә капкалап алырга табын хәстәрләүдә, калганнар да ач карынга зурдан кубарылмыйча вак-төяк эшләр белән мәшгуль булып торалар. Нәҗип абый безгә еш кереп йөри. Баштарак шаян Фәнүзәбез: «Кызый, ул сине күзләп йөрми микән, тикмәгә синең белән бергә студент булмагандыр әле», – дип үртәштерсә дә, минем Нәҗип абыйдан уңайсызлануымны, аңа укытучым итеп каравымны күреп ирештермәс булды. Чынлап та, баштарак миңа группада гел безнең белән булган бер укытучы күзе һәм университет укытучыларның икенче контроле бар кебек тоела иде. Тик авылдаш укытучы абыемның минем янәшәмдә булуына, аның үз итеп, ярдәм итеп торуына да күнегеп барам бугай инде. Мин аңа яклаучым, һәрчак

таянып булырдай абыем шикелле карый башладым хәзер. Мин «абый» дип дәшкәч, төркемдәгеләрнең күбесе аңа шулай дәшә башладылар. Нәҗип абый көлә: «Студент булгач, яшәрермен дигән идем, картайттың син мине, авылдаш», – ди. Кыскасы, менә шул Нәҗип абый безнең бүлмәгә килеп керде һәм кулындагы газетаны сүтеп җибәрде.

«Менә, авылдаш, сиңа истәлеккә», – дип, миңа бер фото сузды. Барыбыз да «Аh!» иттек. Аның кулында Мөхәммәт Мәһдиевнең берничә көн элек кенә безнең тулай торакта студентлар белән очрашу кичәсендә төшерелгән фотосы. Нәҗип абый – оста фотограф. Еш кына безнең бүлмәгә ул нинди дә булса фотосурәт тотып керә.

Фото шунда ук кулдан-кулга китте. Һәр кыз сурәттәге кешегә үзенең бәяләмәсен бирергә ашыкты:

– Мөхәммәт абый кебек оста позировать итәр өчен махсус курс үтәргә кирәктер, – дип, Розалия үз сүзен әйтеп куйды.

Фото Фәнүзә кулына күчкәч, ул аны кул сузымына ерагайтып та, якын китереп тә өйрәнде һәм, чигәсенә куеп, ашыгып сөйләп китте:

– Бу кешене Берләшкән Милләтләр Оешмасына вәкил итеп җибәрсәң, иртәгә бөтен дөнья халкы татар дигән милләт белән ду килеп кызыксына башлар иде, минемчә. Бигрәк тә Англия королевасы нәселеннән булган ледилар, – диде дә вәкарь белән генә фотоны Гөлсинә туташка тапшырды. Анысы, уймак күк авызын бераз очлайтыбрак, һәр авазны әйткәндә, иреннәрен максималь хәрәкәтләндереп, кыска гына билгеләмә биреп үтте:

– Форма һәм эчтәлекнең тәңгәллеге – сирәк очрый торган күренеш. Кара: И.Нуруллин, «Социалистик реализм», 2 нче бүлек, астан 3 нче юл. Әлеге фотода без шундый тәңгәллекнең гүзәл үрнәген күрәбез. Тагын бер өстәмә: фотодагы кешенең башка беркемдә дә була алмый торган ирен читләренә кунган бу елмаюны мин «Мәһди елмаюы» дип атар идем.

– Бирегез монда фотоны! Мөхәммәт Мәһдиевнең затлы кыяфәте сезнең бәяләүгә мохтаҗ түгел, – дип, мин фотоны тартып алдым да бик кадерләп кенә альбомыма тыгып куйдым.

– Ой-ой-ой! Янәсе, үзенең курс эше җитәкчесенә тел тидертми. Без бит аны мактыйбыз, тел тидермибез, – диде Фәнүзә, мине үртәп.

– Әй кызлар, кыяфәттәмени хикмәт. Беркөнге очрашуда аның сөйләвен таң калып, авыз ачып тыңладым. Чын галим, чын язучы! Бөтен сөйләгәнен тормыш белән бәйләп бирә. – Быел гына мәктәп бетергән безнең кебек укытучыларыбызга «аһ-уһ!» килмичә генә бәя бирүче Нәҗип абый фикере булды монысы.

– Тизрәк безнең группада лекцияләр укый башласын иде инде.

– Ул лекциясен кәгазьләренә карамыйча сөйли икән, кызлар, – диештек без.

Нәҗип абый белән бергә өстәл янына утырышырга, Фәнүзә кыздырып кергән макаронны ашап, чәй эчеп куярга биш минут вакыт җитте. Өстәлдәге табага сузылган калаклар бәрелешкәндә көлешкәләп алуны, таба төбен кыру авазларын санамаганда, тыныч ашадык. Филолог теле белән әйтсәк, безнең бүлмәдә табын янында сөйләшүгә табу куелган. Башлап җибәргән тема кызык булса да, сөйләшеп тамак туймаганны беләбез. Кунакка кергән бишенче «калакның» үтә дә җитез йөрүен күреп торганда бигрәк тә. Ашап туйгач, менә әңгәмә куертсаң да ярый. Кунагыбыз, Мөхәммәт абый

турындагы сүзен дәвам итеп, «Әллүки» газетасын чыгарулары турында сөйләп алды:

– Газета өчен җаваплы укытучы Марсель абый укуда бит әле. Кафедрада бу эшкә Мәһдиевне билгеләгәннәр. Әйтәм бит, гаҗәп эрудицияле укытучы икән. Мине грамматикасының көчле булуы шаккатырды. Корректор кызлар төзәтми калдырган әллә никадәр хата тапты. Газетаның бизәлешен тулысы белән студентларның үз ирегенә куйды. Байтак «яшьләрски» әйберләр өстәп җибәрдек газетага бу санда. Күрерсез әле, – дип, рәссам абыебыз безгә кызыксыну оеткысы да салып куйды.

– Арча педучилищесы белем ягыннан көчле, грамоталы укытучылар әзерләгән и һәм әзерләвен дәвам итә. М.Мәһдиевнең «Без – 41нче ел балалары» повестен укырга тәкъдим итәм. – Яңарак кына бүлмәгә кергән Арча кызы Мәдинә, шулай дип, Нәҗип абый сүзләрен йомгаклап куйды. Аның тамчы да көлмичә, кырыс диктор тавышы белән китапча итеп сөйләве җитә калды: бүлмә көлү авазларына күмелде. Татар бүлеге студентларына төрле образларга кереп, телдә булган барлык стильләргә күчеп сөйләшү берни тормый.

– Ну, Розалия, шәп әйттең син язучылар белән очрашу кичәсендә социалистик реализм турында, – дип, көлүләр туктагач, Гөлсинә гәпләшүне дәвам итте. Сүзгә мин кушылдым:

– Ой, мин сиңа әйтергә онытканмын, Розалия, Мөхәммәт абый да нәкъ шулай диде. – Минем курс эшем җитәкчесе Мөхәммәт Мәһдиевнең бүген консультациядә әйткән сүзләрен иясенә тапшырып. Җитәкчем тик торганда гына Розалияне мактый башламады, әлбәттә. Башта ул тулай торакта узган язучылар белән очрашу кичәсе турында фикеремне сорады. Мин «ык-мык» итеп тора башлагач, Розалиянең шартлатып үз фикерен әйтүен ошатканын әйтте һәм дәвам итте: «Ә бит әсәр турында сөйләшүебез, очрашуыбыз бөтенләй көтелмәгән якка борылып маташа иде егетләрнең чыгышыннан соң. Мин Хәсән Сарьянны студентлар тарафыннан тәнкыйтьләү өчен чакырган булып кала яздым».

Моннан берничә көн элек безнең тулай торакның Кызыл почмагында Мөхәммәт абый, язучы Хәсән Сарьянны һәм Ибраһим Нуруллинны чакырып, «Бер ананың биш улы» әсәре турында сөйләшү оештырган иде. Нәҗип абыйның алдан ук художник каләме белән белдерү язып элүе артык та булып чыкты. Татар бүлеге оештырган мондый кичәләрдә, чын-чынлап, алма төшәрлек тә урын булмый. Ул көнне дә Кызыл почмак урындыклары килүчеләрнең яртысына да җитмәде. Журналистлар, тарихчылар, рус-татар бүлеге студентлары бүлмәләребездән урындыклар алып төшеп утырдык. Кичә башланды. Кызыксынып, Хәсән Сарьянны күзәтәбез. Соңгы елларда татар укучысы яратып укый торган язучы. Журналларда басыла, китаплары чыга. Күбрәк авыл кешеләре турында язуы белән җәлеп итә. Соңгы әсәре бер ананың биш малай тәрбияләп үстереп, эчүчелек аркасында төрле хәвеф-хәтәрләргә юлыккан дүрт улын югалтуы турында. Тетрәткеч трагик хәлләр сурәтләнгән бу әсәрне, тәэсирләнеп һәм мондый хәлләрнең безнең авылда да булып ятуына ачынып, «Казан утлары»ннан мин дә укыган идем.

Хәсән Сарьянны тыңладык. Язучының чыгышы ышандырды, сокландырды. Күңелгә, мондый хәлләрдән сак булу өчен нык кавырсыклы

булырга кирәк дигән төеннәр төйнәлде... һәм шулчак бер егет сүз алып: «Безнең илдә коммунизм төзибез дип, иң матур яшәеш бездә дип шау иткән заманда, мондый социалистик реализм кысаларына сыймый торган әсәр яшь буынны дөрес тәрбияләүгә комачаулый...» – дип китте тезеп, китте тезеп. Аны икенче егет дәвам итте: «Матур җәмгыятьне матур эшле, матур уйлы кешеләр төзи. Эчкечеләр турында язып, безнең җәмгыятькә хас булмаган күренешне өскә чыгарып, без ни отабыз?» һ.б., һ.б. Өченче егетнең чыгышы бигрәк тә ачулы яңгырады: «Татарга эчүчелек гомумән хас сыйфат түгел. Ул күренеш әдәбиятта зурайтып сурәтләнергә тиеш түгел...»

Минем башым түбән иелгәннән-иелә бара. Иелгән баш белән залда утыручыларны күзәтә алмыйм. Бәлки алар да идәнгә карап утыра башлаганнардыр. Каникулларга, бәйрәмнәргә өйгә кайтканда, күрешеп хәл-әхвәл сорашып алуга, әнинең зарлана башлавы колакта яңгырагандай була: «Хәерлегә булсын инде, картаеп барганда, атагыз бәйдән ычкына башлады. Салып кайтмаган көне юк. Тормышлар әйбәтләнә бара дип, без, хатын-кызлар, сөенәбез, ә ир-атлар, без – фронтовиклар дип, гел өч борынга оешу ягын гына чамалап йөриләр». Бездә шундый хәлләр гел булып торгач, ничек бу сөйләшүгә кушылып китәргә кирәк? Кайбер башка кызларның өйләрендә дә шундыйрак хәлләр булганын беләм лә мин. Үзара сөйләшәбез бит. Әдәбият теориясе укытучыбыз Ибраһим Нуруллинга сүз бирелгәч, ул тамагын бик еш кыргалап: «Безнең тормышка хас булмаган күренешләрне типиклаштыру социалистик реализм юнәлешенә каршы килә, иптәшләр», – дип сөйләп, урынына утырды.

Залда авыр тынлык урнашты. Әкрен генә тирә-ягыма күз салам: бик күп башлар иелгән йә күзләр идәнгә төбәлгән... Психолог булмасам да, беләм: әсәр турында сөйләшүне дәвам итәргә кирәк монда. Башка ракурстанрак. Укытучы буларак, Мөхәммәт абыйның чыгышы монда язучыга ярдәм кулы сузуга охшап калачак. Зал үзе гәпләшеп, әсәрне әдәбият теориясе дигән тукмак белән тукмаудан коткарырга тиеш. Бу повестьның бөтен татар укучысына ошаган сәнгати көчен әһәмияткә алырга кирәк бит монда. Шулай уйлап утырам, тик иелгән башны күтәрә, күзне идәннән аера алмыйм. Кая ул нәрсәдер әйтү! Шул вакыт Розалия торып басты.

– Җәмәгать («иптәшләр» дип сөйләшүче укытучыларыбыздан аермалы буларак, без, татар бүлеге студентлары, шундый эндәш сүзне хуп күрәбез. Безнең бу әллә нинди тирән фәлсәфә салмаган эндәш сүзебез Мөхәммәт абыйга бик ошый һәм ул болай дигән иде: «Сез шулай дип эндәшә алуыгыз белән бәхетле»), мин бу әсәрне бик яратып укып чыктым. Миңа калса, без монда әле әсәргә берьяклы гына бәя бирәбез. Мин бу повестьта биш баладан дүртесен югалтып та сынмаган, бирешмәгән көчле ана образы да күрәм. Искә төшерсәк, ул бит әле сугыш афәтен дә кичергән. Бер ана да үзенең баласы эчкече, җинаятьче булсын дип үстерми. Аны тормыш, төрле алшартлар, сәбәпләр китереп чыгара. Хәсән Сарьян шуларны ачыклап биргән, укучысын кисәткән. Гыйбрәт өчен булган хәлләрне язу начармыни? Кисәтү начармыни? – дип, залга сорау бирде дә тагын берничә җөмлә белән генә үз гаиләләрендә өч ир бала үсүен һәм әниләренә эти дә, әни дә булып тормыш арбасы тартырга туры килүен сөйләп алды. Әнисе белән горурлануын әйтеп, урынына утырды. Афәрин, Розалия! Залны, очрашуны коткардың.

Йомгаклау сүзен Мөхәммәт абый сөйләде. Тавышында күтәренкелек, җиңеллек:

– Тормышның үзеннән алып язылган әсәрләр генә шушындый бәхәс, фикерләр уята ала, – дип башлады ул сүзен. Бәхәс уята алган икән, русча итеп әйткәндә, әсәр «удался». Әдәбият белеменнән сез бик яхшы беләсез: яхшы әсәр кеше тәрбияли. Хәтта әсәрдәге тискәре геройлар да, җәмгыятькә ят булган күренешләрне тасвирлау да уңай шәхес тәрбияләүгә юнәлдерелә. Әзерлекле укучы аны шулай кабул итә дә. Алда чыгыш ясаган егет сүзләре белән дә килешәбез. Эчкечелек татар милләтенә хас күренеш түгел. Дөресе – хас булырга тиеш түгел. Тик, ни кызганыч... Бар бит ул, тамыр җәеп маташа бит ул күренеш җәмгыятебездә. Искә алмыйча яшәп кенә, ул юкка чыкмый бит. Аның тамырлары каян килә? Шуны ачыклыйк. Татар ир-аты яхшы ук эчәргә Бөек Ватан сугышыннан өйрәнеп кайта... Әле бу күренешнең нәтиҗәләре ничек булып бетәсен алдагы гасыр күрсәтәчәк, моны өйрәнәчәкләр, нәтиҗәләр ясаячаклар. Ә язучы шул алдагы гасырга күз салучы, артка карап, анализ ясаучы бит ул. Сарьян шул эшне башкарган. Һәм яхшы башкарган...

Мөхәммәт Мәһдиев сөйли... Залдагы иелгән башлар күтәрелә, идән санаган күзләр аңа төбәлә, һәр сүзен йотлыгып күңелгә сеңдерә башлый. Мин дә әтинең салмыш баштан: «И-и, кызым, син аңламыйсың, син укысын, кеше булсын дип яшим бит мин. Менә әзрәк салган идем шул. Әзрәк арсак, шушы зәһәрне тели күңел. Йә, ярар, бетте, бетте», – дигәнен ишеткәндәй булып, күңелем белән аны бер тамчы гаепләмичә, башымны турайтып утырам һәм укытучымны тыңлыйм.

Менә шушы кичә турында фикеремне сорашкан иде миннән Мөхәммәт абый. Мин әсәр турында фикер әйтү түгел, укытучым сораганга да төгәл җавап бирә алмаган идем ул көнне.

– Фикер әйтергә куркып, башны иеп, идәнгә карап утыру өчен очрашуга килмиләр. Бик күбәүләр башын иеп утырды ул кичәдә. – Укытучымның бу сүзләре сүз арасында гына, өстәлдә таралып яткан кәгазьләрен җыйнаганда, тыныч кына әйтелсә дә, минем телемне ачтылар. Күзләр пәрдәләнеп китсә дә, гел сүз әйтергә куркып утырырга димәгән! Кыенсынуымны җиңеп:

– Мин дә башымны иеп утырдым ул көнне, – дидем. Күзләремне йоммаска тырышып, зур ачып, укытучыма карадым. Шулай итсәң, күзне каплаган пәрдә яшь булып акмый, таралып бетә. Күп сынаганым бар. – Чөнки безнең әти дә эчәргә ярата. Мин нинди фикер әйтә алыйм ул кичәдә? Шуңа күрә эндәшмичә утырдым...

Бераз тынлыктан соң, Мөхәммәт абый сорап куйды:

– Әтиең сугышта булганмы?

– Булган.

– Менә – җавап. Син борчылма. Алар буыны нык әле. Бирешмиләр алар, гаиләле фронтовиклар. Менә алардан соңгы буында бу нәрсәгә каршы торучанлык кими инде. Әтиең бу повестьны укысын. Бәлки ярдәме тияр.

– Әти китап укымый безнең. Дөресрәге, юньләп укый белми ул. 20 нче елларда авылда ачылган мәктәпкә ул чабатасы тузганда гына барып кайта торган булган.

Бөтенләй кирәкмәгән юнәлештә сөйләшеп утыруымны сизеп алдым, ләкин соң иде инде. Мөхәммәт абый кызыксынулы күзләрен миңа төбәде:

– Нишләп чабатасы тузганда гына?

«Ык-мык» итеп кенә котылып булмый хәзер. Сорау бирелде. Мин җавап бирергә тиеш.

– Әзрәк дәресләр укыган да, берәрсенең яңарак чабатасын киеп, качып кайтып киткән...

Әти җае чыккан саен кешеләргә ничек «белем алып» йөрүен сөйләгәндә, мин аның өчен оялып, бу хикәятен сөйләтәсе килмичә тыңласам, укытучыма бу хәл кызык тоелды бугай:

– Үткен малай булган икән әтиең! – дип көлемсерәде.

Курс эшемнең җитәкчесе булгач, мин еш кына шулай Мөхәммәт абыйга консультацияләргә йөрим. Һәрберсенә ул күрсәткән әдәбиятны укып, күзәтүләр ясап, күпмедер күләмдә язмалар белән барам. Темабыз – «Татар, башкорт, удмурт, мордва, мари, чуваш әкиятләрендәге батыр образларын чагыштырма планда өйрәнү». Лекцияләрдән чыккач, туры тулай торакка юл ябылды апагызга. Китапханә залларында әкият укып утырам. Әкият батырларының исемнәрен, яшәү урыннарын, киемнәрен, тышкы кыяфәтләрен, кылган гамәлләрен барлый барам, таблицаларга теркәп куям, чагыштырам. Татарның әкият пәһлеваннары бик тиз үсәләр, башкортныкылар тау кебек булалар. Мукшы, ар, чувашларныкы урман сыйфатларына бай булганнарын күрсәтәм. Һәр милләтнең пәһлеваннарында шул халыкның милли сыйфатларын, уртаклыкларны табам. Укытучым мине фәнни тикшеренүгә өйрәтә. Эшемне яратып башкарам.

Дөресрәге, кышкы каникулга кадәр бу шулай булды. Каникулда без авылларыбызга таралыштык. Әнинең тәмле ашлары, өйдәге энекәшләрем, кар түгүләр, көн саен клубка киногa чыгу, кинодан соң «вечер» уйнаулар сагындырган. Әдәбият теориясе теле белән әйткәндә, каникулның кульминациясе мәктәптә очрашу кичәсе булды. Укытучыларыбыз, классташлар, укыган классыбыз – барысы берьюлы тәэсир итеп, ул көнне эйфория кичердек. Миңа һәм Нәҗип абыйга караш икенче төрлерәк. Что син, без бит авылдан беренчеләр булып Казан университетына укырга керүчеләр! Студентлардан миңа да сүз бирделәр. Ашарга бирмә, сөйләргә бир – мин үзе булам инде. Университетта уку тәртипләрен, тулай торакта яшәүнең кызыкларын тәмләп сөйләп бирдем. Әкиятләр буенча курс эшемне искә алдым. Миннән соң сельхозда инженер булырга укучы өченче курс студенты сөйли башлады. Укуларының бик тә катлаулы, бик тә авыр икәнлегенә кат-кат басым ясый бу. «Кемнәрдер университетта әкият укып ятканда, без сопромат үзләштерәбез. Илне икмәк, яшелчә һәм ит белән тәэмин итү өчен әзерләнәбез», – дигән сүзләре яңагыма суккандай яңгырап китте. Тел төбен аңламый калдым. Беттем, сүндем, иелдем. Каникулның соңгы көннәренең кызыгы югалды, тәме китте. Үземне орышып та карыйм: «Серкәң су күтәрми дип миндәйләргә әйтәләр. Туктат! Нәрсә булды шулкадәр?!»

Каникулдан килгәч, консультациягә теләмичә генә бардым, яңа бер җөмлә дә язылмаган дәфтәремне демонстратив төстә ачып куйдым. Әңгәмәгә теләмичә генә кушылам, сорауларга да «тырт-пырт» кына җавап бирәм. Ниһаять, Мөхәммәт абыйның сабырлыгы төкәнде булса кирәк, сөйләшүне туктатып, капыл кистереп сорап куйды:

– Нәрсә булды?

– Бернәрсә дә булмады. Икенче тема алып эшләргә мөмкинме? Мин өлгерәчәкмен.

– Беренчедән, юк, мөмкин түгел. Темалар уку елы башында ук кафедрада раслана, деканатка тапшырыла. Икенчедән, әйбәт кенә эшләп килдең, нәтиҗәләр ясый башладык. Яз башында ук яклауга куярга булачак. Ни өчен курс эшенә карата үзгәрдең? Шуны аңлат. Шунсыз алга таба бергә эшләү кыен булачак.

Мин кыскача гына җитәкчемә очрашу кичәсендә ишеткән сүзне, үземне экиятләр укып йөрүче детсад баласы хәлендә тоюымны, эшемнең әһәмиятен дә бик кечкенә итеп күрә башлавымны сөйләп бирдем. Җитәкчемнең ирен читләренә «Мәһди елмаюы» кунды. Ул җиңел сулап куйды.

– Ә син нәрсә дип җавап бирдең?

– Бернәрсә дип тә. Анда сөйләүләр дә бетте инде озакламый.

– Бөтен залга түгел, шул егеткә генә. Берәр җай табып әйтергә иде. Танцылар булмадымыни? – Мин, сәерсенеп, Мөхәммәт абыйга карап торам, нәрсә әйтергә теләгәнен аңламыйм.

– Син үз курс эшеңне, үзеңне, инде килеп университетны якларга тиеш идең. Эшләгәндә, темаңны бик мөһим күреп язасың бит. Нигә аны башка берәүгә кимсетергә юл куйдың? Без бит аңа экият итеп кенә карамыйбыз. Никадәр мөһим нәтиҗәләр чыгарырга өлгердек. Эх, Мингалимова... – диде ул.

Танцылар башлангач, теге «критик» егет минем каршыга килеп, биюгә чакыруын әйтерсең Мөхәммәт абый күреп торган. Кая инде аның белән биюгә чыгу! Апагыз ул егет кисәген мәңге кичермәс дошманнар исемлегенә теркәп куйды бит инде. Бу турыда укытучыма әйтеп тормадым.

– Ул егет сиңа игътибарын шулай белдерергә теләгән булырга мөмкин. Гадәттә, дуслык шулай чеметкәләү, төрттерүләрдән башланучан, – дигән сүзләрен бик уңайсызланып тыңлыйм. Үзем тизрәк бу теманы туктатасым килә. – Мингалимова, онытма. Үзеңне һәм үз эшеңне яклый белсәң генә, бәя аласың бу дөньяда. Юк икән, зур тырышлык куеп ирешелгән хезмәтең юкка чыгарга мөмкин. Сиңа киләсе консультациягә бирем шул: теге егеткә җавап әзерләп килергә! Ә тагын бер кечкенә генә бирем бар икән. Курс эшең темасы буенча доклад язып кара әле. Кафедрада күрсәтәсе бар.

Хәйләкәр минем җитәкчем Мөхәммәт абый. Атна буена көн-төн язылырга мөмкин докладны кечкенә бирем итеп, ә теге бер җөмләлек җавапны зур эш итеп йөкли. Мин моның мәгънәсен докладны язып бетергәч аңладым: ул доклад тулысы белән теге «критик»ка җавап булып килеп чыкты да инде.

Икенче консультациядә мине Мөхәммәт абый ирен читләренә теге, без, кызлар, үзара терминлаштырган, «Мәһди елмаюы»н кунаклатып каршылады:

– Безнең курс эше буенча доклад белән Уфа университетына барасың дисәм, ни әйтерсең, Мингалимова?

– Ә-ә-ә?!

– Кафедра утырышында синең докладны, группагыздан Нәҗипнең, Фаязның һәм 5 нче курстан Зәмзәмиянең эшен башкорт дусларга конференциядә укып кайтырга лаеклы дип таптылар. Менә шулай,

Мингалимова, әкият кенә булса да, фән нигезендә өйрәнеп, кызыклы гына күзәтүләр ясадык без синең белән фольклор өлкәсендә.

– Ә минем тел очына теге егеткә яңача җавап килде, Мөхәммәт абый.

– Йә, йә? Мин аны оныттыңмы әллә дип уйлаган идем инде.

– Синең көчкә-өчкә үзләштергән сопроматың «международкадан» артык билге белән бәяләнмәгәндер әле, ә менә минем әкиятемне Уфа университетына конференциягә хәтле чакырдылар!

Укытучым бу юлы инде елмаеп кына калмады. Көлеп җибәрде. Башын артка җибәребрәк, тыелыбрак көлүе белән.

– Авылчарак булса да, әйбәт чыкты бу. Адресатның үзенә генә әйтәсе калды.

– Анысы булмас инде, мин аны тагын кайчан күрәм әле. Тиешле кешеләргә әйтермен. Җиткерерләр, – дидем мин.

## Лекцияләр төрле, сөйләүчеләре дә...

Өченче курс ул сиңа инде шәлә-вәлә түгел (тарих-филология факультеты студенты буларак, бу диалекталь сүзнең мәгънәсен аңлатып үтим: «шаляй-валяй» дигән русчадан кергән гыйбарә булып чыга ул). Әти-әни, алай аңлатып тормасалар да, Казанга һәр чыгып киткәндә, икәүләп шушы сүзне тәкрарлыйлар: «Кара аны, шәлә-вәлә килеп йөрисе түгел анда! Әйбәтләп укыйсы!» Балачактан ук мәгънәсе миңа яхшы аңлашылган бу сүзне колак кырыеннан уздырып, алар белән саубуллашам: «Сез нәрсә, шәлә-вәлә килеп йөрергә безнең анда вакыт барые, ди!»

Менә шул шәлә-вәләләрсез генә, җитдиләнеп, өченче курска җиттек. Моны уза алсаң, өлкән курслар сөйләве буенча, вуз югарылыгы яуланган дип санарга була икән.

Килеш-килбәтне алдагы ике елда вуз калыбына кертергә тырыштык үзе. Күп кызларның чәчләре кыска итеп киселде, буялды, бөдрәләнде. Егетләр дә чәчләрен бер-берсенекен генә төзәтешүдән туктап, парикмахер кайчыларына ияләнә башладылар. Кызлар, очсызга чыга дип, без студент булгач модага кергән чалбарлар тегеп кидек. Миниларның заманы уза барганны күреп, тиз генә тездән түбән ярыммакси итәкләр хутка җибәрелде. Урамдагы модницалардан күреп алып, ул итәкләрнең бер ягына тездән өскәрәк төрле бизәкләр чигелде. Мондый эшләрне группабызда иң беренче Нурия мәтәштереп куя. Ни генә тегеп кисә дә, үзенә килешеп торганны күреп, калган «модельләр» аңа ияребез. Бәйләгән кофта, итәк, күлмәкләр модага кергәч, гомуми лекцияләрдә соңгы рәтләрдә утыручы студенткалар өстәл асты бәйләү дәресләрен ачып җибәрделәр. Безнең группада бәйләү буенча Флёраны берәү дә уздыра алмады: салкынча көннәр башлануга пардан башлык-шарфын, француз журналларыннан карап, шуларга бер ансамбль итеп бәйләнгән кофтасын киеп куйсамы?!

Группаның яртысы Алексеевск якларында сентябрь буе бәрәңге алып, төзелеш отрядындагылар авылларында ял итеп, бүген менә барыбыз бер аудиториягә җыелып, беренче дәресне көтәбез. Барыбыз да энәдән-җептән киенгән. Бигрәк тә төзелеш отрядында умырып акча эшләп кайтучылар шәп! Ул тәэсирләр, ул җыелган сүзләр! Ә күзләр әледән-әле ишектә. Мөхәммәт

Мәһдиев керергә тиеш. Бу – без ике ел көткән вакыйга. Ашыкмыйча гына, башын югары тотып килеп керде, ишекне ачык калдырды, портфелен җайлап кына өстәлгә куйды. Исәнләште. Безгә күз йөртеп чыкты.

– Бик күбегезне мин беләм икән инде. Яхшы. Танышып вакыт уздырмабыз.

Шулвакыт ачык калган ишектән берничә соңга калган студент кереп, рөхсәт сорап утырыштылар.

– Беренче пар лекция студент өчен нәрсә икәнен мин бик яхшы аңлыйм, – дип, соңга калучыларны күзәтеп, дәвам итте укытучыбыз. – Ишек лекция башында бүгенге кебек ачык булыр. Алдан ук сөйләшеп куйыйк: исәнләшеп, рөхсәт сорап, үзеңнән соң ишек ябып, әдәпле булырга тырышмыйбыз. Соңга калып килеп, сез зур әдәпсезлекне күрсәттегез була инде, шул җитә. Соңга калган студентларны ачулану гадәтем юк. Мин Казанда транспортның ничек йөрүен бик яхшы беләм.

Быел Мөхәммәт абый XX йөз башы татар әдәбияты курсын укытачак. Студентлар көзлегеннән караганда, иң катлаулы, иң авыр чор. Тукай, Рәмиевләр, Дәрдемәнд, Г.Ибраһимов, М.Гафури, Ф.Әмирханнар чоры. Нибары ике дистәгә якын елны үз эченә алган чор әдәбиятына бер семестр вакыт бирелгән. Хәзергә авыр карашларын укытучыбызга текәп утырган группадашларымның берничә лекциядән соң, очкынлы күзләрен ялтыратып, ишеткәннәрен калдырмыйча язып барырга тырышачакларына иманым камил. Мөхәммәт абыйга ишекне дә ачык калдырырга кирәк булмаячак әле, менә күрерсез. Остазымның тел куәсе, тирән белеме, киң эрудициясе белән группадашларыма караганда алданрак очрашканга, шундый уйлар белән лекция язам. Кара-каршы утырып, консультациядә әңгәмә үткәрү – бер нәрсә, ә аудиториядә кафедра артында укыган доцентның лекциясен тыңлау – бөтенләй икенче. Мин хәтта остазымның бераз дулкынлануын да сизәм кебек.

Тәнәфестә старостабыз Хәлил группага белдерү ясады:

– Җәмәгать, бу пардан соң физкорпуска Госманга барабыз.

Мөхәммәт абый аудиториядән чыгып барышлый бу сүзләргә игътибар итте:

– Мин университет профессорлары Шофман, Гофманны беләм. Госман турында ишеткәнем юк. Яңа укытучы мәллә? Нинди курс алып бара?

Аудитория шым булды. Сүз профессор Хатип ага Госман турында бара. Аның исемен яһүдиләштереп, басымын күчереп әйтүебезнең үзенә күрә бер тарихы бар. Шушы старостабыз Хәлил чыгарды ул яһүди исемне. Беренче курсның тәүге көннәрендә парлар бетүгә Хәлилне уратып алабыз да сораулар белән күмәбез: «Хәзер кая барасы?», «Ул кайсы бинада?» Лекцияләр, дәресләр, семинарлар университетның дүрт бинасына таратып куелганнар. Табып, соңга калмыйча кереп тә утырасы бар бит аудиториягә. Хәлил аңлата: «Беренче пар икенче катта 112 дә пр. Гофман лекциясе, икенче пар өченче катта актлар залына пр. Шофманга керәбез, өченче пар дүртенче этажда пр. Госман дәресе куелган. Аңладыгызмы, җәмәгать? Бүген гел бер корпуста гына. Адашып йөрмәһhез тип уйлаем инде». Ашыгып сөйләшкәндә, Хәлил шулай Башкортстанын «искә төшерә» башлый.

Пр. Госманның татар әдәбияты кафедрасы мөдире профессор Хатип ага

булып чыгуын, бернинди дә яһүди Госман түгел, ә Госманов фамилиясенең (каты гъ белән) Госман дип кыскартылган булуын белгәч, беренче дәрес тиешледән күпкә югарырак җанлылыкта узган иде. Хатип ага безнең бу шыбырдауларның сәбәбен аңлый алмыйча, кисәтү дә ясарга мәҗбүр булды ул көнне.

Менә шушы безнең группа мәзәген кыскача гына сөйләп бирергә туры килде Мөхәммәт абыйга. Ул көлемсерәп куйды.

– Студентларның укытучыларга төрле кушаматлар ябыштырып сөйләшүе бар, анысы. Гомумән, татарга хас әйбер дә бит әле ул – кушамат. Ләкин шуны онытмагыз: үзен башкалар хөрмәт итүләрен теләгән кеше беркайчан да кушамат белән сөйләшми. Ну сезнең кушамат бик остроумно (Мөхәммәт абый бу русча сүзне әйтер алдыннан уйланып торды, мөгаен, уңышлы татарча вариантын эзләгәндер). Нәкъ студентларча. Атаклы яһүд профессорларыбыз белән бер яңгыраштагы фамилия тагылуга мин дә каршы булмас идем. Бу вакытта аудиториядә калганнар барыбыз да Мөхәммәт абый тирәсенә җыелышкан идек инде. Соңгы сүзләреннән соң үзенең тыйнак кына көлеп куюына безнең дә шаулашып көлүебез кушылды.

Иртәнге 7 дә 40 минутта башлана торган беренче парга җитешеп, аудиториядә утыру – студенттан зур батырлык сорый торган гамәл. Төнге берләрдә генә тынлыкка чумган тулай торак күзлегеннән караганда – булмастай эш. Ә Мөхәммәт Мәһдиевнең беренче парына без – 446 нчы группа тулы составта диярлек аудиториягә килеп утырабыз. Мөхәммәт абый староста Хәлилдән исемлеккә «явка»ны билгеләп баруын сорап җәфаламый, беркайчан безгә кисәтүләр ясамый, «язып барыгыз» дип искәртми. Чөнки бу нәрсәләргә ихтыяҗ юк. Берничә татар журналист егетнең безнекеләргә ияреп, аның лекциясен тыңларга йөрүен дә ул «күрмәмешкә» салыша. Тик аларга күзе төшкәндә, ирен читләренә кунган «Мәһди елмаюы»н барыбер дә яшереп кала алмый инде.

Лекциядән-лекциягә без өйрәнә торган чорда нәрсәләр булып ятканын аңлый, төшенә башладык. Укытучыбыз, кем турында гына сөйләсә дә, шуның образын күз алдына китереп бастырырлык, җанлы итеп, әлеге чорның язучы һәм шагыйрьләрен бер-бер артлы безнең аң пьедесталына менгерде. Тукайга гашыйк итте, Дәрдемәндне сөйләгәндә еладык, Галимҗан Ибраһимовка таң калдык. Мөхәммәт абый Дәрдемәнд белән Тукайның барлык шигырьләрен әллә яттан белә иде инде – бездә шундый фикер калды. Бауман урамындагы китап кибетенә еш кагыла башладык. Туган көннәргә укытучыбыз сөйләгән әдипләрнең берәр китабына котлау язып бирелгән бүләкне иң бәһале ядкарь итеп кабул итә башладык. Үзгәрдек, үзгәрәбез...

– Мөхәммәт абый бүген язган лекциямдә поляга чыгарган язуларны укыйм әле, – ди бер көнне парда утырганда Нуриябез, укучылар шикелле кул күтәреп.

– Укы, Сафиуллина, – ди Мөхәммәт абый.

– «Моны укымасаң, Г.Ибраһимовны беләм дип йөрмә!», «Кызыклы гына әсәр», «Укырга!», «Бу шигырьне табып ятларга!», «Тап һәм шигырь дәфтәреңә язып куй!» һ.б., һ.б. Барлыгы 14 чыгарылган искәрмә. Һәр лекция саен бу, Мөхәммәт абый. Сез сөйләгәч, алар шундый кызыклы, әһәмиятле булып тоелалар. Каян барысына да вакыт табарбыз икән?

– Сафиуллина, шундый чыгармалар белән лекция язып баруың өчен син инде студентлар телендәге «международкага» лаек. «4»ле, «5»легә күтәрү өчен әз генә тырышасы була.

– Мөхәммәт абый, имтиханда студентлардан: «Фәлән китапның тышлыгы нинди төстә?» – дип соравыгыз дөресме?

– Һич юк. Минем өчен китапның эчтәлеген белүегез мөһим.

Бик сирәк кенә укытучыбызны лекциядән шулай читкәрәк тарткан вакытлар да була. Әйткәнемчә, сирәк кенә.

– Ярый әле бөтен укытучылар Мөхәммәт абый кебек укытмыйлар, юкса, безнең башлар: «Җитте! Монда башка урын юк!» – дип кычкырыр һәм шартлар иде!

Шук-шаян Мәдинәбез әйткән бу сүзләрдә хаклык бар.

Быелгы уку елында Мөхәммәт абыйдан группаның өч студенты курс эшләре алдык: мин, Розалия, Фәрхәт. Остазыбызга бу ошады күк тоелды миңа. Тәкъдим иткән темалары үзе укый торган әдәбият курсыннан. Минем темам «Тукай һәм Никитин». Өйдә Иван Саввич Никитинның шигырьләр җыентыгы бар минем. Мәктәптә укучылар җыйган макулатураны тутырганда кулга керде дә бик күптәнге бу басманы алып калган идем. Логика укытучысы әйткән: «Синең белән булган бер генә хәл-вакыйга да очраклы гына килеп чыкмавына, аларның ниндидер сәбәп йә нәтиҗәдә катнашачагына» чып-чын дәлил. Бу китапны да укырмын әле, хәзергә кызык түгел дип калдырган идем. Шул искә төште. Көн саен уку залына йөрмәскә шәп бит инде. Портфелеңдә, гел кул астында китабың була. Әле бер-беребезгә бүләк итешкән Тукай китаплары һәрберебездә бар хәзер. Шушыларны әйткән идем, җитәкчем тагын елмаеп әйтеп куйды:

– Ну, Мингалимова, руслар әйтмешли, «с тобой не соскучишься». Сүз уңаенда: бу русча әйтемнең чиста татарча мәгънәсен табып кара әле. Никитин китабы синдә булу сәбәпле бу теманы алдың булып чыгамы инде?

– Мин Никитинны каян табар идем әле, Мөхәммәт абый? Китапханәдән озакка бирмиләр. Ач тамакка гел читалкада утырасы килми. Эшләргә җайлы булыр дип уйладым инде.

– Ярар, шулай булсын. Студент халкыннан бөтенләй көтелмәгән нәрсәләр ишетергә мин күнегеп барам бугай инде. Студентлар гына иң өстәге яки беренче күз уңындагы фактны төп аргумент итәргә сәләтлеләр.

– Әле без фәнни эш барышында иң өстәге фактлар белән генә эш итмичә, тирән эзләнүләр, анализлар да ясарбыз дип уйлыйм, Мөхәммәт абый, – дип, Розалия дә сүзгә кушылды. Сизәбез: җавап җитәкчебезгә ошады. Икебезгә дә карап:

– Өченче курс студентлары булуыгыз күренеп тора. Сезгә җавап табуы да кыен хәтта. Ярар, кызлар, сезнең белән курс эшләрен әйбәт итеп эшләп чыгуыбызга ышанам, – дип, әйтерсең безгә канатлар куйды ул көнне.

Канат булгач, очарга да кирәк шул. Очып киталмыйча чәбәләнеп торган, инде әйбәт кенә кузгалдым дигәндә, тизлекне югалтып, уңга-сулга авышкан чаклар, ниһаять, тизлек рычагын табып, өскәрәк күтәрелгәч, баш әйләнеп, чытырдатып күзне йомган вакытлар да булды фәнни эшләребезне башкарганда. Консультацияләргә Розалия белән бергә йөрибез. Аудиториядә бергә утыргач, бер-беребезнең әңгәмәләренә дә кушылып китәбез. Миңа калса, Мөхәммәт абый моны махсус шулай эшли иде. Үз темаңда гына казынып, син мәсьәләгә

бер яктан гына карыйсың, ә читтән караган кешенең бу юнәлештә икенче, кызыклырак фикерләре булып куя. Шулай итеп, миңа Тукай белән Никитин иҗатындагы уртаклыкларны Розалия дә табышып анализларга, ә мин аның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре буенча курс эшенә ияреп, гомумән, һәр чорда татар хатынының «ниләр күрергә дучар ителүен» санарга булыша идем. Ну кызып та китә идек инде без Розалия белән татар хатынының хокуксызлыгын исбатлаганда. Шулай беркөнне Розалиянең темасы буенча сөйләшкәндә, Мөхәммәт абый безне тыңлап, әле беребезгә, әле икенчебезгә карап алганнан соң, сак кына сүз башлап кызыксынып куйды:

– Кызлар, сезнең йөргән егетләрегез бармы соң?

Без бик аптырап, укытучыбызга текәлдек. Икебез дә урысчалы-татарчалы итеп «Причем тут егетләр белән йөрү-йөрмәвебез?» дип уйладык шикелле. Һәрхәлдә, мин шундый уй белән Мөхәммәт абыйга төксе генә итеп карап куйдым.

– Бигрәк ир затларына тәнкыйть күзе белән карыйсыз. XX йөз башы татар хатын-кызларының хокуксызлыгын гаепләп чыккан фәнни-әдәби трактатларны бүгенге көнгә үз тормышыгызга күчермәгез дип әйтүем.

Ниһаять, аңлашылды. Безне ипләп кенә хәзерге көнгә, хәл-әхвәлебезгә кайтаруы икән укытучыбызның. Ирен читләренә кунган «Мәһди елмаюы» шул турыда сөйли.

– Соравыма җавап бирү-бирмәү – сезнең эш. Бер-ике киңәшем бар иде, – ди ул, шул елмаюын сүндермичә.

Шундый кызыклы тема буенча укытучыбызның киңәшен ишетәсе килә бит. Шуңа күрә ихлас булырга туры килә:

– Икебезнең дә егетләребез юк. Мин, мәсәлән, укып бетермичә, бернинди егет-дегетләр белән йөрмәскә дип, үземә сүз бирдем. Университетта уку дәверендә ике егетне кире кактым инде, – дидем мин.

– Синнән булыр... – дип, укытучыбыз карашын Розалиягә күчерде.

– Укып бетереп эшли башлагач та җитешербез әле, Мөхәммәт абый, тормыш мәшәкатьләренә чумарга, – ди Розалия, оялып кына.

– Кызлар, укып бетергәч, сезнең күбегез авыл мәктәпләренә тарала. Үзегезгә тиң булырдай, бер-берегезне аңлардай ярны студент вакытта, биредәге егетләр арасыннан күзләгез. Статистика буенча, студент вакытта ук төзелгән гаиләләр нык, тотрыклы булалар. Сез кайткан авылда бер агроном була, бер ветврач, бер инженер. Аларның да күбесе инде ияле булырга мөмкин. Сез – укымышлы кызлар, аңлыйсыз. Фемeнисткалар булып калмагыз. Хатын-кызның тормышта вазифасы – сөекле ир хатыны булу, ана булу.

Тулай торакка кайтканда, Розалия сорап куйды:

– Синең әти-әниләрең шундый киңәшләр биргәне бармы?

– Әй, Розалия, безнең өйдә мин үземне белә башлаганнан бирле «Татар хатыны ниләр күрми»дәге хәлләр, – дидем мин, авыр сулап.

– Миңа да бирүче юк. Бездә ничектер, андый нәрсәләр турында сөйләшү гадәте дә юк.

– Менә, ичмасам, Мөхәммәт абыйның балалары бәхетледер! Нинди мировой аталары бар бит аларның! – дидем мин, үзем дә сизмичә, бала-чага сыманрак итеп. Әллә кайда, эчтә, күңелем төпкелендә аларга кызыгу тойгысы да туган кебек булды.

## Язмый тора алсагыз, язмагыз

4 нче курс ике шатлык белән башланып китте. Тулы бер этажы безнең бүлеккә генә тәгаенләнгән яңа бинада укый башладык. Татфакта яратып укып йөрсәм дә, химкорпусның иң караңгы бер канатына урнашкан, үзләре тар, үзләре кечкенә аудитория-кафедраларның мескенлеге һич кенә дә туган бүлегебезгә карата горурлану хисләре уята алмый иде миндә. Кафедра бүлмәләреннән чыгу юнәлешенә баручы кеше ерактагы тәрәзәнең аз гына төшкән яктылыгына ориентлаша алса да, кафедрага таба баручыга бу ориентир бөтенләй юк. Ул дөм-караңгыга таба атларга мәҗбүр. Шуңа күрә, каршыга килүче укытучыларыбызга башка-баш бәрелмәс өчен, без, студент халкы, күзне түгел, колакны эшкә җигәргә өйрәнгән идек. Синең каршыдагы дөм-караңгылыктан паркет идәннең каты шыгырдавы ишетелә икән, димәк, каршыңа кемдер килә. Иң яхшысы – борылышта кырыйга чыгып, туктап көтеп тору. Чынлап та, адым-шыгырдау, адым-шыгырдау чиратлашкан атлау, син гөманлаганча, Ибраһим аганыкы булып чыга. Аның адымнарын беркемнеке белән дә бутап булмый инде. Фронтовик, профессор, бер аягы протез Ибраһим ага Нуруллин бу бинаның коменданты яки завхозына гел дә шушы канатта лампочка янмавы турында берәр кайчан, берәр тапкыр гына белдерү ясаганы булдымы икән? Адым-шыгырдау, адым-шыгыдау... ераклаша, үтеп китә. «Исәнмесез, Ибраһим ага!» «Кхм, кхм, исәнмесез». Юктыр, профессор зарланмый, мыгырданмый, ул лампочка юклыгын, аның булырга тиешлеген уйлап та маташмый торгандыр. Аның башында аны профессор иткән уйлардыр. Тукайдыр, реализмдыр...

Бераз тиз, бераз туктаулы адымнар Хатип аганыкына охшаган. Әйе шулай, коридорның нәкъ уртасыннан, абына-сөртенә атлаган кебек, муенын иңбашларына яшеребрәк Хатип Госман үтеп китә. Паркет идән шыгырдавыннан шигырь поэтикасын гына ишетүче профессор, мөхтәрәм укытучыбыз да лампочка юклыкка артык аптырамый торгандыр. Юктыр. Шыгыр-шыгыр, шигырь-шигырь...

Паркетны биек үкчәләр текелдәтә икән, көт тә тор, борылыштан Алмазия Нуриева йә Диләрә Тумашева килеп чыгачак.

Бер көйгә, бер җайга салмак адымнар белән атлаучы Мөхәммәт абый булыр. Менә шушы без җайлашкан ритмга үзгәреш кертеп, барыбызга да яктылык, заманчалык бүләк иткән яңа бинада укый башлавыбыз беренче зур шатлыгыбыз булды.

4 нче курста Мөхәммәт абый татар совет әдәбиятын укытучы төп лектор булачагын белеп, икенче шатландык. Аңардан берничә махсус курслар да тыңлаячакбыз икән. Зур күзәтүләр ясала торган совет әдәбиятын һәм хәзерге татар әдәбияты курсын өйрәнеп, имтихан да бирәчәкбез. Тирән анализларга нигезләнгән, искиткеч күләмле курс. Яңа бинаның яңа аудиториясендә яңа курсны тыңларга әзерләнеп, Мөхәммәт абыйны көтәбез. Гадәттәгечә, минут та соңга калмыйча килеп керде. Аудиторияне, безне күзәтте. Өстәлгә портфелен куйды һәм әз генә кырыйгарак куелган трибуна-кафедра артына барып басты. Ике кулы белән кафедрага таянды.

– Менә мин моны аңлыйм. Менә бу, ичмасам, университетта студентларга лекция уку! – Без җиңелчә генә кул чабып куйдык. – Тик мин трибун-лектор

түгел бит. Бу кафедра бигрәк трибунага охшап тора. Югары пафос белән лекция сөйләүче профессорларга тәгаенләнгән кебек. Ә сезнең аудиториягә урнашып, лекция тыңлау җае лекторның өстәл артына утыруын кабул итми. Трибунага җайлашасы булыр, мөгаен, – дип, мөгаллимебез яңа урынны мактап та, бераз кабул итмәвен белдереп тә алды.

– Ә сез аңа трибуна итеп түгел, ә мөгаллим мөнбәре итеп карагыз, – диде шулчак Галимҗан, үзенең йомшак, ләкин үтемле тавышы белән һәм, гадәттәгечә кызарып, Мөхәммәт абыйга карап тора башлады.

– Мөнбәр, мөнбәр, – дип кабатлады укытучыбыз, – кызыклы сүз. Без аны мәчеттәге мулла өчен тәгаенләнгән урын мәгънәсендә генә кабул итәбез. Ә аның мәгънәсе киңрәк, тирәнрәк бит. Башлап, бу сүз халыкка мөһим сүзләр, вәгазьләр сөйләүче өчен махсус биегрәк итеп ясалган урынны аңлаткан. Киләчәктә татар теленә шул мәгънәдә кайтыр әле ул. Әйдәгез, без кайтара башлыйк. Бу аудиториядә минем урынның мөнбәр дип аталуына мин риза.

Нәҗип абый да үзенең төпле фикерен җиткерергә ашыкты:

– Димәк, үз югарылыгы булган мөгаллим Мөхәммәт Мәһдиев мөнбәргә лаек. – Бүген Нәҗипнең фәлсәфи гомумиләштерүе имтихан бирәсе укытучысына ялагайлану кебегрәк килеп чыкты. Хәйләкәр елмаеп, бу сүзләрне әйткәндә, лекторыбыз портфеленнән папкасын алып, әле генә яңа исем алган кафедра-мөнбәр артына килеп басты.

Курсның зурлыгы белән безне куркыту лектор Мәһдиевнең уенда да юк. Беренче лекциясендә үк әллә ничә әдәби әсәрне теге яки бу яктан искә алып үтте, чагыштырулар ясады, гомумиләштерде, үзенчәлекләрен билгеләде. Узган елдагы кебек укырга тиешле әсәрләрнең күплегеннән курку түгел, ә лекциядә искә алынган әсәрләрне бүген үк укыйсы килү теләге безне уку залларына, китапханәләргә юнәлтте. Шул көнне үк.

Хор репетициясенә вакыт бар әле. Читалкага кереп, бүген Мөхәммәт абый кызыктырып калдырган Распутинның «Живи и помни» китабын укый башларга булдым. Аһ, башламаган булсам шул... «Ябылырга 10 минут вакыт калды, китапларны тапшыра башлагыз», – дигәнгә аңга килсәм дә, хорга кереп торырга вакыт та калмаган икән. Җырчыларны ишек төбендә бергәләп кайту өчен генә көтеп алдым.

Башымда һаман китап вакыйгалары. Настёнаның нинди тансык күптән көтелгән бәхеткә – балага узуга ирешеп тә, шул бәхетенә гомере белән түләве – карынындагы сабые белән үзен харап итүе йөрәкне чеметтерә, күкрәккә кату төшерә. Мөхәммәт абый ничек диде әле? «Сугышның батырлыклардан, Ватан өчен күпләрнең үлеменнән генә тормавын, сугышның бары синеке генә булган бәхетне дә җимерә алганын күрсәткән әсәр бу» дидеме? Әни сөйләгәннәр искә төште: безнең авылда шул сугыш аркасында ничәмә-ничә әнинең яшьтәш кызлары кияүгә чыга алмый калганнар, бала үстерү бәхетенә тиенмәгәннәр, ир назын тоеп яшәмәгәннәр... Күз яшьләренә төелеп, бүлмәгә кайтып кердем. Повестьның эчтәлеген бүлмәдәшләргә сөйләдем. Яңа бүлмәдәшем Нәзирә шундук тәкъдим кертте.

– Әйдәгез, бүлешеп укыйбыз да, менә шушылай тәэсирле итеп, калганнарга сөйлибез. Мәһдиев анализлаган бөтен әсәрне уку өчен ел да җитмәс! Ә укыйсы килә бит!

Имтиханнар алдыннан бөтен группа белән җыелышып, укыганнар

укымаганнарга эчтәлек сөйли башладык. Ничек кенә итсәк тә, барыбер Мөхәммәт абый безгә тәкъдим иткән әдәбиятны укып бетерергә мөмкин түгел иде шул... Остазыбызның гаять күп укуы, искитмәле хәтере, әдәбиятны тормыш белән бәйләү осталыгы безне ул елны сокландырганнан-сокландыра барды. Бервакыт остазыбыз лекция темасыннан бераз читләшеп, мондый фикерләр әйтте:

– Университетның татар бүлегендә укыган белгечләр, гадәттә, бик киң профильле булалар һәм төрле өлкәләрдә эшлиләр. Сезнең төркем бераз искәрмә булырга охшаган. Хәер, анысын тормыш күрсәтер. Сезнең яртыгыз иҗат кешеләре, ә яртыгыз укытучы мөгаллимнәр булыр, мөгаен. Хәзер үк каләм сынаучыларыгыз байтак. Кызганыч, каләм тибрәтүче татар укучысына иҗат юнәлешендә милли юнәлешле әдәбият институты юк шул бездә. Шуңа күрә, татар язучысы нинди булырга тиеш, гомумән, язучы нинди булырга тиешлеге мәсьәләсе яктыртылмый. Ә ул бик кирәк. Иҗат кешеләренә, язучы, журналист, шагыйрьләргә бик кирәк. Сезгә бу турыда башка предмет укытучылары җиткермәячәк. Шуңа күрә мин лекцияләремдә «Кем ул язучы? Ул нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Ничек язарга, нәрсә язарга тиеш?» кебек сорауларга да әлеге курс кысаларында кагылып үтәрмен. Ә үзләренең урынын киләчәктә мәктәптә, уку йортларында күрүчеләргә шуны әйтәм: безне бит әле методика буенча курс көтә. Укытучы нинди булырга тиешлеген шунда өйрәнербез.

Мөхәммәт Мәһдиев булсын да, темасыннан читләшеп, ниндидер ят фикерләр әйтсен, ди. Булмаганны! Аның һәр фикере лекциясенең темасын киңәйтүче йә ныгытучы бер факт була да куя. Монда да нәкъ шулай булып чыкты.

Совет әдәбияты курсы булгач, татар әдәбиятын союздагы башка халыкларныкы, бигрәк тә рус әдәбияты белән чагыштырма планда бирә Мөхәммәт абый. Аның рус әдәбиятын тирән һәм яхшы белүенә исебез китә. Рус язучыларының басылып чыккан әсәрләренә күзәтү ясагач, татар әдәбиятында охшаш үрнәкләр күренеп китә дә, Фәез шунда ук соравын ыргыта:

– Бу плагиатлык түгелме соң, Мөхәммәт абый?

– Юк, плагиатлык түгел. Татар авылы балаларының шәһәрләшүе, шуның нәтиҗәсендә тел югалу проблемасын Ә.Еники «Әйтелмәгән васыят»ендә Солоухин, Проскурин, Астафьевларга караганда да алданрак күрә белде. Тик...

Группабызның булачак язучылары, кызып-кызып, шул «тик»не ачыклыйлар.

Мөхәммәт Мәһдиев Ак әби язмышын сурәтләгән әсәрнең поэтикасын сөйли. Без күреп, тотып алмаган әллә никадәр проблемаларны күрсәтә...

Нигәдер остазыбызның паузасы озынгарак сузылды түгелме? Лекция язудан бүленеп, башларны күтәреп карыйбыз. Мөхәммәт абый, каршысына җәеп салган кәгазьләренә текәлеп, тын утыра. Ул инде мөнбәр артыннан өстәл артына күчкән икән. Ниһаять, күзләрен кәгазьләрдән алмыйча гына (бик сирәк була торган хәл), безгә карамыйча гына сөйләвен дәвам итте:

– Бер көн килеп, мондый вакыйгалар бик күпләрнең тормышына да килеп җитә. Әниегез авыр хәлдә дип хәбәр аласыз. Кайтып керәсез, өстәлгә көчтәнәчләр таратып ташлыйсыз. Күрәсез, әниегезнең хәле начар. Ә сез

шаяртасыз: «Бирешмибез әле, әни, ух әле без синең белән!..» Сезнең купшы оптимизмыгыз әниегезнең ирен читләренә көчәнеп елмаерга тырышу булып күчә. Менә шул чакта үзегезне дә, аны да ялган сүзләр белән, буш өметләр белән алдамагыз. Янына утырып, кулларыннан алыгыз, күзләренә карагыз. Сөйләшә алса, аның соңгы сүзен тыңлагыз, сөйләшә алмаса, үзегез сөйләшегез. Фатихасын, бәхиллеген алып калырга ашыгыгыз.

Мөхәммәт абыйның тавышы калтыранып киткәне сизелде. Каршыбызда үз әнисен дөньяда иң изге зат күреп яшәүче, аны олылаучы, шул олылауны, ихластан бездә дә тәрбияләргә омтылучы укытучыбыз утырганын без бик яхшы аңладык бу минутта.

Әдәби процесска, әсәрләргә анализ биргәннән соң, укытучыбыз авторның уңышларын күрсәтә башлый. Мондый сөйләшүләрдә китапны укыганнар гына катнаша ала шул инде. «Ник әсәр йотылып, икенче төрле әйткәндә, бер тында укыла?» – дип сорау куя Мөхәммәт абый, бөтенебезгә карап.

– Чөнки теле җиңел, ясалма түгел, – ди Фәез.

– Нишләп әсәр ышандыра, Сибгат Хәким әйтмешли, укучыны «эләктерә»?

– Автор теманы белеп язганга дип уйлыйм мин, – ди Галимҗан, тагын кызарынып һәм кыяр-кыймас.

– Автор әсәрдә детальләштерү, чорны сурәтләү, геройларның сөйләмен бирү белән артык мавыкмыймы?

– Юк дип уйлыйм, – дип, Флёра дебатларга кушылып китә. Әһә, димәк төн йокламый бу китапны ул укып чыккан. – Ни өчен дигәндә, алар барысы да әсәргә фон бирәләр. Ә фонсыз әсәр – җансыз, кызыксыз. Язучы моны һәрчак истә тотарга тиеш.

– Җиңел дә инде сезнең төркемдә дәрес алып баруы, нишләп икән? – дигән сүзләрне Мөхәммәт абыйның чираттагы соравы итеп лекция дәфтәрләребезгә язып утыруыбыздан көлешә башлыйбыз. Туктавыбызны көтеп ала да укытучыбыз дәвам итә:

– Өстәп, шуны да әйтәм: язучының биографиясе булырга тиеш. Булмаганны, бармактан суырып язып укучыны ышандырып булмый. «Ә нәрсә турында язарга?» – дип сорыйлар. Төннәрен сиңа йокы бирмәгән уйларың, сине туктаусыз эзәрлекләгән сюжетларың турында. Күршеңне, туганыңны борчыган нәрсәләр турында. Темаң да бар, язасы әйберең турында да яхшы беләсең, инде язып китәм дип уйлыйсың. Тик илһам, дәртсенү, язмыйча булдыра алмау барлыгыңны бөтереп алмаган икән, бер җөмләң дә син теләгәнчә килеп чыкмаячак. Булган хәлләрне Хөббениса түти дә бик оста итеп сөйләп бирә ала. Андый осталар һәр авылда, һәр коллективта бар. Ә язучы хәлне сурәтләп, белешмә бирүче генә түгел, аның бурычы гаять зур: ул сурәтләгән хәлләр укучыны уйландырырга, фикер тудырырга, тәрбияләргә тиеш. Язучы әле ул алдагыны сизәргә дә тиеш. Бүгенге хәлләрне генә язып баручы – әле ул зур язучы түгел.

Мөхәммәт Мәһдиев лекцияләрдә әдәби хәзинә белән таныштырып кына калмыйча, ул хәзинәне тудыручы олуг затларга – язучыларга хас сыйфатларны да безгә әнә шулай гел бәян итә килде.

«Язмый тора алсагыз, язмагыз, чөнки язучы ул күп нәрсәдән мәхрүм:

ул язны, җәйне күрми кала, концертка барырга, кызыклы тапшырулар карарга аның вакыты юк. Гаилә өчен дә аның вакыты бик аз. Аның күп нәрсәгә вакыты юк. Әмма дә ләкин табигатьтән язучылык таланты бирелгәннәр, язмый тора алмаучылар, бернәрсәгә карамыйча, барыбер әдәбиятка, язучылыкка киләләр. Андыйларга әдәбият үз ишекләрен ача, чөнки анда нәкъ шундыйлар гына кирәк тә». Соңгы лекцияләренең берсендә мөгаллимебез үз мөнбәреннән безгә шушы сүзләрен юллады. Сиземләве көчле булганга, ул группабызда укыган Нәҗип Исмәгыйлевнең – киләчәктә текстолог-язучы, шәмаилче, Тукай бүләге лауреаты;

Фәез Зөлкарнәйнең – шагыйрь, журналист, әдәбиятчы;

Галимҗан Гыйльмановның – әдәбият галиме, язучы;

Флёра Низамованың – журналист, шагыйрә;

Фәния Сәетгәрәеваның – шагыйрә;

Нәзирә Рахманкулованың – журналист;

Нурания Мингалимованың язучы булып китәчәкләрен алдан ук тойгандыр. Әйе тойгандыр.

## Укытучы булырга өйрәнәбез

– Укытучы булырга өйрәтеп булмыйдыр дип беләм. Аңа бары өйрәнеп кенә буладыр. Гомер буе, ел саен, дәрес саен. – Бу сүзләрне каршыбызда басып торучы Мөхәммәт абый сөйли. – Менә сезнең шул өйрәнү педпрактикагызга мин җитәкчелек итәчәкмен. Мәҗит Гафури урамындагы 35 нче номерлы татар-рус-инглиз мәктәбендә 5-10 классларда татар теле һәм әдәбияты дәресләре укытып, икенче – йомгаклау педогогик практикагызны узачаксыз...

Без, аудиториядә утыручылар, бер-беребезгә карашабыз. Иңбашларны җыергалыйбыз, күз карашларыбызда – гаҗәпләнү чалымнары. Ник дигәндә, Мөхәммәт абыйны мондый таләпчән кырыс кысада күрергә ияләнмәгәнбез. Җитмәсә, соңгы бишенче курска килгәч сагынышкан курсташлар эйфориясеннән чыгып та җитмәдек әле. Укытучыбыз белән иркенләп сөйләшәсебез, фикерләшәсебез килә иде. Теләкләребезне аның катгый җөмләләре кисә:

– Иртәгә нәкъ сигездә мәктәпнең икенче катындагы татар теле һәм әдәбияты кабинетында очрашабыз.

...Киемебезнең һәр бөгелеше, җөе әллә ничә мәртәбә сыпырылды. Чәчләр күп тапкыр рәтләнде. Чират торып та, бер-беребезне этеп-төртеп тә, көзге каршында бөтерелдек. Инде ике сәгать әзерләнгәннән соң, ахыргы эш итеп, бер-беребезгә күз салыштык. Фәнүзә өйрәткәнчә, үз-үзеңә ышаныч булдыру терапиясе үткәреп алабыз. Дүрт караватурталарындагы бушлык – «подиумнан» Гөлсинә туташ уза:

– Минем өстемдәге киемем килешле, уңайлы, балаларны үзенә җәлеп итә торган.

Буй-сынының модельләрнекеннән бер дә ким булмаганын болай да яхшы белгән Фәнүзәбез, «подиумга» чыккач, төс-кыяфәтенә акцент ясый:

– Йөзләргә җитдилек өчен кершән ягылган, бераз кырыслыкка манып, иреннәргә сизелер-сизелмәс кенә иннек тидерелгән, сөрмә белән кашкүзләргә мөлаемлылык һәм хәерхаһ нурлары кундырылган әлеге макияж

«укытучы образы» дип атала, – дип сөйләп уза ул караватбелән карават арасын.

Табигатьнең үзеннән бүләк ителгән бөдрәләренә әле уңнан, әле сулдан бармакларын тидергәләп, «подиумнан» сүзсез генә Розалия үтеп китә.

Туйдыра башлаган бу матавыкны төгәллисе, бу дулкынлануларга чик тә куясы килеп шаяртып аласы иттем:

– Ыспайлыкка, модныйлыкка
Мәһдиевтән өйрәнәбез.
Аның шәкертләре бит без,
Бизәнешеп, төзәнешеп,
Педпрактикага юнәләбез.

– Кызлар, соңга калабыз! – дип кычкырдым такмактан соң.

Чыгып йөгердек. Чынлап та, берничә минутка соңга калып, класска килеп кердек. Укытучы өстәле артында Мөхәммәт абый һәм ике укытучы апа утырганнар. Мөхәммәт абыйның салкын гына кисәтүле караш ташлавы бер дә безнең файдага түгеллеге сизелеп, йөрәк «жу!» итеп куйды. Практикантларны укытучыларга беркетү, программа буенча дәресләр бирүне билгеләү кебек оештыру моментлары булып алды. Ике укытучы апа бу эшләрнең барысын да шулкадәр җай белән алып баралар. Үзләре гел Мөхәммәт абыйга караш ташлыйлар. Нәрсә дияр, килешерме? Мөхәммәт абый: «Яхшы, шулай эшләгез, әйбәт булыр, монысын үзегез беләсез», – дигән сүзләр генә кыстыргалый. Без 15 практикантны бер айга телдән дә, әдәбияттан да дәресләр тыңлауга, дәресләр бирүгә, анализ сәгатьләрендә катнашуга бүлгәләгән расписаниене исебез китеп тыңлап утырдык. Бу расписаниедә бер минут та буш вакыт калмаган иде.

Мөхәммәт абый сүзен укытучы апаларның бу хезмәтенә бәя бирүдән башлады:

– Мондый гадәттән тыш очракларда расписаниене үзгәртеп төзүнең ни икәнен мин бик яхшы аңлыйм. Тулы бер айга әлеге мәктәп безнең хакка үзенең эш режимын үзгәртергә мәҗбүр. Димәк, без дә шушы расписаниене бозмыйча эш алып барырга тиеш булабыз. – Ул өстәл артында утырган килеш кенә безнең барыбызга да күз йөртеп чыкты. – Беренче сүзем – кызларга. Иртәгә сез укытучыларның дәресләренә кереп утыра башлыйсыз. Әгәр шушылай киенеп, бизәнеп киләсез икән, укытучы апаларыгызның дәресләре провалга очраячак. Укучылар борылып, сезгә карап утырачаклар. Үзегез дәрес бирә башлагач, бу бигрәк тә шулай булачак. Психология фәне башта аудитория 5 минут яңа кешене өйрәнә дип аңлата. Димәк, 45 минутның 5 минуты инде юк. Әле шуның өстенә бүгенге кебек кайберәүләр соңга калып та килеп керсә, дәрес бүленеп тагын 2-3 минут югала дигән сүз. (Шулай гына үтеп киттеме дисәк, юк шул!) Бүген укытучы апаларыгыздан мәктәпкә ничек киенеп килү буенча консультация аласыз. Онытмагыз: 10 класста малайлар юк, анда физиологик яктан өлгергән егетләр утыра. Аның күзе бар, ис тоярга борыны бар һәм башка әгъзалары бар. Егетләр, бу сезгә дә кагыла. Монда безнең 5 егет. Шуның өчесе бүген иртән ашамыйча, бишесе дә йокыларын туйдырмыйча килгәннәр. Бөгәрләнгән костюм кигән галстуксыз дәрес бирүче практикант егетне

укучылар, бигрәк тә югары класс кызлары укытучы итеп кабул итәрме икән? Кыңгырау шалтырагач, укытучы бары тик: «Исәнмесез, укучылар, дәресне башлыйбыз», – дип кенә әйтә ала. Сез бирედә 7.30 га килеп җитәргә тиеш. Аның өчен ничәдә йокыдан торасын миңа әйтергә түгелдер.

Студентның тулай торак бүлмәсе – көне буена алган информацияне фильтрлау урыны инде ул. Борыннарыбызны салындырып кайтып кергәч, иркенләп педпрактиканың беренче көнен шул фильтр аша үткәрдек. Кайсыбыз педпрактика расписаниесенең университетныкына караганда да тыгызрак булуыннан зарланды, кайсыбыз беренче көнне үк кәефебезне җибәргән җитәкчебезне хаклы санамавын дәлилләде.

– Бәй, бүген кисәтмәсә, без Мөхәммәт абый әйткән ул хаталарны алга таба да ясаячак идек бит. – Розалиянең бу сүзләренә каршы төшүче булмады. Көндәлек бу фильтрларда без әкренләп җитәкчебезнең безгә карата хаклы таләпчәнлеген аңладык. Гөлсинә соңгы араларда бик уйчан, җитди йөри иде. Тикмәгә түгел, эчтән генә үзе дә анализлап йөргән икән. Беркөнне шулар белән уртаклашты:

– И кызлар, бездәге бала-чагалык инде, әйеме? Беренче көнне үк безне нишләп мактарга тиешләр дә, нишләп әле без гел хаклы булырга тиеш? Аңлаган кешегә аңларлык никадәр төпле фикерләр, киңәшләр әйтәләр укытучылар. Мөхәммәт абый ничек тәфсилле анализ ясый дәресләребезгә. Менә мин аның әйткән киңәшләрен аерым язып куйдым әле. Тыңлыйсызмы? Сезгә дә укып күрсәтәм.

– Тыңламыйммы соң алтын фикерләрне, әле язып куярга дәфтәр ручка да кирәк булыр, – дип, телемә салына башлаган идем, кызлар тиз туктаттылар. – Кызык бит, тыңлыйк әле.

– 1) Киемең «безупречный» булсын. 2) Укучылар каршында һәрвакыт чиста-пөхтә бул. 3) Артык бизәнмә. 4) Дәресеңне биш бармагың кебек бел. 5) Дәрес планыңны язмыйча, мәктәпкә килмә. 6) Син фокусник, укучылар тамашачы түгел, онытма! 7) Теләсә нинди ситуациядән алып чыгарлык бер «тылсымлы таягың» булсын.

Без дәррәү Гөлсинәне бүлдердек:

– Нәрсә инде ул синең тылсымлы таяк дигәнең?

– Бу сорауны мин сездән көткән идем. – Педпрактика бездән укытучы калыплый башлаганы сизелә, Гөлсинә чын укытучы кебек җитди итеп дәвам итте: – Флёра, Нурания кебек җырлый белсәм, бу таяк минем җыр булыр иде. «Татар халык җырлары» темасын үтәбез, ди. Әллә никадәр язмалар, магнитофон күтәреп кермисең, челтерәп торган тавышың белән «Тәфтиләү»не сузып җибәрәсең. Бөтен бала – синең «әсир». Мин шигырьләр яратам бит, үзем дә язгалыйм. Мөхәммәт абый безгә Тукай, Дәрдемәнд шигъриятен ачты. Мин үземнең шигъри күңел картотекасын булдырырга уйлыйм. Шуларның шигырьләрен ятлаячакмын һәм, җаена туры китереп, укучыларга шул «тылсымлы таягымны» әкрен генә селтәп җибәрермен.

– Браво! Афәрин! – дип, калган өчебезнең кул чабуы бер дә чытлыклану түгел иде.

Шул көннән соң, педпрактикада остазларыбызның киңәшләр исемлеген Гөлсинә кебек без дә дәвам иттек. Ай ахырына хәйра-а-ан озын исемлек

килеп чыкты. Алга китеп, бер-ике сүз әйтим әле, хөрмәтле укучым. Укытучы булып эшли башлагач, бик кыскартылып язып куелган бу фикерләргә мин еш мөрәҗәгать итә идем. «Тукай «Шүрәле»сен китаптагыча явыз көч дип аңлатма, ул – халык фантазиясе тудырган мәхлук!», «Әдәбият бөтен кешегә дә рухи азык бирә!», «Дәресеңдә укучы үтә торган әдәби әсәрнең сәнгать көчен тойсын!», «Гап-гади итеп, әсәр укуга гына багышланган дәрес уздырудан курыкма!», «Чама хисең булсын!», «Баланы фәнне яратырга мәҗбүр итеп булмый, ләкин яхшы укытып, үз фәнеңне яраттырып була. Яхшы укыту – синең кулда!», «Әдәбиятны язучы биографиясе буенча түгел, аның иң яхшы әсәрләре буенча укыт!», «Тел укытканда, Ф.Сафиуллина, К.Чуковский, Л.Успенский, Л.Григорян китапларына мөрәҗәгать итегез!» дип, һәрберсе азагына өндәү билгеләре куелган җөмләләрне укыганда, колагыма остазымның һәр сүзне аерып чыгарулы интонация белән сөйләгән йомшак тавышы ишетелгәндәй була иде.

Елга ике тапкыр имтиханнар бирү, семинарлар, чит телдән тәрҗемә итәсе дилбегә буе текстлар, реферат һәм курс эшләре дә урлый алмаган йокыбызны шушы педпрактика урлау гына түгел, тала-а-ап алды! Иртәгә дәрес бирәсе дигән төнне йоклый алмый изаландык. Төненә әллә ничә уянып, сәгатькәябыштык, йоклап, дәрескә соңга калганмын икән дип, тагын чәчрәп торып утырдык. Фаяз сөйли: «Җәмәгать, мин Тукай иҗаты буенча дәрескә әзерләнгәндә, «Туган тел»не ялгышмасам ярар иде дип курка башладым әле». Филүснең борчылуы башка: «Төш күрдем: дәрес биргәндә, татар телендә ничә сузык, ничә тартык барын оныттым! Дәреснең темасы – «Татар алфавиты». (Филүс – тел өлкәсендә иң көчле егетебез. Аңа укытучы-филологлар зур өметләр баглыйлар...) Белгәннәребезне оныткан кебек булдык. Бер дәрескә әзерләнү өчен дүрт ел буе алган гыйлемнәребезне актардык. Таблицалар ясадык, тикшерәсе сүз, җөмлә, текстларны ватман кәгазенә яздык, өстәмә карточка, дидактик биремнәр әзерләп мәш килдек. Дәресләрне техник җиһазлар кулланып үткәрергә тырыштык, шигырьләр ятладык.

Дәресләр уза торды. Мөхәммәт абый, укытучы апалар аларны анализлый бардылар. Беренче атна дәресләрен биргәч, остазларыбыз аларны тикшереп шәрехләп чыккач, Мөхәммәт абый безгә сорау бирде:

– Сезнең фокусник чыгышын күргәнегез бармы?

– Бар инде, – диешәбез.

– Сезнең дәресләрегез шәп фокусник чыгышын хәтерләтә. Костюм, тышкы кыяфәтләр – менә дигән, хәрәкәтләр, тотыш – искитмәле, эчке яшерен кесәләр шаккатыргыч атрибутлар белән тулы – әле күгәрчен оча, әле аллы-гөлле яулыклар сузыла. Әле менә бу да бар, әле монысын күрмәдегез дигәндәй, фокус арты фокус. Тамашачының күзе ялтырый, ачылган авызын ябарга онытып, фокусчыны күзәтә, дөньясын оныта. Тик ул тамашачы гына шул. Никадәр кызыгып карап торса да, бу шаккаткыч күренешләрне эшләп күрсәтә дә, өйрәнә дә алмый, аңламый да кала.

Алга таба җитәкчебез безнең үзебездән үк хатабызны таптырды: без укучыларны тыңлап, карап утыручы итеп кенә күрәбез икән. Икенче атнада үткәреләсе дәресләргә «Мин боларны укучыларга да өйрәтәм» дигән максат белән әзерләнергә кушты.

– Мәсәлән, Мингалимова дәресендә мин аның 4 алым, 6 эш төре, техник җиһаз, схема-плакат, күргәзмә әсбаплар куллануын санадым. Бу күп, бик күп. Сез болай әзерләнсәгез, укытучы апаларыгызны ярты елга күргәзмә материаллар белән тәэмин итеп калдырачаксыз, – дип, Мөхәммәт абый укытучыларга карады. Алар күңелле генә көлешеп куйдылар. Әйтәм аны, безнең дәрес оппонентлары булган укытучы апалардан «Күргәзмә материал ясыйкмы?» – дип сорасак, «Ясагыз, яса!» – дип кенә торалар. Имәндә икән чикләвек диештек без бүлмә фильтрында.

Педпрактика тәмамланып килә. Югары класс укучылары һәм практикантлар катнашында «Туган тел кичәсе» үткәрергә булдык. Теләгебезне Мөхәммәт абыйга әйткәч:

– Бу мәктәптә талантлы балалар, музыка-сәнгать мәктәбенә йөрүчеләр күп. Оятка калырлык булмасагыз гына, алыныгыз. Сентябрьдә бәрәңге алган колхозда концерт бирү кебек кенә булмасын, – диде.

Нуриябез шунда ук җавапны чатнатты:

– Кичәбезнең 10 минуты язучы, галим һәм мөгаллим Мөхәммәт Мәһдиев карамагына тапшырылса, ни әйтерсез, Мөхәммәт абый? Калган 1 сәгать тә 20 минутта – безнең һәм укучыларның чыгышы.

Остазыбызның туксанышар минут аудиторияне эләктереп тотканын яхшы беләбез. Кичәдә без укучыларга тере, бүгенге көннең иң популяр татар язучысын сәхнәгә чыгарачакбыз. Мөхәммәт абыйның укучылар каршында чыгыш ясарга яратуын да чамалыйбыз.

– Минем йомшак якны да беләсез, ә?! – Җитәкченең бу сүзләре безгә ризалык билгесе иде инде. «Ур-ра!»

Мәктәпнең Актлар залында дулкынландыргыч бер җанлылык. Укытучыларның каршылыгын җиңеп, «кичә» сүзенә тугрылык саклап, бәйрәмебез кичке якта уза. Бу – чынлап та, бәйрәм төсмерен алган кичә. Мәктәп укытучылары күбесе гаилә парлары белән килгәннәр. Сәхнә артында музыкант укучыларның үз уен коралларында кыска гына музыкаль өзекләр уйнап куюлары шөһрәтле театрлардагы тамаша башланыр алдыннан була торган дулкынландыргыч мизгелләрне хәтерләтә. Мөхәммәт абый залда. Укытучылар, завучлар, директор белән әңгәмә коруда.

Һәм, ниһаять... Баян (укучылар уйный), курай (Фаяз сыздыра), 2 скрипка (укучылар башкара) составында инструменталь ансамбль «Әллүки»не яңгырата башлады. Шушы моң астында Нәҗип абый Тукай шигырен укый. Моң, миллилек, әллә нинди тирән аһәңнәрнең тәэсир көчен бәяләргә тырышып, мин залны күзәтәм. Дулкынлану бармы залда? Көй һәм сүзләрнең искитмәле гармониясе тудырган милли моң залдагыларны тәэсирләндерәме? Татарстан башкаласындагы иң элиталы саналган мәктәптә инглиз, рус телендә укучы татар балаларына бу моңнар аша буыннар авазы ишетеләме? Башлар күтәрелеп, барысы да моң агылган тарафка багамы? Аллага шөкер! Бар, ишетә, бага икән!

Аннары нәкъ 10 минутка залны Мөхәммәт Мәһдиев «эләктереп» алды. Аны тыңлагач, залдагылар, ярый әле, без татар мәктәбендә укыйбыз, ярый әле, без татар милләтеннән дигән горурлану хисләре кичермичә калмаганнардыр. Флёра белән Нәҗип абый кичәне кызыклы итеп алып бардылар. «Студент һәм профессор имтиханда» дигән мәзәкләр көлтәсе, «Укучы һәм укытучы

дәрестә» дип, Флёраның оста каләме белән практикада булган кызыклы хәлләрне кертеп сәхнәләштерелгән иде. Зал кайбер вакытларда эчен тотып көлде. Безнең шагыйрь егетләребез Галимҗан белән Фәез кайсыбер көннәрдә серле генә: «Безнең эшебез бар әле», – дип, мәктәптә тоткарланалар иде. Менә бүген шул тоткарлануларның сере ачылды. «Мәктәптә безнең педпрактика дәверендә эшләп алган «Шигърият» түгәрәгенең чыгышын тәкъдим итәбез!» – дип белдерү ясагач, сәхнәгә биш-алты югары класс укучысы һәм ике яктан Галимҗан белән Фәез чыгып бастылар. Кырыйдарак төрле уен кораллары белән берничә укучы егет тә урын алган. Мәхәббәт темасына багышланган татарча шигъри миниатюралар классик музыка яңгыравы астында залны бер тында бөтереп алды. Мактана бу димәгез, Ниязның, Нуриянең очынып биюләре, Флёраның челтерәп торган сопраносы, үзебезнең хор репертуарыннан ике тавышка ансамбль белән җыр башкаруыбыз – барысы да бармакларны үбеп куеп, тамашачыга өрфия юллауга тиң иде. Алгы рәттә кырыйдарак утырган педпрактика җитәкчебезнең дә ирен читләреннән «Мәһди елмаюы» китеп тормады бугай бу кичәдә.

Берничә көннән без мәктәпкә педпрактикага йомгак ясау өчен җыйналыштык. «Яхшы», «Бик яхшы» билгеләренә сөенешеп, тормышка да эшкә дә юллама алган кебек Мөхәммәт абыйны тыңлыйбыз:

– Мин – тормышка бик рациональ карый торган үтә дә тәнкыйди карашлы кеше. Теге яки бу күренешне критикага алырга һәрвакыт әзер торам. Тик сез мине чынлап сокландырдыгыз, чынлап ышандырдыгыз, киләчәктә сезгә зур өметләр бagларга җирлек бирдегез. Нәҗип, Галимҗан, Фәез, Флёраларның татар әдәбияты сафларына бер дулкын булып килеп керәчәкләрен мин төркемегезне укыту дәверемдә үк ышанып күзәттем. Шуның өстенә, әле аларда менә дигән мөдәррислек таланты да бар икән. Монысын практика күрсәтте. Булсын, тормышта ул – бик кирәкле сыйфат.

Филүс, Фәнүзә, Нурия, Гөлсинәләрне мин тел өлкәсендә тикшеренүче укытучы галим-галимәләр итеп күзаллыйм. Бик күп уку йортларына, мәктәпләргә сезнең кебек укытучылар кирәк. – Мөхәммәт абый тукталып калды.

– Арагызда бүген мәктәпкә барып, завуч булып эшли башларлык студентлар да бар. Исемнәрен атамыйм инде, йә мәктәпкә баргач, әлеге вакансияне дәгъваларлар. Борыннарын күтәрерләр. Кемнәр икәнен алар үзләре беләләр, – дип, ирен читләренә кунган елмаюлы шушы сүзләре белән безне шаулатып көлдереп җибәрде остазыбыз. Безнең тынычланганны көтеп алды да сүзен дәвам итте:

– Минем сезгә тагын бер нәрсәне искәртәсем килә. Аны сезгә беркем дә әйтмәячәк, беркем дә сезне моңа мәҗбүриләмәячәк. Аны үтәмәсәгез дә, сезне беркемнең дә гаепләргә хакы булмаячак. Бу сезнең бары үзегезнең намус эше булып кына калачак. Башы булган эшнең һәрвакыт ахыры да була. Матур гына эшләп йөргәндә, бер көн килеп, сезне лаеклы ял дигән нәрсә көткәне билгеле була. Бик матур исемле булса да, ял дигәне кызыктырса да, аны бер генә шул яшькә җиткән кеше дә яратмый. Яратмый гына түгел, аннан качарга тырыша, үзен тапмасын дип, тышкы кыяфәтен үзгәртә, яшьләрчә киенә башлый. Үзенең әле элеккечә булдыра алганын күпләр алдында исбатларга тырыша. Тик вакыт галиҗәнапларына каршы

тора алу адәм баласының көченнән килми. Вакытында эш пьедесталыннан матур итеп китә дә белегез. Матур итеп китә белү дә зур батырлык сорый.

Күтәренке рухта, алдагы тормышыбызда бары уңышлар гына теләп тәмамлау сүзләренә күнеккән без бу сүзләрдән соң аптырашып калдык. Әлеге дә баягы – староста таягы дигәндәй, Нуриябезнең шаянлыгы безне пенсия алды яшеннән бүгенге көнгә кайтарды:

– Үләм, Мөхәммәт абый, бик тиз була түгелме соң бу? Укыта башладык та инде пенсиягәме?

– Сафиуллина, һәрвакыттагыча сорауны мөгезеннән алып бирә. Бу киңәш укытучыларга кагыла. Бөтенегез дә укытучы-мөгаллим булып эшләмәскә мөмкин. Мин мәгариф һәм фән өлкәсендә күпьеллык тәҗрибәмә һәм күзәтүләргә таянып ясаган нәтиҗә ул. Ялга хәтле тормышыгыз, эшегез күпкырлы булса, җәмгыять сезгә, чынлап та, лаеклы ял бирә алса, сез бик рәхәтләнеп, эш дәверендә җитешмәгән юнәлешләрне сайлап, тагын да кызыклырак итеп яшәп китәчәксез. Җәмгыятьтә яшьләргә юл, яшь көчләргә мәйдан, яңа идеяләргә мөмкинлекләр бирелергә тиеш. Шулай булмаган җәмгыятьтә деградация башлану куркынычы бар. Белеп торуыгыз кирәк. Чөнки сезне диплом алгач, озын хезмәт юлы, күп әйберләрне оныттыра, үзгәртә торган тормыш көтеп тора. Ә салынып куелган мәгълүмат кирәк чакта искә төшә ул.

Мөхәммәт абыйның соңгы сүзләре безне тынычландырып җибәрде. Безнең җәмгыять, андагы яшәү кануннары, күрәсең, безне шулкадәр калыплаган, әз генә башкача фикерләү, икенче яктан карау безне хәзер коралсызландыра икән бит. Югыйсә ул безне киләчәктә очрашачак бер тормыш хәленә куеп кына күрсәтте. Ә без ул яшьтә каршыбызда бары өлкәнәюне генә күреп куркып калдык. Хәер, күп вакыт остазыбыз безнең белән бәхәс куертмый, ә үзе сынаган, ышанган нәрсәләрне кагыйдә рәвешендә яисә әдәби әсәрләрдәге геройларның тормыш тәҗрибәсе аша оеткы итеп күңел түренә салып куя белә иде.

* * *

Группабызда укыган унҗидебез төрле уку йортларында, мәктәпләрдә үз белгечлегебез буенча укытучылар булып эшләячәген дә Мөхәммәт абый дөрес фаразлаган булып чыкты.

## Чираттан тыш имтихан

Старостабыз Хәлил яши торган бүлмәнең ишеге туктаусыз ачылып-ябылып тора. Әкрен генә шакуга эчтән бернинди тавыш бирүче юк. Ишек төбенә килеп баскан кеше кыяр-кыймас кына эчкә узса да, «кем кергән?» дип кызыксынучы, «ни йомыш?» дип сораучы юк. Гомумән, бүлмәдә беркем дә юк. Баш-аягы белән одеялга төренеп, караватына капланып ятучы берәүне санамасаң. Ә ул берәү эндәшми. Кергән кеше, моның Хәлил икәнен белеп, әкрен генә капланып ятучы янына килә. Әйтәсе сүзен әйтеп, бераз басып тора да борылып чыгып китә. Ишек төбендә хәл белергә керүче тагын бер группадашын күрә. Алдагы хәл тагын кабатлана.

– Хәлил, ятма болай, үзеңне кулга ал. Дөнья беткәнме әллә. Менә

күрерсең, бар да әйбәт бетәчәк. – Одеял кымшанмый. Үгет иясе бераз таптанып тора да коридорга атлый...

Саный барсаң, мондый үгетләр бүген унлап булгандыр инде.

– Хәлил, юләр булма, тор, иртәгә үк деканатка бар... – Одеял җавап та бирми.

– Иптәш Хәлил, сезгә группа исеменнән каты шелтә, староста башыгыз белән калганнарга тискәре үрнәк күрсәтеп ятканыгыз өчен. – Кәефен күтәрергә теләп, үзенчә шаяртырга тырышкан комсоргка да одеял битараф калды.

– Хәлил, бүген Мөхәммәт абыйны очраткан идем, иртәгә мине күрсен әле диде.

Керү-чыгучылар – күбрәк кызлар. Ничек борчылмасыннар алар? Дүрт күз белән стипендияне көтеп торганнарын белеп, кич кайтып керсә дә, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, «степашка»ларын өләшеп чыга торган, тулы курс лекцияләрендә була алмаучыларны да «сатмаган», төркем эшләрен гел гаделлек белән бүлгән, хөкем иткән старосталары бит ул. Кызлар шулай гөманладык. Ниһаять, аларның миссияләре туктап торган арада, Хәлил торып, ишекне бикләп алды. Соңгы хәбәр аны кузгатып куйды. Мөхәммәт Мәһдиев – факультетның партоешма секретаре. Димәк, партоешмага килеп ирешкән. Әйтте шул милиция бүлегендәге протокол тутыручы: «Син коммунист булгач, эшең шунда җибәрелә», – диде.

Менә икенче тәүлек инде ул ашамый, эчми, йокламый. Гәүдәсе караватта, ә үзе туктаусыз өченче көн булган вакыйганы кинокадр кебек күзаллый – чигенә, тагын күзаллый, тагын чигенә...

Педпрактикалары тәмамланып, бераз лекцияләргә йөреп алгач, бишенче курсларның ирекле чорлары булып ала икән. Махсус курсларга йөрүдән һәм диплом язудан торган бу вакыт студентка әз генә дөньяга күз ачып карарга мөмкинлек биреп алды. Кемнәрдер экраннарда барган шәп фильмны карарга йөгерде. Камалда аншлаг белән барган спектакльне карамасагыз, татар бүлегендә укыйм дип тә йөрмәгез дип кисәткәннәрен искә төшереп, кайберәүләр театр сукмагын таптап алды. «Әй кызлар, киләсе ел бу вакытларда кайсыларыбыз кайларда булырбыз бит! Сагынырбыз әле Казанның сәнгать учакларын, соңгы елда йөреп, күреп калыйк», – диючеләр музейларга, очрашуларга, кичәләргә чаптылар.

Ул көнне берничә егет белән Хәлил якындагы кинотеатрга барган иде. Шәп кино карап чыктылар. Көз азагы. Кыш тулы көченә керергә, дилбегәне үз кулына алырга дәгъвалаган көннәр. Алар кино караган арада да эре бөртекле кар яуган. Тротуар-юллар, агач-куаклар сәгать ярымда сихри үзгәреш кичергәннәр. Казан урамнарын акка буяп, ут янган баганалар тирәсендә әле күбәләккә әверелеп, әле яфрак кебек бөтерелеп, ул һаман явып тора. Янып-пешеп эссе залдан килеп чыккан егетләр бу хозурлыкка исләре китеп карап тордылар. Кыска гына сөйләшү булып алды: трамвай-троллейбуска утырып кайталармы, 3-4 тукталышны җәяү атлыйлармы? Бер-берсенә ак кар йомарламнары атыша башлап, шаярышып, тротуар кырыена өеп куелган кар өеменә төртеп егулар белән мәш килеп, җәяү атлый башладылар. Көчләрен кая куярга белмәгән, каннарында яшьлек, узышу дәрте кайнаган бу егетләр кайчакта әдәп чигеннән чыкканга да охшап

китәләр иде читтән караучыларга. Нишлисең бит. Яшьлек! Каршыларына татарча сөйләшеп атлаучы кызлар төркеменә кар йомарламнары оча башлагач, тегеләр, тирә-якны яңгыратып көлешеп, тиз генә йөгереп үтеп киттеләр. Соңгы кар йомарламнары кызлар артындагы ике кулларына сумка, сеткалар күтәргән төксе чырайлы хатыннарга да барып тигәләде. Ул хатыннар йомарлам килеп тигәч, яшь чакларын, ак кар яуганда чыркылдашып куышуларын искә төшереп тормадылар, әлбәттә. Алдарак каршыларына очраган патруль милициягә генә хәбәр салдылар. Хәлил ике егет белән көрттә әүмәкләшеп ятканда, тротуар кырыена троллейбус туктап маташа, алдагы егетләр патруль килгәнен күреп, ачык ишек эчендә юкка да чыгарга өлгергәннәр иде. Бернәрсә искәрмәгән егетләр һаман әүмәкләшә, чөнки җиңү шарты – бүрекне бәреп төшерү. Хәлил берсенекен төшерде, икенчесенекен төшерәм дигәндә, анысы, нишләптер тарткалашудан туктап, бүреген киеп йөгереп тә китте. Өс-башын каккалап, төркемдәшләренең йөгерүләренә сәерсенеп күтәрелеп караса, каршысында милиция патруле. Әле үзенә ни өчендер честь тә биреп маташалар: «Совет районы милиция бүлегенең патруль командасы. Безнең белән машинага баруыгызны сорыйбыз».

Тормышында иң мәгънәсез ялгышу менә шушы мизгелдә, шушында көтеп торган икән Хәлилне. Ул әле милициягә артык игътибар да итмәгән иде. Кузгала башлаган троллейбуска ничек кирәк алай эләгеп китеп баручы егетләрдә иде аның бар игътибары бу минутта. Үзе дә егетләр артыннан китәргә талпынып куйды, тик ике көчле «келәшчә» аны шундый итеп кысып китерде – адым түгел, карыш та урыныннан кымшана алмады. Аңлатырга, кулын бушатырга тырышуларга патруль бер сүзне тәкрарлады: «Әйдәгез машинага, шунда барысын да аңлатырсыз». Аңлашу машинада да, милиция бүлегендә дә барып чыкмады. Ул әйткәннәрнең бер генә сүзенә дә ышанмаулары йөзләренә чыккан. Протоколга «ике егет белән сугышып, бүрекләрен алырга маташкан чакта тоткарланды, тоткарланган чакта качып китәргә омтылыш ясады» кебек җөмләләр белән килешмәвен әйткәч, «без, берничә милиционер, үз күзебезгәме, синең сүзеңә ышаныйкмы?» – дип авызын яптылар. Мин кинода бергә булган егетләрне күрсәтсәм, беренчедән, болар эшне ничек дәвам итәрләр бит әле? Икенчедән, уйнашып кайтып килгән иптәшләрне милициягә күрсәтү егетлек булыр микән? Кыскасы, Совет районы милиция бүлегендә төне буе уйлап та очына чыга алмады ул уйларының. Алай да гел үк бәхете юк түгел икән. Үзе белән түш кесәсендә һәрвакыт партбилетын йөртү гадәте хәленә әз генә җиңеллек бирде: артык тупас кыланмадылар, инде соң булса да, картотекага мөрәҗәгать итеп, партбилеты аша башка мәгълүматларын алдылар. Икенче көнне эш сәгате башлануга чыгарып та җибәрделәр: «Факультет партоешмагызга хәбәр ителде, язмышың алар кулында», – диделәр. Гаеп-кыек эшләмәсә дә, булган хәлләр аның язмышын бөтенләй кирегә үзгәртергә мөмкин булуын бик яхшы аңлый иде Хәлил.

Менә икенче тәүлек бүлмәсендә шулар турында уйлап ята. «Ир-ат солидарносте»ның язылмаган кагыйдәләренә тугры калып, «кино яратучылар» күптән инде җыелышып сөйләшкәннәр иде. Хәлил аларга, ике сөйләшергә урын калдырмыйча, берәүнең дә фамилиясе милиция

бүлмәсендә әйтелмәгәнен һәм эш ничек кенә дәвам итсә дә, әйтелмәячәген белдерде.

Чиратта – партоешманың бюро утырышы. Ә аңа кадәр Хәлил белән Мөхәммәт Мәһдиев арасында сөйләшү булды. Ирләрчә, коммунистларча.

– Хәлил, син миңа ничек бар, шулай сөйләп бир бу хәлләрне, – диде Мәһдиев, егеткә туры карап. Һәм ул сөйләп бирде, ничек бар – шулай. Шулай ук укытучысының күзенә туры карап. Сөйләп бетергәч, катгый тавыш белән әйтеп куйды:

– Тик бюрода мин бары тик протоколдагыча, үземне генә күрсәтәм.

Мәһдиев, озак сүзсез торганнан соң, сорау бирде:

– Әгәр университетта калдырмасалар, нишләргә уйлыйсың?

– Ераккарак берәр җиргә эшкә урнашам. Әниләргә, мине бер елга практикага җибәрәләр дип хат язам.

Бюро утырышы турында бик чәчелеп сөйләшеп йөрмәделәр. Бу хәлләр турында белгәне белеп, белмәгәннәр белми дә калды. Тик Хәлил үзе бу хәлләрдән сер ясамады. Үзенең шаянлыгын да мулдан гына кушып, бюро утырышын безгә тасвирлап бирде. Сүз Мөхәммәт абыйга килеп җитүгә, ул җитдиләнеп китә һәм мөгаллимебезне чиксез хөрмәтләвен яшереп кала алмый иде:

– Җәмәгать, студентны аталарча кайгыртучы чын кеше икән ул Мөхәммәт абый. Русча әйтем бар бит әле «горой стоит» дигән. Бюрода Мөхәммәт абый минем өчен менә шулай «горой стоял». Кураторыбыз Лена апаны да чакырганнар бюрога. Ул инде елый-елый мине мактый. Шушы бюро утырышында үземнең бик шәп җегет булуыма ышанып чыктым мин. – Борчылып, жәлләп, Хәлилнең авызына карап утыручы кызлар, соңгы җөмләләрдә егетнең сабын куыкларын мулдан очыра башлавын сизеп алып, аны «дөмбәсли» башлыйлар.

– Хәлил, җитте сиңа, шундый җитди әйберләрне уенга борма!

– Ничек булып бетте, сөйлә кешечә итеп.

– Булды, булды, – ди, старостабыз киң җилкәләрен бездән яшереп. – Университетыңда укып бетер, бүтән вакытта егетләр белән киногa йөрмә, кызлар белән генә бар дип, бюродан куып чыгардылар. Кызлар, минем белән кинога йөрергә исемлек төзик әле.

– Шулай итте, ди, менә. Бик дөрес әйткәннәр, әнә, Миләүшәң белән йөр кинога, – диешәбез кызлар.

* * *

Мөхәммәт абый бюрода безнең старостабызны яклап, аңа ышанып сөйләгәч, бюро күпчелек тавыш белән Хәлилне университетта калдырды. Менә шулай бу дөньяда гел юктан гаепле булып калуың, тормышыңның кискен борылыш ясавы тиз икән. Бу вакыйга шушылай гына тәмамланса, бер хәл иде. Юк шул. Дипломнар алып, кайсыбыз кая таралышып, юлламаларыбызны тотып барып эшлисе мәктәпләребез, редакцияләребез, оешмаларыбыз белән танышып йөргәндә, безне шок хәлендә калдырган хәбәр ишетәбез: «Безнең Хәлил Уфада эчке органнарга эшкә кергән!»

Группабыз дус һәм бердәм иде. Биш ел күрешмичә чак түзеп, җәй көне беренче очрашуга җыелдык. Университетта уку елларында ук яратышып

йөргән Миләүшәсе белән беренче очрашуга, тагын биш елдан икенче очрашуга, аннан өченче, бишенче очрашуларга килә Хәлилебез. Һәр килгәнендә шунда ук эшләвен әйтә. Ранглары гына күтәрелгәннән-күтәрелә бара. Федераль дәрәҗәдәге исемле урыннарда эшләвен беләбез, ләкин эше, дәрәҗәсе белән беркайчан мактанмый, артык җәелеп сөйләми. Һаман шулай шаян, баянын алса, дөньясын оныта. Ә минем күңелдә һаман бер сорау: «Филолог-тарихчының бу юнәлештәге эшне сайлавы теге хәлләр белән бәйле түгелме икән?» Ниһаять, Мөхәммәт абый турындагы бу язмамны язганда төркемдәшләремнән истәлек-хатирәләр сораштырганда, чират Хәлилгә дә җитте. Хәл-әхвәл белешәбез, сагынып, университетны искә алабыз. Әлбәттә, укытучыларны. Мин йомышымны әйтәм. «Студент елларда бөтенебез яраткан Мөхәммәт абыйның якты образын сурәтлисем килә, синдә аның турында берәр истәлек сакланмыймы?» – дим. Көлешеп, теге хәлләрне искә алабыз. «Менә шуны дәвам итеп, сез белмәгән бер истәлек сөйлим әле», – ди бу. Минем тыным кысыла, ничә еллар үз-үземә генә биреп йөргән соравыма җавап ишетәм түгелме?..

– 90нчы елларның башлары иде. Без Миләүшәләргә Арчага кайттык. Беркөнне Арчаның үзәк урамында Мөхәммәт абыйны очраттым. Хәзер ялда булуын, кайчан тели, шунда туган авылына кайтып килә алуын сөйләп алды. Миңа сорау биреп куйды:

– Син, Хәлил, Башкортстанда яшәмисеңмени?

– Яшим. Тик мин Арча кияве дә бит әле.

– Әйе, юньле кешеләр Арчаның кияве генә булса да, булалар шул, – дип, үткен язучы фразасын да ыргытып алды. Җиңелчә көлештек.

– Мөхәммәт абый, сез хәзер кая барасыз, Гөберчәккәме? Әйдәгез, мин сезне илтеп куям, – дим.

– Гөберчәккә, ләкин катгый «Юк!»

– Мөхәммәт абый, үземнең хөрмәтле укытучыма, тормышымда авыр чакта ярдәм иткән кешегә әз генә ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирелгән икән, шуны эшләмәсәм, кем булам мин һәм алга таба мин ни битем белән җир йөзендә яшәрмен, – дип башлаган идем...

– Чү-чү-чү, – дип, мине туктатып, машинага кереп утырды. Кайтканда, тирә-якка карап хозурланып барды. Артык сөйләшмәдек. Өйләренә кайткач, апасы белән кадерле кунак кебек хөрмәт күрсәттеләр. Мин гомердә ашап карамаган кызыл чөгендер катыгы белән сыйладылар. Озатканда, Мөхәммәт абый да минем белән чыкты. Өйләре янында утырткан тупылны, бакчадагы җиләк-җимеш агачларын күрсәтеп йөрде.

– Әти-әни истәлеге болар барысы да, алар дөньяда иң кадерле нәрсәләр булып кала икән үзләре киткәч. Хәлил, теге вакытта протоколга «тегелгән» легенда бигрәк көчле иде бит. Тик мин сиңа ышандым. Беләсеңме ни өчен? Шундый моментта да әти-әниеңне кайгыртып, аларны борчымау җаен уйлап куйган идең бит син. Әти-әнине кайгыртып яшәгән кешеләр – яхшы күңелле, өметле кешеләр алар. Инде сөйлә, ничек органнарга эшкә киттең?

– Сөйлә дип, әллә ни сөйләрлеге юк инде, Мөхәммәт абый. Ышансагыз, шул хәлләр этәргеч бирде миңа бу юнәлешне сайлауга. Төне буе бер уй боргычлады мине ул вакытта. Пүчтәк кенә бер нәрсә кешенең язмышын борып куя ала икән бит. Органнарда битараф кешеләр эшләргә тиеш түгел

икәнлеген аңладым мин ул төнне. Эштә хәзер башкалардан да һәрвакыт шуны таләп итәм. Ә сезгә чын күңелдән рәхмәт, Мөхәммәт абый. Миңа ышанганыгыз өчен.

Мин, сигнал биреп, капка төбеннән кузгалып киткәндә, Мөхәммәт абый һаман бакчада иде әле. Менә шундый истәлек сиңа, группадаш.

## Соңгы сүз

Мөхәммәт абый җитәкчелегендә диплом язуыбызны, яклавыбызны, җитәкчебезне котлап (диплом яклау җитәкченең дә җиңүе бит ул!), аңа чәчәкләр бирүебезне, чәчәкләр тапшырганда, аның күзләрендә яшь чагылып китүен, минем моңа бик гаҗәпсенүемне тәфсилләп язып тормыйм. Әйе, бар да нәкъ шулай булды. Шулай төгәл һәм кыска. Алай да остазымның: «Мингалимова, синең кебек җиңел һәм рәхәт итеп диплом язучым булганы юк иде әле», – дигән сүзләре миңа иң зур бүләк булганын да язып үтми кала алмыйм. Остазымның шәкертенә әйтелгән зур мактавы бит ул.

Мин бу язманы менә хәзер, инде үзем Мөхәммәт абый яшеннән дә өлкәнәеп киткәч язам. Бу вакытта мин инде аның бөтен әдәби әсәрләрен (берничәсеннән кала, ул аларны безне укытып чыгаргач язды) көлеп тә, елап та, сокланып та укып чыккан идем. Мәкаләләрен, чыгышларын, әңгәмәләрен укыганда, безгә лекция сөйләгәндә әйтелгән фикерләре чагылып киткәч, күптәнге кадерле нәрсәмне тапкан кебек чын күңелдән куандым. Остазыбызның дөрес фикерләре, төпле киңәшләре, мәгънәле ишарәләре гомерем буе мине озата бардылар. Алар миңа кирәк булдылар, һәм алар тормышка ашып та бардылар. Розалия дә, мин дә авыл мәктәбенә укытырга киткәч кенә кияүгә чыктык. Балалар үстердек. Мин фәнемә һәрчак тугры калдым. Туган тел һәм әдәбият укытуга күп төрле карашлар күрергә туры килде: туган тел дәресләренә икенче сорт итеп караган 80 нче еллар да, суверен республика булгач, рәхәтләнеп, киң программалар белән укыткан чаклар да, оптимальләштерү кайчысының баш өстендә эленеп тора башлаган вакытлар да булды. Мин бер нәрсәгә инандым: нинди чор, нинди генә программа, дәреслекләр булса да, баланы предметны яратырга өйрәтеп була. «Ә яраткан фәнне начар укып булмый инде аны», – ди торган иде остазыбыз Мөхәммәт абый.

Әллә никадәр планнар, хыяллар белән эшләп ятканда, беркөнне миңа да Мөхәммәт абый безне кисәткән пенсия яше килеп җитте. Авыл мәктәпләрендә балалар кимегәннән-кими барган вакытлар. Әнә шул чакта остазымның күңел халәтен аңлап, аның кичерешләре белән дә сугарылып, мин дә мәктәптән аерылдым.

Мөхәммәт абый: «Язмый тора алмасагыз гына, яза башлагыз», – дигән иде. Остазымның бу сүзе дә күптән инде мине үз артыннан ияртеп алып китте. Инде төркемдәшләр барыбыз да аннан өлкәнрәк яшьтә булсак та, ул һаман безнең буй җитмәс үз мөнбәрендә остазыбыз булып кала һәм шул югарылыгыннан безгә уңышлар тели кебек тоела.



Энҗе
Хөсәенова

# БЕР СӨЙЛӘШИК ӘЛЕ...

***

Бермәлне сагынып сөйләрмен,
елмаеп багарлар күзләрем.
Ул чакта уйлар да, фикер дә,
йөзем дә, үзем дә үзгәрер.

Бермәлне сагынып сөйләрмен
уйламый юләрлек кылганны.
Киң дала буенча йөгереп,
мәш килеп кууым кылганны.

Бермәлне сагынып сөйләрмен
битәрләп елавым үземне.
Шулкадәр юләргә сабышып,
Аллаһтан соравым түземне.

Бермәлне сагынып сөйләрмен
язмышның иң үткен камчысын.
Күңлемә йотуым (мең тапкыр!)
яңгырның иң эре тамчысын.

Бермәлне сагынып сөйләрмен
җилләрнең ыжгырып искәнен.
Яшереп саклаган иң ихлас
әйтмичә калдырган хисләрне.

***

Бер сөйләшик әле...
Сөйлә миңаниләр уйлавыңны.
Үз-үзеңә каршы килеп, елмаюлы
битлек киеп уйнавыңны.

---

Энҗе ХӨСӘЕНОВА (1996) – *шагыйрә, С.Сөләйманова исемендәге стипендия һәм «Иделем акчарлагы» (2021) яшь иҗатчылар бәйгесенең Гран-при иясе. Казанда яши.*

Бер сөйләшик әле...
Сөйлә миңа күңелеңә тулганнарын.
Мең бәхетле көннәр арасында
үкенечле көннәр булганнарын.

Бер сөйләшик әле...
Сөйлә миңа вакыт-вакыт талуыңны.
Бик әйтәсең килгәндә дә,
тешең кысып дәшми калуыңны.

Бер сөйләшик әле...
Сөйлә миңа нинди хисләр кичерүең.
Күңелеңнән генә дулап йөреп,
бар дөньясын урыныннан күчерүең.

Бер сөйләшик әле...

***

Мең уйлар биләде, мең төрле,
мең шигырь язылды сык(ы)рап.
Минем бит бүгенге көнемнән
үткәнем мең кабат яктырак!

Яшь катыш елмайдым берүзем,
көзгегә бакканда күзләрем.
Йөрәкне мең әрнү тишкәндә,
бер тамчы ярату эзләдем.

Бер хисләр ташкыны биләде,
бер буп-буш калды ла күңелем.
Син мине аңламас чагыңда,
ялгызым калдым да түгелдем.

Бураннар дулаган мизгелдә
йә киң ул дөньясы, йә бик тар.
Үлдем дип уйлаган чагымда
йөрәгем түрендә шытым бар!

***

Күпме шигырь язылган бит
сиңа атап минем исемнән.
Исеңдәме, вәгъдәләшкән идек
язның матур айлы кичендә.

Назлы караш, ихлас елмаюлар
бүгенгедәй әле исемдә.
Бүгенгедәй тоям кулыңдагы
сирень чәчәгенең исен дә.

Сөенечтән йөгергәнем истә
биек тауның иң-иң өстендә.
Әйтче миңа, мәхәббәтле дөнья,
гүзәл яшьлек нәрсә төсендә?

Исеңдәме, бик бәхетле идек
язның матур айлы кичендә?!
Синең ничек?.. Әйтче дөресен...
Минем сүзләр әле көчендә!..

***

Ни сүзләр әйтим соң юатып?
Ерактан газизең көткәндә.
Күзеңә моң тула, зар тула,
башкалар ярларын үпкәндә...

Ни сүзләр әйтим соң юатып?
Төннәрең йокысыз үткәндә.
Ялгызак мендәрең кочаклап,
Саг(ы)нулы яшьләрең түккәндә...

Ни сүзләр әйтим соң юатып?
Өметең өзелгән мәлеңдә.
Син инде ничә көн... ничә ай...
тетрәнү кичергән хәлеңдә...

Ни сүзләр әйтим соң юатып?
Һәр көнең куркудан торганда.
Синең бит һәр минут, һәр сәгать
күк тоташ, җир тоташ томанда...

Ни сүзләр әйтим соң юатып?..

***

Бер язасым килә...
барысын бәйнә-бәйнә сөйләп.
Язылас сүзләремне
күңелемнән йөрим көйләп.

Бушанасым килә сөйләп
бу тормышның ваклыкларын.
(Ә югыйсә син өйрәттең
һәрнәрсәдә хаклык барын!)

Бер сөйлисем килә...
авыр, «рәхәт» хәлләремне,
күңел яшен түккән чакта
мең елмайган мәлләремне.

Берәр кайчан, көчем җыеп,
белмим... сиңа сөйләрменме
еллар буе җыеп килгән
үзем белгән хәлләремне...

***

Ишетәсеңме... җирдә апрель ае...
хатирәләр белән уралган.
Безнең сөю күптән «онытылган» –
күңел түрләрендә «югалган».

Ничә язсам шушы шигырьләрем,
хәлләреңне килә беләсем!
Мин интегәм хәзер, ача алмыйм
бикле күңелеңнең келәсен.

Нихәл диеп сорыйм танышлардан,
саулык микән бүген аңарда?
Кавышалмый калган мизгелләрне
тырышамы икән аңларга?

Ә мин менә аңлый алмыйм һаман...
Аңлый алмый йөрәк... нишләсен...
Аңа бәхет, нигъмәт сорар өчен
көтеп алдым Кадер кичәсен...

...Бик сагынам безне таныштырган,
сөйми калган апрель иртәсен...

***

Җитәр бер көн: мин янармын
күңелемне битәрләгән тирәлектән.
Күз йомармын җанны әрнеткәнгә,
үзем теләп түгел, кирәклектән.

Җитәр бер көн: мин янармын
берәүләрнең нахак сүзләреннән.
Һәм качармын гомерлеккә,
битәрләмә диеп, үзләреннән.

Җитәр бер көн: мин янармын
кемнәрнеңдер ялганыннан.
Тик шулай да тынычлыгым җуймам
йөрәгемә кереп калганыннан.

Җитәр бер көн: нокта куярмын мин
авырлыктан дөрләп януыма.
Сөенермен күз яшьләрем аша
бүгенгәчә исән калуыма.

***

Син сорама, ә мин әйтмим сиңа
күңелемнәнниләр кичергәнем.
Тыным кысылганда, дөньясының
йөрәгемне
ур(ы)нынnан күчергәнен.

Син сорама, ә мин әйтмим сиңа
көнем белән төнем буталганын.
Тыныч яшәп яткан мизгелемдә
җанкаемны ялкын-ут алганын.

Син сорама, ә мин әйтмим сиңа
күзләремнең нигә яшьләнгәнен.
Таудан сикерепләр төшкәнемне,
югалтканым хәтта яшәү ямен...

Син сорама, ә мин әйтмим сиңа
тирән яраларым тырналуын.
...Бүген – минем япа-ялгыз калып,
үзләреннән, үзәгемнән качып,
яшем эчкә йотып тын алуым.

***

Шигырьләрдән кеше үзен таный:
күрә кайчак йөзен, язмышын.
Терсәк якын, әмма тешләп булмый,
бик соң белә кылган ялгышын.

Шигырьләрдән кеше үзен таный:
шик йөгерә кайчак күңелгә.
Эчтән бүре булып йөргәннәр дә
тыштан куян булып күренә.

Шигырьләрдән кеше үзен таный:
шул хисләрне үзе кичерә.
Киләчәккә әйди безне язмыш
йә бер адым артка күчерә.

Шигырьләрдән кеше үзен таный:
күп нәрсәгә шигырь сәләтле.
Бик хуп булыр иде, әгәр безгә
иман иңсә шигырь сәбәпле!



Ркаил
Зәйдулла

ХИКӘЯЛӘР

# КАРЫНДЫКЛЫ ИДЕ ТӘРӘЗӘСЕ

Төп урамнарның берсен танымый тор әле син! Парижда, мәсәлән, моны күз алдына да китерүе кыен. «Ротонда» берничә гасыр элеккеге кебек үк шул көе тора, керәсең – каршыңа Модильяни белән Ахматова җитәкләшеп чыгар сыман... Истанбулда да шул ук хәл: Византиядән калган кабер ташлары янында каһвәханә; дәверләр буталган, үзеңне мәңгелек дип хис итәргә менә дигән халәт. Әлбәттә, тәгаен син түгел, кеше дигән җан иясе мәңгелек. Дөрес, мәңгелек дигәнең дә мәңге шулай тормас, бер очы булыр...

Ә монда Сәлим үзен ниндидер таныш булмаган шәһәргә килеп эләккәндәй хис итте. Югыйсә аның яшьлеге монда – Казанның уртасында – борынгылык исе аңкып торган йортлар арасында үтте. Әлеге урамда да – ул вакытта рәсми рәвештә Свердлов урамы дип аталса да, шәһәрнең төп халкы аны Суконка дип кенә атый, элек-электән монда постау басучылар яшәгән – еш булырга туры килә иде. Менә әле дә шул замандагы ярымҗимерек борынгы агач йортлар күз алдына килде Сәлимнең. Шул заман дип... әллә күпме вакыт та үтмәгән инде аңа. Гасыр ахырында трущобаларны, ягъни мәсәлән шул иске тарихи йортларны юк итәбез дип, тоташ бистәне җимереп ташлаганнар да өр-яңа кала салып куйганнар! Заман шундый, иле дә шундый инде – кемнеңдер хатирәләре белән санлашып тормый... Агач йортлар белән бәйле хатирәләрнең гомере дә әллә ни озын булмый, күрәсең. Сыйфатлы кызыл кирпечтән салынган чиркәүләр әле дә кукраеп утыра, аларны төзегәндә үк киләчәк гасырларны күздә тотканнар һәм ялгышмаганнар. Калын диварлары әллә нинди зилзиләләргә дә бирешмәгән. Әнә берсе күпме еллар Курчак театры булып торды да инде яңадан чиркәү! Урамның элекке исеме дә Егорьевский чиркәве белән бәйле бит, ә аңарчы ул Кирпеч урамы дип

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург; Татарстанның халык шагыйре. «Мәгарә», «Ташка ордым башны», «Саташкан сандугач» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

аталган. Чөнки Казанны алып күп тә үтми, яңа хуҗалар монда кирпеч заводы салып куйганнар. Яңа кала салганда, кирпеч – иң кирәкле нәмәрсә. Ә ханлык заманында монда әрмән бистәсе булган диләр. Аларга да таш, кирпеч ят булмагандыр. Ләкин ни гаҗәп, Сәлим белгәндә, урам күбесенчә иске агач йортлардан гыйбарәт иде.

Әйе, шаккатырды Петербург урамы Сәлимне. Чыннан да, җәяүлеләр өчен көйләнгән бу урамда йөргәндә, үзеңне Аурупа каласына эләккәндәй хис итәсең. Исемен дә әлеге гасыр башында юкка гына Петербург дип атамаганнар, ул да бит, уйлап баксаң, Аурупа шәһәрләренең күчермәсе кебек. Сәлим үзалдына көлемсерәп куйды, тарихтан хәбәрдар булуын ул дус-ишләре алдында да еш кына купайтып ала, ә монда берүзе, ләкин ирешелгән белем, үзең генә калганда да, күңелгә рәхәтлек бирә шул, шайтан алгыры! Ул бит узган гасырның сиксәненче елларында Казан университетының тарих бүлегендә укыды, тарихны бераз чамалый. Ләкин Сәлим яшьлегендә тарихтан бигрәк әдәбият белән кызыксынды, һәм хәзер әйтергә дә оят! – шигырьләр дә язып маташты әле. Дөрес, бүген ул тарихтан да, шигырьдән дә бик ерак, инде егерме елдан артык чит илдә яши, нәни генә бизнесы бар, Казанга да шул бизнеска бәйле кайткан иде. Монда инде аның якын туганнары да юк, сагыну-саргаю дигән нәрсәләр дә аны борчымый, биредә калган дус-ишләрен дә барламый ул, дуслык бит уртак мәнфәгатьләр булганда гына яши; аралашмый торсаң, бертуганың да онытыла. Кеше арасындагы мөнәсәбәтләр белән гап-гади мәнфәгатьләр идарә итә. Алардан башка беркая да бара алмыйсың, наныкачкаем. Хис кешесе түгел Сәлим, ул моңа чын күңелдән ышана һәм кайчандыр үзенең шигырьләр язып матавыклануына тора-торып үзе дә гаҗәпләнеп куя иде. Исенә төшкәндә, әлбәттә. Һәм менә, Петербург урамыннан атлап барганда, әллә ниләр исенә төште аның. Җәяү йөрү, гомумән, хатирәләрне уята. Әгәр дә яшьлегендә бик тиз машинага тиенмәсә, кем белә, бәлки ул шагыйрь була алмаса да, әдәбияттан бөтенләй үк китмәс иде – җәяү йөргәндә, күзәтүчәнлек тә көчәя, ә әдәбият шул бит инде ул! Тик шунысы бар – әдәбият заманы узган иде инде Сәлим балигъ булып җиткәндә. Рәшә кебек юкка чыккан иде! Ул моны бик җәһәт сизде: башка заман, башка кошлар!

Башына әллә нинди йөгәнсез уйлар килүенә шаккатып, кыска гына көлеп куйды да үзе урнашкан «Сөләйман палас» кунакханәсенә борылды ул. Бу отель дә аңа ошады, чын аурупача! Хадимнәре дә бик итагатьле, өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар, чәчләре белән идән себерәм дип торалар инде менә! Отель хуҗалары моңа ничек ирешкәндер, гаҗәп. Безнең кеше бит канауда аунап ятса да, үзен беркемнән ким күрми, әле үзенең гади хезмәт кешесе булуы белән горурлана – совет тәрбиясе! Шуңа да тупас официантлар, дорфа җыештыручылар, үзләрен генерал итеп тоючы вахтёрлар... Хәтерли аларны Сәлим. Димәк, илдә җәмгыять нык үзгәргән. Бу үзгәрешнең төбендә ни ятканын шактый озак еллар Аурупада яшәгән Сәлим яхшы белә иде, билгеле.

Менә бу бина... Аның хуҗасы бар инде һәм шәп хуҗа! Үзе салганмы, әллә дәүләтнекен юк кына бәягә үзләштергәнме, хәзер инде мөһим түгел. Мәһабәт, затлы. Үз бәясенә сатканда, күпмегә тарта икән? Юк, Сәлим тагын илле ел бизнес белән маташса да, аңа якын да килә алмаячак. Ә бит Казан

үзәгендә шундый кунакханә тотсаң?! Хыялый дип, үз-үзеннән көлеп куйды Сәлим. Әйе, хыялый булып тусаң, бу – гомерлек.

Кунакханәнең ишегенә мәрмәр баскычтан күтәрелгәндә, аның ми күзәнәкләренең берсендә чаткы чәчрәп киткәндәй булды. Отель бинасы затлы, монда инде ул гасырлар дәвамында торадыр сыман, ә бит күп булса, егерме еллар элек кенә салынган. Ул, туктап, тирә-ягына күз йөртте. Әнә... каршыдагы йорт... Ул бит аның яшьлегендә үк бар иде сыман. Әйе, бар иде! Мондый купшы кыяфәттә түгел иде, билгеле, йоны коелган тавыкны хәтерләтә иде, ялгышмаса. Хәзер әнә йон кундырганнар – нинди гүзәл: канатын җәйгән бөркет диярсең. Ә менә бу кунакханә урынында... Әле утыз гына ел элек... Истә, истә!

...Нәкъ менә шигырь белән саташып йөргән еллары иде Сәлимнең. Көз иде. Тротуарга коелган көрәнсу-сары яфракларны борчып, Комлев урамы буйлап ул Язучылар йортына таба китте. Хәер, урамны инде бу вакытта Мөштәри исеменә үзгәрткәннәр иде, ахры. Борынгы агач йортлар күп иде әле монда да. Менә ул кайчандыр Гадел Кутуй яшәгән ишегалдын узды. Аларның йортын күптән түгел сүткәннәр бугай, нигез урыны беленеп тора, яраксыз берничә бүрәнә, кирпеч ватыклары аунап ята. Ниндидер әдәби кичәдән соң Сәлим шул нигез янында чүгәләп торучы бер сакаллы кешене күреп калган иде. «Шагыйрьнең улы, үзе дә шагыйрь, – диде кемдер. – Айга бер монда килеп, шулай елап китә».

Менә сәүдәгәр Оконишников салып калдырган ике катлы затлы бина. Балаларым, оныкларым монда рәхәт чигәр дип салган инде ул аны, бахыр. Сиксәненче еллар уртасында аны язучыларга бирделәр. Парадный ишек, гадәттәгечә, бикле иде, Сәлим, ишегалдыннан әйләнеп, элек хезмәтчеләр йөри торган ишектән икенче катка күтәрелде. Ишек янындагы кысан бүлмәдә чәй эчеп утырган вахтёр карчыкка башын салмак кына кагып сәлам биреп үтте – аны монда беләләр! Карчык элпә каплаган аксыл күзе белән аңа яратмыйча карап калды. Каләм тибрәтүче яшьләр белән эшләүче әдәби консультант Әсәд Бушков та аны караңгы чырай белән каршы алды. Елга берничә тапкыр шулай кәефсезләнеп ала иде ул. Сәлим белә иде инде – авырлыгын киметер өчен коры суга калып, бер ун көн ач торып ала иде консультант. «Ун көннән соң очып китәрдәй буласың, – дип сөйли иде коргаксыган иреннәрен ялаштырып. – Шундый рәхәт, малай!» Аксыл чырае учка сыярлык кына калган, ул мондый вакытларда үзе дә карт бер малайны хәтерләтә иде.

– Нишләп йөрисең? – диде ул Сәлимгә, өнәмичә генә. – Күптән күренгәнең юк.

– Авылда идем, – диде Сәлим, киң елмаеп. Бу елмаюдан йөзе тагын да аркылыга җәелеп китте. – Ну язып та күрсәттем, абзый! Укыймммы?

Әлбәттә, графоманнардан болай гына котыла алмасын Бушков яхшы белә иде. Качып та әллә кая китә алмыйсың, куып җитәчәкләр, берәр почмакка кысып, язганнарын барыбер укыячаклар! Аннары аның төп эше бит – консультант! Татарча язаларны, русчамы, ул аларга киңәш бирергә, язу-сызу серләренә өйрәтергә тиеш. Нишләсен, «интересно», – дигәләде, графиннан агызып, бер стакан су эчеп куйды. Ашыйсы килгәне беткән сыман тоелды. Хәер, соңгы көннәрдә инде аның ашыйсы килү теләге дә юкка чыгып бара иде.

Авылда шигырьләрне күп язды Сәлим, рәхәтләнеп укыды Бушковка.

Кемнәрдер ишекне ачып карады, кемнәрдер дип, йә күрше бүлмәдәгеләр, йә юл уңае кагылып чыккан каләм ияләре инде, кулларын болгап шигырь укыган Сәлимне күрүгә, ишекне ябып, тизрәк бу тирәдән шылу ягын карадылар.

Бер сәгать чамасы узуга, Бушков аны кул ишарәсе белән туктатты.

– Булды!

– Булмады! – дип карышты Сәлим. – Иң яхшылары калды, укыйм инде?

Бушков аны нәфрәт тулы карашы белән чәнчеп алды:

– Слушай, парень, калганнарын да син язгансыңдыр бит?

– Мин!

– Соң... аңладым бит инде мин синең нинди поэт икәнеңне. Элек тә шикләнми идем.

– Нинди?

– Беренчедән, шагыйрь мондый симез булмый. Кара инде син үзеңә! Хәтта бүксәң чыгып килә. Шушы яшьтә! – Ул тагын Сәлимгә, ашарга җыенгандай, ач карашын төбәде. Сәлим куырылып китте, Алла сакласын, әнә ачлык елында кеше ашаучылар турында Галимҗан Ибраһимов нәрсәләр язып калдырган. Ул киң җилкәләрен җыерып куйды, бүксәсен эчкә тартты.

– Конституция шундый минем, – диде ул, читкә борылып.

– Шагыйрь ябык, ярлы һәм һәрвакыт ач булырга тиеш! – диде Бушков, кире каккысыз тавыш белән. – Тукай! Күргәнең бармы аны?

– Юк... – диде Сәлим, бөтенләй югалып. – Исәнмени ул?

– Ул мәңгелек! Ач-ялангач булган, шуңа да бөек! Шуңа да һаман яши. Ә син? Кара инде үзеңә, бөтенләй җәелгәнсең.

Сәлим үз-үзенә карар өчен стенадагы көзгегә бакты. Аның карашынча, кеше куркытырлык берни юк иде кыяфәтендә. Олы инде гәүдә олысын, Тукай бит фотода малай сымак кына... Ләкин бит ул Тукай булырга җыенмый да. Сәлим булуы да авыр әле монда.

– Ә Маяковский? – диде ул, аптыраганнан.

– Маяковский озын буйлы булган, ләкин ябык. Аннары... Маяковский да булдымы шагыйрь? Аның агиткалары хәзер артыңны сөртергә дә ярамый. Ә менә Есенин... – Бушковның ак кәгазьдәй йөзенә кызыллык йөгерде, ирененә дә алсулык кергәндәй булды, ул тагын бер стакан су алып эчте. – Менә, ичмасам, чын шагыйрь! Глыба! – Ул тагын, Сәлимгә таба борылып, бөҗәккә караган кебек чирканулы караш ташлады.

– Алар бит инде әллә кайчан яшәгән. Хәзер заман үзгә, – дип акланды Сәлим.

– Әйдә, җыен, мин сиңа чын шагыйрьне күрсәтәм! Алар бүген дә бар! – Бушков, яңа тутырылган туп шикелле атылып, ишек янына килеп тә басты. – Истинный поэт, вот увидишь!

Барышлый кибеткә кереп, бер шешә аракы алдылар. Сәлим кесәсенә тыгылганчы, Бушков түләп өлгергән иде инде. «Казынма, – диде ул, елмаеп. – Минем дә студент чаклар бар иде». Юмарт, киң күңелле, вакланмый торган кеше иде Бушков. Аны хәзер алыштырганнармыни – күзе яна, бит очларында ике кызыл тап. Һәр хәрәкәтендә эшлеклелек. Димәк, уразасына бүген ясин чыгачак! Ясинның гына әле нинди буласын күз

алдына китереп бетерми иде Сәлим. Шулай да фольгага төрелгән, шырпы тартмасыннан аз гына зуррак йомшак сырга үзе түләде ул. «Дружба» дип атала идеме соң? Анысы инде тиеннәр генә, һәм сыры да бөтенләй үк сыр түгел. Арзан булганга эчкечеләр арасында бик популяр иде ул.

Свердлов урамына төшеп җиткәндә, көн инде караңгыланган иде. Алар, кайсы авыш, кайсы кыек янкормалар аша үтеп, бер нәни генә йорт каршында туктап калдылар. Йорт димәсәң, хәтере калыр... Алачык дип атау дөресрәк, мөгаен. Ләкин ул сыпушка түгел, кайчандыр бүрәнәдән салынган. Бик борынгы заманда, ахрысы; әрмәннәрдән үк калмаган булса! – караңгыда яртылаш җиргә иңгән сыман тоелды. Аскы ниргәдә каен үсентесе шытып чыккан һәм хәзер инде хәйран буй җиткереп, яшәр өчен мәйдан даулап утыра. Тәрәзәдә ут юк иде. Тәрәзә дип... аның бер өлгесендә генә пыяла калган, башкаларына фанер кисәге кагылган, ә бер өлгедә... карындык тартылган! Кайдан тапкан хуҗа аны, исең китәр. Пыяла кадерле чакларда карындыкны ярлы-ябагай кулланганын Сәлим тарихтан белә иде. Әллә кайсы заманнарда... Бер шигырь юлы да искә төште әле шунда: «Карындыклы иде тәрәзәсе, яба, яга иде саламын...»

Бушков өйнең кыйшык ишеген тартып карады, ишек бикләнмәгән иде. Эчкә үттеләр...

Әйе, шушы кунакханә урынында иде ул йорт-алачык. Әлбәттә, бу бина зур мәйданны били. Моның урынында унлап шундый нәни йорт урнашкан булгандыр. Ул фойеда уңга борылды. Әнә... Лобби-бар дигән төштә иде ул. Шунда... Сәлим яшел күн белән тышланган түгәрәк кәнәфигә килеп утырды. Алдындагы тәбәнәк өстәлне читкәрәк этәрде. Тын алырга да өлгермәде, ак күлмәк якасына кара күбәләк тагып куйган хезмәтче егет килеп җитте.

– Нәрсә телисез?

– Каһвә...

– Ниндиен?

– Иң яхшысын, яңа гына уттан төшкәнен.

– Хәзер, берничә минуттан китерәм, – дип, хезмәтче чыгып югалды.

«Баш өсте!» дияргә кирәк тә бит, болар шул тарихны белми, татарчалары да юк» дип, битараф кына уйлады Сәлим. Ул инде ерактан карап та татарның сүнеп баруына күнегеп килә иде. Алланың каһәре төшкән халыкның башта үзаңы югала диләр бит. Үзаңсыз син нинди милләт инде?

...Өй эче караңгы, электр уты янмый – хакын түләмәгәнгә өзгәннәр бугай – ләкин монда беркем дә юк икәне буш караваттан күренә иде. Җиһаз монда шул гына, тагын өстәл сыман өч аяклы нәмәрсә каршы почмакка терәп куелган. Анда суган кабыкларыннан башка берни юк. Урамнан үткән машиналар ара-тирә өй эчен яктыртып ала. Бушков кайдандыр шәм эзләп тапты. Тәрәзә төбендәге ике стаканны шәм яктысында тикшерде дә урыннарына кире куйды.

– Шешәдән эчәргә туры килә, – диде ул, авыр сулап. – Эчкәнең бар идеме?

– Юк...

– Борчылма, өйрәнерсең. Башта гына кыен сыман ул.

Пычрак каткан идәндә ниндидер кәгазь кисәкләре ауный. Бушков ике бармагы белән генә берсен күтәреп күзенә китерде.

– Җыеп өлгермәгән... гадәттә, ул теләсә нинди кәгазьгә шигырь яза да чемоданына тыгып куя. Әнә чемоданы, – дип, караватастына күрсәтте.

– Кем соң ул?

– Шагыйрь! Зур хәрефтән! Менә тыңла! – Ул, кәгазь кисәгенә карап, иреннәрен кыймылдатты, хәрефләрне танып бетерми иде, ахрысы. – Әһә! Вот! Послушай...

Во мне не сердце, а кусочек грома,
С отсветом молний, падающих гроз,
Я в ливни чувств сверкающих закован
И весь насквозь из хохота и слез.

Йә, ничек?!

Сәлим шигырьне сеңдереп өлгермәгән иде әле, ләкин бу юллардан ниндидер сүз кодрәте бөркелүен кайсыдыр күңел кыллары белән сизде, әлеге шигырьне тышка чыгара алган шәхеснең күз яшьле һәм каһкаһәле фаҗигасен аңлаган кебек булды. Бугазына килеп тыгылган төерне йота алмыйча караватка утырды.

– Шул-шул, – диде Бушков, аның хәлен аңлап. – Мә, йотып куй.

Бер-берсенә эндәшмичә шәм яктысында озак утырдылар. Һәркем үз уйларына чумган иде.

– Дөньяга туу – үзе үк бәхет инде ул, – диде Бушков, тынлыкны бозып. – Миллион сперматозоид арасыннан нәкъ менә сине яралтучысы максатына ирешкән, бу бәхет түгелмени? Хәтта аз гына яшәсәң дә, син бит кояшны күреп каласың. Могҗиза!

Бераздан йорт хуҗасы да кайтып керде. Өендә чит кешеләрнең булуына бер тамчы да исе китмәде аның. Ләкин бераздан Бушковны танып алды:

– Әсәд! – дип кычкырды. – Син түгелме соң бу, шайтан малае?! Һаман да кемнәрнедер шигырь язарга өйрәтәсеңме? Үзең яза белмәгәнне...

– Өйрәтәм, – диде Бушков. – Менә таныш бул – Сәлим. – Аннары Сәлимгә борылды: – Фамилияң ничек әле синең?

– Не важно! – Хуҗа, килеп, ике куллап Сәлимнең уң кулын селкеп торды. – Тыңлама син боларны! Үзеңчә яз. Синең кебекләр миллион! Шигырь язучыны тәкъдир генә шагыйрь итә.

– Нәрсә соң ул тәкъдир? – дип сорады Сәлим.

– Менә, браток, анысын мин үзем дә белмим. Вакыты җиткәч, үзе белгертә ул.

– Сәлим, таныш бул, хәтереңдә калдыр, синең алда Казанның иң бөек рус шагыйре Винсент Макаров!

Бөек шагыйрь нәни генә буйлы ябык бер бәндә иде. Таушалган сырма кигән, төсе уңган ыштанының тез башлары сидрәгән... Кирза итектән... Сөйләшкәндә, сырма якасыннан башы өскә тибәрелә, ияге чөелә, ул мондый вакытта оясыннан чыгып очарга ниятләгән, ләкин әле очарга өйрәнмәгән чыпчык баласын хәтерләтә: менә-менә очып чыгар да җиргә егылып төшәр кебек. Ләкин Сәлим җаны белән сизде: бу дөнья кешесе түгел ул, кавырсыны ныгымаса да, тиздән тышка ташланыр һәм таш кебек җиргә мәтәлер. Аның язмышы шул. Ул үлгәнче чыпчык баласы булып калачак. Тәкъдир!

– Винсент әле бер атна элек кенә ЛТПдан[1] кайтты, – дип өстәүне кирәк тапты Бушков. – Әле ул безнең тормышка җайлашып җитмәгән.

– Юкка... – дип, чыраен сытып кулын селтәде тегесе, нәрсә инде аны сөйләп торасың дигәндәй. Анары Сәлимгә борылды: – Анда мин ара-тирә гел кереп чыгам. Алкоголизмнан дәвалыйлар. Кайчакта нәтиҗәле! – Һәм ул, сорап та тормыйча, тәрәзә төбендә торган шешәдән мул итеп аракы йотты. – Әйбә-әт!

Ишектән тагын кемнеңдер кергәне ишетелде.

– Фәрештәм! – диде Винсент, керүчене аяк тавышыннан танып. Һәм аракы шешәсен җәһәт кенә почмакка яшерде...

Юк, Сәлим әле дә аны оныта алмый: япь-яшь кенә кыз иде ул; килеп керүгә үк мескен өй эченә нур тулгандай булды. Инде әллә кайчан булган хәлләр, ләкин вакыт пәрдәсе куерган саен шулай ап-ачык, яп-якты килеш күз алдында басып тора ул. Киемнәре истә түгел инде, алар гади дә, үтә зәвыклы да иде төсле... Кыз шулкадәр зифа, сылу, әйтерсең лә бәллүрдән коелган, соры-фирүзә карашын урап алган уктай керфекләре чәнчеп тора, сап-сары чәче иңбашына шарлавыктай агып төшкән. Сул кашы өстендә нәзек кенә, кыйгач ай җепселе сымак кына җөй дә бар – бала чагында егылудан калдымы икән... Күктән җиргә егылганда шундый эз каламы соң әллә? Җөй аның йөзенә кабатланмас гүзәллек өсти иде.

– Фәрештәм! – дип кочагын җәйде шагыйрь.

Ләкин кыз аның янына килмәде, Сәлим кырына караватка утырып үксеп елап җибәрде. Кулын өскә күтәрде, озын ак бармаклары ярым караңгылыкта үтә күренмәле кебек... үзәкне өзәрлек сагыш төсле... дерелди иде...

Юк, моны ничек онытасың!

Кызы идеме ул шагыйрьнең, әллә, чыннан да, фәрештә идеме? Фәрештә булгандыр, чыннан да, мондый алама ир-аттан андый сәмави кыз ничек тусын?!

– Без бит килешкән идек, – диде ул, ничектер сабыйларча ачыргаланып. – Син бит сүз бирдең!

Ул, җавап та көтмәстән, җәһәт кенә урыныннан торып, яшерелгән шешәне тәрәзәгә томырды, туры китерүен кара: шешә карындыкны ертып, тышка очты.

Шагыйрь ике кулы белән битен учлап, почмакка борылды. Анда кемдерме, нидерме бар сыман иде.

– Кичер мине, Фәрештәм! – диде шагыйрь.

Кыз, килеп, аның иңеннән кочты. Иңенә аскан киндер капчыгыннан алып, аңа кәгазь кисәкләре сонды:

– Менә яңа шигырьләрең...

Шагыйрь мәрткә киткән кеше кебек карават янына юнәлде, иелеп, кәгазь кисәкләрен чемоданына тыкты.

– Соңрак укырмын, – диде ул, иреннәрен чак кыймылдатып.

– Укырсың... – Кыз чакырылмаган кунакларга ымлады – тик боларга укыма, боларга андый шигырьләр төс түгел!

[1] ЛТП – лечебно-трудовой профилакторий, Совет заманында эчкечеләрне дәвалый торган урын.

– Әйе, бу шигырьләр үзем өчен, бары минем өчен...

Сәлим белән Бушков, аяк очларына басып, үзләрен чиксез гаепле хис итеп, алачыктан чыгып киттеләр.

Әлеге вакыйгадан соң Сәлим шигырь язудан туктады...

Каһвә, чынлап та, шәп, затлы иде. Исеннән генә дә чебеннәр очышта килеш егылып төшәрлек. Тик монда алар юк, көзге зәһәр чебеннәргә биш йолдызлы отельләрдә юл ябык. Талгын музыка тавышы колакны иркәли, каһвә уртлап куйгач, Сәлим озынча бокалдан салкынча су йотты. Тәм бүтән! Каһвәнең әчкелтем тәме контраст булып бөтен кан тамырларына тарала. Ләкин аңа рәхәтлектән изрәп озак утырырга туры килмәде, лобби-барга зәңгәр халат кигән җыештыручы хатын килеп керде. Юантык, киң чырайлы, җәлпәк борынлы, төртеп тишкәндәй кечкенә яшел күзле. Мондыйлар Казан урамнарында меңнәр! Ләкин бу хатын аңа бик тә таныш булып тоелды. Сул каш өстендә җөй бар түгелме соң? Ахырзаман алдыннан кемне искә алсаң да, каршыңа килеп чыга диләр иде, шулмы соң бу?

– Обеденный перерыв! – диде хатын, идән чүпрәген чиләккә чумдырып. – Бер сәгатькә!

Сәлим күзен чытырдатып йомды. Аңына килгәндә, аңа бер сылу кыз иелеп тора иде. Соры-фирүзә карашлы, төз борынлы, уктай керфекләре йөрәкне чәнчеп ала... Сул кашы өстендә кыйгач ай җепселе. Сәлим йөрәген учлады.

– Фәрештәкәй!

Йөрәкне яндырып алган ут тиздән бөтен тәненә таралды. Күктән тавыш ишетелгәндәй булды. Чү, шигырь түгелме соң бу?!

...Кыз аның башыннан сыйпады.

– Алҗыгансың... Сиңа тынычлык кирәк!

Кирәк шул... Бик кирәк. Хатирәләргә шулай бирелергә ярыймы инде, йә? Бигрәк тә кайчандыр шигырь язган кешегә?

Аның өчен дә чөнки... чөнки... шагыйрьләрнең элеккесе булмый.

# КЫЯР ИСЕ

Әбиләр чуагы бу! Нигә шулай дигәннәрдер... Әбиләрнең картаясылары килмичә, чуак көннәрдә соңгы ымсынулары белән бәйлеме икән? Шайтан белсен... Күктә төсен җуя барган кояш елмаеп азаплана, юл кырыйларына утыртылган карамаларның алтын йөгертелгән яфраклары җил искәнен көтеп тын калган, тиздән алар урам себерүчеләрне мәшәкатьләп, тротуарларда кырын ятар, сүрән кулларын сузып, узгынчылар аяк астында нидер пышылдап калыр. Әнә берничәсе инде җирдә ауный, сары суккан йөзләрендә кызгылт тимгелләр.

Көз...

Әнвәр, кибетне урап, үзләренең ишегалдына керде. Алар өе каршында өянке, иелеп, янәшәдәге миләш агачына нидер сөйләп тора сыман иде. Миләшнең яфраклары әле ямь-яшел, җимешләре кып-кызыл, ә өянке

инде көзне үтеп бара; шулай... һәркемгә көз төрлечә килә, үз вакыты белән.

Хатыны өйдә иде, иренең төмсә йөзенә игътибар итеп, сораулы карашын төбәде. Әнвәр исә дәшми-тынмый чишенде дә кабинетына кереп китте. Беркем белән сөйләшәсе килми иде аның, беркемне күрәсе килми иде. Беркем дип... шул хатыны белән инде. Ике баласы күптән ике якта, үз тормышлары белән яшиләр. Улы монда, Казанда әле, муеннан мәшәкатьтә, онытканда бер шалтыратып ала, хатыныннан зарланып башлый, тиргәп сүзен тәмамлый. Кызы, бер нефтьчегә кияүгә чыгып, бөтенләй Себергә китеп барды. Кайчагында шалтырата, ирен мактаудан башлый, күккә чөеп тәгәлли. Әйбәт инде!

Ул, язу өстәленә нәфрәт белән карап, кушеткага ятты, түшәмгә төссез күзен текәде. Анда өтергә тартым бер эз бар... өтерме соң ул, әллә инде бөкрәйгән куянга охшаганмы, кайсы ноктадан карыйсың... кәефсез чакларда ул гел шуңа карап ята.

– Нәрсә булды? – дип сорады хатыны, ишектән башын тыгып.

– Булмады, – дип, Әнвәр стенага борылып ятты.

Нәрсә әйтсен? Бүген аны эштән кудылар. Юк, беркем дә аңа дорфа сүз әйтмәде, намусына кагылмады. Институт директоры хәтта уңайсызлангандай, күзлеген салып, озак кына пыяласын кер дә кунмаган ак кулъяулыгы белән сөртте, мәш килде. Ә кечерәеп калган күзе шундый мәэсүс карый иде. Мәэсүс... менә бит нинди сүз...

– Поймите нас правильно, Анвар Хакимович, – диде. – Без...

Нәрсәсен аңлыйсың?! Аларның бөтен институтын куып таратсаң да, дәүләткә бернинди зыян булмаячак, ә файдасын кемдер күрергә мөмкин. Эш шуңа бара. Һәрнәрсәдән файда, керем эзләүчеләр заманы.

Ул, кулын күтәреп, директорны сүздән туктатты:

– Мин барысын да аңлыйм, – дип, үз теләге белән китү турындагы гаризасын сузды. – Миннән башлавыгыз бәлки әйбәттер дә... Яшем дә бар...

Илле яшьтә гомер буе эшләгән урыныннан китү җиңел түгел, әлбәттә. Директор үзе җитмешне узган иде, аның хәлен аңлагандыр, юаткандай кыланып:

– Эшсез калмассыз... Сез але сравнительно молодой. Дерзайте! Миңа әле соңыннан спасибо скажете, – дигән булды.

– Бик ихтимал, – дип, Әнвәр торып басты. Тагын ни әйтсен? Сипкелле чыраена мыскыллы елмаю элеп, чирек гасыр бергә эшләгән директорына кул да бирмичә, кабинеттан чыгып китте. Эшләгән дип инде... эшләп маташтылар анысы. Директор ничектер, ул үзе гел саннар дөньясында гомер кичерде, бер тәрәзәле тар гына бүлмәсенә кайчан килеп керсәләр дә, аны һәрвакыт таблицалар, төрле формулалар тулы ватман кәгазьләргә күмелеп утырганын күрерләр иде. Үз эшенең кирәклегенә, мөһимлегенә чын күңелдән ышана иде Әнвәр. И-и, наив чаклар! Аның исәпләүләренә, фикер сөземтәләренә нигезләнеп, хезмәтне нәтиҗәле итеп (эффектив!) оештырырга тиешләр иде дәүләттә. Ахыры ничек бетүен хәзер инде һәркем үз күзе белән күрә... Эффектив бетте.

Хатыны акрын гына ишекне япты.

Бик озак ятты Әнвәр, чигәсенә тибеп торган «нишләргә?» дигән гаҗиз

тинтерәүне исәпкә алмаганда, башына бер уй кермәде. Кая барып, кемнең ишегенә сугылырга? Кемгә кирәк ул, аның һөнәре, сәләте, белеме кемнәргә хаҗәт?

Әллә соң сугышка китәргәме? Контракт төзесәң, яхшы гына акча да түлиләр икән... Тик бит менә саулык кына... Ул калын пыялалы күзлеген рәтләп куйды. Аны яшь чакта да армиягә алмаганнар иде. Хәзер инде анда ул ни эшли алсын? Бу яшьтә... Хәер, хәзер сугыш та бүтәндер, бәлки; штык атакасына барасы юктыр. Штабта эш булырга мөмкиндер дә... Тик анда да әлеге дә баягы шул ахырзаман санагын, ягъни компьютерны белергә кирәктер шул!

Аның күптән инде телевизор караганы юк, интернет белән дә дус түгел... Ләкин тиздән өйрәнәсе булыр, шайтаныма барасыңмы? Эшсез-нисез ничек көн уздырмак кирәк? Пәрәвездә чәбәләнү ләззәтен кичерәсе бар әле, чуртуматыр! Бәлки берәр рәт чыгар... Юкка гына барысы да шуңа капланып ятмас иде. Нигә блогер булып китмәскә, ит-ти-тит?! Башы булган кешегә анда миллионнар эшләргә була, имеш. Ә Әнвәр Хәкимович үзенең башы нәкъ үз урынында булуына иманы камил иде.

Ишектә тагын хатынының йөзе пәйда булды.

– Сиңа әйтәм... нәрсә балтаң суга төшкәндәй ятасың? Чык, әйдә, тамак ялгап ал!

– Әнвәр кулын гына селтәде. Ашау кайгысымы монда? Киләчәктә нишләргә? Ничек тормыш итәргә? Уйлыйсы бар, уйлыйсы...

– Малай, былтырмы соң, ноутбугын калдырып киткән иде, өйрән дип...

Хатыны тагын йөзен сузып, аңа төбәлде. Чиктән тыш гаҗәпләнгәндә, ул гел шулай итә.

– Нигә ул сиңа?

– Өйрәнәм! Динозавр кебек яшәп булмый бит инде, наканис!

Хатыны кайдандыр тиз генә ноутбук алып керде. Капкачы дымлы, яңа гына тузанын сөрткән. Әнвәр көчәнеп кенә урыныннан торды. Хатын һәмишә, кулын бөеренә терәп, аңа карап тора иде.

– Бар! – дип ишеккә ымлады Әнвәр, син әлегә мишәйт кенә итәсең, янәсе.

– Күптән кирәк иде! – дип, хатыны чыгып китте. Өстендә иске ертык халат, сирәкләнеп калган аксыл-сары чәч учмасын резинка белән арттан бәйләп куйган. Аягында тапталган башмагы... И-их дип куйды Әнвәр Хәкимович үзалдына. Үтте гомер, үтте. Хәзер инде бернишләп булмый, булмый, шайтан алгыры!

Аш бүлмәсеннән килгән тәмле минтай исе ишек ярыгына кысылып калды.

– Күптән, күптән... – дип мыгырданды Әнвәр һәм ноутбукның капкачын ачты.

Кара экранга карап, озак утырды ул. Ничек язалар әле мондый очракта? Әйе, әйе, дөрес язалар – бөтен гомере күз алдыннан үтте аның. Балачагын искә төшереп тормады, күп кешенеке кебек аның да балачагы сизелмичә үтеп китте – гамьсез, ваемсыз чак... Сәлимә белән ул студентларның тулай торагында танышкан иде. Нинди кыз иде бит! Шаян, чая, чәчрәп тора инде менә. Аңа кызыгып йөрүчеләр,

сүз кушучылар күп булды. Ә ул мокыт кына Әнвәрне сайлады. Гаҗәп! Мәхәббәт булгандыр инде бу аның тарафыннан. Югыйсә Әнвәрнең шәрикләре арасында үткен, ушлы егетләр күп иде. Берсенә дә карамады Сәлимә. Тулай торактан ерак түгел «Мир» кинотеатрына барганда култыклап алды да бүтән яныннан җибәрмәде.

Яхшы яшәделәр. Җайлы хатын булды Сәлимә, яманлап сүз әйтерлек түгел. Беркайчан да чыгырдан чыкмады, кызып китеп, әллә ниләр әйтеп ташламады. Хәер, аралар бозылырга сәбәп тә юк иде, Әнвәр беркайчан соңлап кайтмады, күп сөйләшмәде, хезмәт хакын тиенenә кадәр хатынына кайтарып бирде. Өй кошы иде ул. Бик тә, бик тә пар килгән иде алар бер-берсенә. Олыгая төшкәч, холыклары да шулкадәр бер-берсенә тәңгәл килә башлады, ул гынамы – читтән караганда, кыяфәт белән дә алар бер-берсенә охшаш иделәр! Игезәкләр диярсең! Икесе дә тормыш итүдә тыйнак, дәгъвасыз, азга да риза булып көн итүчеләр затыннан иде. Сәлимә мәктәптә укыта, аның да кереме Әнвәрнеке белән бер чама, шулай да моңарчы очын очка ялгап, җан асрый алдылар. Менә хәзер нишләргә? Әнвәр, имән бармагы белән төртеп, ноутбукны кабызды.

Әллә соң сугышка китәргәме дип, кабат үз-үзенә сорау бирде ул. Ләкин сорау өндәү түгел, битараф һәм төшенке иде, һәм аның тормышка ашмаячагы Әнвәрнең үзенә дә ачык иде.

Блогер булып акча эшләр өчен синең абунәчеләрең меңнәрчә булырга тиеш икән, башлы кеше буларак, Әнвәр моның коры хыял икәнен тиз аңлады. Әмма пәрәвез аны бичара чебенне эләктергән үрмәкүч кебек әсирлеккә алган иде инде. Аш бүлмәсендә тиз-тиз генә тамак ялгап, хатыны белән бер сүз дә алышмыйча, ул үз бүлмәсенә, ноутбугы каршына ашыга, йоклаганда да шул кара тартманы кочаклап ята торган булды.

Һәм шул пәрәвезнең ниндидер тылсымлы җепселләре аша аңа мәхәббәт килде!

Мәхәббәт... Әнвәр өчен өр-яңа хис иде бу. Хатын-кызга шундый тартылу хисен моңарчы аның беркайчан тойганы булмады. Менә... килде бит, Ходайның хикмәте. Компьютер дигән шушы нәмәрсә булмаса, мәхәббәтнең ни икәнен дә белмичә үлеп китәсе икән ләбаса. Алай да була. Андыйлар бик күп. Мәхәббәт өчен дә сәләт кирәк. Һәркемгә бирелми. Ә менә Әнвәргә ул сәләт бирелгән булган, ул вакыты җиткәнен көтеп, күңеленең кайсыдыр төбәгендә йокымсырап кына яткан икән, Адәм тәганәсе. Этеп җибәрүне генә көтеп яткан. Һәм шул этәргечне ул ниндидер бер танышулар сайтыннан тапты. Кызык өчен генә ул анда башлап үзе язды. Күңеле тулып ташыган чак иде, кызып китеп, бар тормышын тасвирлады: ялгызлыгын, чарасызлыгын, алда берн инди яктылык булмавын... «Мине кызганмагыз, киңәшләр бирмәгез, – дип, таныш булмаган ханымга эндәште ул. – Миңа сердәш кенә булыгыз, мин дә сезгә иптәш булырга тырышырмын. Бер-беребездән берни таләп итмичә, читтән торып бер-беребезгә юату сүзләрен әйтик».

Мондый эчкерсез сүзләрдән соң исемне дә атарга кирәк бит инде. Үз исемен әйтергә ул кыенсынды, әлеге язма таныш-белеш кулына керсә, бөтен дөньяга оятка калуың да бар. Әлбәттә, бу шәхси язышу, тик сакланганны Алла саклар дигәннәр бит. Совет кешесе буларак, «шәхси»

дигән сүзгә бик ышанып бетми иде ул. Алар яшь чакта «шәхсән» дип җыелышларда Брежневка гына мөнәсәбәт белдерәләр иде. Шул вакытта мөнәсәбәт белдерүчеләр үзләрен дә күпмедер шәхес дип хис иттеләр булса кирәк. Башлы кеше буларак, ул хәзер дә хәлләрнең әллә ни үзгәрмәвен сизенә иде. Шуңа күрә ул чын исемен белдермәде, үзен нигәдер Җамал дип атады.

Җавап озак көттермәде. «Сүзләрегез күңелемә кагылды, – дип язган иде таныш түгел хатын. – Сезнең хәлләтегез миңа бик якын. Сезне аңлыйм, йөрәгем белән аңлыйм. Читтән торып булса да, сезне юатасым килә. Мин инде яшь түгел, шуңамы ялгызлыкны сезнең кебек үк авыр кичерәм. Болай мин ялгыз да кебек түгелмен, ләкин иң тирән серләремне сөйләрлек кешем юк. Балалар таралды, үз тормышлары; иремдә минем кайгы юк, аның үз дөньясы, һәм ул мине үз дөньясыннан куып чыгарды. Әйдәгез, читтән торып булса да, бер-беребезне юатышыйк. Бәлки җиңел булып китәр... Ә минем исемгә килгәндә, мине Алия дип атагыз».

Алия! Төгәл фәннәр кешесе булса да, ә кем белә, бәлки нәкъ менә шуңа да – гомере буе саннар, диаграммалар белән әвәрә килгәнгә, фантазиягә бай кеше иде Әнвәр. Аның күз алдына моңсу, ләкин горур, әле төсен җуймаган ханым килә, ул затлы, зәвыклы киенгән... кызыл итекле... Һәм хыялланудан җиңелчә генә башы әйләнә башлый иде. Шуны туктатыр өчен ул аш бүлмәсенә чыга, хыял белән генә яшәп булмый! Бераз тамак та ялгап алырга кирәк. Дөресен әйткәндә, бик аз ризыклана иде ул. Иртән солы боткасы, төш вакытында йомырка тәбәсе, кичен... юк, кичен ашамый иде, сөтле чәй генә эчеп куя, күк чәй. Көтмәгәндә башы әйләнә башласа, бер касә су... Ә анда ертык халаттан хатыны әллә нишләп йөри. Аның да ашауга әллә ни исе китми. Алар бу яктан да бер-берсенә нык охшаш иде.

Охшавын охшаган, тик ир-ат хатын-кыздан барыбер ние беләндер аерыла. Ние дип, анысын инде һәркем белә, минем исә ни әйтәсем килә – холык димме, омтылышлармы, ирләрнеке үзләренчә, һәмишә борынгы заманнардан килгән инстинктлар кыймылдап куя әле аңарда. Таш гасырларда мамонт аулап йөргән чакларда барлыкка килгән сунарчы комары. Безнең чорда инде бу аермалык җуелган да кебек – ир-атның үзен аулаучы әллә нинди ерткыч хатын-кызлар бар. Әйе, әйе, үзе аучы, үзе ерткыч... Тик аларның җәтмәләре һәркем өстенә төшми, безгә кагылмый, алар бай ир-атларны гына аулый, имеш.

Ху-уш, менә шул комар уяндымы, үзе белән язышкан серле ханымны күрәсе килә башлады бит Әнвәрнең. Әллә ни өметләр дә багламый иде ул болай үзе. Мөмкинлекләрен белә иде... Күрешкәч, өстеңә төкереп китсә, нәрсә? Күзлекле, пеләш, өтек гәүдәле, кыска буйлы ир сәләмәсе. Баш бар анысы, тик аның белән генә ерак барып булмый хатын-кыз тирәсендә. Анысын гына белә иде Әнвәр.

Шулай да «Өметсез – шайтан» диләр бит, әллә соң очрашуга чакырып караргамы? Бик озак икеләнеп йөргәннән соң, язарга базнат итте ул: «Мин бернигә дә өмет итмим, – диде. – Без инде икебез дә яшь кешеләр түгел, икебезнең дә җәмәгате бар. Инде тәртип бозарга, уңга-сулга чалуларга ярамый. Шулай да халкыбызда бер сүз бар бит: бер күрешү – бер гомер

дигән ул... Әйе, минемчә, безгә дә бер тапкыр гына булса да, көрешергә кирәк». Аннары, озак кына уйлап торгач, үзенчә фәлсәфи итеп өстәде: «Кем белә, бәлки, бу көрешү безнең моңа кадәр яшәгән гомеребезгә тиң булыр?»

«Ай да, Пушкин, ай да, ...»

Җавап бер атнадан соң гына килде. «Мин озак кына икеләнеп йөрдем. Көрешү кирәкме икән дип... Ләкин барлык язганнарыгызны кабат укыгач, сезнең нечкә күңелле, тиз яраланучан кеше икәнегезгә тагын бер тапкыр инандым. Сезнең үтенечегезгә каршы килү үзе үк әхлаксызлык булыр иде. Көрешик, сөйләшик тә аерылырбыз. Мәңгегә...»

Казан үзәгендә Лядской бакчасында Державин һәйкәле янында көрешергә булдылар. Анда бик уңайлы эскәмияләр бар, ятларның игътибарын җәлеп итмичә генә, рәхәтләнеп сөйләшергә була.

Ә ничек таныр соң ул аны? «Күңелегез тартса, танырсыз!» дип язылган иде җавап хатында.

Кырынып, «Адмиралъ» одеколоны сибенеп, үтүкләнгән күлмәк киеп, чыгып китте Әнвәр өйдән. Әллә кайчан онытылган хисләр кайнады күкрәгендә. Алар бер тына, янәдән кузгалып, йөрәкне китереп кыса. Дулкынлану дигәннәре нәкъ менә шул буладыр инде. Көрешкәч, нәрсә дияргә? Әйбәт кенә яшәп ятасызмы дип булмый бит инде. Җырдагыча «Мин сине шундый сагындым!» дияргәме? Моңарчы бер тапкыр да күрмәгән кешене сагынып буламы икән соң? Озак уйлагач, «була!» дигән катгый фикергә килде Әнвәр. Чыннан да, ул бит үзен аңлаучы, хәленә керүче, кызгана белүче кешене сагынып яшәгән икән ләбаса. Ә Сәлимә? Яшьрәк чакта ул артык та хәленә кереп ташлый иде түгелме соң? Әйе, хәтта туйдырып бетерә иде. Ләкин хәзер шул алар икесе ике планета кебек. Һәрберсенең үз орбитасы. Якынлык, хөрмәт бар, билгеле, дип аклангандай уйлады ул, туганнар арасындагы якынлык кебек. Соң, сиңа тагын нәрсә кирәк, карт тәре, дип, эчтә бер сыек тавыш йөрәген сызлатып, бәгырен чеметеп алды. Әнвәр, аңа игътибар итмәскә тырышып, автобус тукталышына юнәлде.

Державин һәйкәле янына капылт кына барып басарга кыймады ул, урамның теге ягында читтән күзәтергә булды. Төшке унике туларга озак калмаган иде. Һәйкәл янында әле беркем дә күренми. Бәлки Алия килмәс тә әле дип өметләнде ул. Беркайчан да күрмәгән кеше белән «свиданье»гә килмәскә дә мөмкин. Бәлки берәрсе аңа шаяртып кына язып яткандыр? Кинәт ул Лядской бакчасы буйлап аллеядан килгән хатынын күреп алды. Башын аска иеп, моңсу гына атлап килә, җаныкаем. Әнвәрнең хатынын кызганудан йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Хатыны эшләгән мәктәп якында гына, төшке аштан соң йөрергә чыккандыр дип уйлады ул. Бөтен тәне эсселе-суыклы булды. Ниндидер ят хатын белән монда хәзер ничек көрешәсең? Бер елга якын өйдән чыкмаган ирен монда күреп, Сәлимәсе ни диярг дә белмәс. Юк, күрмәве хәерле. Һәм ул, кырт борылып, автобус тукталышына таба ашыкты.

Ә хатыны кичкә таба гына кайтты. Әнвәр түшәмгә карап яткан җиреннән колагын торгызды – озак кына чишенде Сәлимәсе. Гадәттәгечә, авыр сулады. Аннары аш бүлмәсенә узды. Газны кабызып, чәй куйганы ишетелде. Аннары шык-шык тавыш чыгарып, пычак белән нидер турый

башлады. Әнвәр бүлмәсенең ишеге чак кына ачык калган иде – ярыктан борынны кытыклап, кыяр исе килеп керде.

Кыяр исе!

Бөгәрләнеп яткан җирендә ул тагын да кечерәеп калгандай булды. Ирексездән сулкылдап куйды Әнвәр Хәкимович. Балачагы, туган авылы искә төште. Анда кайтмаганына да күпме еллар үткән. Аралар әллә ни ерак булмаса да, юллар өзелгән шул инде. Авылда инде аның бер якын туганы да юк. Әти-әнисе урта зиратта каеннар күләгәсендә. Вак-төяк мәшәкатьләр белән узган да киткән гомер дигәннәре. Авыл үзе дә бетеп бара бугай инде, егерме еллар элек соңгы тапкыр кайтуында бары тик бер урам калган, анда да җыен карт-коры гына яшәп ята иде.

Ни дисәң дә, хатирәләргә бирелү – олыгаю билгесе инде ул. Бер мизгел эчендә әллә кемнәр искә төште. Әтисе белән әнисе, җитәкләшеп, каршына килде Әнвәрнең. Чибәр кешеләр иде алар. Яхшы яшәделәр.

Әтисенең менә дигән яшелчә бакчасы бар иде. Җир җылына башлау белән ул, озын чокырга чи тирес тутырып, өстенә бер сөямгә якын туфрак өеп, кыяр утырта иде. Күпмедер вакыттан соң сыек яшел кыякларда кыярлар күренә, су сибеп торганда – анысы инде Әнвәр өстендә! – алар бик тиз өлгерә, сусылланып, сине чакырып тора. Әниләре шуларны икегә ярып, өсләренә тоз сибеп, арыш икмәге белән улына бирә. Кетер-кетер кыяр кимереп, шуны ипи белән сипләп куюдан да рәхәт ни бар икән малай-шалай өчен? Аны әле күрше-тирә малайларына да өләшәсең. Кыяр үстерүчеләр алар очында бөтенләй юк иде. Авылда булдымы икән әле? Яшелчә үстерергә хирыс түгелләр иде алар ягындагы халык. Кабартма белән елкы ите иде төп ризыклары.

Кыяр исе басылмады, киресенчә, көчәя генә барды. Әнвәрнең борын яфраклары дерелдәп куйды. Ул урыныннан торды да, каударланып, аш бүлмәсенә чыкты. Караса... анда әнисе пычак белән шык-шык итеп, кыяр турый. Янәшәдә түгәрәк арыш ипие. «Нишләп турый, ул бит аны урталай гына яра иде» дип уйлады Әнвәр. Тик моңа җавап табарга вакыты юк иде, күзендәге яшен йотып, ул әнисенә омтылды.

– Әнием!

Әнисенең җиңел гәүдәсен кочагына алып, тагын сулкылдады:

– Әнием!



*Хөрмәтле әдәбият сөючеләр! «Кардәш халыклар әдәбияты» сериясендә күренекле әдипләр иҗатыннан үрнәкләр бирүне дәвам иттереп, Россиядә барган Гаилә елы уңаеннан журналыбызның бу санында сезне Карачай-Чиркәс Республикасыннан кызыклы бер гаилә белән таныштырырга уйладык. Сүз карачай-балкар әдәбият-сәнгатенең күренекле вәкиле, язучы, драматург, шагыйрь һәм карачай композиторы Альберт Магомет улы Узденов (1957) һәм аның җәмәгате Венера ханым гаиләсендә туып үскән өч шагыйрь – аларның балалары Рөстәм (1986), Фатыйма (1987) һәм Шамил (1990) Узденовлар иҗаты турында бара.*

*Шунысы кызыклы: әти-әниләре әдәбият-сәнгатьнең төрле өлкәләрендә бердәй осталык белән эшләгән шикелле, аларның балалары да тормышта әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итү белән бергә, уртак бер профессияне сайлап – юрист белгечлеге буенча югары белем алып, шул юнәлештәге эшчәнлек белән шөгыльләнәләр. Яшь араларында бер генә ел аерма булган абыйлы-сеңелле Рөстәм белән Фатыйма, 2003 елда Чиркәс шәһәрендә урта мәктәп тәмамлагач, Мәскәү Хокук академиясенең юридик факультетына укырга керәләр. Берничә елдан соң энеләре Шамил дә абый-апалары артыннан шул ук уку йортына имтиханнар тапшыра. Бүген алар өчесе дә шушы югары уку йортында алган белгечлекләре буенча туган якларында төрле вазифалар башкара.*



*Рөстәм Узденов академиядә уку елларында халык авыз иҗаты белән кызыксынып, карачай-балкар телендә булган мәкаль һәм әйтемнәрне туплау белән мавыга. 2014 елда Нальчикта «Таулы халыклар әйтемнәре» дигән китап бастырып чыгара. Узган ел аның 2014–2022 елларда язган шигырьләрен туплаган «Дустым белән әңгәмә» дигән китабы дөнья күргән. Рөстәм Узденов – Россия Язучылар берлеге әгъзасы.*

# Рөстәм Узденов

## Дүртьюллыклар

Беркайчан да белер-белмәс эш башлама,
Бер башласаң, кыен булса да, ташлама.
Суда битен каплап йөзсә әгәр инсан,
Көчәнсә дә, күп баралмас, шуңа ышан.

* * *

Кыен көндә аптыраудан артка чигеп калмаек,
Ачуланып, башкаларга гаделсезлек салмаек.
Кызып китеп, дөреслекне бозып, батмыйк гөнаһка,
Дөрес юлдан илтә безне, ышаныйк без Аллаһка.

* * *

Залимнәрнең кулларында булганлыктан хәнҗәр, ук...
Бу тормышның кануннарын төрләндерер чара юк.
Юктыр патша, юктыр бер хан аны үзгәртә алган,
Һәр нәрсәне тиешенчә көйлидер тик бар Аллам!

* * *

Койма эшләү инсаннарны яманлыктан саклаган,
Күпер эшләү – ике ярны бер-беренә ялгаган.
Тәртип булса, койманың һич кирәге калмас иде,
Күпер булмаса, дөньяда кавышулар булмас иде.

* * *

Сине күреп, җан җылысын әгәр бирсә,
Сине яхшы дусты кебек әгәр күрсә,
Син санама ул адәмне ялагайга,
Сиңа кирәк кеше итеп кара аңа.

* * *

Чистартмаган морҗаны гел корым басачак,
Чистартырга ялкауланган сәбәп табачак.
Өйнең эче корымланса, трубачыдыр ул,
Ялкаулану – кыргыйлыкка алып барган юл.

* * *

Буйсыналмый тәкъдиренә, булалмый разый,
Әгәр безгә күрсәтсә аз итеп күпне,
Һәр заманда басачак кайгы йөрәкне...
Азны күп итеп күргән – шулдыр бәхетле.

* * *

Бер дә юкка үрсәләнмә, кимсенмә һич син,
Зарланма да, кулың арык булса ул булсын.
Башкаларның бәхетенә куана белсәң,
Бәхетлеләр бәхетлесе – син, ышан, дустым.

* * *

Хаклыгыңа ышанмасаң, гаепләргә син ашыкма,
Һәрвакытта көндәшеңә нахак яла ягып була.
Гөнаһсызга салсаң аны газап-җаһил утларына,
Кыямәт көн нинди җавап бирәсеңне башта уйла.

***

Агып бетмәсен дисәң кувшинда суың,
Аның тишек түгеллеген тикшер иң элек.
Таныш булмаган затка ачсаң әгәр дә
Серең, бөтен дөньяга бетәр түгелеп.



*Фатыйма Карабашева өч бала – ике кыз һәм малай үстерә. Мәктәп елларында ук шигырьләр яза башлаган кыз Мәскәүдә укыган чагында «Карачай» газетасына үзенең беренче шигырьләрен юллый, шигырьләр белән бергә очерклар, мәкаләләр бастыра. Ул – олылар һәм балалар өчен язган шигырьләрен туплаган «Теләк», «Санау һәм язу» исемле китаплар авторы. Россия Журналистлар һәм Язучылар берлекләре әгъзасы булып тора.*

# Фатыйма Карабашева (Узденова)

## Начар бала диярләр

Кондызны, кортны сытып үтерсәң,
Песи, көчеккә кулың күтәрсәң,
Газонда йөрсәң чирәмен таптап,
Берәр кызчыкның толымын тартсаң,
«Начар малай бу!» – диярләр сиңа,
Уйныйк дип беркем килмәс яныңа.

## Ягымлы бул

Әниең белән кибеткә кергәч,
Сиңа ошаган уенчык күргәч,
Бирәсем килә сиңа бер киңәш:
Әниең белән ягымлы сөйләш.

Кибеттә йөргән башка кешеләр:
«Нинди акыллы малай!» – дисеннәр.
Шунда әниең моны күрәчәк,
Сиңа уенчык алып бирәчәк.

## Керпечек

Керпе-керпе, керпечек,
Борыны очлы ничек!
Энәле күлмәк кигән,
Курыкмый һичбер нидән.
Аннан куркып, бер читтән –
Карап тора көчек тә!

## Таза җан

«Нәрсәдә дип бу яшәүнең мәгънәсе?» –
Сорау бирә бик еш Хода бәндәсе...
Төрле булган кебек җирдә һәрбер җан,
Үзенчә бер җавап таба һәр инсан.


Кемгә – рухи байлык яшәү мәгънәсе,
Мал җыюда кайсыныңдыр фәтвасы.
Рәхәт гомер сөргән җирдә кем генә?
Кемдер тели җитәкчелек итәргә.

Алдамаган, урламаган, атмаган,
Акча өчен дип намусын сатмаган,
Хәләл эшләп, күпме кыен ашаган,
Шул инсан бу җирдә дөрес яшәгән.

Ата Йортын, туган илен бик сөйгән,
Милләтенең кайгысына бик көйгән,
Кирәк чакта Ата Йортын саклаган,
Ана телен, таза динен яклаган,
Бер Аллаһның берлегенә инанган,
Ул инсанда, һичшиксез, сау-таза җан.

## Гафу үтен

Тәртип бозсаң, укытучың орышса,
Бәхәсләшмә, акланырга тырышма.
Ялгыштым дип, гаебеңне таны да,
«Кичерегез, бүтән алай итмәм», – дип,
Гафу сора һәрчак аның алдында.



*Шамил Узденов мәктәптә укыган елларыннан бирле шигырьләр яза. Ул – дүрт китап авторы. Россия Язучылар берлеге әгъзасы.*

# Шамил Узденов

## Ватансызлык

Яшьнәде яшен, телеп күк йөзен,
Ярып тынлыкны, күкләр күкрәде.
Ярсып тибәргә тотынды йөрәк,
Ярып чыгардай булып күкрәкне.

Әй, коя яңгыр, әй, коя гына!
Ант эчкән кебек һич туктамаска...
Әй, күкри күкләр, өметен өзеп
Куанган җанның, «Чыктым дип язга!»

Тәкәббер яшен күкләр күкрәтә,
Ява күк күкрәп яшенле яңгыр.
Яралы йөрәк сыкрый, сыктый,
Ватанын җуйган йөрәккә авыр.

## Тау җырын тансыклау

Машинада кайтам Прагадан...
Радиода нидер гыжылдый...
Җилдә җилферди җилән итәге.
Карачай чикмән тау җырын җырлый.

Машина шавы баса җил тавышын,
Чәчемне тарап исә җилләре.
Аһ, минем татлы сагышларыма
Киртә булгандай, телә йөрәкне.

## Акыллылык

*Мал – ашаган җиренә,*
*Адәм туган җиренә кайта.*
Халык әйтеме

«Ата йортым – туган җирем!
Йа Аллаһым, күрсәт юл!» – дип,
Унөч яшьтә өйдән киттем.
Сагынуларым аша йөреп,
Тәмам арып,
Ахыр чигенә җиттем...

Тик «тук эткә» әйләнмәдем.
Җир читенә җиталмадым.
Яхшымы-яманмы булдым?
Космополит италмады.

Сагышларга тәмам батып,
Татлы хыял ташлап китте.
Ялгызлыкның чиге җитте.
Ялгызым күп михнәт чиктем...

Күпме гизеп, дөнья йөзен
Атам йорты италмадым.
Атам-анам, якыннарым,
Каберен ташлап киталмадым...

## Үзем белән калыр сагышларым

Булмаса бу җир йөзендә таянычым,
Күпме генә җәелсә дә куш-кочагым,
Ата йортым үзенә гел дәшеп тора,
Шигырьләрем тынгысызлый һәрчак җаным.


Җаным минем, утарыннан адашкан бер
Бәрән кебек, аерылса да тән-санымнан,
Гел үлемсез булып калыр, аерылмас
Атам-анам сөйләшкән тел-учагымнан.

## Бер көч

Яшьлегемдә чит җирләрдә күп йөрдем,
Ерак-ерак кыйтгаларны күп күрдем.
Яңа йортлар күрергә гел омтылдым,
Күз күрмәгән урыннарда күп булдым.

Тукталырга инде хәзер исәбем.
Китте тәннән элекке хәл-көчләрем.
Үтте вакыт, кердем гомерем көзенә,
Килер кебек күренми яз күземә.

**Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре*



*Айдар Нуриев Актаныш районының Югары Гәрәй авылыннан. 2004 елда Такталачык урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт техник университетының Түбән Кама шәһәрендәге филиалына укырга кереп, аннан инженер-энергетик белгечлеге алып чыга. Бүгенге көндә Түбән Камада яши, эшкуарлык белән шөгыльләнә.*

Айдар
Нуриев

# ТАВЫК ЭШЕ

хикәя

Участковой Фидәис Мәргүбкамал карчыкның йортына җырлый-җырлый килеп керде. Кәеф яхшы, күңел күтәренке:

Э-э-э-э-э-эй, дүртпочмаклы өстәлләрне,
Э-э-э-э-э-эй, түгәрәк итик әле...

Беренче эше тавык урлауны тикшерүдән башланыр дип күз алдына да китермәгән иде – язмыш шулай кызык итәргә булгандыр, күрәсең. Икенче яктан, ярамаган ни – безнең ише югары белемле эспециәлистләргә тавык ни дә сарык ни. Заманча тикшерү ысуллары белән теләсә нинди җинаятьнең очына чыгарга була ул!

Менә сиңа мә-ә-ә! Менә сиңа дүртпочмаклы өстәл, чынлап та. Әллә мине табын әзерләп көткәнме бу Мәргүш?! Булмас, булма-а-ас – берәр кунак көтүедер.

Ни дип дәшәргә белми, бераз гына азапланып торырга туры килде. Югыйсә өйрәнелгән кечкенәдән үк – Мәргүш, Мәргүш... Кемнең алмасын урлыйбыз – әйдә, Мәргүшнекен; кемнең бәрәңгесе күмер астына озатыла – Мәргүшнеке, әлбәттә!..

– Әйбәт кенә әле... кем... Син кем буласың соң әле?

Менә сиңа мә монысы, чынлап та! Үзе тавыгымны урладылар дип, участковой чакырта, үзе, килгәч: «Син кем соң?» – дип торган була!

– Участковойны кем чакыртты соң, Мәргүб түти? – Үз-үзен мәҗбүриләп булса да, Фидәис елмаеп куйган булды.

– Мин бит үзебезнең участкайны чакырткан идем, кемне әле... Рәисне.

– Үзебезнең участкай хәзер мин булам, Мәргүб түти.

Фидәис, соңгы көчен җыеп диярлек, тагы бер елмаеп куйды. Юк, юк, ялгышлык булды, ахры, гомерлек хезмәт юлыңны Мәргүш эше белән башлау.

– Бәт-тәч икән! – Мәргүбкамал карчык урындыгына «шап» итеп утырды да, тагы да ныграк тавыш чыгарып, ботына сугып куйды. – Рәискә берәр нәрсә булдымы әллә?

– Аңа берни дә булмады, Мәргүб түти, ул пенсиядә хәзер. – Фидәис, өрҗяңа, кара күннән тегелгән папкасын ачып, протокол тартып чыгарды да: – Хәзер мин аның урынына. Йә, сөйлә соң – кайчан, кайда, ничек дигәндәй... тавыгың ничек югалды?

– Бәт-тәч икән! – Мәргүбкамал карчык, баягыдан да көчлерәк итеп, тагын ботына сугып алды. – Ә син кайсы авылныкы соң, улым?

Ялгышкан Фидәис, ялгышка-а-ан беренче эшендә үк Мәргүшкә килеп. Әнисе элек үк әйтә иде – ерак юлга чыкканда, каршыңа Мәргүш очраса, хет төкерен шунда, хет төкеренмә, юлың барыбер уңмаячак ди торган иде. Шул Мәргүшнең йортына үз аякларың белән килеп кер инде!

– Мәргүб түти, танымыйсызмыни мине? Көтүче таягы белән арт ягыма тамызганыгызны һаман да бик яхшы хәтерлим әле мин. – Юк, юк сезне гаепләмим дигәндәй, бераз сүзсез торгач, тагы өстәп куйды Фидәис. – Соң, үземдә инде гаеп... Ну, ярар ла соң, ничек анда тавык белән?

Мәргүбкамал карчык, эчкә баткан күзләрен бер чекерәйтеп, бер түгәрәкләндереп, Фидәискә карап торды да:

– Кем малае соң әле син, улым? Аның күзе дә бит хәзер...

Кем малае, кем малае... Тиз генә котылып булмас, ахры, бу тозактан. Хәзер, кем малае икәнен белеп алса, әби-бабайларны сораштыра башлар инде... Әти-әниләрне «сикереп», бабайга күчсәм, тизрәк булыр, ахры.

– Әбүзәрнең оныгы булам... Чатан Әбүзәрнең. Кайчан урладылар тавыгыңны?

Фидәис соравын кычкырыбрак биреп караса да, ярдәме тимәде. Мәргүбкамал карчык, берара аның йөзеннән таныш чаткылар эзләгәндәй, күзәтеп торды да:

– Бәт-тәч! Әбүзәрнең оныгы буласыңмыни син?! Әйтәм аны... Син аның кайсы малаеның малае буласың соң әле?

Мәргүшнең йөзе җанланып китте. Беренче карашка бигрәк тирән күренгән җыерчыклары да сөйкемле генә икән. Батты Фидәис монда кереп, батты-ы-ы! Кайсы мәхлугына кирәк булган инде шушы Мәргүшнең тавыгы?!

Ярый элек, Фидәис үскәндә, тавык урлау гадәти хәл кебек иде аның ише яшүсмерләргә. Хәзер бит инде аның яшүсмер дигәннәре дә телефоннарыннан аерыла алмыйлар...

– Төпчек малаеныкы булам, Мәргүб түти. Әйдәгез... Тавык эшенә әйләнеп кайтыйк әле.

– Бәт-тәч... Теге чибәр киленнеке буласыңмыни?!

Мәргүш каршында югары белемең дә көчсез, ахры...

– Әйе, әйе! Тавык эше көтә, Мәргүб түти. Та-вык эше-е-е!

– Берсендә, апаем, чибәр килен белән икебезне сарыкларны алып кайтырга җибәрделәр болынлыктан. Ул чакта килгән вакыты гына булгандыр әле...

О-о-о... башлады бит бу. Юк, юк! Мәргүшкә бер хут бирсәң, тиз генә туктатырмын димә! Төбеннән үк «кисеп ташламасаң», кичкә кадәр шушында утыртыр!

– Мәргүб түти, Мәргүб түти! Гафу итегез, әлбәттә, тик мин монда эш буенча кердем! Тавыгыңны урладылармы?! Кайчан урладылар?! Урланганын кайчан сизеп алдың?!

Менә шулай менә! Сорау алуның менә шундый ысулы да бар аның – һич көтмәгәндә, тиз-тиз генә сораулар бирә башладыңмы – югалып калган кеше җавап бирми кая китсен! Алдашмыймы, дөресен сөйлиме – анысы да сизгер тикшерүченең игътибарыннан читтә калмас.

– Тавыгымны урладылармы дип соң... урладылар инде, урладылар... Кечатна көнне... әйе.

– Бер тавыкны гына алганнармыни?! Тагы берәр нәрсә югалган идеме?!

Менә шулай, менә шулай! Лейтенант Хисмәтуллин җебегән түгел ул сиңа... Авызыңа карап утырырга!.. Мәргүбкамал карчык исә бөтенләй үк югалып калды. Сүзләре бер-берсенә беркеп чыга башладылар:

– Бетавыкнгна... Бетавыкнгна. Жук-жук... Бүтнбрәберндә... Бүтнбрәберндә...

Әллә арттырып ук җибәрдемме мескен карчык белән? Үлеп китмәсен тагы! Беренче эшеңдә Мәргүшнең башына җитсәң...

Алга таба «фән» дигәннәрең ничек эш йөртергә тәкъдим итә әле? Беренче эш артыгы белән эшләнелде, ызначится, башка ысулга күчәргә кирәк. Анысы – «урау-урау сорау» дип атала.

– Мәргүб түти, – дип сүзен башлады Фидәис бераз гына тынычрак итеп, тик сөйләшү тонын артык йомшартмады (анысын фән шулай куша). – Тавыгыңны урлаганчыга кадәр ничә баш тавыгың бар иде?

Җирдә озак гомер кичергән Мәргүбкамал карчык сөйләшүнең беразга гына булса да йомшара төшкәнен бик тиз сизеп алды:

– Ул тавыкларны мин, апаем, ун ел элек асрый башлаган идем. Туктале, минәйтәм, миннән ике яшькә картрак Өммекәшифә тавык саны арттырып ятканда, мин тик кенә карап ятарга тиешмени? Сарык бар чагында, тавыкка ушым китми иде минем, апаем, әйе. Өммекәшифәне өч ел элек җирләп куйдык инде, әйе, урыны оҗмах түрләрендә булсын...

О-о-о... тагы кереп китте бит бу! Фидәис, аптыраганнан, бераз ияген кашыштырып алды. Мәргүш инде ул арада тәмам элекке халәтенә кайтып өлгергән иде.

– Шуннан, апаем, ымы, нигә соң әле минәйтәм...

Фидәис салмак кына, шул ук вакытта көчле генә итеп, папкасын өстәлнең буш урынына чәпеп куйды. «Шап» иткән тавышка Мәргүш сискәнеп куйды да авыз эченнән генә нидер сөйләнә башлады. Әһә, белгән догасын укыштыра булса кирәк. Курку хисе тәмам таралганчы эшне тиз тотарга кирәк!

– Ничә тавыгың бар хәзер абзарыңда?

– Туг... тугыз... Сигез...

– Тугызмы, сигезме?!

– Әт... этәч белән тугыз...

Тагы агарына башлады... Туктатып торырга кирәк булыр сорау алуны. Бераз тын алсын инде. Шундый уйлар белән Фидәис Мәргүбкамал карчыкның йөзенә күз ташлады. Күз ташлады дип, ныграк игътибар итте...

Киң маңгай. Әллә кая тирәнгә кереп баткан яшелле-зәңгәрле күзләр. Киң борын... Бәрәңге борын диләрме әле? Бер сызык кебек кенә күренеп торган авыз... Ныклабрак карамасаң, иреннәре күренми дә икән бит моның. Алга чыгып торган ияк. Һәм җыерчыклар, җыерчыклар, җыерчыклар...

– Тә-ә-әк язып куябыз, алайса – сигез тавык, бер әтәч...

Фидәис язган арада, Мәргүбкамал карчыкка тагы җан керде булса кирәк – тынлык озакка сузылмады:

– Апаем, бу пуртфилне дә хөкүмәт үзе тапшырамы? – Сорауга җавап биреп торасы булмады. Бернинди паузасыз алга таба сөйләп китте Мәргүбкамал карчык. – Менә элек ничек иде бит ул. Утын кирәк икән – лесхуз ишеген таптап интегәсең. Печән кирәк икән – калхуз ишеген таптыйсың. Әгәр дә инде...

– Җитте, Мәргүб түти! – Кыяфәте дә сөйләменә туры килсен өчен, Фидәис торып басты да, өр-яңа костюмын сөрткәләп: – Мин монда, панимаетили, уен уйнарга килмәдем! Үзең әйтмешли, хөкүмәт эше белән килдем!

Әллә, чыннан да, Фидәиснең «командирларча» тавышыннан шүрләде Мәргүбкамал карчык, әллә «хөкүмәт» сүзеннән... Соңгысыннандыр, мөгаен... Ни генә булмасын – кыяфәте җитдиләнде, иреннәре, калтырансалар да, бер-берсеннән аерылмадылар. Ә инде яулык арасыннан бер колагын да «чыгарып» куйгач, Фидәис эченнән генә: «Вәт так-то», – дип куйды.

– Кайсы көнне урладылар тавыгыңны?!

– Кайсы көнне дип, соң... Кечатна булды микән...

– Язып куябыз – четверг көн-не-е-е, ызначится, өч көн элек. – Ничектер... ышандырырлык итеп әйтми әле бу. Югыйсә бит тугыз тавыкның берсе югалу аның өчен уен эш түге-е-ел. Кичен дә саныйдыр тавыкларын, иртәсен дә саныйдыр әле... Хм... Нидер ошамый әле миңа монда!

– Иртәнгә югалган идеме, кичкәме?!

– Иртән бит, апаем, мин бик иртә торам. Мин торганда, радиуга алып баручылар да килмиләр әле. Аннан киләләр инде алар. Ә алар килгәнче җыр гына җырлаталар. Аннан соңрак киләләр алар, апаем. Көтү чыгар вакыт җиткәч чыгам мин урамга. Алай көтүгә чыгарырдай малым юк инде, барыбер дә башкаларныкын үземнеке кебек озатып калам мин, апаем. Каршы алганда да шулай каршы алам. Өч көн элек Сәрбиләрнең чираты иде сыер көтүендә... бер килене генә килгән бу башка...

Фай-да-сыз... Криминалистикада Мәргүш өчен аерым ысул уйлап табарга кирәктер, күрәсең... Кинәт кенә Фидәисне «ток суккандай» булды. Ничә көн элек ди – өч көнме?!

– Мәргүб түти, ә тавыгыңны Сәрбиләр чираты узгач урладылармы, әллә инде аңа кадәрме?

Бу юлы Фидәис соравын бернинди җитдиләнүсез, гадәти сорау кебек кенә бирде. Мәргүбкамал карчык та бу үзгәрешне шунда ук сизеп алды – янәдән ике учын берләштереп, ике тезе арасына шудырды да рәхәтләнеп сөйләп китте:

– Сәрбиләр чиратына кадәр, Сәрбиләр чиратына кадәр. Ул Сәрбинең киленен әйтәм...

– Мәргүб түти, ә шулай да Сәрбиләр чиратына кадәр ничә көнләп булды икән?

Менә шулай бүлдерә-бүлдерә сөйләшсәң генә инде моның белән... Башкача булмас, ахры.

– Ике-өч булгандыр, апаем, әйе. Ике-өч көн булгандыр Сәрбиләр чиратына кадәр. Нәрсә сөйли идем әле мин?.. Ә! Сәрбиләрдән соң чират Хәсәншаларныкы бит инде...

Менә сиңа «Беренче чәчәкләр»! Картлык белән буталып сөйлиме кайчан тавыгы урланганын, әллә инде-е-е...

– Мәргүб түти, синең хәтерең шундый яхшы икән әле, әйеме?

Мәргүбкамал карчык җанланып ук китте. Кулын селтәп, «кет-кет» көлә-көлә:

– Кая инде, апаем, хәтер булсын минем яшьтә...

– Юкка алай дисең, Мәргүб түти, юкка-а-а. Менә мин сиңа бер сорау бирсәм – иманым камил, име – һичшиксез җавап бирәчәксең.

Фән буенча түгел, әллә ничек шунда... балаларча килеп чыкты инде бу... Тик шулай да Мәргүбкамал карчыкның йөзендә кызыксыну чаткылары күренде. Башлап карыйк соң... балаларча булса да, ярамаган ни? Нәтиҗәсе генә булсын!

– Менә әйтеп бир әле син миңа... – Мәргүбкамал карчыкның кызыксынуын тагы да арттырыр өчен, Фидәис берара сүзләрен һавада «элендереп» калдырды. – Кар эреп бетеп, тавыкларыңны беренче тапкыр ишегалдына чыгарганда, ничә баш тавыгың бар иде, ә?

Соравын бирде дә, сынаулы караш ташлагандай, маңгаен җыерып, Мәргүбкамал карчыкка төбәлде.

– Апаем, аның быел язы да әллә ничек кенә килде бит шунда. Инде матур гына карлар эреп бетеп килгәндә, тагы кыш килде бит! Ул мескен сыерчыкларны кире җылы якларга кайтып китмәсәләр ярый дип борчылган идем, ярый, калдылар инде. Менә элек – без яшь чакта – яз каршы алганда, име, апаем...

Фидәис учын маңгаена «шап» итеп сугып куйды да башын селеккәләп алды. Тагы алып кереп китте бит, ә? Бик тирәнгә өстерәсә, адашып калуың да бар – туктатырга тизрәк, туктатырга!

– Ну анысын хәтерлисеңдер, Мәргүб түти. Ә тавыкларыңны... җәй башында ничә тавыгың бар икәнен хәтерлисеңме соң, ә? – Та-а-агы бер кат маңгаен җыерып, башын бераз алга сузып, сынаулы караш ташлады Фидәис.

– Ничек шуны гына хәтерләмәскә инде?! Сигез тавыгым, бер әтәчем... барысы да исән-имин генә кыш чыктылар. Март башында буран котырган иде бит әле...

Менә сиңа «икенче чәчәкләр»! Юк, юк! Бутамый Мәргүш. Нәрсәне-нәрсәне – ә ничә тавыгы бар икәнен бутамы-ы-ый! Җәй башында да сигез тавык, бер әтәч... Хәзер дә сигез тавык, бер әтәч. Шулай булгач нәрсә килеп чыга – бер тавыгын да урламаганнар Мәргүбкамал карчыкның. Шулай булмый ни – кемгә кирәк аның ябык тавыгы, кибет тулы ит булганда?.. Төрлесеннән, причум. Кыргый җанварлар күптән якын килмиләр авыл тирәсенә, карчыгаларга да иртәрәк әле... Шулай булга-а-ач... хм – нигә кирәк соң аңа бу спектакль?

Ул арада Мәргүбкамал карчык һаман яшьлегеннән «кайтып кермәгән» иде әле, күрәсең:

– Тирес таптаганда, апаем, беләсеңме нинди җае бар аның?..

Тукта, тукта. Аңлашылды бит, барысы да аңлашылды бит! Тик... тик бер генә сорау бирәм дә менә:

– Мәргүб түти, Мәргүб түти! Карале минәйтәм... Синең ул тавыгыңны элегрәк тә урлаганнары бар идеме?

Мәргүбкамал карчык көтелмәгән сораудан югалып ук калды бермәлгә. Бер карасаң, гап-гади сорау кебек тә соң, тик менә Фидәиснең нәкъ шушы вакытта... Әле алай гына да түгел – нәкъ шушы мизгелдә бирүе – бу сорауны гадиләр рәтеннән бик югарыга күтәрә дә куя инде менә! Әле ничек итеп җаен китереп соравын әйт әле син аның!

– Булыштыргалады бугай инде, апаем. Участкай Рәис килештерә иде шул...

– Мәргүб түти, карале, минәйтәм. Ә менә... Рәис абыйның ничә тапкыр килгәнен хәтерлисең соңгы арада?

Мәргүбкамал карчык бераз гына уйга калды да, кулларын бер-берсенә ышкыштыргалап, сөйләп китте:

– Ничә тапкырын кем белгән инде аның, апаем. Шул язлы-көзле дип әйтимме соң...

Фидәис акрын гына торды. Ручкасын, тутыра башлаган протоколын дәүләт биргән сумкасына тыгып куйды. Аннан ашыкмый гына сумкасын япты. Шулай ук ашыкмый гына чыгып китәргә торган җиреннән торраташтай катып калды да, бер бармагын күтәреп, Мәргүбкамал карчыкка тагы бер сорау бирде. Бүгенгә соңгысыдыр инде:

– Мәргүб түти! Ә менә Рәис абыйның кайчан да бер синең урланган тавыгыңның очына чыга алганы булдымы?.. Кем урлаганын таба алдымы?

Бу юлы Мәргүбкамал карчык уйланып тормады. Ныклы, ышанычлы итеп:

– Юк, апаем, юк!.. Язганны күрми гүргә кереп булмый диләр бит. Шулай икән шул бит ул, шулай икән! Ничәнче еллар булды икән, анысын кем белгән инде аның... Минем Мөхәммәтнурым әрмиядә иде. Шул язган хатында: «И әни...», – дигән.

Мәргүбкамал карчык әллә Фидәиснең чыгып киткәнен сизми дә калды инде – урамга чыккач та, өй эченнән аның тавышы килә иде әле.

Хәзер туп-туры Рәис абыйның өенә барырга кирәк! Рәис абый – хөрмәткә лаек кеше, әлбәттә, тик менә шундый пүчтәк кенә эшнең дә очына чыга алмаган бит ул. Ә Фидәис нәрсә – беренче көнне үк чишеп атты Мәргүбкамал карчыкның башваткычын!

«Ну, Рәис абый, ну, Рәис абый!» – дип, эченнән генә кабатлый-кабатлый бара торгач, остазының йорты янына килеп тә җитте. Тагы бер тапкыр уй-фикерләренә кыскача анализ ясап алды да, элекке участковойның ишегалдына кереп, ишектәге төймәгә басты.

Остазының өйдә үзе генә икәнен белсә, басып та тормас иде, әлбәттә! Үзе генә түгелдер шул – кая китсен аның озын телле «еланы». Елан дигәне – хатыны. Кем кушкандыр андый кушаматны?.. Ялгышмаган, бер сүз белән әйткәндә.

Берникадәр вакыттан остазы – Рәис абыйсы килеп тә чыкты.

– О-о-о, Гринтамут килгән! – диде ул, ике куллап күрешеп. – Син нәрсә... звонокка басып кыланып торган буласың?!

Фидәис кулын селтәп:

– Урамда да рәхәт бит... Аннан...

Фидәис сүзен ничек башларга белми аптырап калды – килгән хутка ярып ташларгамы «чикләвекне», әллә?.. Нинди чикләвек диген әле син аны – Рәис абый үзе ничә еллар буе вата алмаган чикләвек бит ул!

Пауза озакка сузылгач, элекке участковой түзмәде:

– Йә, өйгә керик инде, әйдә. Апаң да өстәл тирәсендә бөтерелә иде. Йә, башла сүзеңне дигәндәй! Майлы күзләреңнән күреп торам – юкка килмәгәнсең бит.

Юкка түге-е-ел, Рәис абзый, юкка түге-е-ел. Хәзер күрсәтәм мин сиңа «гринтамут»ны. Тик ничек кенә башлап җибәрергә икән соң?.. Масаеп сөйлимме, әллә инде «карт бүре»не бераз кызганыргамы? Дүрт аяклы ат та абына бит дигәндәй...

– Рәис абый, монда гына сөйлим дә китәм мин – өеңә кереп тормам, рәхмәт.

– Үзең беләсең, үзең беләсең... Йә, ни бар анда?

– Мәргүб түтигә бардым бүген! – Фидәис урап йөрмичә генә, турысын ярды да салды: – Тавыгын урлаганнар менә.

– Ә-ә-ә... – Остазы шундук нәрсәдер әйтмәкче иде дә кебек, ахыр чиктә әйтми калды. Кулы белән ишегалларындагы эскәмиягә ишарәләде дә, икәүләп шунда барып утырдылар.

– Таптым бит мин ул тавык бурын! – Фидәис шулай диде дә, башын борып, Рәис абыйсының йөзенә карады. Тик, ни кызганыч, бернинди гаҗәпләнү дә күрмәде анда. – Таптым бит ул тавык карагын дим, Рәис абый!

– Йә, кем соң?

– Кызык булып киттеме әллә кем икәне?! Югыйсә бит практика үткәндә, мин бөтен архивны карап чыктым – анда бернинди дә «Тавык эше» юк иде. Ә Мәргүб түти әйтүе буенча син инде берничә мәртәбә... – Фидәис бераз гына кирәкле сүзен исенә төшереп торды да – Язлы-көзле! Әйе, язлы-көзле «Тавык эше» буенча килгән булгансың икән бит аңа.

Фидәис тагы бер мәртәбә остазының йөзенә күз ташлап алды – бераз гына булса да оялу, кыенсыну ише очкылар күренмәсме, янәсе. Ярар, ярар – таш кебек утырган бул әле – алга таба карарбыз!

– Тик менә, Рәис абый, практик яктан булган «Тавык эше», ә теоретик яктан беркая да теркәлмәгән.

Соңгы сүзенә арттырыбрак басым ясап, инде өченче мәртәбә карашын ташлады остазына – кая анда кыенсыну! Киресенчә, авызы ерыла башлаган әнә. Нидер әйтергә җыена, ахры. Әйдә соң, әйдә – тыңлап карыйк.

– Син, Гринтамут, мин ничә еллар буе булдыра алмаган эшне бер көндә булдырдым дип уйлыйсың инде, алайса?!

Үтерә инде шул «Гринтамуты» белән! Беренче көннәрне «Яшел пәмидур» дип йөртә иде... шаяртыбрак, әлбәттә. Бераз бер-берсенә ияләшә башлагач, ялварып сорады Фидәис остазыннан:

– Рәис абый, бер генә үтенечем бар – шуны эшли аласыңмы?

– Әйтеп кара соң – аннан ары карап карарбыз.

– Әйтмә әле миңа башка шул «Яшел пәмидур»ыңны! Берәрсе ишетеп алса, күп кирәкмени авыл җирендә?..

– Ярар соң, – диде дә башка алай дип эндәшмәде ул Фидәискә. Ә икенче көнне үк «Гринтамут» дигән кушамат тагып куйды. Монысы да шул ук «Яшел пәмидур», бары тик инглиз телендә генә... Кызы мәктәптә инглиз теленнән укыта – шуннан сораган, күрәсең...

– Йоклап киттеңме әллә?! Мактанырга килдең инде, ә? – Фидәиснең колагына җиңелчә генә чиртеп алды. – Истән чыккан бит сиңа Мәргүб түти турында алдан әйтеп куярга...

– Нәрсәне әйтеп куярга?! – Фидәис җанланып китте.

– Нәрсәне, нәрсәне – язлы-көзле шулай чакырта дип...

Ничек?! Әллә Рәис абый да белгән булганмы дөреслекне?! Алайса, нигә?..

– Ну... шуннан нәрсә?

– Ну-у-у... чуннан нәрчә? – Карт бүре бераз «попугайланып» алды да алга таба җитди генә сөйләп китте: – Беренче баруда ук белдем мин, кәнишне, тавыгын беркем дә урламаганын. Алга таба да шулай булды – җинаять эше юк, ә Мәргүб түти урлаганнар ди. Беләсеңме нәрсәгә чакырта? Ялгызлыктан тәмам интеккәч шулай эшли ул.

Кәшифә түти исән чагында бер-берсенә йөрешәләр иде, ул үлгәч йөрер кешесе дә бетте. Улы күптән үлде инде... Оныклары кайтмый. Кунак итәсе киләдер инде, күрәсең... Табын җәйгән булгандыр үзенчә...

– Бар иде шул табын дигәнең! Әйе!

– Вәт-вәт. Ә синең архивыңа килгәндә... Бернинди дә протокол язмадым, әлбәттә. Ярты елга бер сәгатем жәл түгел... үзебезнең авыл кешесе бит. Участковой гаилә конфликтларын җайга салырга тиешме? – Тиеш! Менә шулай итеп карадым мин бу эшкә... Син әйтмешли, «Тавык эшенә».

– Алай икә-ә-ән, – диде Фидәис, күңеле төшкәнен яшермичә. – Мин бит... мин бит башкачарак уйлаган идем.

– Үзенә әйтеп ташламагансыңдыр бит алай-болай?.. Мәргүб түтигә дим...

– Юк, юк, әйтмәдем! Мин... минем тизрәк синең янга киләсем килгән иде... Мактанмакчы булган идем...

Остазы тагы бер кат Фидәиснең колагына чиртеп алды да:

– Зыян юк, иптәш лейтенант! Барысын да белеп туып булмый инде ул. Теоретик белем әйбәт нәрсә, әлбәттә, тик... Тәҗрибә туплар өчен вакыт кирәк шул. – «Карт бүре» бераз гына, әйтергә микән, юк микән дигәндәй, «ык-мык» килеп торды да, – хет тугыз хатын белән йоклап чык бер төн эчендә – барыбер бер айдан бала тумаячак, энем. Бала өлгерсен өчен тугыз ай кирәк!..

Фидәис, Рәис абыйсыннан чыккач, акрын гына өенә таба атлап китте. Бераз баргач, үзе дә сизмәстән җыр сузып җибәрде:

> – Сукыр җырчы урам чатларында
> Җырлый дөньяларын оныты-ы-ып...



*Айгөл Баһавиева 1978 елда Әтнә районы Олы Әтнә авылында дөньяга килгән. Хәзерге вакытта Күәм авылында яшәп иҗат итә. Белеме буенча татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Әтнә районының «Изгелек» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгендә эшли. Шигърияткә балачактан гашыйк булса да, беренче иҗат җимешләре туучга уллары сәбәпче.*

Айгөл
Баһавиева

# КОЯШ ЭЛДЕМ МИН КҮГЕМӘ БҮГЕН...

## Эзләмәгез

Бизмәннәрга салып үлчәнмидер хаклык,
Ни рәвеше, ни бәясе сатлык...
Хәзер аны эзләмиләр киштәләрдән,
Бик күп булса, берәү алыр дистәләрдән.

Эзләмиләр аны, тапканнары – яшерәләр.
Аны эзләп керми күрше күршегә дә...
Кемгә кирәк, ята аунап, типкәләнеп;
Анда-монда йөреп беткән тишкәләнеп.

Кирәге дә инде аның шуның кадәр...
Хаклык эзләү, тапканнан да бугай хәтәр...
Эзләүчедән җыйнаулашып көләләр дә
Телен бикләп куйдыралар келәләргә...

Эзләмәгез! Юк ул хаклык дигәннәре!
Тапканнарның... хәзер башын игән мәле...

***

Көткән кешең кайта алсын өчен юллар кирәк.
Үткәннәрнең кадерен белер өчен еллар кирәк.

Хәтер сандыкларын актарырга уйлар кирәк.
Җимешләрне үрелеп өзәр өчен буйлар кирәк.

Нәни адымнардан эз салырга айлар кирәк.
Бер сукмактан тигез атлау өчен җайлар кирәк.

Усалларны бераз юмаларга көйләү кирәк.
Сансызларга аңлатырга мең кат сөйләү кирәк.

Авыр чакта дусларыңа иңне терәү кирәк.
Гомерлеккә янәшәңдә терәк – бирәү кирәк!

***

Мин күгемә бүген кояш элдем.
Әйдә, син дә шул җылыма килеп кара.
Талчыгудан гаҗизләнгән йөрәкләргә
Кояшымның кайнарлыгы булсын дәва.

Кояшымны кара болыт каплар диеп
Көткәннәргә минем инде бар җавабым:
Әгәр бер көн кояшымны сүндерсәгез,
Юлын табып, кабызырга көч табармын.

Кояш элдем мин күгемә бүген,
Җылынырга килгәннәргә күңел ачык,
Бүлешергә кояшымның нуры белән
Мин әзермен... көтәм сезне ишек ачып!

***

Тормыш ул – берьяклы озын юл,
Билетын кассадан сатмыйлар.
Йөкләрен күтәреп шул юлдан,
Кем ялгыз, кем парлы атлыйлар.

Катмарлы, ураулы юллардан
Атлавы, ай, авыр адашмый.
Кемнәрдер турыга юл таба,
Бер адым абынмый, ялгышмый.

Тезләрен канатып тузанда,
Берәүләр теш кысып түзәләр.
Кемнәрдер түмгәкне сикереп,
Берәүләр ташны да
Әйләнеп узалар.

Һәркемнең үз юлы, сукмагы
Кабатлап басылмый адымнар.
Кемгәдер юл чаты – тукталыш,
Берәүгә атлыйсы
Меңләгән адым бар.

***

Исләремә төшә гамьсез чагым:
Офыкларда кояш сүрелгәч,
Әй йөгерә идем каршыларга,
Чат башында әткәй күренгәч.
Балта тоткан көчле кулларына
Алыр иде әткәй кочаклап.
Сагыз исе, агач исе тойсам,
Сагындыра кабат шул чаклар.
Куанычым чиксез иде, әткәй,
Синең кызың булу – горурлык!

Адымнарым чутлап саный идем,
Тигез атлап, сине куарлык.
Йомычкалар уйнап калыр иде
Әткәй юнган агач өстеннән.
Син ясаган тәрәз йөзлекләренең
Борма бизәкләре исемдә.
Их, әнә шул әткәемле чаклар
Бәхетләрнең булган олысы.
Учларымда һаман тоям төсле
Әткәй кулларының җылысын.

***

Каеннардан тамчы тамган чакта
Елый икән диеп уйламагыз!
Ходай кушса, бар да яхшы булыр.
Булмастаен, зинһар, сорамагыз!

Каеннардан тамчы тамган чакта,
Коеламы икән яфраклары?
Каерылып озак карап тордым
Һаваларда казның кыйгаклавын.

Каеннардан тамчы тамган чаклар
Йөдәтерләр кереп төшләремә.
Җитез җилләр белән куышканым
Төшәр әле озак исләремә.

Каеннардан тамчы тамган чакта
Җилләр тирбәтәдер алкаларын.
Насыйп булса, тиздән күрешербез.
Ачык калдыр, әнкәй, капкаларың.

## Яхшылыкның яралары калмый

Яхшылыкның яралары калмый...
Шуңадырмы, тиз оныта кеше.
Истә калмый кемдер өчен янып
Әйткән сүзең яки кылган эшең...

Яхшылыкның яралары калмый...
Әрнеп өзгәләми, өтми җанны.
Тиз югала кеше хәтереннән,
Артык азапламый саркып каны.

Яхшылыкның яралары калмый...
Бары беленмәслек җылы кала.
Шуңа микән, әллә шуңа микән,
Изгелекләр онытыла бара.

***

Мин көзләрне сөймим бүтән, көзләр елак...
Адымнарга сарган яфрак кала елап.

Мин көзләрне сөймим бүтән, көзләр усал...
Җиле назлап исәр иде юаш булса.

Мин көзләрне сөймим бүтән, көзләр башка...
Сурәт калмый эзләремнән юеш ташта.

Мин көзләрне сөймим бүтән, көзләр хәтәр...
Көннәр туса, килгәне юк юньле хәбәр.

Мин көзләрне сөймим бүтән, кышны көтәм.
Әрсез тамчы җавап яза: тиздән китәм...

## Син китәсең...

Аэропортның салкын диварының
Эретмәкче булып бозларын,
Минем сөю яңгыр булып ява,
Оныттырып йөрәк сызлавын.

Син китәсең... бер сәгатьтән күккә
Күтәрелер синең очкычың.
Күзләреңне миннән алмасаң да,
Элеккечә инде кочмыйсың.

Син китәсең... Минем йөрәк тибә,
Сәгать телләренә ияреп.
Сөюемнең соңгы мизгелләрен
Дога итеп ятлыйм, инәлеп.

Син китәсең... Аэропортта бүген
Мин калырмын ялгыз сөялеп.
Безнең сөю яңгыр булып явар,
Күктә болытларга ияреп...



Гөлнара
Гыйлемханова

# ПАРЛЫ БИЮ

ХИКӘЯ

Талгын гына музыка башлангач, өстәл янында утыручылар берәм-берәм биюгә төште.

– Әйдә! – диде Әхәт, Илгизнең аркасына кагылып, һәм тар өстәл арасыннан узып, Альмирасын чакырып чыгарды. Тегесе иркәләнеп кенә, аның муенына асылынды, музыка көчәюгә, бөтерелеп биеп тә киттеләр. «Килештерәләр инде!» дип уйлады Илгиз.

Аларга уң як күршеләре Рөстәм белән Сания да кушылды. Карале, олпат гәүдәле ир янында Сания нинди бәләкәй генә калды! Рөстәм аның билләренә үзенең көрәк кадәр олы кулларын куйган. Иренең тау кадәр корсагы комачаулыйдырмы, Сания иреннән читтәрәк йөргән кебек, куллары да Рөстәмнең иңнәренә тияр-тимәс кенә тора. «Читтән карап торсаң, бик көлке күренәләр икән» дип уйлады Илгиз.

Ә менә Лариса белән Фәрит – игътибарны үзләренә тарта торган пар: икесе дә матур, шартын китереп бииләр, бер-берсенә карап көлешеп алырга да онытмыйлар. «Егерме елдан артык бергә яшәгән ир белән хатынның нинди кызыклары бардыр инде? Артистлар!» дип уйлады Илгиз.

Парлар берәм-берәм биюгә төшә торды. Хәтта ялгыз Зилиягә дә пар табылды, хатыны соңарып киләсе Финус аны биюгә чакырды. Кыска итәкләрен озынайтырга теләгәндәй, күлмәген тарткалый-тарткалый, биюгә төште хатын. Гомер буе биеп йөргән диярсең, Финус бик килешле кыймылдый иде. Илгиз аны кызыгып күзәтте.

Өстәл янында хатыны Айсылу белән Илгиз генә утырып калды. Ир кулында шешә бөкесен бөтерә иде. Айсылу, олы табыннан ялгызы гына утырып калудан кыенсынган кебек, гәүдәсен яртылаш биючеләр ягына борып, йөзендә елмаю әсәре чыгарырга тырышып, кунакларны күзәтә.

– Нишләп мондый матур пар вальска төшми! Әйдәгез, әйдәгез! – Ут кебек житез тамада ханым Илгизне урыныннан тартып та торгызды.

Биергә чыгарга әзер булмаган Илгиз, Зилия сыман, бер дә кирәкмәсә дә, кофтасын аска тартып, төзәтештереп куйды. Әле биючеләргә, әле Айсылуга карады. Эх, җыры да бетеп кенә куймый бит аның! Үч иткәндәй, тамадасы да яннан китми, сүзләренең нәтиҗәсен көтеп, янында басып тора. Илгиз

Айсылуга карады. Ул кулына ниндидер бокал тотып утырган, эчкән кеше диярсең! Аптыраудан алгандыр инде, ялгыз хатын кебек өстәл янында берүзе утырып калгач кыенсынгандыр. Парлы бию булмаса, Илгиз уйламас та иде, ә болай матур түгел инде: бар ирләр дә хатыннарын биюгә чакырган, бары тик ул гына Айсылуын чакырмаган булып чыга. Дөресен генә әйткәндә, Илгизнең бер дә биисе килеп тормый, тик шушы тамада хатын сагыз кебек ябышты бит!

– Йә инде! – дип, һаман яннарында басып тора.

Илгиз әкрен генә Айсылуның иңнәренә кагылды.

– Биибезме?

Ханым сүзсез генә басты да Илгизгә таба борылды. Аның башы югары чөелгән, аркасы турайган иде. Белә инде Илгиз Айсылуның үпкәләгәндә, үзенең дәрәҗәсен күрсәтәсе килгәндә шулай йөрүен. Кулларын да, әнә, иренең иңбашларына матур итеп салмады, ваемсыз гына, әһәмиятсез генә куйды. Аның һәрбер хәрәкәте «Биюгә чакырып, миңа одолжение ясадыңмы? Булдыксыз! Мөртәт!» дигәнне кычкырып тора иде.

Ир хатынның йөзләренә текәлде. Айсылуның яңак мускуллары тартылган, иреннәре һаман ачулы итеп кысылган иде. Илгиз белә: бу ачу әле берничә көн дәвам итәчәк.

Кичә алар тиргәште. Барысына да шул акчасызлык сәбәп инде. Илгиз эш хакын күтәреп кайтты, ай буе эшләсә дә, унҗиде мең сум акча чыккан иде.

– Нәрсә бу?! – дип аптырады Айсылу, акчаны чутлап чыккач. – Шушымыни хезмәт хакың? Нәрсәгә генә җиткерим соң мин моны? Әнкәйләргә генә ун мең бирәсе бар, Фәгыйләгә – өч мең сум. Балаларга мәктәптә ашауларына түләргә, квартплата, утка, суга, телефон, телевизор, интернет... Бу акчамыни, Илгиз?

– Интернетсыз да торырга була, – диде ни әйтергә белмәгән ир. Ай саен хезмәт хакы азрак чыкканга аның эче пошмыймыни?! Узган айда унсигез мең сум чыккач, алдагы айда артыграк булыр әле дип, хатынын да, үзен дә тынычландырган иде. Кая артыгы – тагын да азрак чыккан! Үзе дә белә инде ул бу акчаның беркая да җитмәгәнен, әмма Айсылуга нигә шулай каты бәрелергә кирәк инде?

– Интернетсыз хәзер бер көн дә торып булмый! Әнә беренче сыйныфтан ук интернет аша өйгә эш биреп кайтаралар! Югары сыйныфларын сөйләп тә тормыйм! Болай да ике ай түләнмәгән, хәзер сүндерәләр бит. Бу акчаны ничек кенә җиткерим мин?! Кеше кебек үземә духи, помада сатып алган юк. Туйдым инде беткән помадаларны шырпы белән чокып, иренгә сыларга! Миңа илле тула, Илгиз, илле-е-е! Әле һаман бер юньле тормыш күрсәткәнең юк! – Айсылу кызганнан-кызды. – Әнкәйләр алдында оят, тотабыз да акча сорыйбыз, тотабыз да алардан сорыйбыз. Үзебез аларга ярдәм итәр урында! Вакытында бирә алсак ярар иде! Әнә, үзеңнең туганнарыңнан алсаң, абына-сөрлегә, зарплатаң өйгә кайтканчы ук илтеп бирәсең, ә минекеләргә бирмәсәң дә ярый! Шулай булып чыга бит! Алар – чүп! Аларны кешегә санамыйбыз, иң мөһиме – Илгизнекеләргә кыенлык килмәсен. Миңа уңайсыз, Илгиз. Аңлыйсыңмы син – у-ңай-сыз!

Илгиз эндәшмәде.

– Кешеләр балаларын репетиторга йөртә. Диниска мәктәпне тәмамларга ярты ел вакыт калды, кая репетиторга дигән акча? Нәрсәм белән түлим мин аңа? Шул акчасызлык аркасында баланы юньле уку йортына да кертеп булмаячак. Хәзер шөгыльләнсә, алтмыш-җитмеш меңгә басар иде, ә түләп укыта башласаң, елына

ике йөз мең сум кирәк! Син аны берничек тә укыта алмаячаксың! Шуларны белә торып, унҗиде мең сум акчаңны күтәреп кайтып кергәнсең!

Айсылу утырып елап ук җибәрде.

– Ничек җаның тыныч синең, Илгиз? Мин шуңа аптырыйм. Ничек үз балаларыңны шулкадәр яратмаска мөмкин? Уйлап та бирмисең шуларның киләчәкләрен!

– Нишләп уйламыйм? Ул бурычларны барыбер мин түлим бит. Репетиторга йөртмичә дә шул имтиханнарны биреп буладыр, нигә юкка акча түгәргә? – Моңарчы эндәшми генә утырган ир, балалары турында сүз чыккач, авызын ябып кала алмады.

– Үзең бир! Үзең «бишле»гә бир шул имтиханнарны бернинди әзерлексез! Мәктәп белеме белән! Әллә син аларны да үзең кебек шофёр булсыннар дисеңме? Әз генә ярдәм булса, Динистагы баш вузга керерлек! Кит, шул баланы да укыта алмагач инде! Әллә миңа кеше арасында кыен түгел дисеңме? Әнә, ата-аналар комитеты көн аралаш ватсаптан акча сорап яза. Ремонтка тапшырмаган бер без генә калганбыз, көндезге ашлары өчен түләнмәгән. Яңа елга бүләккә тапшырылмаган. Бер без, Илгиз, бер без!

– Ремонтка ат хакы кадәр акча җыймасыннар! Без аны бирергә бурычлы түгел. Әлегә безнең илдә уку бушлай.

– Шулаймы? Алайса, бар әле, ипләп кенә үзең аңлат шуларны укытучыларына. Директорга кер! Югыйсә өйдә кухняда гына сөйләнергә шәпсең. Мәктәптә ләм-мим утырасың. Пока акчам юк, бушка ашатып торыгыз әле диген! Синең бит җыелышка да барганың юк, әнә Динисның чыгарылыш кичәсенә алты мең сум җыялар. Бу зарплатаңнан шуның яртысын булса да түләргә иде. Кая гына бүлим бу мескен акчаңны?!

Илгиз эндәшмәде. Әйе, акчалары җитми. Өйдә шул аркада еш тавыш чыга башлады. Эчкече дә, ялкау да түгелләр, тапканнарын юк-барга да түкмиләр. Икесе дә эшли, әмма җиткерә алмыйлар. Артык әйбер сатып алганнары да юк, концертка, театрга, кинога-мазарга бару кебек күңел ачулар күптән онытылган, кунакка да йөрмиләр. Чөнки кунакка барсаң, күчтәнәче-мазары кирәк, гаиләдә бер тиен дә артык акча юк. Өстәмә эш килеп чыкса, икесе дә алырга тырышалар. Айсылу, җае чыкса, туйларда фотога төшерә. Илгиз – ташчы, шофёр эшеннән тыш, җәй айларында кич озын дип шабашкалар ала. Шулай булса да, очын-очка чак ялгап баралар. Соңгы ике-өч ел бөтенләй авыр, хезмәт хаклары икесенеке дә сизелеп азайды, ә балаларга үскән саен күбрәк кирәк. Быел Ләйсәннәре дә беренче класска укырга керде. Аны мәктәпкә чак җыеп илттеләр! Ярый инде, 11 класс, соңгы ел дип, Динисларына күп нәрсәне алмадылар. Җиңнәре кыскара төшкән күлмәкләрен дә, пинжәк эченнән ярар әле, улым, дип ташламады Айсылу, чалбарының да узган елгысын гына кияргә булдылар. Аяк киеме генә юнәттеләр. Сумкасының каешлары бик искергән, яңаны алырбыз дип уйлаган иде дә Айсылу, тик анысына да чут чыкмады, искесе белән генә йөри әле уллары. Әти-әнисенең акча җиткерә алмаганын күреп, алар бик соранып бармыйлар. Аеруча уллары Динис, үзенә берәр нәрсә алырга җыенсаң, «Әни, әнә, Ләйсәнгә алыгыз, минеке бар әле», – дигән була.

Өс киеме бер нәрсә, әмма соңгы вакытларда ашауга да җиткерә алмый интегәләр. Әле чәе бетеп куя, әле шикәре. Элек, берәр нәрсә бетсә, хәзер

генә кибеткә барып килеп була иде, хәзер алай итә алмыйлар, тиен дә акчалары калмый. Айсылу еш кына Илгизнең алдыннан ашауны алып, балаларга таба куя башлады. Ите дә чутлы, мае да. Ә ир рәхәтләнеп уртлап ашый. Иртәгегә юк дип тә уйламый, балаларга калсын әле дә дими. Башта ире моңа әллә ни игътибар итмәгән иде, соңрак хатынының үзеннән ризыкны жәлләвен аңлады. Ә бер көнне, Илгиз икмәккә үрелгәч:

– Илгиз, иртәгегә иписез калдык, син чамалабрак аша әле, миндә акча бетте, – диде. Илгиз бу сүзләрне ишетте ишетүен, әмма чынга аласы килмәдеме, «чамаламады». Шуңа да өченче телемгә үрелгәндә, хатыны:

– Илги-и-из! Иртәгә балаларга ашарга калмый, – дигәненә ачуы килде. Үзенең икмәккә дип үрелгән кулына сугуларына риза түгел иде ир кеше һәм моны мыскыллау дип кабул итте. Гарьләнде.

Ә Айсылу, киресенчә, ирен мәнсезлектә гаепләде. Хезмәт хакын алырга әле бер атна вакыт бар, бурычка алып торыр кешеләре дә калмады. Ашар ризык бармы-юкмы – аңа барыбер, өстәвенә балалар турында да һич тә уйламый. Инде мескеннәрнең болай да груша-банан күргәннәре юк, өстәлдә кәнфит-печенье – сирәк кунак, Айсылу еш кына ипине дә чутлап телә, ә ирнең гаиләм нәрсә белән туена, иртәгә нәрсә ашарбыз дигән уй башына да керми.

Акча җитмәгәнлектән башланган ызгыш Илгизнең җиде буынын барлау белән тәмамланды.

– Инәң-этәң юньле тәрбия биргән булса, син шундый да булмас идең. Ничек инде өй тулы бала үстереп, берсенә бер югары белем бирмәгәннәр? Юньлерәк эштә эшләсәң, хезмәт хакың да кешечә булыр иде. Малайлы була торып, яшәр урыннарын кайгыртмаганнар, хәзер менә ипотека түләп чиләнәбез, дүрт малайга бер фатир да юнәтмәгәннәр! – дип тезеп китте хатын.

Сүз бу урынга җиткәч, Илгиз түзмичә:

– Сезнең генә нәсел шәп инде! Примадонналар! – дип кычкырды да урынына барып ятты. Айсылу әле моннан соң да бик күп кычкырды, керфекләрен чылатты, «юньле булсаң, бу хәлдән чыгар юлын эзләр идең, кеше ирләре кебек Себергә китәр идең, әнә!» – дип тәмамлады ул сүзен. «Китәм, иртәгә үк китәм!» – дип ятты Илгиз. Тик бер проблема икенчесен тудыра бит ул, кесәләрендә бер буханка ипи алырлык та акчалары булмаганда, фәлән мең тәңкәне билетка кайдан юнәтергә? Югыйсә шушы сүзләрне ишеткәнче, чыгып китәр иде дә рәхәтләнеп эшләр иде. Эштән курка торган кешемени ул? Эшләп-эшләп тә түләмәгәч, нишләсен. Хөкүмәтен әйтер идем – кешене нинди мескен шартларга куя бит!

Иң начары – бу сүз балалар алдында булды. Ләйсән куркып калып, үз бүлмәсенә кереп посты да, барысын да ишетеп торса да, шуннан чыгарга кыймады. Динис, башын иеп, ишек төбендә утырды. Ни әтисенә, ни әнисенә бер сүз катмады. Каядыр чыгып китәргә җыенган идеме, киенгән килеш шунда утыруын белде. Бары тик әтисе йокы бүлмәсенә кереп киткәч кенә, өс киемен салып, сеңлесе янына юнәлде дә аның белән дәрес әзерләргә тотынды.

Балалар янында әйткәләшергә туры килүләренә Айсылу соңыннан үкенде дә соң, тик эш узган иде инде.

Илгиз Айсылу йокларга ятканда гына уянды. Авыр көрсенеп, бик озак тегеләй-болай әйләнгәләде хатын, әмма ир уянганлыгын сиздермәде, бичәсен кочаклыйсы да, юатасы да килмәде аның. Аркага-арка куеп йокладылар.

Абыйларының юбилейларына барасы иртән генә исләренә төште. Үзләре өчен өтәләнеп торган Илнурның кәефен төшерәселәре килмәде, көндезен бер-берсенә эндәшми йөрсәләр дә, вакыт җиткәч, икесе дә кафега барырга әзерләнә башлады.

– Ике мең салыйммы, өчнеме? – дип сорады иреннән Айсылу коры гына.

– Бөтенләй салмасаң да була, абыйга үзем аңлатырмын әле, безнең финанс хәл аның өчен яңалык түгел, – дип җаваплады Илгиз.

Мондый җавап болай да тынычланмаган Айсылуны чыгырыннан чыгарды.

– Кит, мөртәт! Булдыксыз! Һаман да «табармын», «эшләрмен», «булдырырмын» дими, бала-чага кебек буш кулын селтәп барырга риза. Илле яшеңдә дә шундый ыштансыз булуыңнан оялыр идең! – дип үртәлде.

* * *

Турысына каткан Илгизнең килбәтсез генә бер урында таптануы Айсылуның кәефен тагы да ныграк төшерде, ул ачуы белән иренә таба күтәрелеп карады. Тегесе битараф карашын әллә кая төбәгән, кәефе бөтенләй юк иде. Кулларын бичәсенең билләренә куйса да, Айсылу аларның җылысын тоймады. Дәү гәүдәле, инде чигә чәчләренә чал керә башлаган ире аңа ничектер җәл булып китте.

«Каты бәрелдем бугай кичә. Зарплатаны шулай аз түләүләренә ул гаепле түгел бит инде! Югыйсә илле мең сум хезмәт хакы күтәреп кайтуы аңа да нинди күңелле булыр иде!» дип уйлады хатын.

Илгиз исә күршедә генә биегән Ларисаны күзәтте. Килешле гәүдәсенә сыланып торган бик матур күлмәк кигән иде хатын. Ир кеше булса да, Илгиз аның киеменең кыйммәтле булуын чамалады. Мондый күлмәк Айсылуга да килешер иде дип уйлады ул, хатынына караш ташлап. Айсылу бәйрәмнәргә кия торган ак якалы зәңгәрсу күлмәгеннән иде. Бу күлмәкне алганга да инде дүрт-биш ел бардыр, хатыны һәр бәйрәмдә шуңардан. Матур аның Айсылуы. Әнә бит, иреннәрен бүрттерсә дә, матурлыгы һич югалмаган. Җитендәй чәчләре нинди куе, матур! Их, нинди бәхетле итәр иде аны Илгиз, әллә нинди кыйммәтле күлмәкләр алып бирер иде, әллә, чынлап та, Себергә чыгып китәргә микән? Динис әле ярты ел өйдә, сеңлесен мәктәпкә йөртергә булышыр иде. Тәвәккәлләргә микән? Болай гел интегеп яшәү эшмени инде, ярты гомер үтеп бара бит...

«...Балалар алдында әтиләрен тиргәп, ялгыш эшләдем. Улын да, кызын да сөеп-яратып кына үстерде бит ул. Әйбәт аның Илгизе, бары тик шушы вакытлыча булган авырлыкны гына үткәреп җибәрергә кирәк». Шулай уйлап, Айсылу кулларын иренең муенына салды. Менә бит нинди көчле аның ире, нинди дәү – шушындый кешене бала-чага урынына тиргә инде! Элек ничек матур итеп бииләр иде алар вальсны, Илгиз аны очыртып кына йөртә иде, ә хәзер эт белән песи кебек торалар. Кешедән оят. Айсылу Илгизгә таба елышты.

Илгиз хатынына төбәлде. Айсылуның күзләрендә ачу сүнгән иде. Көчле куллары белән ир аны күкрәгенә кысты. «Айсылу, бәгърем, бәхетле итәм мин сине барыбер! Менә күрерсең!» – дип пышылдады ул эченнән генә. Парлы бию дәвам итте...

# «ДӨРЕС ЧОРДА» ТУГАНСЫҢ, ШАГЫЙРЬ!

## ЗИННУР МАНСУРОВ ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Үткән гасырның соңгы чирегендә сүз сәнгатебезгә укучы балалар белән яшүсмерләргә атап язылган кыска, афористик, шул ук вакытта мәгънәле шигырьләре белән килеп кергән Зиннур Мөҗип улы Мансуров – хәзер күпкырлы иҗаты, аерым алганда, нечкә хисле лирик әсәрләре, колачлы эпик поэмалары һәм сүз сәнгатебезгә багышланган публицистикасы, иҗтимагый эшчәнлеге белән танылган күренекле шәхесләребезнең берсе. Ул – замана алып килгән мәүзугъларга, милли тарихыбызга ифрат игътибарлы булса да, шигырь сер сакларга, гүзәллеге белән ләззәт тә бирергә тиеш дип иҗат итүчеләребезнең берсе. Әдәби-сәнгати осталыгының нигезендә үткәндәге казанышларны иҗади үзләштерү өстенә кеше, шәхес буларак җитлеккәнлек, интеллект көче, белемлелек ята.

Ул башлангыч чор иҗатында да, соңрак та йолалар колы дәрәҗәсенә төшмәде, «үзе» булып кала алды. Татар һәм, гомумән, Көнчыгыш шигърияте кыйммәтләрен иҗади үзләштереп, Көнбатышның шәкли алымнарыннан да кирәгенчә оеткы алып, сүзен укучысына җиткерерлек сурәтләү чараларын сеңдергән өслүбен булдырды. Ул, бер яктан, ватандарлык хисенә өстенлек бирүе, катмарлы сурәтләү чараларын үзенә «хезмәт иттерә» алуы, символ – кодларны үстерүе җәһәтеннән «акыллы хис» шигърияте даһилары Акмулла, Тукай, Дәрдемәнд, Такташ традицияләрен иҗади үзләштерсә, икенчедән, шартлы алымнарны максатка буйсындыруда Ә.Фәйзи, Ә.Баянов (З.Мансуровның «Кул бирәм» исемле беренче җыентыгына кереш язган Әхсән Баянов калебе кабул итмәгән шагыйрьләрне якын китермәде), Р.Мингалим, Зөлфәт, Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановлар, күпмедер күләмдә Р.Харис, Р.Фәйзуллинның сәнгатьчә фикерләүләрен күңеленә иңдерү белән берррәттән, яшьрәк буын каләмдәшләренең эзләнүләренә дә игътибарлы, иҗади табышларына сөенеп, тәнкыйди-мәдхияви бәяләрен үзләренә ирештерә тора.

Каләм әһеленең иҗат серләрен тормыш «буразналарыннан» эзлә диләр. З.Мансуровның биографиясе гадилеге белән гыйбрәтле. Казан дәрелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлеген уңышлы тәмамлаган егет армия мөддәтен офицер дәрәҗәсендә, кая дип уйлыйсыз (белүемчә, татар әдипләреннән бердәнбере), яһүдиләрнең Рәсәйдәге башкаласы Биробиджанда узганнан соң, башы-аягы белән журналистикага кереп чума. Хәзерге исемнәре буенча «Ватаным Татарстан», «Казан утлары» редакцияләрендә, Радиокомитетта каләмен чарлаганнан соң, 1995–2015 елларда зыялылар матбагасы «Мәдәни җомга»ның баш мөхәррире вазифаларын уңышлы башкара.

Тәрҗемәи хәленең мәгълүм гонсырларын искә төшерүнең төп сәбәбе: аның гомере буенча (безне сөендереп, озак яшәсен) «Хөкүмәт эше» белән ана сөте, туган туфрак җылысы аша, йөрәгенә сеңгән шигъриятне, авырсынмыйча, бергә иңләп алып баруын искәртеп үтү ихтыяҗы иде.

Хәзер ул – Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның халык шагыйре һәм, иң мөһиме, тормыш романтикасы белән «җылытылган» реалистик башлангычка

өстенлек биреп, метафора белән мифтан дәрт алып, шигъри өслүбен төрләндерү, баету юнәлешендә эзләнүләре белән беррәттән, онытыла барган илаһи сүзләрне иҗатка кайтарып, үзеннән өстәп, гарәп-фарсы телләреннән алынмаларны куллануда арттырып та җибәреп, «ваем», «гамь», «фидаи»ларына тугрылыклы калып иҗат итүче, кабатланмас фикер иясе – Татар әдибе.

Шигърияттә «Юк сиңа барачагым» («И, балачак») дип килеп кергән җилкенчәк хәзер бай һәм төрле юнәлешле лирикасы, сугыш батырына багышланган «Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар» героик дастаны, дини-мифологик «Хозыр галәйһиссәламны эзләү», фаҗигаи «Ике егълау» поэмалары, «Юлын белгән арымас» (1998), «Күңелдә фидаи яшәсә» (2006), «Тукай белән әңгәмәләр» (2014, 2021) кебек әдәби-публицистик хезмәтләре – З.Мансуровны җитди иҗтимагый-сәяси, тормыш-яшәеш-мәүзугъларын тиешле сәнгати югарылыкта сурәтләүгә сәләтле сүз «каһарманы» булуына күргәзмәле дәлилләр[1].

Поэманы шигъриятнең үсеш дәрәҗәсен билгеләүче жанры дип санап, З.Мансуровның лиро-эпик әсәрләре белән мавыгуымның сәбәбе «Казан утлары» журналының 2022 елның җиденче санында шигыйрьнең «Бәгырьдәге гамьнәр төенләнә» исемле яңа тупланмасын тәкъдим итүе булды. Шул туплама игътибарымны үзенә борып куйды. Әлеге шигырьләренең басылып чыгуына шактый вакыт узса да, аларны хәтердән алып ташлап булмады. Атамага чыгарылган «бәгырь», «гамь», «төен» сүзләре үк хәятнең «аргы якларын» иңләгән суфыйлар фәлсәфәсен хәтерләткән шәлкемне, «үземне ялындырып» кына укый башласам да, шигъри бәйләмдәге «Серле күчеш» шигыренең соңгы мисрагын кабатлап утыруымны абайламый да калганмын!

*...Яшелнең сарыга дүнүен*
*Эчкәрәк яшереп, төн килде.*
*Гәрәбә дисбемнән Мәңгелек*
*Елмаеп куйгандай тоелды.*
(«Серле күчеш»)

Җәйгә ямь биреп яшәткән төснең «акрынлап сарыга» алышынуының нигезендә Җир шарының үз күчәре тирәсендә әйләнүенә дә «ым» ясала икән.

Табигать яшәешендәге үзгәреш – матурлыкларны кеше кичерешләрен сурәтләгәндәге шикелле шагыйрь нечкәлек, саклык, шулай әйтергә ярaса, психологик тирәнлек белән шәрехли.

*Җир-суны озаклап күзәткәч,*
*Төрлечә хисләнәм: әллә-лә!...*
*Аһ, җәйне яшәткән яшел төс*
*Акрынлап сарыга әйләнә.*
(«Серле күчеш»)

Бер төстән икенчегә күчүдә мизгел белән мәңгелек арасындагы якынлыкны шигъри йөрәкле зат кына күрә, бәяли һәм догалы нәтиҗәсен ясый аладыр.

*Шушындый сихерле күчештә*
*Хәяти хикмәт тә, гамь дә бар.*
(«Серле күчеш»)

Әлеге гаҗәеп тирән хисле, беркадәр моңсу да кичерешле «Серле күчеш» З.Мансуровның фикерләү рәвешенә, димәк, иҗат методына хас үзенчәлек – кеше белән табигать яшәешләрендәге рухи-ихтыяҗи якынлыкны искәртү үзенең дәвамын «Алкын дәрья хәтере»ндә таба икән. Самими кичерешләр адәм баласына гына тач дип уйлап, бик нык ялгышабыз икән ләбаса.

[1] Кара: Йосыпова Н. Зиннур Мансуров. Татар әдәбияты тарихы. – Казан, «Фолиант», 2021. – Б. 327-340.

*Инде ничә тапкыр басып торам*
*Күпне күргән Идел ярында.*
*Авыр итеп сулап ага дәрья,*
*Ишетелеп куя зар-моң да.*
(«Алкын дәрья хәтере»)

Шагыйрь, Иделне якын күреп, ихласи хөрмәт белән аның «Җанга имдәй тансык юнь» бөркүен тыңлап ләззәтләнсә дә, зур елгалар тирәсендә гомер сөргән халкының нахакка рәнҗетелүен гафу итә алмый.

*Олы суга һичкем гаеп такмый,*
*Безне бәйли уртак сөйдергеч.*
*Татарларны елга тирәсеннән*
*Җиргә туймас патша сөрде ич.*
(«Алкын дәрья хәтере»)

«Алкын дәрья хәтере»нең югарыда китерелгән соңгы ике юлы 12 мөстәкыйль шигырьдән торган тупланманың миллилегебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклауга барып тоташкан фикри юнәлешен һәм тональлеген билгели дисәк тә, шәт, зур гөнаһ булмастыр. Бу хакта борчылмаган үзаңлы татар кешесе юктыр. «Этнографик дәфтәрдән» дигән ачыкламыш белән тәкъдим ителгән «Мунча исеме» һәм «Зинһарлау» шигырьләрендә З.Мансуров ошбу мәүзугъны аерым бер үҗәтлек белән калкытып куя.

*Элгәрләрем мунча иясенә*
*Инәлгәндер: «Нинди бәла мин!...»*
*Үзенеке белән алыштырып*
*Куя каһәр... милләт баласын.*
(«Мунча исеме»)

Фәнни белемгә гашыйк, сыйфат кимәлен югары дәрәҗәдә тоткан иҗатчы алдагы юлларда халкын иң «аяныч» хәленнән чыгару турында борчылуы белән уртаклаша. «Сәяси чыныгуны» Биробиджанда узган шәхес, «бар җаваплылыкны» үз өстенә алмыйча, ерак туганының абруена «таяна».

*Ерак бабам дәшкән: «Канны бутап,*
*Кертмә безне авыр хәлгә син...»*
(«Мунча исеме»)

«Мунча исеме» тәгъбире «ышыгында» иҗатчы шактый катлаулы уй-фикер өермәсен алга чыгара: «Җеннең котын алып шартлы ат-нам күбесенә калган тагылып», – «Күпме татар бөтен дөнья буйлап йөртә шундый мунча исемен» дип, серлелекне арттырганнан-арттыра барса да, милләт баласына «юыну урынында» кушылган исемне «Җиде йозак» ачкычында калдыра. Ягъни «ат-нам»ны ачыклауны һәм нәтиҗә ясауны укучының үзенә «ышанып тапшыра».

Халкыбызның киләчәге өчен борчулы уйлану – «Зинһарлау» шигыренең дә хисси-мәгънәви асылын тәшкил итә. Әлеге газәлендә ул: «Гаҗәп түгел: Җирдә төрле төсләр бер-берсенә китә кушылып», «Шулай дәвам итәр, Аллаһ колы нинди генә уйлар кормасын», – дип, укучысын тормыш-яшәешне ничек бар, шулай кабул итүгә әзерли.

Инде «язмыштан узмыш юк» дигәнрәк моңсу нәтиҗәгә ризалаштык дигәндә генә, шагыйрьне авыр мизгелләрдә беркайчан «ташламаган» ерак туганы янәдән «сүзгә кушлып китә».

*Ерак бабам миңа хитап кыла:*
*«Канны гына бутый күрмә син,*
*Милләт канын бутый күрмә син...»*
(«Зинһарлау»)

Фикер тирәнлеге вә сәнгати үзенчәлеге җәһәтеннән «Койрыклы йолдыз хитабы» шигыре, беренче карашка, күк җисеме киңлекләрендә йөзеп йөреп, һәр 76 ел үткәннән соң җиргә кабат-кабат якынаеп алган Галлей кометасын сурәтләүгә багышлангандай тәэсир калдырса да, чынлыкта ул – Җиһанда хөкем сөргән гаделсезлектән иза чиккән шәхеснең бәргәләнүен, экзистенциаль сагышын үзәккә алган тезмә. Иң әүвәл лирик затны тыныч тормыш белән сугышның үзара якынлыгы, даими рәвештә диярлек бер-берсен «алыштырып» торуы борчый. Автор бу хактагы фикерен икеюллыкка сыйдыра.

*Таңга калам тыныч тормыш белән*
*Сугыш арасында чик юкка.*
(«Койрыклы йолдыз хитабы»)

Икенчедән, аны хакимиятне кулларына төшергән иләмәннәрнең «ялган, мәкер, үчлек, рия, гайбәт» белән фәрештәләрне биздерүләре, гайре табигый тормыш белән яшәүләре аптырашта калдыра. Бу хакта йолдыз исеменнән әйтелгән юллардан да төгәлрәк, җете үтемлерәк сүз кату мөмкин түгелдер.

*Аналарның күккә ялваруын*
*Тыңлап бакмый һичбер иләмән.*
*Әлмисактан алып әйләнүем.*
*Эчтән сызып, ничә ел янам!*
(«Койрыклы йолдыз хитабы»)

Күңеле белән «нечкә хисле» йолдыз, чарасызлыктан тәкате корып, мондый гаделсез, миһербансыз яшәеш белән килешмичә, аны ташлап китәргә була.

*Үкенечкә берни үзгәрмидер –*
*Җентекләдем җирнең бар төшен.*
*Мондый хәлдән тәмам гайрәт чигеп,*
*Чиксезлеккә китеп барышым.*
(«Койрыклы йолдыз хитабы»)

«Койрыклы йолдыз хитабы» – эчтәлеге, яңгырашы белән гражданлык лирикасының үрнәге «йолдыз белән лирик зат»ның берсен-берсе тулыландырып, ачыклап килүе җәһәтеннән катлаулы структуралы әсәр. Аның үзәгендә фәндә кабул ителгән «икеләтелгән проекция» алымы: бер үк вакыйга – хәлгә үз «хитабында» (мөрәҗәгатендә) әүвәл койрыклы йолдыз бәя биреп, кәнәгатьсезлектән «чиксезлеккә» китсә, лирик зат «тотнаксыз илләр тәхетенә шамакайлар килеп утыра», «явызлыкны кем соң авызлыклар, ә ул артка чикми» дип иңрәп, заманыбызга бәясен буяуларны кызганмыйча, киңрәк җирлеккә иңдерә.

*Күкрәк сөте сихри көчен җуяр,*
*Берсен-берсе ашар инсанда.*
*Болар курку белмәс, иблис булып,*
*Яман төшләренә иңсәң дә.*
(«Койрыклы йолдыз хитабы»)

Милли аңыбызны саклауда таянычларыбызның берсе – тарихи үткәнебез, олы язмышлы шәхесләребез ди кебек шагыйрь «Төнге сынау» шигырендә. Әлеге тезмәсендә бөтен иҗатына хас үзенчәлекләренең берсе – уртак вазгыятьләрдәге төрле чор кешеләрен якынлаштырган вакыт категориясе. Шул нисби төшенчә үткән гасырларда яшәп, бакыйлыкка күчкән асыл затларыбызга ихтирамын һәйкәлләренә мөнәсәбәте аша сиздерергә мөмкинлек бирә.

Көн белән төнне бутаган каһарманның «изрәр тәненә» тәшвиш салып, хозурында «убыр уты гөлт итеп» кабынып, күңеленә сәер төш иңдерә. Ул, төшендәме – өнендәме,

«Кинәт моң-зар белән иңрәп» куйган «пайтәхетнең ай-вае»н ишетә, Сөембикә манарасының авышуын сиземли, «мәйдандагы Җәлил сынының» урыныннан кузгалуын күрә, Такташның «гыйсъянчыдай кубарылуын» – «Чәчәк тулы пьедесталдан җиргә төшеп», «Тукайның кирмән тарафына» ашыгуын «аерымачык күреп», киң күңелелеге белән барысын да фәкать яхшыга юраса да, аны Сөембикә җанының тынычсызлыгы борчый.

Әсәрнең башында һәм ахырында искә алынып, композицион бөтенлекне тәэмин итүне «өстенә» алган «Сөембикә үзе турында «кайгыртуга» мохтаҗ икән. Ниһаять, йокысыннан уянган «каһарман әүвәл бу бурычны дәрелфөнүн каршындагы Ульянов сынына тапшырмак» була.

*Сөембикә җанын ничек сөендерер*
*Дәрефөнүн каршындагы Ульянов?...*
(«Төнге сынау»)

Уйланыбырак торгач, әлеге гозерен үтәүне нәсел-нәсәбе белән безгә якынрак башка шәхескә йөкләү кулайрак булыр дигән нәтиҗәгә килә.

*Патшалыкның татар канлы Державины*
*Көрсиендә утырадыр уйланып.*
(«Төнге сынау»)

Матурлык һәм халкына бирелгәнлек символы Сөембикә – шагыйрьнең җанын әрнетеп, бәгырендә утырган газиз затларның берсе. Шул уңайдан аның эчтәлек һәм сәнгатьлелек тарафыннан иң камил поэмаларыннан «Ике егълау» хәтердә уяна. Казан ханлыгы биләренең үз байлыкларын, башларын саклап калу турында хыялланып, Явыз Иванның, соңыннан үтәлмәгән вәгъдәләренә ышанып, Сөембикәне коллыкка тотып бирүләрен һәм шул хыянәтнең нәтиҗәсе буларак, дәүләтчелегебезне югалтуны татар тарихының иң аянычлы буыны дип бәяли автор.

З.Мансуровның «өлгер каләме», татар мохитенең олы затлары белән беррәттән, Россия, Советлар иле тарихында мөһим кәнәфиләр иләп, эшчәнлекләре, кыланышлары белән игътибарга лаеклы шәхесләрне дә шигъри «уена» «буйсындыра». «Чиктән ашу», «Ышанмыйм» шигырьләре – шуңа дәлилләр. Элегерәк «Екатерина II каретасы» исемле тарихи газәлендә ул Казанның Бауман урамын «бизәп» торган истәлек-һәйкәлгә ихтирамын белдерсә, «Чиктән ашу»да татар халкы үз итеп, «әби патша» дип йөрткән Екатеринаны зирәк акылы өчен олылап искә ала. Патшабикә Казанга зиярәт кылганда, мөселманнарга манаралы мәчетләр корырга рөхсәт бирә һәм аның карарына каршы чыккан кара көчләрнең, «Күкләр минем биләмә түгел» дип, авызларын «каплый».

«Гаҗәп хәлләр тулып ашкан чорда искә төшә шушы сүз һаман» дип, бүгенге көнебезгә кайтып, «Хәзер инде бүтән төрле үлчәм», «Заманында иман зәгыйфләнгәч түбәнәя кебек гареш тә» (күк түбәсе) дип, җәмгыятьне, бигрәк тә байлыкка табынып, кешелек сыйфатларын югалта барганнарны тәнкыйть божрасына ала.

Байлыкка табынуның, комсызлыкның чиктән тыш азынуын автор уңышлы табылган күзәтү, тирән мәгънәле бер деталь белән фаш итә.

*Ачыттыргыз бугаз төерендә*
*Тыпырчынып куя зар-нида.*
*Туймас адәм, әнә, бүлеп алган*
*Бозлык астындагы җирне дә.*
(«Чиктән ашу»)

Киңәйтелгән метафорага, архетипик образларга таянып иҗат ителгән «Ышанмыйм» шигыре Советлар чорының җитәкчесе Н.Хрущёвның Казанда сый-хөрмәт өстәле янында, татар чәк-чәгенә мөкиббән китеп, «Не верю, что в чак-чаке нет кукурузы» дигән сүзләрен искә төшерә.

Чынлыкта шигырьнең асыл мәгънәсен, татар халкының авыр язмышы, теленең киләчәге турында борчылу билгели.

Заманында көчле дәүләт – ханлыклар тотып, ерак далаларны иңләп, бик күп мәмләкәтләргә ярдәм итеп яшәгән татар халкының эзсез югалуын акылына сыйдыра алмавын калкытып куя шагыйрь. Аның дәлилләре фәнни дә, югары фәлсәфи дә. «Өммәтләргә Аллаһ җир-су өләшкәндә», эш сөючән, тормышка гашыйк, зирәк акыллы татар кавеменең йоклап калырына «ышанмыйм» ди шагыйрь.

*Кайчак тарих катламнарын җәһәт кенә*
*Айкап чыгар телмәтләргә охшаш мин.*
*Мәмләкәтчел падишаһлар тамырында*
*Татар каны булмавына ышанмыйм.*

(«Ышанмыйм»)

Рәсәйдә «булганнан соң», Француз императоры Наполеонның «теләсә кайсы русны «кармалап» баксаң, анда «татар эзен табарсың» дигәнрәк канатлы гыйбарәсе яши. Ул үзе шулай әйткәнме, әллә аңа «сылап» кына калдырганнармы – хәзер өздереп раславы кыен. Татар шагыйренең иманы камил: «Гадел күкнең иң югары катламында да татар телен белмәүләренә ышанмыйм», – ди чиксез хыялга бай иҗатчы түбәндәге юлларда:

*Гадәләтле гарше әгъля галәменең*
*Татар телен белмәвенә ышанмыйм.*

(«Ышанмыйм»)

Милли телләрне кысуның көчәйгәннән-көчәя баруын истә тотып, милләтпәрвәр фидаи затның кыюлыгына теләктәш булган тәкъдирдә дә, аның ошбу хыялы, сабыйларны ирештергәндәй, үзебезне алдау гына булыр иде.

Дөнья барышы, милләт хәсрәтләре, кешенең тормыштагы вазифасы кебек җитди мәсьәләләрне иҗтимагый-фәлсәфи дулкында яңгыратып алганнан соң, укучыларның зиһен шәрифләрен «ял иттереп» алу нияте белән дип уйлыйм, «Имтихан тәртибе», «Бүләк бирсәң», «Тамгалау» кебек артык «акыллы булуга» дәгъва итмәгән тезмәләрен дә укучысына тәкъдим итә шагыйрь. Дөрес, тормыш-көнитеш «ваклыкларын», әхлак-тәрбия борчуларын сурәтләгәндә, «оста мэтр» кулы сизелеп, «астан бәреп» тора.

«Имтихан тәртибе» газәлендә шигыйрь «адәм затын» таң калдырып, «Җирдә бериш газәбләр озак яши» дип, үзенең күзәтүләре, нәтиҗәләре белән бүлешкәннән соң, кояш нуры тизлегендә таралган, кешеләрне һәрдаим, адым саен «сагалап» торган бер начар әхлакый чирне-ялганны «кояш яктысына чыгарып» фаш итә. Ул ахыр чиктә хаклыкның җиңәчәгенә ышана. Җыйнабрак әйткәндә, исемгә чыгарылган «Имтихан тәртибе» буенча ялган җиңелеп, хаклык тантана итә.

Шигырьнең соңгы юллары күңелдәге икеләнүле юшкынны юып төшергәндәй яңгырыйлар.

*Каршы төшмик: хәят үзе барысын белә,*
*Болар өчен кирәк түгел чик-чара...*

(«Имтихан тәртибе»)

Әлеге шигырь композициясендә фәндә интертекстуальлек дип йөртелгән капма-каршы төшенчәләрне (бу очракта «ялган – хаклык») янәшә кую алымы үстерелә.

*Ялган сине ашыкмыйча даим сыный,*
*Аннан хаклык тәҗел хөкем чыгара.*

(«Имтихан тәртибе»)

«Тамгалау» тезмәсендә ялачы – ләгыйньне мыскыл итү әмәле табыла. Әүвәл З.Мансуров аның нәзберек каләменә бик үк ятышып бетмәгән күзәтүе белән «таң калдыра».

*Кайчак нәҗес нәмә килеп төшә,*
*Киек кошлар очып барганда.*
(«Тамгалау»)

Бәетнең соңгы ике юлында шагыйрьнең әләкчегә биргән каһкаһәле киңәше алга чыга.

*Кошлар уткән мәлне өскә карап,*
*Авызыңны гына ачып тор.*
(«Тамгалау»)

З.Мансуровның ирешкәннәреннән, иҗатына нисбәтән лаеклы мактаулардан оеп утырырга мөмкинлеге генә түгел, хакы булса да, күрәсең, камиллекнең чиге юк дип фаразлап, ул эзләнүдән, сүз-сурәт өлкәсендә тәҗрибәләрдән туктамый. Әлеге бәйләмендәге «Ялгышасым килә» тезмәсенең нигезендә үз-үзеннән кәнагатьсезлеге, борчылуы, «уйнаклавы» күңелне «тырнап» узды. Шундый олы әдәби-бәдигый шәхеснең «Дөрес чорда тудым микән диеп, дәшкән чагым булды язмышка» юллары һәркемне пошаманга салырлык иде. Сүз сөрешеннән аңлашылганча, аны бит вак-төяк, көнитеш мәсьәләләреннән бигрәк, чорга нисбәтән шәхес иреге, милләт язмышы борчый. Әүвәл, бер шагыйрь сүзләре белән «Әти, Әни һәм... Ватанны сайлап алмыйлар» дип, җиңел генә котылмакчы идем дә, алдарак килгән «...хаксыз хәлдә тоеп, ялгышырга тели бар кеше» һәм «Ялгышасым килә, валлаһи! Ялгышасым килә...» дип кабатлавы беркадәр аптырашта ук калдырды...

Эчкерсез фикерле, хыял уенына, кинаяле метафорага өстенлек биргән шигырьнең каршылыклы уйлар тудыруы табигый иде. Мәгәр тезмәнең һәр җөмләсен, сүзен игътибар белән укысаң, «чытыклануының» чишелешен «Ялгышасым килә»нең беренче мисрагының (куплетының) соңгы ике юлында ук «гаепне» үз өстеннән төшереп, үсмер чагына «сылап» калдырган икән.


*Соңра эчтән дога укып куйдым:*
*Үсмер сүзе чыксын ялгышка.*
(«Ялгышасым килә»)

З.Мансуровның «Бәгырьдәге гамьнәр төенләнә» тупланмасына иркенләбрәк тукталуның сәбәпләренең җитдие бер тамчы суында чишмәнең бар үзенчәлеге, тәме сизелгәндәй, әлеге шигырьләрендә бөтен иҗатына хас мәгънә җегәре саклануы, сыйфатлылык, образлылык тарафыннан үз биеклегендә калып, эзләнү-тәҗрибәләрен дәвам итүе иде.


Сүземне аңа мөрәҗәгать белән тәмамларга булдым.

Зиннур туган! Бүгенге катлаулы чорда (ханлыгын югалтканнан соң, татарның үзе теләгәнчә яшәгән дәвере булдымы икән?) телебезне, миллилегебезне саклау өчен тартышта сезнең кебек үзен аямый торган фидакарьләргә ихтыяҗ аеруча зур. Шуңа күрә, «Дөрес чорда тудым микән», «Ялгышасым килә» дип үзегезне, безне – укучыларыңны борчып, бимазалап, олы абруегызга таянып, «чиратсыз кереп», «койрыклы йолдызыңа» ияреп, чиксезлеккә ашыкмагыз, анысы да бездән генә калмас! Вакыты җиткәч китәрбез!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*Татарстанның халык язучысы.*



Татарстанның халык
язучысы Тәлгат Галиуллин.



Рим Кәримов белән.



Эдуард Касыймов, Илдар Юзеев, Тәлгат Галиуллин, Шәүкәт Галиев.



Бер гаиләдән өч профессор: Зиннур Шәрәфетдинов, Әфхат Галиуллин, Тәлгат Галиуллин.



*Рәис кулыннан Рәхмәт хаты алу.*



*Каләмдәшләр Эльмира Шәрифуллина, Фәүзия Солтан (Галиуллина), Ринат Мөхәммәдиев, Тәлгат Галиуллин.*



*Вахит Хаков, Марсель Бакиров, Тәлгат Галиуллин, Николай Мышёв, Фәрит Юсупов, Васил Гарифуллин.*

*Фотолар Т.Галиуллин һәм «Казан утлары» архивларыннан алынды.*

# ОНЫТМАДЫК СИНЕ, ЗӨҺРӘ АПА

Кандидатлык диссертациям 1920–1926 елларда Идел буе өлкәләрендәге хатын-кызлар хәрәкәтенә багышланган иде. Шөкер, тигез, матур тормыш төзү өчен үз-үзләрен аямыйча, намус белән эшләгән хатын-кызларыбыз хакында архивларда да мәгълүматлар бар иде әле, ул шәхесләрнең кайберләре белән үзләре исән чагында танышырга да насыйп булды. Шуларның берсе – үзем күреп белгән, аралашкан һәм гомерем буена сокландырган Зөһрә Мөслимова-Баимбетова иде. 1919–1921 елларда Татарстанда яшәп, Гражданнар сугышында үлем белән күзгә-күз очрашкан, республиканың татар хатын-кызлары хәрәкәтен җитәкләгән, ачлык вакытында меңнәрчә балаларны чит өлкәләргә озатып, ач үлемнән коткарып калган олы шәхес ул.

Архивта аның кулы белән язылган мәгълүматлар сакланган. Күргәч, язуының матурлыгына, әмма бигрәк тә үз чоры вакыйгаларына мөнәсәбәте, хатын-кызлар хәрәкәте алдында торган эшләргә, катлаулы бурычларга карашы, фикер тирәнлегенә сокланып туя алмый идем. Исән булса, бер күреп сөйләшсәсе иде дигән теләгем дә көчәйгәннән-көчәйде.

Ниһаять, Мәскәүдә яшәгәнен белеп, адресын таптым да хат яздым. Хатыма җавап бирмәде. Заманында Казанда Зөһрә апа белән бергә эшләгән Н.А.Ваньковага мөрәҗәгать итәргә булдым. Ул үз җавабында: «Янына барып йөри күрмә. Ул чукрак, аягы аксак, беркемне дә кабул итми», – диде. Әмма мин Зөһрә апаны табарга, нинди хәлдә булса да, күрешергә ният иттем.

Таптым. Фатирына кердем дә таң калып карап тордым. Чәчләрен матур итеп үргән, ачык, матур төстәге крепдешин күлмәк кигән мөлаем бер апа («карчык» дияргә тел бармый) миңа карады да көлеп җибәрде.

– Ник аптырадыгыз, Ванькова сөйләгән карчыкны күрергә уйлаган идегезме? – ди. – Ул сезгә генә түгел, бөтен кешегә дә минем хакта шулай сөйли, ә менә мин әле Аллага шөкер.

Чынлап чукрак та, аксак та түгел, кыяфәте дә соклангыч чибәр иде.

Зөһрә апа янына берничә тапкыр бардым, бик якын күрде, рәхмәт. Урыны җәннәттә булсын. Татарстан, Казан хәлләрен сорап туймый иде. Ул вакытта бездә чыккан газета-журналларны да алдырып, укып барганын күреп хәйраннар калдым. Болай күз йөртеп кенә түгел, кызык дип тапкан хәбәрләрнең астына сыза-сыза укый. Тарихыбызны, шәхесләребезне белүенә дә ис китәрлек иде.

Ул үзе 1899 елда Уфада туа. Әтисе Әхтәм Җиһангир улы Мөслимов авылдан чыгып, Урал шахталарында эшләп имгәнгән, соңрак Уфада төпләнеп, балта остасы булып көн күргән. Әнисе Фәрхи апа яшьтән ятим калып, 7 яшендә Курков дигән рус гаиләсенә бала карарга килгән һәм 17 яшенә кадәр аларда яшәгән. 17се тулгач, Әхтәм абзыйга кияүгә чыккан. Матур гына гомер иткәннәр, 9 балалары булган.

Олы балалары Зөһрәне мәдрәсәдә ике ел укыткач, кыз балалар өчен ачылган рус-татар училищесына биргәннәр. Укыса, тормышы җиңелрәк булыр дип уйлаган әти-әнисе. Училище янында интернаты да, яхшы укучыларның яшәве дә дәүләт хисабына булган. «Рус кызларына караганда да, күбрәк тырышырга туры килде, татар телендә сөйләшергә дә рөхсәт итмәделәр. 30 баладан училищены бары алтыбыз гына укып бетердек. Мин классыбызда иң яхшы укучы идем», – дип искә алды Зөһрә апа.



*Татарстанда хатын-кызлар арасында эшләүчеләрнең 2 нче Өлкә киңәшмәсе делегатлары. 22-24 февраль, 1921 ел. Астан беренче рәттә, сулдан уңга дүртенче Зөһрә Баимбетова.*

1913 елда училищены тәмамлагач, ул Уфада ачылган өч еллык укытучылар курсына кабул ителә. 1916 елда «Учительница народных училищ для инородческих детей» белгечлеге буенча диплом ала. Рус булмаган милләт балаларына гына рус теле өйрәтергә хокукы булган, димәк.

Яшь укытучының хезмәт юлы Караякуп волостеның Арслан авылында земство карамагындагы башлангыч училищеда башлана. Яратып башкара үз эшен, тик озак эшли алмый, илдә барыбызга да мәгълүм үзгәрешләр башлана.

Февраль революциясеннән соң урнашкан Вакытлы хөкүмәт хатын-кызларны тигез хокуклы гражданнар дип игълан итә итүен, әмма хатын-кызларга бу «тигез хокуклылык» дигән төшенчәне аңлатырга кирәк була әле. Зөһрәгә менә шушы бурыч тапшырыла. Тик моңа каршы чыгучылар күп була, «шәригать кушмаганны, ничек инде хатын-кыз ирләр белән бертигез булсын» диючеләр Зөһрәнең һәр эшенә аяк чалалар. Җыелышларны куып тараталар, төрлечә яныйлар.

Зөһрә апа мөфти Галимҗан Барудига ярдәм сорап бара (1917 елда I Бөтенроссия мөселманнары съездында Г.Баруди мөфти итеп сайлана һәм Уфада урнашкан Диния нәзарәтендә эшли башлый). Мөфти Зөһрәне бик җылы кабул итә һәм «Хакимият рөхсәте белән генә түгел, Диния нәзарәтенең дә рөхсәте һәм тәкъдиме белән хатын-кызларның тигез хокуклыгын аңлату эшен алып бару тапшырыла» дигән кәгазь (документ) бирә.

1918 елның маенда Зөһрә большевиклар партиясенә керә һәм шунда ук Губерна мөселманнар комитетына эшкә чакырыла. Төп эше шул ук: хатын-кызлар арасында агитация, пропаганда эшләре. Вакыйгалар бик тиз алмашынып, кешеләр язмышлары да шулай тиз үзгәргән чор бу. Шушы 1918 елның июлендә Мәскәүдә Советларның V съезды чакырыла. Уфа делегациясе составында татар кызы Зөһрә Мөслимова да съездда делегат буларак катнаша. Бу көннәрдә Советлар властеның хәле бик мөшкел: сул эсерлар баш күтәргән көннәр, чехлар, һөҗүм итеп, Казанга якынлашалар. Съездда В.И.Ленин чыгыш ясап, барлык делегатларны Гражданнар

сугышына кушылырга өнди. Башкалар белән бергә Зөһрә дә Свияжскида оештырылган 5нче Армиягә китә.

Бөгелмәдә бу армиянең штабы урнашкан була һәм Политбүлегенең органы булган «Кызыл яу» газетасы чыга башлый. Язмыш дими, ни дисең. Зөһрә шушы газетаны оештыручыларның берсе, революциянең танылган солдаты, Уфада яшәгәндә үк үзенә гашыйк булган Гыйлемдар Баимбетовны очрата. Алар өйләнешәләр.

Зөһрә армиянең политбүлегенә агитатор итеп билгеләнә. Аның алдына солдатлар һәм якын-тирәдәге авыл халкы арасында Совет власте хакында аңлату-төшендерү һәм Кызыл гвардиягә өндәү бурычы куела. Рус, татар, башкорт телләрен камил белгән, большевиклар тоткан юлны чын күңеленнән кабул иткән кешегә, ягъни укытучыга агитация алып бару, чыгышлар ясау кыен булмагандыр. Әмма әлегә рухи, сәяси кыйблаңны белдерү бик хәтәр. Советны яклаган өчен генә дә, дошман кулына эләксәң, күкрәккә йолдыз кисүләр, туганнарыңны, хәтта әти-әниләреңне асып куюлар, хатын-кызларны көчләүләр һ.б. тарихта билгеле фактлар бит. Зөһрәнең бәхетенә ире Гыйлемдер Баимбетов янәшәсендә әле. Ул мөселманнардан махсус хәрби частьлар оештыруга бөтен көчен куеп йөри.

– Фронтка килгәндә, безгә хәтта хәрби киемнәр дә бирмәделәр, – дип искә алды Зөһрә апа. – Съездга нинди кием киеп килгән идек, шулай йөрергә дә туры килде. Төрле хәлләр булды инде, хәзер искә алырга да куркыныч. Бервакыт берничә кеше Татар Шырданы авылына крестьяннар белән җыелыш җыярга, аларны Кызыл Армиягә язылырга өндәргә килдек. Бу авылда Зыя Вакыйф дигән мөгаллим Кызыл Армиягә ярдәм итә торган булган. Без үзебез белән листовкалар, воззваниеләр алып бардык. Җыелыштан соң иптәшләрем китте, мунчага керәсем килгән иде, мин калдым. Икенче көнне уракка киткән авыл кешеләре, «аклар килә» дип кычкырышып, куркып, кире кайттылар. Зыя миңа ат биреп озатмакчы иде, тик үзем генә китәргә кыюлыгым җитмәде, ахры. Мин алып килгән әдәбиятны Зыя тиз генә тирес астына күмде дә гаиләсен алып чыгып китте. Сеңлесе минем белән калды. Берзаман бикле капкага бик яман итеп, ачыгыз дип бәрә башладылар. Бәхетебезгә, кермичә кире киттеләр. Вакыйф күпмедер вакыттан соң гына кайтты.

Халыкны куркытып, авылга басып керүчеләр Каппель отряды сугышчылары булган икән. Үз башларына булгандыр, Троцкий тиз генә аларга каршы бронепоезд җибәреп, 3 сәгать буе солдатларны да, авылны да утка тоттылар. Өч көннән соң безнең гаскәрләр килде.

Зөһрә апа, һич ялгышмыйча, 1918 елның 5-6 августында Казанның чехлар һәм акгвардиячеләр кулында калуын да, 10 сентябрьдә Кызыл Армия тарафыннан азат ителүен дә дулкынланып сөйли иде. Үз күз алдында булган хәлләр бит.

Чыннан да, Россиянең язмышы шушы Көнчыгыш фронт кулында булганын хәзер тарихтан укып беләбез. Троцкий Свияжскига килгәндә, яңа оешкан армиядә дисциплина бик йомшак була. Солдатларның күбесе кичәге крестьяннар, заводлардан мобилизация белән килгән эшчеләрдән тора. Ул килү белән, коточкыч ысуллар кулланып, армиядә тәртип урнаштырырга керешә. «Сез – тарихчылар беләсез булыр, – дип сөйләде Зөһрә апа, – Троцкий иң беренче итеп заградительный отрядлар (сугышчылар чигенмәскә юлны каплау өчен) оештырды. Мондый алымны Пётр I Полтава сугышында иң беренче булып куллана бит. Аны беләсездер инде (гафу итсен Зөһрә апа, белми идем – *авт.*), 29 августта 2 нче номерлы Петроград полкы, Каппель гаскәрләре кысуга каршы тора алмыйча, позицияләрне ташлап китә башлады. Ачуыннан ярсыган Троцкий шунда ук полк комиссары Пантелеевны һәм командир Гнушевны атарга боерык бирде. Сугышчыларны тезеп куйдылар да һәр 10 нчы кешене аттылар. Күз алдыбызда 41 кеше юк ителде, кызым. Мин алар арасында, алар күз алдында йөргән кеше бит. Ничек онытыйм. Мәетләрне суга ыргыттылар да катерларның винтлары белән бәрдереп тә үттеләр әле. Күрергә язмасын. Мин

бу хәлләрне тыныч кына кичерә алмадым, авырдым. Ярый әле, ирем Гыйлемдар да Свияжскида иде. Баштарак армиядә рус телендә генә «Гражданская война» дигән газета чыга иде. Әмма Баимбетов политбүлектә мөселманнарга аерым газета чыгару өчен тырышты. Куркып тормады. Ниһаять, 1918 елның 6 декабрендә Бөгелмәдә «Кызыл яу» газетасының беренче саны чыкты».

Зөһрә апаның искиткеч хәтеренә сокланып туя алмый идем.

Казанны алгач, кызыл гаскәрләр Сембер, Бөгелмә шәһәрләрен ала. Тик Зөһрә апа шул тетрәнүләрдән соң тиф белән авырый. Армиядән азат ителеп, 1918 елның декабрендә Уфага әйләнеп кайта. Авырудан сәламәтләнгәч, Уфа губкомының мөселман секциясендә эшли башлый.

Тик Гыйлемдарын Казанга чакыралар. Зөһрә апа да Уфадан китәргә риза була. Алар Казанда бергә яши башлыйлар.

1919 елда Казан губкомының мөселманнар бюросы секретаре һәм бер үк вакытта татар хатын-кызлары арасында эшләү өчен губкомның хатын-кызлар бүлеге инспекторы вазифаларын да башкара. Ул эшне үз тәҗрибәсенә таянып җәелдерә. Шәһәрдә генә түгел, авылларда да хатын-кызлар советлары оеша башлый. Хатын-кызлар арасында җыелышлар үткәрү, балалар бакчалары, ясләләр ачу, артельләр оештыру; хатын-кызларны мәктәпләргә, рабфакларга кертү; профсоюз, кооператив оешмалары, совет органнары эшенә тарту; аларга көндәлек ярдәм күрсәтү; Кызыл Армиягә булышу атналары оештыру – менә шундый һәм башка бик күп төрле вазифаларны үтәүдә Зөһрә башлап йөри, башкаларны да өнди. Ул шул еллар матбугатында чыгып килгән «Хатын-кыз сәхифәләре»нә күпсанлы мәкаләләр яза. Кайберләре үзәк матбугатта да басыла. Хатын-кызлар күңелен аңлый белүе, аларның кайгы-хәсрәтләрен үзенеке итеп уртаклашуы, ярдәмче булганы өчен үз итәләр Казанда Зөһрәне һәм, яратып, «Таң кызы» дип йөртәләр.

Шул ук вакытта Зөһрә апага 16 нчы мөселман пехота полкы командирларын хәзерләү курсларында да дәресләр алып барырга туры килә.

1919 елның ноябрендә Казанда татар коммунистларының конференциясе үтә. Анда Зөһрә апа Мәскәүдә узачак Көнчыгыш халыклары коммунистларының II Бөтенроссия съездына делегат итеп сайлана. Съездда аны президиумга утырталар. Биредә ул В.Ленин һәм Н.Крупская белән сөйләшеп утыра алган. Н.Крупская Уфада сөргендә булган хәлләрен сөйләгән. Ленин исә, Зөһрәнең рус телендә камил сөйләшүен игътибарга алып, бик кызыксынган, Казан хәлләрен сорашкан.

Бу хакта язуымның төп сәбәбе дә – Зөһрә апаның аларны шулай бик үз итеп, бик җылы итеп искә алуы.

1920 елда ТАССР оешкач, Зөһрә апа партиянең Өлкә комитетына да әгъза булып сайлана. Мәскәүдә 1920 елның декабрендә үткәрелгән Советларның VIII съездында катнаша, хәлиткеч тавыш иясе була (право решающего голоса). Кайту белән Татарстан партия Өлкә комитеты Зөһрә апага хатын-кызлар бүлеген җитәкләүне тапшыра. Аның тырышлыгы белән 1921 елның гыйнварында Казан дәүләт университетының Актлар залында татар эшче һәм крестьян хатын-кызларының беренче съезды ачыла. «Бу съездны оештыруда күрсәткән ярдәме өчен Исхак абый Казаковны әле дә рәхмәт хисләре белән искә алам», – дип сөйли иде Зөһрә апа. Чөнки Татарстанның матди хәле бик авыр. Мәскәү «ярдәме» белән башланган ачлык котырган вакыт бит бу. Һәркемгә нинди дә булса бүләк бирергә, күңелләрен табарга кирәк. «Безне кешегә санап дөньяга чыгардың, изге җандыр син», – дип елый-елый аркасыннан сөючеләр күп булган аның. Съезд 22 гыйнварга кадәр гөрләп барган. Үзәк һәм җирле оешмалар матбугат съездның эшенә югары бәя биргәннәр. Мәскәүдә 1921 елның 21 июненә тәгаенләнгән Шәрык хатын-кызларының I Бөтенроссия съездына доклад хәзерләүнең дә нәкъ Зөһрәгә тапшырылуы да очраклы хәл булмый, әлбәттә.

Әйткәнебезчә, Татарстанда бу вакытта ачлык көннән-көн куркыныч төс ала. Съезд

да шуңа күрә үткәрелми кала. Хатын-кызлар бүлеге мөдире Зөһрәгә хәзер гаять авыр бурыч йөкләнә. Ул – ач балаларга ярдәм күрсәтү комиссиясе рәисе, Татарстанда ачларга ярдәм күрсәтү комиссиясе әгъзасы, Халык мәгарифе Комиссариатының социаль-тәрбия бүлеге мөдире. «Гомер буе исемнән чыкмады ул коточкыч көннәр, – дип яза ул үзенең истәлекләрендә. – Татарның пәһлевандай ирләрен Урта Азиядә Совет власте урнаштырырга җибәрделәр. Урамнарда, пристань, вокзалларда, ишегалларында, олы юлларда аунап яткан ачтан шешенгән, сәләмә киемнәрдән, тәннәрендә җаннары көч-хәл белән сакланган балаларга ярдәм күрсәтү өчен 291 пункт ачылды. Аларда эшләү өчен хатын-кызлар бүлекләре вәкилләре, югары уку йортында укучы студентлар тартылды. Алар эшне балалар өчен дарулар, кием-салымнар, ашханәләр өчен савыт-саба, кашык җыюдан башладылар (чөнки кайбер ашханәләрдә 80 балага 1 кашык туры килгән»). Нәкъ менә шул хатын-кызлар тырышлыгы белән ачлар файдасына «Балалар», «Кызыл Хач», «Ачларга ярдәм» һ.б. атналыклар оештырылган.

Икмәкле өлкәләргә озату өчен балаларны башта беттән арындырырга, мунча кертергә, өс киемнәре һәм поездларда озата баручыларны табарга кирәк булган. Балаларны икмәкле өлкәләргә озату өчен махсус санитар поездлары оештырылган. Беренче поезд 1921 елның сентябрендә киткән. Зөһрә апа эшләгән дәвердә 15 мең бала, ач үлемнән коткарылып, читкә озатылган.

1922 елда аны көтмәгәндә генә бу эшеннән азат итәләр. Эвакуация комиссиясен Лидия Гришина җитәкли башлый.

Зөһрә апаның тагын бер истәлеген язып үтәм. «Мине, эшкә дип Татарстаннан Бохарага җибәрделәр. Китәчкә тә, үзем читкә озаткан балалар күз алдында торды. Юкка булмаган икән. Берничә елдан, Кисловодскидан Мәскәүгә кайтып барышлый, сеңлем белән вокзалда утырабыз. Безнең татарча сөйләшкәнне ишетеп, сәләмә киемле бер бала килде. Елый-елый: «Апа, сез Казандагы Зөһрә апаны белмисезме? Безне Казаннан җибәргәндә, кайтарам дип вәгъдә биргән иде. Кайта алмадык бит менә. Мин монда бер байда ялчы булып хезмәт итәм, туйганчы ашаганым да юк», – дип үзәгемне өзде. Кемлегемне әйтергә оялдым». Бу истәлек үзе генә дә халкыбыз кичергән фаҗига хакында сөйли бит.

Зөһрә апаның Татарстаныбыз белән бәйле гомере, хезмәте шулай 1922 елда туктала. Әмма ул никтер туган Уфасын түгел, Казанны күбрәк сагына кебек тоела иде. Кемнәрне генә сөйләми, кемнәр белән генә аралашмаган бит үз вакытында. Әмма аларның күбесе репрессияләр чорында юк ителгәннәр, шуңа күрә истәлекләрен яза алмый иде. Әле үзгәртеп кору башланмаган, белгәннәрне сөйләргә рөхсәт юк иде.

Үзем бервакыт Зөһрә ападан: «Ни өчен сез үзегезне документларда башкорт кызы дип күрсәтәсез? Әтиегез татар, сөйләшкәндә, татар кызы икәнлегезне әйтәсез», – дип сорадым.

– И кызым (ул миңа гел кызым дип әйтә иде – *авт.*), Татарстанда, ни кызганыч, татарларның кадере юк. Ә Башкортстан безне ничек хөрмәтли. Картайгач, күңел әнә шул хөрмәтне дә өмет итә икән, – диде Зөһрә апа. Аның матур истәлеген Татарстанда да онытмасыннар иде.

1986 елда Мәскәүдә вафат булды ул. Кабергә күмелмәде, кремацияләнде. Аны белгәннәрнең балалары рухына дога кылсыннар. Татар халкына күрсәткән игелекләре үзенә савап булсын. Исеме тарихыбызда урын алсын, онытылмасын.

**Тәэминә БИКТИМЕРОВА,**
*тарих фәннәре кандидаты,*
*Татарстанның атказанган*
*мәдәният хезмәткәре.*

# ШУНДЫЙ ТӨРЛЕ ҺӘМ ШУНДЫЙ БӨТЕН... ЯЗМЫШ

## ФӘЙРҮЗӘ МӨСЛИМОВА ТУРЫНДА КАЙБЕР ИСТӘЛЕКЛӘР

*Фәйрүзә апа – минем өчен балачактан алып соңгы көннәренә кадәр әллә никадәр төсле кыйпылчыклардан җыелган, әмма һәрвакыт бөтенлеге белән гаҗәпләндергән, сокландырган шәхес ул. Без аны «Ялкын» гаиләсе белән һаман да сагынабыз, искә алып сөйләшәбез, аннан калган канатлы сүзләрне, афоризмнарны кабатлап йөрибез.*

*Ә үзем... шигырьләре белән сөйләшүемне дәвам итәм. Шигырьдә без – үлемсез.*

### Фәйрүзә апа һәм уңыш формуласы

*«Язуыңны ташлама, яме...»*



…тормыштагы Фәйрүзә апа миңа иң башта әнә шул сүзләре белән тышлыгына Чаткы сурәтләнгән зу-у-ур конверттагы хат булып килеп төште. Бер өтерен дә калдырмый укый, ай саен көтеп ала торган кадерле «Ялкын» журналыннан. Анда минем әле беренче генә мәртәбә язуым. Дөресрәге, язган-сызганнарымны туплап, аларга әнием җибәрде, үзем җөрьәт итмәс идем. Татар теле һәм әдәбият укытучысы булганга гына түгел, ә бар йөрәге белән иҗатны яратканга күрә, шулкадәр язуыма юл бирергә теләдеме икән дип гаҗәпләнә идем. Аннары миңа мирас булып калган көндәлекләрне, алардагы шигырь-хикәятләрне укыдым да аңладым: әбием дә, әнием дә гомер буе язганнарын кешегә күрсәтергә, дөньяга чыгарырга тартынганнар, әмма күңелләрендә иҗат бөресе таҗларын ачарга оялып яши биргән барыбер...

Озын сүзнең кыскасы, Назлыкай исемле песием турындагы шигырь белән Тиен хакындагы әкиятне «Ялкын» журналында эшләгән Фәйрүзә апа укыган да миңа җавап язган – егылып китәрсең! Мин шулай иттем дә – зу-у-ур конвертны кочаклап, егылып китмәс өчен тизрәк диванга менеп кунакладым. Һәм аны бик сак кына ачтым. Эчендә шундый ук Чаткы сурәте төшерелгән бераз гына саргылтрак шоп-шома кәгазьгә матур, җыйнак почерк белән язылган сүзләр:

*Кадерле Луиза!*

*Безгә җибәргән шигырьләреңне һәм әкиятеңне алдык, рәхмәт. Шигырьләреңнең кайберләрен, уңышлы килеп чыкканнарын, журналда бастырып чыгарыр өчен сайладык, күзәтеп бар. Ә менә әкиятеңә килгәндә, аны бастыра алмыйбыз. Ул әле җиренә җиткереп эшләнеп бетмәгән, бу темага язылган кайбер башка әкиятләрне кабатлый. Ышанам, син кызыклырак сюжет, темалар табарга сәләтледер. Шуңа күрә уйлап йөр дә яңасын яз! Бу сүзләрдән күңелең төшеп, каләмеңне, язуыңны ташлама, яме! «Ялкын»ны укып бар һәм безгә тагын хатлар җибәр.*

*Уңышлар теләп, Фәйрүзә апаң Мөслимова*

Шигырьләремне «Ялкын»да бастырыр өчен сайлап алганнарын белү иңгә канатлар куйды, ә менә әкиятемнең чиле-пешле булуын белү кыбырсытты, билгеле. Шунда ук аның уңышсызлыгы нәрсәдә икәнен ачыклар өчен кат-кат укырга утырдым. Чыннан

да, минем бу Тиен турындагы әкиятемдә бер генә дә моңарчы язылган әкиятләрдә булмаган яңалык юк икән шул. Димәк, башкача уйларга һәм язарга кирәк...

Фәйрүзә ападан килгән хат мине бик мөһим бер нәрсәгә өйрәтте – нидер барып чыкмаса, салкын акыл белән, утырып, эшләгән эшеңне анализлап кара.

Әни дә, әнә: «Фәйрүзә апаң бик дөрес сүзләр язган, кызым», – дип тора. Шуннан мин шигырьләремне дә кат-кат укып чыгып, кайсыларын сайладылар икән дип уйланырга керештем. Үзем өчен кимчелекләре аермачык ярылып ятканнарын билгеләп куйдым да уңышлырак кебек тоелганнарын, аерып, яңа дәфтәргә күчереп яздым. Бу мине системага күнектерде. Шуннан соң инде «каралама» дәфтәрдән «акка», әйтик, биш шигырьнең берсе генә күчә башлады...

Ә аннан мин кроссвордлар төзү белән мавыгып киттем. Тырыша-тырыша төзеп, рәсемнәр ясап, бизәп, боларны «Ялкын»га юллыйм – менә җир йөзендәге иң үзенчәлекле җәнлекләр турындагысы, менә иң сәер атамалы илләргә багышланганы... Кроссвордлар буенча миңа хатлар килмәде-килүен, әмма аларның икесен шулай да журналда бастырып чыгардылар. Фәйрүзә апа белән танышып, инде бер редакциядә кара-каршы өстәлләрдә утырып эшли башлагач, бер үк балалардан бер үк төрле язмалар даими килеп торганда, ул миңа ара-тирә көлеп әйткәли иде: «Карале, Луиза, үтерден генә бит син берара безгә ай саен кроссвордлар яудырып...»

Иҗатта уңыш формуласы – бик серле төшенчә. Кайчакта ул әдипнең чын-чынлап таланты һәм масштабы белән тәңгәл килмәскә, бик күп башка төр иҗтимагый факторларга бәйле булырга да мөмкин. Яшерен-батырын түгел, һәр каләм тибрәткән кеше монда чакта ук исемен дә, текстларын да ташка бастырып, мәңгеләштереп калдырырга тырыша, әле аны тагын премияләр белән дә ныгыта алса – бөтенләй хозурият. Әмма әдәбият юлына аяк баскан бик күпләргә уңышның җигелеп эшләгән хезмәтең һәм үзеңә бирә алган азмы-күпме төгәл, адекват бәяң икәнен төгәл аңлатучы булмый. Һәм иҗатка кеше «мине тизрәк күрсеннәр», «барысы арасыннан аерып, мине бәяләсеннәр» дигән агу белән агуланып килә. Ә дан белән сыналуны кайчак бик гаярьләр дә күтәрә алмый.

Хәзерге акылым белән аңлыйм: әнә нинди олы эш башкарган «Ялкын»дагы Фәйрүзә апалар – алар безгә, әле акны-караны аера белмәгән, ныгып җитмәгән балаларга, үҗәтлек һәм тырышлык дәресе биргәннәр. Нәрсә язсам, шул ярый дип, иҗатка җиңел карамаска. Тәнкыйтьне кабул итә белергә һәм үзең белән күзгә-күз калып, кан яңартырга өйрәнергә. Умырткаңны тикшереп карарга – күтәрә алачакмы ул бу йөкне, юкмы? Әгәр шикләнәсең икән, бәлки, урының монда түгелдер?

## Фәйрүзә апа һәм «Алтын каләм»

*«Журналистика белән*
*филологияне бутамагыз!»*

«Борис Полевой» теплоходында «Алтын каләм» белән сәяхәттә йөргәндә, безне татар журналистикасының киләчәге булыр өчен тәрбияләделәр. Әйтергә кирәк, бу – «Алтын каләм»нең иң гөрләгән еллары, республиканың да яңарган, үз милли кадрларын барлаган, үстерергә йөз тоткан вакытлары. Без, «суверенитет җилләре»н сулап, бөтенләйгә төзәлмәслек булып чирләп калган буын балалары, ул елларга уйда еш әйләнеп кайтабыз. Яңа чорны ваемлар өчен. Дөресрәге, ваемлап-ваемлап та, ваем инде тәмам өзелгәндә...

Татар журналисты, язучысы булу абруйлы саналган, исеме горур яңгыраган чаклар ул. Каләм белән дөньяны үзгәртеп була дип ышанган чаклар.

Фестиваль барган көннәрдә без Казандагы гына түгел, ә Мәскәүдән килгән мәртәбәле кунаклар вә журналистлар белән дә очрашабыз, аралашабыз. Алар әйткән сүзләрне сөземлибез, анализлыйбыз. Осталык дәресләре алабыз, биремнәр

башкарабыз. Фикер алышабыз. Бәхәсләшәбез. Килешәбез. Килешмибез. Кабул итәбез. Уйланырга калдырабыз.

«Алтын каләм»дәге бер очрашу, сөйләшү вакытында Эльмира апа белән Фәйрүзә апа безнең язмаларны җентекләп анализлаган, сүтеп-җыеп чыккан иде. Шунда кайберәүләребезгә бик җитди вердикт чыгарылды: сез оператив журналистика вәкилләре түгел, сез күбрәк журнал форматына, аналитикага йөз тотасыз. Миңа һәм тагын бер-ике кыз белән егеткә Фәйрүзә апа, һәрвакыттагыча туры итеп, кистереп әйтте: «Журналистика белән филологияне бутамагыз! Сезгә филологияне сайлау кулайрак булачак!»

Баштарак бу сүзләр мине үртәлдереп җибәрсә, университетка кергәндә, үзсүзлеләнеп, барыбер ике факультетка гариза тапшырсам да, тора-бара аңладым: Фәйрүзә апа үз тәҗрибәсенә таянып, бик хак әйткән. Ә аннары, без аның белән редакциядә яшь журналистларның текстларын тикшергәндә, редакцияләгәндә, шуны да сиздереп куя иде ул, кырыс кына итеп: «Менә, Луиза, әйтә идем бит – филологиягә барырга кирәк дип! Редакцияләрдә журналистларның текстларыннан конфет ясар өчен редакторлар кирәк чөнки!»

Асылда, алар безне еллар буе күзәтеп, кайсыбызның кайсы ягы көчле, кем нинди юнәлеш белән китә ала икәнен фаразлап торганнар. Мин Фәйрүзә апа белән «Ялкын» редакциясендә бергә эшләгән елларны аерым бер наз һәм сагыну белән искә алам.

## Фәйрүзә апа һәм дәвамчанлык

*«Сез – яшьләр, дөнья яшьләрчә барырга тиеш, ә без – күзәтеп, төзәтеп торучылар»*

Әйтүен шулай әйтсә дә, Фәйрүзә апаның беркайчан да бәйләнеп, мыжыкланып, ягъни өйрәтеп, «төзәтеп» утырганын хәтерләмим. Аңарда, шәрран яра торган турылыгы белән беррәттән, гаҗәеп тактика, әдәп, саклык бар иде. Беркайчан да кешегә күтәрелеп, орылып бәрелмәү, ә нindидер бер җиңел генә юлын, сукмагын, җаен таба белү. Кемнәрдер артык «һавагарак» менеп киткәндә, йә шаяртып, йә бик тә тормышчан фразасы белән шапылдатып, җиргә төшереп тә куя белә иде Фәйрүзә апа.

Барлык яңалыкларга, эзләнүләргә, экспериментларга ачык иде ул. Талантлы булган һәр нәрсәне, күңеле якын итеп бетермәсә дә, таный белә һәм кабул итә. «Кеше үз вакыты белән тиешле урынына кайтып төшә ул» – әнә шул фәлсәфә аны авыллардагы зирәк Акъәбиләр белән тиңләштерә дә, мөгаен. Бик җилкенчәк яшьләр дә итәкләрен җыярак төшә.

Аңарда гомер буена төрле авырлыклар күргәндә дә, сынауларны кичкәндә дә җуелмыйча сакланып калган кызыксынучанлык һәм балаларча мавыгу бар иде. Нindидер кызыклы яңа әйбергә балаларча чын күңелдән шаккатa, гаҗәпләнә белә иде ул.

Шундый ук кызыксыну һәм мавыгу, димәк ки, ихласлык белән Фәйрүзә апа рухи кыйблага да еллар буе баргандыр, минемчә. «Яшьлектә хаталандык та, җүләрлекләр дә эшләдек инде...» – дип сукранып куйган чакларында да, публика өчен түгел иде аның сүзләре. Бу – аның әлеге дә баягы шул еллар буена сузылган уйланулары, эчке мантыйгы, тормыштан сөзеп алынган фәлсәфәсе. «Коръәнне аңлап укыйсым килә» дип башлаган Фәйрүзә апаның алга таба Хаҗ сәфәрләреннән, хәзерге тел белән әйтсәк, нинди инсайтлар белән кайтканын күрә идек. Анда да ул дуслар таба, кешеләргә ярдәм итә, алар белән аралашып яшәвен дәвам итә, Аның биргәненә шөкер итә...

*«Мин картлыгымның Фәйрүзә апаныкы кебек булуын телим» дияргә ярата идем «Ялкын»да эшләгән елларымда. Һәм хәзер дә еш искә алып уйлыйм бу хакта.*

Әлеге дә баягы, эчендә утырган «сабый» аны сәяхәтләргә әйди иде. Фәйрүзә апаның

Луксорга, Карнакка сәфәр кылып, Фиргавеннәр үзәнен үз күзләре белән күреп кайтып, карашы очкынланып, янып сөйләгәннәре әле дә күз алдымда. Бөтен редакция белән җыелышып, компьютерда ачып, аның йөзләгән фотоларын караганыбыз да.

Ул – редакциянең мыжлап, кайнап торган чагы, ә Фәйрүзә апа, без шаярып кына бер атаганча – «Верховная Жрица». Әмма бу шаяруда хаклык бар иде.

Менә без «Ялкын: журналистика мәктәбе» балаларын көтүләре белән редакциягә алып килеп, берәр проект уйлап чыгарабыз; менә университеттагы дәресләреннән, радио һәм телевидениедәге маҗараларыннан соң Линар Закиров кайтып керә дә эчләрне катырып көлдереп бетерә; менә кичке параларыннан соң, актыкка тиеннәреннән колак каккан һәм Ленин дамбасын буран ера-ера җәяүләп кичкән, мәңге ач Эльнар Байназаров (редакция телендә – «Байназаврик») килеп керә дә, суыткычны бушата-бушата, гитарасын чиртә...

Ә андый очраклар өчен Фәйрүзә апада һәрчак диярлек чөгендер кәтлите бар иде. Бу серле ризыкны аннан соң безнең барыбыз да рецептын төп-төгәл үтәп әзерләп карады. Нәрсә дип уйлыйсыз? Билгеле, барып чыкмады! Чөнки ул «фирменный» кәтлит иде. Бары Фәйрүзә апа кулыннан гына шундый тәмле булып пешеп төшә торган...

...шулай да пешергәлим. Ностальгия һәм дәвамчанлык.

Аларның игътибарын, кайгыртуын тоеп үскән буын буларак, иңгә-иң куеп, редакция эшен алып бару бик зур җаваплылык та, горурлык та булган икән. Гомумән, бу дәвамчанлык безнең милли журналистика белән әдәбият мохитендә хәзергә кадәр кадерләп саклана бирә. Менталитет та, тәрбия дә бу.

## Фәйрүзә апа һәм «егетлек»

*«Егетләрчә» дигән мактау сүзе,*
*Миңа калса, чыкты модадан.*
*«Егетсең!» – дип хупласалар кинәт,*
*Кызлар кебек никтер кызарам.*

*Бик күпләрен, пирчәткәмне ташлап,*
*Дәшәр идем атыш-дуэльгә.*
*Тик шикләнәм, йөзен яшермичә,*
*Каршы чыгар икән кем генә?*

*Егет булмыйк әле, хатын-кызлар!*
*Өстен калыйк мондый ирлектән.*
*Ходай биргән хатын-кызлык ямен*
*Саклап яшик җирдә ничек тә.*

Шигыре дә юктан гына язылмагандыр, шигырьдәге мондый уйланулар да безгә мирас булып юкка гына калмагандыр... Әмма мин Фәйрүзә ападагы «егетлек»не ярата идем. Һәм әлегәчә яратам.

Гадәттә, бу сыйфат безнең милли-мәдәни мохиттәге күпчелек егетләргә җитешеп бетми, ә менә Фәйрүзә апада ул бар иде. Әйтсә, сүзен ярып, фикерен чатнатып әйтеп сала, уйламаганын, шулай дип исәпләмәгәнен сөйләнеп, сүз болгатып утырмый. Ни гаҗәп, аның бу «егетлеге» ике җенес вәкилләре өчен дә уңай иде – барысы да аның белән сер бүлешә, киңәшләшә, гозерен сөйли. Кемнәр өчендер «жилетка» вазифасын да үти иде Фәйрүзә апа. Әмма нәкъ менә «егетләрчә»: ыспайлап-назлап тормый, ә ситуациясенә карап, кистереп әйтә. Турысын әйтергә ярамаганда, дәшмәүне кулайрак күрә.

Тирә-ягында кемнәр нәрсә сөйләмәсен, ничек кенә талпынмасын, гасабиланмасын, Фәйрүзә апа ул шаукымнарга бирелми, үз көйләнешендә кала бирә. Мине аңардагы тагын бер бик сокландырган сыйфат – адәмнәр егылып, дан артыннан куганда да, мал артыннан куганда да, комарлыкка бирелмәве. «Биргәненә шөкер!» – дия иде Фәйрүзә

апа һәм вакытын юк-барга, ваклануларга түгел, ә эшкә багышлый: китаплар, мәкаләләр яза, бертуктаусыз текстлар редакцияли, нидер тәрҗемә итә, оныкларны тәрбияли, Хаҗ сәфәренә җыена, бакчасын үстерә, шунда чакырып мунча кертә, кунак итә...

«И егетләр!» дип кенә куя кайчак Фәйрүзә апа, чираттагы берәр «сер капчыгы»ннан соң, йә шаккатып, йә тел шартлатып. Әмма сабыр гына тыңлый да, булыша да, шелтәләп, сүккәләп, кирәкле юнәлешкә борып та җибәрә... Аллаһы Тәгалә аның аша узарга җибәрелгән бер генә бәндәне дә кире бормый. Ул чакта әле без аны яшьлегебез белән, билгеле, аңлап бетермәгәнбез. Хәзер менә аңлыйбыз, Фәйрүзә апа. Сиңа килеп, сер бүлешер чаклар бар, әмма син юк...

## Фәйрүзә апа һәм ирония

*Сикерә дә чыга әрсезләнеп телем.*
*Шул телемне җиңсәм, әйбәт яшәр идем.*
*Дәшмәм дигәнем бар, әйтмәм дигәнем бар,*
*Телләремне тешләп, башым игәнем бар.*

*Дәшми калу – рәхәт, сүзсез тору – рәхәт.*
*Түзеп булса икән шулай рәхәт яшәп.*

Дөньяга карата – иронияле, ә үзенә үзиронияле иде Фәйрүзә апа. Шулай берсендә безнең балалар редакциясенә гомер булмаган бәхет елмайды – суыткыч бүләк иттеләр. Хәзер инде төгәл генә хәтерләмим – кемнән, каян һәм нәрсә өчен... Әмма бик каты сөенгәнебезне хәтерлим!

Суыткыч редакциягә китерелде, бик күпне күргән искесе бүлмәдәге «коронный» урыныннан чыгарылды. Мондый куаныч хөрмәтенә бар редакция җыйналды. Һәм менә иске «Свияга» урынына яңа, матур, ялт итеп торганы сыямы-юкмы икәнен фаразлыйбыз. Редакциянең ике бөртек егете – Линар белән Эльнар – күз белән үлчәп карадылар-карадылар да Фәйрүзә апага мөрәҗәгать итәргә булдылар: «Ничек уйлыйсың, Фәйрүзә апа, сыярмы икән?» Фәйрүзә апа шулай ук килеп карап-карап торды да ике генә сүз әйтте: «Гарантия юк!»

Шуннан бирле «гарантия юк!» гыйбарәсе – иң киеренке дә, иң әкәмәт, шаккаткыч та хәлләр булганда, безнең гел Фәйрүзә апаны искә алып куллана торган кадерле афоризмыбыз.

Гарантия дигәннән. Җир йөзенә һәркем үз миссиясе белән килә, аны мөмкин булган масштабында үтәргә тырыша. Иҗат кешеләре бигрәк тә. Мин Фәйрүзә апаны үз миссиясен план-максимум белән үтәгән кеше дип исәплим.

Аңардан тыйнак, әмма берәгәйле итеп төзелгән күркәм Иҗат йорты, җирдәге кадерле нигезе, балалары, туруннары, шигъриятен, прозасын яратучылар һәм без – бәрәкәтле йогынтысы, тәрбиясе, дуслыгы эләккән дәвам кала.

Без әле бу Җир йөзендә яшәгәндә, синең дә исемең, иҗатың яшәячәк, аны үзебездән соң килгәннәргә дә тапшырып китәчәкбез, Фәйрүзә апа. Шулай булгач, гарантия бар!

**Луиза ЯНСУАР**



*Чыңгыз Мусинны мин күреп белү бәхетенә ирешә алмый калсам да, исеме балачагым туры килгән туксанынчы еллар башыннан ук таныш. Үзем Әгерҗе кияве булганчы, аның бу тарафларда туып үскәнен һәм гомерен Илдус Гыйләҗев сыман үз төбәгенә багышлаган шәхес булуын тәгаен белә идем. Шуңа да карамастан, шагыйрь исән чакта ул туып үскән Тирсә авылына да, гомере үткән Мордвый җирлегенә дә, берничә мәртәбә аның авылы янәшәсеннән машинада яки автобуста узуымны исәпләмәгәндә, юлым төшмәде. Ә менә вафаты алдыннан «Казан утлары» журналына юлланган соңгы шигырьләре әлегәчә күңелне бимазалап тора иде.*

*Ул чакны шигърият бүлеге мөдире Гөлзадә Бәйрәмова сөйли: «Кичке тугызларда ваннага кергән идем, берәү кесә телефонына шалтырата. Алсам, Чыңгыз Мусинның «Шигырьләр җибәрдем, килеп җиттеме?» – дип кызыксынуы икән. Эш сәгатендә шалтыратса булмый микәнни соң бу картларга?» – ди. Шуннан озак вакыт та узмагандыр, 2016 елның 24 октябрендә Чыңгыз Мусин 82 яшендә дөнья куйды. Ә соңгы юлланган шигырьләре редакция папкаларында калды...*

*Чыңгыз Мусин – шигырьләре Иж, Чаж елгаларының суларында сугарылган Әгерҗе шагыйре. Аларда үзе яшәгән төбәк топонимикасы, шул төбәктә гомер итүчеләрнең хис тойгылары, уй-фикерләре, холык-фигыльләре, фольклоры чагылыш таба. 1934 елның 16 июлендә Тирсәдә дөньяга килгән аксакалның хезмәт юлы автомобиль транспорты белән бәйле була, шул ук вакытта ул дүртенче сыйныфларда укыганда ук шигырьләр иҗат итә башлый. Үзе исән чакта «Язмышым үзәннәрендә», «Тамырлар», «Кадер кичендә», «Баганалы юллар», «Гомер юлы», «Карт юкәләр яшь чәчәктә», вафатыннан соң «Иж буенда кала эзләрем» шигырь җыентыклары, ә 2008 елда үзе туплаган тарихи материаллардан гыйбарәт булган «Әгерҗе төбәге: тарихи сәхифәләр» китабы дөнья күрә. Чыңгыз Мулламөхәммәт улы Мусин − 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы; Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

Чыңгыз
Мусин

# СУКАЛАНГАН ҖИР БАШЫ...

## Кадер кичендә

Кайвакытта рухың белән үсәсең дә,
Сихри дөнья тарафына күчәсең лә.
Фәрештәләр җиргә иңгән бер заманда
Шигырь яздым, изге Кадер кичәсендә.

Шигырь туса, минем күңелем үсә кебек.
Нурланамын, гүя назлы бичә кебек.
Шигърият – ул Ходай биргән олы тәхет,
Һәркемгә дә тәтемидер мондый бәхет.
Бу гамәлем дөньябызны җайлар кебек.
Җырларымны кошлар отып сайрар кебек.
Фикер кылу тынмас җанга бер сәбәптер,
Һәр ялгышны ярлыкарлык мең саваптыр.
Бу могҗиза һәр гамәлдән югарырак.
Ни кызганыч, күпләр аннан ераграк.
Шигърият ул җан түрендә бер таҗ кебек,
Бу бәхетемне җуймасам дип куркам берүк.
Сәясәттә зиһеннәре какшаганда
Шигырь укып илһамлана патшалар да.
Шигырьне мин түшәк итеп җәямен дә
Юрган итеп ябынамын өсләремә,
И Ходаем, тагын бер зур бәхетем артты,
Илһам бирдең изге Кадер кичләрендә.

## Еллар узгач

Мин карт инде хәзер, бу җиһанда
Сизелмичә килде картлыгым.
Һәр ел саен бер кат тирем үсте,
Хәзер инде сиксән катлымын.
Сиксән тапкыр язлар кабатланды,
Ашкындырып дәртле хисләрне.
Һәр ел саен тирем калынайды,
Маңгайларга сырлар өстәлде.
Тик салмадым әле тәүге тапкыр
Иңнәремә кигән биштәрне.
Бер гасырга җитә язган икән
Миңа тигән шушы аралык.
Кыштыр-кыштыр әле дә яшим шулай
Кеше хисабында саналып.
Һәр ел саен язлар кабатланды,
Язгы көннәр торды төрләнеп.
Сандугачлар кайтты, җырын сузды,
Бөдрә талларында тирбәлеп.
Тормыш ваклыклары, шатлыклары
Сиздермәде түгел, сиздерде.
Төгәл генә кемнәр хәтерләсен
Узгандагы һәрбер мизгелне?
Мин тормышта күпне кичердем шул,
Инешләрдә атлар эчердем.
Кемнәр дошман, кемнәр дус булуын
Еллар узгач кына төшендем.
Тормыш мәйданында сынатмадым,
Бил бирмәдем бәйге-ярышта.
Карашларым инде көнгә түгел
Төбәлгәннәр кояш баешка.
Сиксәнемә табан кереп барам

Каешланган кат-кат тиредән.
Ирексездән тәүге тойгыларым
Үткәннәргә кайта киредән.
Ач үлемнән безне йолып калды
Кычытканлы заман өйрәсе.
Нинди хикмәт, нурсыз ул көннәрне
Килә бер кат кайтып күрәсе.
Язмышларга ничек түзгәнбездер?
Газиз баштанниләр узмаган?
Ач карынга үлән ашасак та,
Сагындыра никтер ул заман.

## Ак яулыклы авыл әбиләре

Ак яулыклы авыл әбиләре
Утыралар капка төпләрендә.
Искә алып яшьлек хатирәсен,
Үкенмиләр гомер үткәненә.

Хәтерләрдә еллар хатирәсе,
Узган авыр еллар болгавырлы.
Көнбатыштан чыккан утлы давыл
Кайгыларга салган бу авылны.

Ак яулыклы авыл әбиләре
Искә ала гомер агышларын.
Искә ала яшьлек елларында
Сөйгәннәре белән кавышканын.

Терәкләрсез калган авылларны
Давыллардан кемнәр аралаган?
Ир-егетләр иртә күзен йомган
Яу кырында алган яралардан.

Ак яулыклы заман карчыклары,
Исләренә төшә әллә ниләр.
Телләрендә еллар кайтавазы,
Тик шулай да гайбәт сөйләмиләр.

Бисмиллалы татар әбиләре,
Нинди сафлык нурлы йөзләрендә.
Зилзиләле хәтәр еллар кичеп,
Килеп кергән гомер көзләренә.

Болыннарда алар печән чапкан,
Кибән салган, урган урагын да.
Гомер буе бушка тирен түккән,
Җәфаланган колхоз кырларында.

Капка төбендәге карт әбиләр
Азат кебек гайбәт-ялалардан.
Көн туугa алар хәбәр көтә
Чит җирләрдә йөргән балалардан.

Кырыс гомер юлын кичсәләр дә
Карашлары нурлы, сөбханалла.
Бирешмиләр әле салкыннарга,
Бирешмиләр әле сырхауларга.

Үткәннәрнең серен барлар өчен
Күбебезнең җитми вакытлары.
Гасыр юлын узган ак әбиләр –
Чорыбызның тере шаһитлары.

## Агыла болытлар

Ак болытлар агыла, ак болытлар,
Итәкләре ертык, өзгәләнгән.
Ак болытның кара күләгәсе
Шәүлә булып шуа үзәннәрдән.

Ак болытлар агыла, ак болытлар,
Җил канаты белән канатланган.
Ирексездән, гүя чарасыздан,
Китеп бара безнен тарафлардан.

Ак болытлар агыла, ак болытлар,
Тирбәләләр һава дулкыныннан.
Ара-тирә җир өстенә карап,
Кояш көлә аның ертыгыннан.

Көчле җилләр куа болытларны,
Көчлеләргә барча юллар ачык.
Кешеләр дә китә еракларга,
Булмыйдыр шул язмышыңнан качып.

## Улаклар

Авыл яши изге торакларда,
Чишмә суы тулы улакларда.
Чишмә суын эчеп үскән күпләр
Еракларда инде, еракларда.

Күпләрне бит башка тарафларда
Читләр корган җәннәт кызыктыра.
Ятим калган авыл өсләреннән
Агымсудай еллар узып тора.

Без таптаган таныш сукмакларны
Каплап китте инде кыргый үлән.
Замандашлар инде сирәгәя,
Җир куенына керә берәм-берәм.

Кемдер корган чишмә улаклары,
Чүпләнерләр, мүкләнерләр инде.
Бик күпләрнең гамьсез йөрәкләре,
Мүкләнделәр бугай күптән инде.

Җылы җәйләр ел да кабатлана,
Җир җылысы туган тарафларда.
Тал-тирәккә кунып тәүге тапкыр
Җырчы кошлар монда канат кага.

Авыл халкы гади җыйнак кына,
Гомер итеп ята тыйнак кына.
Тик нигәдер заман чыбыркысы
Авыл сыртын әле дә кыйнап тора.

Көмеш сулар ага улаклардан,
Түбәсенә кошлар кунаклаган.
Авыл тарафына ара-тирә
Сагыну хаты килә ераклардан.

## Сукаланган җир башы

*Бүзләрем маналмадым.*
Дәрдемәнд

Ике ызан кара-каршы.
Сукаланган җир башы.
Буе җитмәгән үрләргә
Ник үреләир башы?

Гөл чәчәкле болыннарым,
Кырларым, урманнарым.
Тауларга карап ымсындым,
Тик таулар булалмадым.

Тауларга меналмадым шул,
Даннарга уралмадым.
Милләтемнең иң сөекле
Тукае булалмадым.

Нигәдер асыл затларга
Якташ була алмадым.
Зәңгәр күзле, үткен сүзле
Такташ була алмадым.

Ул затларга тиң булырлык
Кая инде мәртәбәң?
Алар туган башка заттан,
Ә мин башка әнкәдән.

Бераз гына шигырь сырлыйм,
Башка нәрсә майтарам?
Мин фәкать иҗат үренең
Итәгендә чайкалам.

Җир-Әнкәнең кочагында
Минем гүзәл аймагым.
Мин ошбу серле тормышның
Казанында кайнадым.
Тик шулай да ызаннарда
Сихри иҗат мәйданым.

Яңгырлары булмаганга,
Игеннәрем уңмаган.
Сукаланган җир башында
Боргалан да боргалан.

Юлларда да югалмадым,
Иҗатта уңалмадым.
Мин фәкать үземнән гайре
Беркем дә булалмамын.

*Каюм Насыйриның 200 еллык юбилеен каршылап, журналыбызда яңа рубрика башлыйбыз.*

*Беренче карашка, мәшһүр татар этнографы, мәгърифәтче, галим һәм тагын бик күп исем-дәрәҗәләргә лаек Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (1825–1902) турында барыбыз да күпмедер мәгълүматлы. Аның татар дөньясында яңарышка ишекләр ачуын да, төрле фәннәрне нигезләвен дә, 25 еллап татар басма сүзенең – газета-журналларның – чишмә башы булган календарьлар нәшер итүен дә ишеткәнебез бар. Мәгарәдән тылсымчыга әйләнеп чыккан Әбүгалисинасы да күпләргә таныш. Әмма яңа рубрика белән дөнья күргән язмалар бөтенләй үзгә Каюм Насыйрины күз алдыгызга бастырыр дип уйлыйбыз.*

*Ни кызганыч, совет идеологиясе мәгърифәтченең ач-ялангач тормышы сурәтен ассызыклап килде. Бүген инде без Каюм Насыйриның – яшь вакытында Казан шәһәрендәге иң затлы киемнәрдән, кыйммәтле кама туннардан йөргән ир-егет булганын да, заман спортчыларыннан да уздырып, физкультура белән шөгыльләнгәнен дә, матди тормышны да яхшы белеп – сәүдәгәр абыйсына сату-алу эшендә ярдәм итеп торуын да, үзенә илаһи иңдерелгән язмыш бурычларын үтеп чыга – милләтенә киләчәккә туры юл күрсәтә алуын да аңлыйбыз, Насыйри феномены серен – аның көчле һәм алдынгы карашлы нәселендә, ата-бабалары үрнәгендә күзәтәбез. 1860 елда татар зыялылары арасында беренче булып, дин кардәшләренең татар халкы булуын әйткән, милләт формалашуга хезмәт иткән кеше дә – Каюм Насыйри икән. Бүгенге гүзәл татар телебезнең нигезләрен салучы, аның лексик байлыгын безгә китереп ирештерүче дә – ул. Башка халыкларны татар мәдәнияте белән таныштыруны башлаучы да, химия, физика, астрономия, геометрия, математика, география, медицина, тарих, ботаника, агрономия, музыка, генеалогия һ.б. бик күп фәннәрне татар телендә нигезләүче дә... Гаяз Исхакый, Гали Рәхим, Галиәсгар Камал, Әхмәтгәрәй Хәсәни кебек XX йөз башы татар яңарышын булдырган бик күп талантлы татар яшьләренә – остаз, фикердәш, киңәшче... Татарлар арасында беренче фольклорчы, беренче методист, беренче эпиграфия белгече һ.б. Шушы беренчелекнең серләрен бергәләп Каюм Насыйриның тормышыннан, язмышыннан – аның «Әбүгалисина мәгарәсе»ннән эзләп карыйк.*

# НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ КАЙЛАРГА КИТӘ...

## Каюм Насыйриның нәсел-нәсәбе

Каюм Насыйриның (тулы исеме Габделкаюм бине Габденнасыйр әш-Ширдани әр-Рәззакый әл-Болгари) Кече ватаны – Казан губернасының Зөя өязе Кече Шырдан авылы (хәзер Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы), XIX гасыр урталарына кадәр рәсми документларда Югары Шырдан дип йөртелгән. Җанисәп документлары буенча ясаклы татарлар авылы 1646 елдан билгеле. 1782 елда биредә ир-ат җенесеннән 244 кеше яшәгән. 1834 елда 283 ир-ат һәм 292 хатын-кыз көн күргән (*Татарстан Дәүләт архивы (ТДА)*, *3 фонд, 2 тасв., 96 эш).*

X ревизия материалларыннан күренгәнчә *(ТДА, 2 фонд, 3 тасв., 525 эш)*, 1858 елда Кече Шырданда 138 ихатада 357 ир-ат һәм 363 хатын-кыз саналган. XIX гасыр ахырына авылда яшәүче халык саны 1231 кешегә җиткән *(Берстель К.П. Список селений Казанской губернии. Казань, 1908. 104 б.).*

Авыл Сәкел елгасы ярында, Казаннан – 49, өяз шәһәре Свияжскидан – 19,

XIX гасырда Олы Шырданда булган волость идарәсеннән 7 чакрым ераклыкта урнашкан.

Хәмит исемле авыл карты сөйләгәннәргә караганда, аның агалары Сәлам белән Җәгъфәрдән соң Югары Шырдан авылында имам вазифаларын Әхмәт мулла башкарган, аннан соң – Җәгъфәр мулла, Хөсәен мулла, Габдессәлам (Әбсәлам) мулла, Хөсни мулла, Һибәтулла мулла, Габделкави мулла булган. К.Насыйри Югары Шырданда яңа мәчетнең 1815 елда Казан сәүдәгәре Йосыф Апанаев акчасына салдырылганын теркәп калдырган (*Насыйри К. Сайланма әсәрләр, 2 томда. 2 том. Казан, 1975. 20-21 б.*). Гыйбадәт кылу йорты искергәч, 1874 елда Каюмның *(ТДА, 4 фонд, 1 тасв., 6789 эш)* ул вакытта Казанда яшәгән өлкән абыйсы Габделхәй акчасына янә яңа мәчет салалар. Ул Казан губерна идарәсе технигы И.А.Александров проекты буенча эшләнә. 1887 елда, киңәйтелеп, манара куела.

Кече Шырданда мөселманнардан тыш керәшен татарлары да яши.

Туган авылында керәшеннәр барлыкка килү тарихын Насыйри Югары Шырданда таралган риваятьләргә нигезләнеп яза. Янәсе, Сәлам мулла белән Җәгъфәр мулла заманында ясаклы татарлар өчен дә рекрут бурычы кертелә. Югары Шырданның армиягә рекрут итеп алынган бер кешесе хәрби хезмәт йөкләмәсе буенча дәүләттән гомерлек ташлама алу өчен чукына. Югары Шырданнан рекрутлар туплаганда, аның үрнәгенә тагын унлап ир-ат иярә. Чираттагы чакырылыш вакыты җиткәч, Җәгъфәр мулла авылдашларының чукынуын туктатыр өчен үзе армия сафларына баса, энесе Сәламгә авылдашларын ислам диненә өйрәтергә кушып китә. Җәгъфәр мулла хәрби хезмәттән исән-сау әйләнеп кайткан дип сөйлиләр, кайткач рухани вазифаларын башкаруын да дәвам иткән. (Рекрутлык бурычы ясаклы татарларга 1721 елда кертелә, һәм бу вакыйгалар, күрәсең, XVIII гасырның икенче чирегендә булганнар. Хәмит исемле авыл карты сөйләгәннәр буенча югарыда телгә алынган Җәгъфәр мулла исә вазифаларын 1650 нче елларда башкарган).

Е. Малов мәгълүматлары (*Малов Е. Статистические сведения о крещёных татарах Казанской и некоторых других губерний в волжском бассейне. Казань, 1866. 22 б.)* буенча, 1866 елда авылда 31 ир-ат һәм 35 хатын-кыз керәшен татары исәпләнә, алар барысы да шул ук елны исламга кайта. Архив материалларында *(ТДА, 2 фонд, 3 тасв., 525 эш)* 1874 елны авылда 109 мөселман динендәге хуҗалык башлыгы һәм 26 ихатада яшәүче 88 ир-ат һәм 94 хатын-кыз – исламга кайткан керәшен татарлары күрсәтелә, соңгылары православие динендәге руханига да буйсынмыйлар, мөселманнардан да аерым яшиләр *(ТДА, 4 фонд, 1 тасв., 6789 эш).* Бу төркем җирле мөселман мәхәлләсенә 1905 елның 17 апрелендә чыккан «Дин иреген тану башлангычларын ныгыту турында»гы закон нигезендә исламга күчү өчен шартлар булгач кына теркәлә.

## Насыйри бабалары

Каюм Насыйриның ата-бабалары Кече Шырдан авылында һәм тирә-якта билгеле кешеләр була.

Каюмның гаиләсендә ата-бабаларны белеп һәм хөрмәтләп кенә калмыйлар, аларны балалар тәрбияләгәндә үрнәк итеп тә куялар. Аталары йортында ядкарь итеп саклана торган шәҗәрәне Каюм кече энесе Габделкави белән бергәләп, әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да тулыландырып, 1880 елда бастырып чыгара. Әтисе ягыннан шәҗәрә – «Шәҗәрәи Раззакыя», әнисе ягыннан «Шәҗәрәи Хөсәения» дип атала. Шәҗәрәгә кереш сүзендә Каюм, бу хезмәтнең киләчәк буыннарга атап халыкка чыгарылуын искәртә; әгәр нәселләрендә аның үзе кебек хезмәт сөюче берәрсе туса һәм ул башлаган эшне дәвам иттерсә, нәсел җепләре өзелмәс, ахырзаманга кадәр яшәр дип яза *(Д.Б.Багаутдинова. Фонд Каюма Насыри в Государственном музее ТАССР // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976. 210 б.)*.

Каюмның мәгълүматларына караганда, аның ата-бабалары җиде буынга кадәр укымышлы кешеләр булганнар. Иң борынгы күренекле бабалары булып, Казан ханлыгы чорында халык арасында ихтирам яулаган казак атаманы Бираш баба саналган, ул Иделнең уң як ярында гомер иткән. Аның улы Габдераззак мулла, Мәскәү гаскәрләре Тау ягын яулап алганнан соң, русларга хезмәткә кергән. Үзенең бик тәкъва бабасы белән горурланып, Насыйри югарыда телгә алынган шәҗәрәдә болай дип яза: «Безгә аның акылы, мәшһүр кеше булуы һәм укымышлылыгы ошый». Аның «кол чура»лары, ягъни хезмәтчеләре күп булган, ул аларга крестьян хуҗалыгы алып бару өчен йортлар да төзегән.

Габдераззакның дүрт улы булган, аның, шулай ук, җирле халык арасында абруйлы, еш кына кешеләр арасында чыккан низагларны хәл иткәндә төп сүзне әйтеп катнашканлыгы мәгълүм. Явыз Иван белән Фёдор Иванович патшалык иткән чорда ул хакимияткә хезмәт итә: Тау ягы – Зөя өязе халкыннан ясак җыючы итеп тәгаенләнә. Гаилә тарихында Габдераззакның рус патшалары белән шәхсән таныш булуы турында да истәлекләр сакланган.

Абруйлы һәм бай бу кеше бик зур утар тоткан. Утарының 27 капкасы гына булган, шулай ук зур икмәк амбарларын хакимият тарафыннан махсус куелган казаклар саклаган. Башта ул амбарларга халыктан җыелган салым тупланган, аннан соң икмәк билгеләнгән урынга озатылган.

Габдераззак ике улын, хәрби киемнәр киендереп, тәхеткә яңа гына менгән рус патшасын котларга җибәрә, әмма алар XVII гасыр башында ялган Дмитрий сугышлары вакытында һәлак булалар. Габдераззак үзе дә баш күтәрүчеләр кулыннан зыян күрә: бөтен байлыгын югалта һәм хәерчелектә вафат була.

Аның улы Галикәйнең өч ир баласы була: Йосыф, Габделмән, Габделгазиз. Габделгазиз нәселен Яхъя белән Әлмөхәммәт дәвам итә: алар төбәк тарихында шактый тирән эз калдыра. Халыкта Мүки дип йөртелгән Әлмөхәммәт дин кардәшләре арасында да, рус телле халык арасында да үзе яшәгән җирлектә төрле вакыйгалар, караклыклар, урлашулар һәм тәртип бозулар турында алдан белүе белән дан тота. Күрәсең, андый вакыйгалар турында хакимияткә дә хәбәр итеп торган ул. Бер үк вакытта тирән белемле, киң мәгълүматлы дип искә алалар.

Әлмөхәммәтнең балалары күп була: Шәһрезадә, Миһербану, Җәгъфәр, Гөлбану, Хәсән, Динмөхәммәт, Хөсәен, Сафкол. Әлмөхәммәт Хөсәенгә – Каюмның булачак бабасына – яхшы дини белем бирә. Ул Югары Шырданда мулла булып тора.

Хөсәеннең гаиләсендә Габденнасыйр, Мөхәммәтгалим һәм Хөснетдин исемле уллары үсә. Уртанчы улы Мөхәммәтгалим 1829 елда Казанга күчеп китә дә мещаннар сословиесенә языла *(ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 282 эш)*, базар янындагы Ак мәчеткә мөәзин булып урнаша (*Ногман М. Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кульъязмаларының тасвирламасы. III чыгарылыш. Каюм Насыйри кульъязмалары. Казан, 1958. 37 б.)*. 1834 елгы 8 нче җанисәп кәгазьләре (*ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 96 эш*) Габденнасыйр гаиләсендә аның кече энесе Хөснетдин үзенең әнисе Шәрәпи Уразаева (62 яшь) белән яшәгәнлекне күрсәтә. Шәрәпи (рус телендәге архив материалларында шулай язылган) Уразаева Хөсәен мулланың икенче хатыны булып чыга.

1830 еллар ахырында өйләнеп, Хөснетдин үзенең крестьян хуҗалыгын булдыра. 1858 елда аның гаиләсендә 2 улы һәм 4 кызы тәрбияләнгәнлеге билгеле (*ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 627 эш*).

Бабасы турында Каюм Насыйри түбәндәгеләрне яза: синтаксис һәм этимология өлкәләрендә тикшеренүләр белән шөгыльләнә, «Шәрхе мелла» (грамматика дәреслеге), «Мисбах» (дин нигезләре турында китап), «Сарыф һәваи» (синтаксис китабы) кебек хезмәтләр язып калдырган. Бу китапларны хәзерге вакытта да кулланылышта очратырга мөмкин. Бәрәзәдә яшәгәндә, Хөсәен баба 1190 елда (Милади ел исәбе буенча 1773 елларда) дини-дидактик «Кәшеф әл-әсрар» («Серләрне ачу») китабын язган Сәгыйть хәзрәттән сабаклар ала... Хөсәен баба каллиграфия остасы да була.

Сөйләүләренә караганда, ул үз гомерендә Коръәнне йөз тапкырга якын күчереп язган... Әйтергә кирәк, аның зиһенлелеге кайбер балаларында һәм аларның балаларында да ялтырап ала (*Насыри К. Избранные произведения. Казань, 1977. 51 б.*).

## Каюмның әтисе

Хөсәеннең олы улы – Габденнасыйр – башта Казан өязенең Мәчкәрә авылында Дагыстанда белем алган Мөхәммәдрәхим ибн Йосыф әл-Ашытиның (?–1818) данлыклы мәдрәсәсендә укый (бу хакта Ш.Мәрҗанинең «Мостафад әл-әхбар...»ендә әйтелә), аннан соң, 1810 елдан башлап, укуын Казанда, шушы ук мөдәррис тарафыннан оештырылган Ак мәчет мәдрәсәсендә дәвам иттерә.

1812 елда 26 яшьлек Габденнасыйр белән 14 яшьлек Фатыймага никах укыйлар. (1834 елның 12 апрелендә уздырылган җанисәптә Габденнасыйрга – 48 яшь, Фатыймага 36 яшь була) *(ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 96 эш)*. Бу вакытта Кече Шырдан авылы кешеләренең Габденнасыйрны мулла итеп сайлау турындагы карар кәгазе Казан губерна идарәсе тарафыннан Мәхкәмәи Шәргыягә җибәрелә. Әмма Габденнасыйр, иҗтимагый һәм башка эшләр белән мавыгып китеп, рухани вазифасыннан баш тарта һәм Уфага дини дәрәҗәгә шаһәдәтнамә алу өчен имтиханга бармый (*Насыри К. Избранные произведения. Казань, 1977. 51 б.*).

Каюмның әтисе муллаларның иҗтиһад (үз фикерен белдерү) дәвере узды дигәнне кабул итми. Ул: «Иҗтиһад – һәркемгә кирәк эш» – дип кабатларга ярата (*Гайнуллин М*. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // *Насыйри К*. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956.13 б.). Бу четерекле мәсьәләдә бәхәсләр еш килеп чыгу сәбәпле, шушы темага трактат та яза.

Габденнасыйр Хөсәенов улларын үзе укыта, шуңа да алар бәләкәйдән үк иҗтиһад идеяләре белән танышып үсә. Бу – Каюм Насыйриның киләчәктә мәгърифәтчелек карашлары формалашуны аңлау өчен мөһим әйбер.

Әтисенең гыйлемлегенә нисбәтле Насыйри түбәндәгеләрне язган: «Гәрчә указной мулла булмаса да, тирә-якта Насыйр мулла бик мәшһүр иде. Замананың голямәсе иде. (...) Язуга бик оста иде. Хәзердә үз кулыннан чыккан егерме бишләп китаплар бар. Фарси һәм гарәби язуга маһир иде. Хосусән, ахыргы көннәрендә бик күп китап язды вә һәм тасниф кылынмыш ничә рисаләсе бардыр гарәп телендә» (*Насыйри К. Сайланма әсәрләр, 2 томда. 2 том. Казан, 1975. 19 б.*).

Каюмның әтисе, шулай ук, ул чорда Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселман җәмәгатьчелегендә бәхәсле булган ястү намазына мөнәсәбәтле трактатлар да яза: ястү намазының да, шулай ук тәравих намазының да кирәклеген исбат итә. Ул чор фәне традицияләрендә фарсы фикер иясе Санаиның (1080-1131) «Тәбакат әл-хаҗәт» («Мөһим эшләр тупланмасы») китабына шәрехләү һәм тәнкыйть характерындагы хезмәт тә иҗат итә.

Габденнасыйр шулай ук татар халкының тарихы һәм этнографиясе белән дә кызыксынган. Аерым алганда, ул татар теленә «Казан тарихы»н тәрҗемә иткән (К.Фукснның 1822 елда университет нәшриятында басылып чыккан «Казан шәһәренең кыскача тарихы» хезмәте дип уйлыйбыз), шулай ук Сабан туе бәйрәмен һәм әлеге милли бәйрәмдә ат чабышы кебек ярышларны уздыру традицияләре турында да язган.

Аның татар авыллары тарихлары белән кызыксынуы, күрше авылларның эпитафик (кабердаш) һәйкәлләрен өйрәнеп, алар турындагы мәгълүматларны дәфтәренә теркәп баруы мәгълүм. Аерым алганда, Бакырчы авылын тасвирлаганда, К.Насыйри әтисенең 1855 елгы язмасыннан файдалана. Ул анда 1532 һәм 1252 елгы кабер ташлары язуын күчергән була. Каюм абыйсы Габделкави белән 1873 елда шул ук каберташларын карап йөргәндә, алардагы язулар укылмаслык дәрәҗәдә җуелган була инде *(Насыйри К. Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча) // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 том. 23 б.)*.

Габденнасыйр, мәдрәсәне тәмамлагач, эшкуарлык белән шөгыльләнә, башлыча кыйммәтле җәнлек тиреләре белән сәүдә итә. Коммерция эшләре белән ярминкәләргә

йөри, Түбән Новгородтагы халыкара Мәкәрҗә ярминкәсенә дә еш бара. Дөрес, аның хатлары белән таныш булган Гали Рәхим коммерция эшләре Габденнасыйрның күңеленә ятмаган дип саный. Картайгач, сәүдә эшләрен ташлап, ул улларына ярдәм итүгә күчә. 1848 елда Габденнасыйрның Мәкәрҗә ярминкәсенә олы улы Габделхәй белән барганлыгы мәгълүм *(Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф.Исламов. Казан, 2017. 554 б.)*.

XIX гасырның беренче яртысында рус телендә сөйләшә һәм укый-яза белгән татарлар күп булмый. Илдә барган вакыйгаларны аңлап, җирле чиновникларның кабинетларына кереп сөйләшә алган шәхес – киңәшче, документларны күчереп язучы, дин кардәшләренең үтенеч язуларын төзеп бирүче һәм, бәхәсле мәсьәләләр килеп чыкканда, авыл кешеләре белән хакимият структуралары, судлар арасында арадашчы, яклаучы булган *(Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Казан, 2020. 43 б.)*. Мондый иҗтимагый эшне мөселманнар югары хак белән бәяли торган булганнар. Шундый социаль вазифалар башкарып, әлеге «җәмәгать хадимнәре» бөтен тирә-якта танылган абруйлы шәхесләр булып китә, җирле чиновниклар белән таныш була. Әтисе шәхесенең бу ягы турында Каюм Насыйри бик җылы һәм горурлык белән искә ала: «Һәм үз заманының атасыдыр. Ягъни һәрбер мөбтәля кешегә вә аннан ярдәм эстәп килгән адәмнәргә ата кебек шәфкатьчән булган адәмдер. Шул сәбәпле, изгелекле вә изгелеге күп булган өчен Әбүлхәер ләкабе[1] кушылсын. Бу Габденнасыйр мулла үзенең заманында гайяр, үткен вә һәм бик зирәк адәм булгандыр. Вә һәм урыс телен кәмаһүә[2] яхшы белгәндер. Бик галим кеше, хәтта заманының галлямәсе[3] дип атасак та, садыйк булыр» *(Насыйри К. Сайланма әсәрләр, 2 томда. 2 том. Казан, 1975. 18-19 б.)*.

Габденнасыйр, Казанга килгәндә, энесе Мөхәммәтгалимгә төшә. Каюм да әтисен күрер өчен шунда килә торган була.

Гаилә башлыгы турында аның улларына язган хатларыннан да күпмедер күзаллау тудырырга мөмкин. Хатларында Габденнасыйр бик диндар һәм холкы белән таләпчән кеше буларак ачыла. Аның Каюмга кәвеш тектерергә яки шәхси мөһер ясатырга кушуы үтенеч кебек кенә түгел, ә тиз арада берсүзсез үтәлергә тиешле таләпләр кебек яңгырый. Шунысы да игътибарга лаек: Габденнасыйр Коръән телен өйрәнүдән беркайчан да туктамаган. 1850 нче елларда язган хатларының берсендә ул Каюмнан гарәп теле синтаксисы буенча китап сатып алып җибәрергә куша *(Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф.Исламов. Казан, 2017. 595, 596, 599 бб.)*.

Хуҗалыгында Габденнасыйр бакчачылык белән шөгыльләнә *(Ногман Мостафа. Күрс. хезмәт. 41 б.)* һәм иген игә – аны балалары хезмәт тәрбиясе алып үсә.

1851 елда Габденнасыйр хуҗалыгында эш атының булмавы билгеле. 1868 елда гаилә башлыгы тиешле вакытында имана салымын түли алмый, чөнки олы улы Габделхәй үз вакытында вәгъдә ителгән акчалата ярдәмне җибәрми калган *(Ногман Мостафа. Күрс. хезмәт. 47 б.)*.

Каюмның мәгълүматларына караганда, мөселман әхлагы һәм иман мәсьәләсендә Насыйр мулла үтә дә тәкъва кеше булган. Аның хатирәләреннән аңлашылганча, соңгы егерме биш елда ул Коръәнне башыннан ахырына кадәр бер мең өч йөз тапкыр укып чыккан, үзенең бәллүр кебек пакь күңелен бер генә хилаф гамәл белән дә пычратмаган *(Насыйри К. Сайланма әсәрләр, 2 томда. 2 том. Казан, 1975. 20 б.)*.

Каюмның әтисе 1871 елны вафат була *(Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Казан, 2020. 43 б.)*.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

[1] Әбүлхәер ләкабе – шәфкатьле кушаматы.
[2] Кәмаһүә – тиешенчә.
[3] Галлямәсе – зур укымышлысы.

## *Хатлар яздым утырып*

### Әнгам Атнабай хаты

*24 май, 1966 ел*

Рәдиф![1]

Ике хатыңа һәм бигрәк тә китабыңа җавап бирә алмавым өчен гафу үтенәм. Дөньясы да бик мәшәкатьле. Үзең теләгәнчә генә яшәп булмый: әле анысы, әле монысы. Газета ыгы-зыгысы туйдыра башлады шикелле. Арт якны басып кына утырасы килгән чаклар ешайганнан-ешая бара. Язасы килгән нәрсәләр дә байтак җыелды булса кирәк. Гомер буе берәдәк булып йөреп, бернәрсәсез кабергә кереп китәрсең, Алла сакласын. Бу тизлек заманында кешенең гомере дә шулай тиз узадыр инде ул, күрәсең. Башны әллә кайларга олактырасы һәм тынычлыкта калдырасы килә. Ә бер генә көн ялны да үткәрә алмыйча җәфаланып бетәсең үзе. Аптыраган.

Менә шундый китап чыккан булды. Аның да кызыгы бетте инде хәзер. Синеке әйбәт. Укып чыккач, чын күңелдән балаларча шатланып һәм «менә шулай башласаң иде ул» дип көнләшеп куйдым. Ә юк... Үткәнне кире кайтарып булмый, башлап булмый...

*Әнгам Атнабай*

### Разил Вәлиев хаты

*28 июнь, 1966 ел*
*Ташлык*

Рәдиф агай!

Хатың алдым. Деловой киңәшләрең һәм Рәфкатькә ярдәм кулы сузуың өчен рәхмәт!

Мин исән. Монда җилләр начар исә әле. Саф һава сулый-сулый, кызына-кызына, тирләп эшләргә кайткан без ярлы шәкертләргә бик уңай түгел. Күзачкысыз тузан да тузан. Китапка язылмый торган сүзләр ычкындыра-ычкындыра, Алланы каргап тик ятабыз. Бер юньле эш тә кырган юк. Менә бер-ике көннән шабашкага чыгып китәм. Казанга әзрәк көрәеп килеп булмасмы?..

Иштирәккә еш барам. Г.ны сирәк күрәм. Чыкмый, каһәр. Артыннан егетләр калмыйча йөриләр. Туйдырып бетерделәр инде, бәйләнәләр дә бәйләнәләр дип әйтә, ди. Хәзер шуңа кич чыкмыйм дип әйтә, ди. Фотога төшерермен аны.

Синең китап кайтып җитә алмады монда. Казанда алып бетергәннәрдер. Мин ун данә таптым аны, Казаннан. Сиңа кирәк булыр, җибәрәм.

«Татарстан яшьләре»ндә минем ике шигырьне чыгарганнар. Равил сүз башы язган.

Егермеләрендә Казанга барып кайттым. Фәритләр Минзәлә районына коровник җиткерергә киткәннәр. Район газетасында минем тәнкыйть мәкаләсен басканнар. Хәниф ничава гына тәэсирләнгән.

Иштирәктә сине бик яратып искә алалар. Рәфкать синең китабыңдагы барлык шигырьләрне, Әнисә, Әминә 5-6 шигыреңне яттан беләләр. Төне буе алмаш-тилмәш сөйләп йөриләр. Әй, бер көнне бик кызык булган әле. Габделхәй урам буйлап китеп бара икән. Юлда Г. очраган да моңа исәнләшү урынына «мияу-мияу» дип әйтә, ди. Габделхәй шаккаткан. Нишләсен, сынатасы килмичә, бу да «мияу-мияу» дип киткән инде. Юл буе уйлап кайткач кына башына җиткән Габделхәйнең. Г. синең «мияу-мияу»ыңны отып калган икән ул. Вәт шул.

10 көнләп элек Ә.Авзалова концерт белән килде. Әзәл Яһудин синең «Ирләр булыйк!» шигырен укып йөри. Шәп!

*Ярый, хәзергә саубуллашып торыйк. Рәшит һәм Рәфит абыйларга, үзеңә сәлам белән, Разил.*

---

[1] Р.Гаташ искәрмәсе: Бу хат җибәрелми калган – язылып та бетмәгән булган. Шул җәйдә, Уфага кайтып күрешергә кергәч, үземә бирде; хатта әйткән китабын да шигъри автограф белән бүләк итте.

**P.S.** Синең хатың бер көнгә соңлап килде. Рәфкатьләр киткәннәр иде инде. Мәһдиевкә бирәсе кәгазьне хат белән җибәрәм Рәфкатькә. Шулай килештек.

## Сибгат Хәким хаты

*21 гыйнвар, 1969 ел*

Рәдиф дускай!

Мине эзләнүчеләр беркайчан да куркытмады. Ә менә эзләнмәүчеләрдән, үзен бик тиз табып, җиңел-ансат табып, әзер сукмактан – кеше салып биргән сукмактан йөрүчеләрдән, барысыннан да канәгать булып, күптән табылганнардан канәгать булып яшәүчеләрдән куркам һәм аларга ышанмыйм.

Китабың да бит «Диңгез эзлим» дип атала, яртысы эзләнү шигырьләреннән тора. Мин моны табигый саныйм. Минем сизүемчә, синең көчең җиргә, халык җанына тоташкан хисләрдә, конкреттан гомумиләштерүдә. Беренче тапкыр син шулай чыктың, беренче шигырьләр, беренче җыентык шул ягы белән хәтердә калган. Мин үзем синең шул сыйфатың киләчәктә көчәер дип өмет итәм. Синең җирлегең нык дип уйлыйм. «Һенрих Һейне белән сөйләшү» әйбәт. Син табынган Һейнены Германия язмышы зур иткән бит! Авырганда, Тукайны искә төшерүең дә ошады. Кызык: кеше авыр хәлдә Тукайга әйләнеп кайта...

«Диңгез эзлим»дә миңа ошаган шигырьләр шактый. «Әллә бик тугры түгелбез», «Кайларда йөрмәдем», «О, күңелнең көче», «Лениза» һ.б.

Кыскасы, мин әле һаман синнән нидер көтәм, синең мөмкинлекләреңне күреп торам, хисләр бер үзенең эзенә төшәр. Аңа-моңа карамыйча яза бир.

Мине белгәннәргә сәлам әйт.

*Сибгат Хәким.*

## Наҗар Нәҗми хатлары

*26 сентябрь, 1977 ел*
*Уфа*

Рәдиф!

Бу хатымны «Татар Башкортстаны», ягъни «Кызыл таң» газетасы редакциясендә язып утырам. Җомга көнне сезгә дигән шигырьләрне машинисткага биргән идем, ул басып утыра, ә мин сиңа хат язам – димәк, тунны якмаска булдым: «Дөнья матур, дөнья киң...»

Бер сәгать элек кенә шул шигырьләрне җибәрер өчен сиңа таныш урмандагы өйдән кайттым. Кайтуга, өстәлдә – «Казан утлары», №9. Шигырьләреңне күрдем, монда йөгерү сәбәпле, укый алмадым, соңрак укыйм.

Минем шигырьләрне шул көенчә, шул тезмәдә җибәрсәгез иде. Карарсыз. Үземә ошаганнары да бар шикелле, шуны сизәм: картаям булса кирәк. Ошамаса, «картлачка ярамаганмы» диебрәк әйтерсез. Ничегрәк бирергә уйлыйсыз? Сурәт кирәк булса, «Азат хатын»нан алыгыз. «Азат хатын»да «нигә?» дисәләр: «Аңа 60 тула бит», – диярсез. Алар да белсәләр, эчне тишмәс, белмәсәләр, белеп булмый, үпкәләп тә куярлар.

Шигырьләрне эшеңә җибәрәм, ә хатны – өеңә. Серләшү өйдә күбрәк була бит. Тагын нәрсә? Башкача язар сүзләрем дә юк шикелле.

«Иблис»не алып-алып (кулдан-кулга) укыганнар. Тәбрик итүчеләр булды, ә кайсыбер зур шагыйрьләргә дә ошаган, ләкин сүз әйтергә түбәнчелек итеп саныйлар булса кирәк. Мин, имеш, аны важный бер әйбере өчен тәбрик итмәгәнмен. Ә ул әйберне тәбрик итәрлек санамаган идем.

Менә сиңа бер «яңалык». Мондый яңалыкны өйгә генә язарга мөмкин.

*Кочаклап, Наҗар абыең.*

**P.S.** «Аз и Я»ны укыйм. Өйдә, вагонда. Казакъ инәләрен эшерә бит! Миннән соң Байбурин укыйм, ди. Аннан соң кайтарырмын. Кайтарыргадыр бит?

***

*22 ноябрь, 1981 ел*
*Ессентуки*

Рәдиф энем!

Санаторийга үзең килгәнче үк, хат килеп көтеп торса, бик күңелле икән. Рәхмәт!

Иң мөһим хәбәрем – Сибгат агай юбилее. Шуны конкретрак хәбәр итә алсаң, бик хуп булыр иде, чөнки мин 20 декабрьдә өйгә кайтып җитә алам. Путёвканың срогын үзгәрткәндә, мин аңа – юбилей булачагына игътибар иткән идем – ул 24 декабрьдә туган булса кирәк. Һәм туган көнне алдан үткәрмиләр иде бит. Минем уйлавымча, 24-25ләрендә булырга тиеш. Монда мәсьәлә театр бинасы белән бәйледер, әгәр дә анда үткәрсәләр. Ничек булса да, мин кайтып җитәчәкмен, тик чакырыламмы, юкмы – анысын белә алмыйм. Алдан әзерләнү турында (әгәр дә чакырылганымны белсәм) Союзга хат та язар идем.

Шуның өчен, Рәдиф, син окончательно барысын да бел әле. Бу – бер.

Икенче: Гомәр ага Бәшировның адресын җибәрче – күңелдән белмим.

Барсам-нитсәм, очрашу һәм башкалар хакында. Юбилей вакытында ул реаль булмас шикелле. Ике көймәнең койрыгын тотып булырмы икән? Теге көймә дә зур бит – Сибгат Хәкимне әйтәм. Ул койрыкны тотып чыдап булса, бик шәп булыр иде. Ярый, күз күрер, исән булыйк, киңәшләшербез.

Сибгат агайга барганда, кульязма да алып барырга иде исәп, чөнки Туфан аганы җирләгәндә, минем калын гына китапны чыгару турында сүз булды. Ул сүз СССР Язучылар съезды вакытында да барды. Шул китапны машинисткага басарга бирергә онытып китеп барганмын. Әй, үзем дә җебегән инде. Берәү булса, әллә кайчан әзерләп җибәргән булыр иде.

Монда килә-килә ял иттем. Күңелдә буран дулавы дәвам итә. «Поэзия!.. Һиннән каскым килә...» дигән шигырь язасы килә. Үзем өчен генә, әлбәттә. Күңел урынына утырып, бер-ике шигырь яза алсам, һәйбәт булыр иде.

Нүжәли барып чыкмас икән – С.Х. тәгаенләгән әйберне әйтәм[2]. Бер өметләндергәч, бик авыр була бит әле. Юк, күңел булырына ышана. Иң зур сәбәбе: «берне бирдек бит» дип әйтүләре бар. Җиһанов алды бит. Белмим тагы.

Гасыр башындагы поэзия турындагы фикерләрең бик шәп. Тукайлар, Бабичлар рухы... «Поэзия! Һиннән каскым килә...» әнә шуңа бәйләнгән. Язылса, шигырьне җибәрермен әле. Хәзергә су эчәргә киттем. Хатны да юл уңаена салам. Сизәм: синең хатларың утлы, хисле, тойгылы, фикерле. Күбрәк поэзия хакында язасың, ә минекеләр төрле гадәти хәбәрләр белән тулы. Көне шундыйдыр. Шундый хатларың өчен рәхмәт. Берәр вакыт мин дә синнән калышмам әле.

*Сәлам белән, Нажҗар абыең.*

## Вәзих Исхаков хаты

*2 ноябрь, 1984 ел.*
*Уфа*

Саумы, Рәдиф!

Сүземнең башы – барыгызга да кайнар сәламнәр, ә сиңа аеруча зур рәхмәтем барсын.

Кичә үзең белән сөйләшкәч тә, хат язмакчы идем дә, булдырып булмады. Хәзер менә сәгать төнге өч. Бераз тынычракмын һәм сиңа хат язарга тотындым.

Премия[3] уңае белән бер-ике сүз.

Әйе. Ул миңа соңлабрак килде. Элегрәк тә бирүләре ихтимал иде (мине бит аңа 1969, 1974 елларда да тәкъдим иткәннәр иде). Әмма уйлыйм да, әле дә соң түгел.

[2] Н.Нәҗми биредә РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт премиясе турында әйтә. Премия аңа 1982 елда бирелә.

[3] Бирелә сүз БАССРның әдәбият, музыка, сынлы сәнгать өлкәсендә бирелә торган Сәлам Галимов исемендәге премиясе турында бара. 1995 елдан Ш. Бабич исемендәге Дәүләт республика яшьләр премиясе дип үзгәртелә.

Дөрес, кайберәүләргә ул арты белән килеп керә. Юк кына әсәрләре, барлы-юклы гына хезмәтләре белән алалар. Мин исә аны бик хаклы алдым булса кирәк.

Аннан соң хәзер ул премияләрне алу елдан-ел катмарлана башлады. Претендентлар шактый күбәйде.

Һәрхәлдә күңелле хәл. Үзенә күрә хезмәткә бер бәһа бит ул.

Котлаулар бик тә күп. Телефонның шалтыравы туктаусыз диярлек. Телеграммалар да байтак килде. Күрәсең, иптәшләрнең теләктәшлеге көчле.

Республика китапханәсеннән зур гына букет чәчәк китергәннәр. Директорына шалтыраттым да:

– Сезгә һәр лауреатны котлар өчен акча каралмаган. Акча каян таптың? – дидем шаяртып. Ул исә бик җитди итеп:

– Вәзих дускай, без исә һәрбер лауреатны котламыйбыз да ул, – дип җавап бирде. – Сине бит бөтен библиотека белән яраталар. Язган һәр әйбереңне укып барабыз.

Менә шуннан соң сөйләш син алар белән! «Һәнәк»тән котлаганда, Марат Кәримов болай ди: «Сиңа бу премияне бирми мөмкин түгел иде. Син бит аны иҗатың, язмышың белән асфальтны тишеп чыккан үлән сыман исбат иттең».

Кабатлап әйтәм, иптәшләрнең, каләмдәшләрнең һәм, гомумән, укучыларның ихлас котлаулары үземне нык дулкынландырды, куандырды. Нигәдер әле һаман Роберт белән Тәлгать кенә хәбәр бирмиләр.

8 ноябрь көнне радио аша «Умырзая сәскәһе» буенча эшләнгән сәгать ярымлык радиоспектакль тапшырачаклар. Сценариен Я.Колмый язды. Режиссёры – Әхтәм Әбүшаһманов. Төп геройны Олег Ханов башкара. Барый Ногманов: «Агай, бик әйбәт спектакль килеп чыкты», – дип торды.

Ә.Әбүшаһманов – безнең бик талантлы егет. Ул миңа килде. Аның белән озак кына сөйләшеп утырдык. Фикерле, уйлый һәм матур уйный белгән артист.

Ишмулла Дилмөхәммәтов[4] турында телефоннан әйткән идем инде. Фаҗигале һәлак булды...

Синең белән сөйләшеп, бер ярты сәгать үткәч, радиодан Фәрит Габдерәхимнең яңа шигырьләрен укыдылар. Гаҗәп кеше ул Фәрит. Болай бер дә кычкырып, шаулап йөргән кеше дә түгел. Ә менә поэзиясе саф чишмә суы сыман. Шигырьләрендә фикер бар, мәгънә бар, шул ук вакытта бик нечкә лиризмга корылган. Ахрысы, ул кешенең күңеле шундый шигъридер инде.

Яратып тыңладым. Ошады.

Югыйсә бездә үтә ялтыравык һәм шалтыравык әйберләр күмеп бара. Бар, әнә шулар арасыннан сайлап алып кара!..

Бу араларда үзем эшли алмыйм. Нигәдер нык сызланам. Тәкатьне ала, брат. Көчне ала. Шулай да бөтенләй үк тик тә ятмаска тырышам. Укыштырам, уйланам. Әз-мәз генә сызгалап, төрткәләп тә куйган булам. Ә бит язасы әйберләр шул тиклем күп – очына-кырыена чыкмалы түгел.

Рәдиф!

Шушы хат белән сиңа М.Гафуровның «Ленинец»та басылган мәкаләсен салам. Шуны укы да (бәлки Салават белән Риммага да укытырсың) кире үземә җибәрерсең, яме. Чөнки көнендә генә алырга баш җитми калган. Соңыннан аның үземә кирәк булу ихтималы бар.

Менә хәзергә шул.

Хат язып тор. Синең хатларыңны мин һәрвакыт көтеп алам, куанып укыйм.

Үзеңә, гаиләңә сәламәтлек телим. Күңел ныклыгы телим.


*Үзеңне яратып, Вәзих абыең.*

[4] Ишмулла Дилмөхәммәтов (1928–1984) – курайчы, җырчы, драматург, композитор.

# ӘДӘБИ СКАНВОРД



| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Таҗи Гыйззәт трилогиясе | | ... Булгакова |
| | | | | Шагыйрь Газинур ... | | Фәйзуллин, Рахмани, Сабыр | | | | |
| | | | | | | | | Абдулла ... | | Шәйхи Маннур романы |
| | | | | Гомәр Бәширов повесте | | Самат Шакир туган авыл | | | | |
| | Иоганн Себастьян ... | | | | | Бер үк жанрдагы әдәби әсәрләр җыелмасы | | Кытай флейтасы | 1906 елда Уральскида чыккан сатирик журнал | |
| | | | | Яков ... (рус балалар шагыйре) | Тарихчы ... Таһиров | | | | | |
| | | | | | Библия персонажы | Россия кинопремиясе | | | | |
| «Диннәр әхрамы»н төзегән архитектор, рәссам | | Кытайда императорлар династиясе | | Максим Горький романы | | | | Илгиз Зәйниевнең пьесалар җыентыгы | | ... Дәүли |
| | | | | Татар шагыйре, прозаик | | | | | | |
| ... Ишморат | | ... Хөснияр | Язучы Кәрим ... | | | | Публицист ... Медведев | | | |
| | | | | ... Акопян (әрмән шагыйре) | | Гадәти, үзгәрешсез | Фәнни хезмәт, әдәби әсәрләр иҗат итүче | | Зөянең сул кушылдыгы | |
| XIX йөз француз рәссамы | Зыя ... (мәгърифәтче, дин эшлеклесе) | | Бөек татар шагыйре | | Аяк киемендәге тар күн кайма | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | Планета | | Немец фәлсәфәчесе / Нота | | | | | | | |
| | Хәрби дәрәҗә | | | | | Шолоховның тын елгасы | | | | |
| | | | | | | | | | | |



**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде.*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *Гаташ, «Бала», Закир, ки, ахун, «Афәт», чуаш, Нури, чуар, лаз, Арк, «Күги», «Уку», Али, Антон, пик, Латыйфи, Аеш, Апуш, Гази, «Буа», асс, Золя, Зыя.* ***Өстән аска:*** *какча, аел, Салих, Уран, «Учак», тут, «Газинур», «Ыргыз», Дунай, Такташ, Фазыл, Якуп, ипи, Ширмән, «Тулгак», ашбаз, Раил, Усы, җиз, Илеш, «Ася».*

*Фирдәвес Әхтәмованың тууына – 85 ел*

# БИБИДӘН БИБИНУРГА КАДӘР ИҖАТ ЮЛЫ



Әле дә юксындырып искә төшә торган якты шәхес, Татарстанның халык артисты Фирдәвес Әхтәмованың тууына – 85 ел. Ул бу якты дөньяга 1939 елның 21 июлендә тәүге аваз салган һәм 2012 елның 22 февралендә бакыйлыкка китеп барды. Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган радиотапшыру аның менә шушы ике дата арасында кылган гамәлләре турында. Фирдәвес Әхтәмова үзенең олы иҗат юлының башында халык күңеленә Г.Камалның «Беренче театр» әсәрендәге Биби роле белән килеп кергән иде. Ә инде шушы юлның ахырында, 2010 елда, VI Халыкара «Алтын мөнбәр» мөселман кинофестивалендә ул, «Бибинур» фильмында төп рольне башкарып, «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңү яулады. Язманы тыңлаганда, Бибидән Бибинурга кадәр гомер юлы күз алдыгыздан чагылып үтәр.

Тапшыру Татарстан радиосы фондында сакланган бер язма белән башланып китә. Театр дөньясын, артистларыбыз тормышын бик яхшы белүче язучы Мәдинә Маликова 1990 елларда Фирдәвес Әхтәмова иҗатына багышланган тапшыру ясаган булган. Ул артистканың сәхнәдәшләренә дә мөрәҗәгать иткән. Менә, әйтик, Равил Шәрәфиев чыгышыннан бер өзек:

«Фирдәвес репетиция вакытында булсын, спектакльдә булсын, бөтен барлыгы белән җиң сызганып эшли, чәчрәп-янып тора. Ул партнёрын үзенә генә буйсындырып, үзенчә бөгәргә тырышмый, аңа үзе җайлаша белә, ә бу – бик зур нәрсә. Фирдәвес турында сөйләгәндә, тамашачылар еш кына: «Их, яратабыз шул артистканы», – диләр. Бу миңа, хезмәттәш буларак, бик күңелле хәл, әлбәттә...»

Шулай ук әлеге язмада Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, күренекле артистларыбыз Наилә Гәрәева һәм Ирек Баһманов, язучы һәм режиссёр Әхтәм Зарипов үзләренең хатирәләре һәм Фирдәвес Әхтәмова иҗатына кагылышлы фикерләре белән уртаклашканнар.

«Бүген, кая гына карама, кешеләргә ихласлык җитми, – ди Әхтәм Зарипов. – Без күп чакта үз-үзебез булудан куркабыз, уйнарга тырышабыз. Фирдәвес сәхнәдә дә, тормышта да үзе булып кала белде. Һәм шуның белән кыйммәттер дә. Ул гади, ихлас булды, шул ихласлыгы аңа дан китерде...»

*Надир Дәүләтнең тууына – 80 ел*

# ЕРАККА КИТЕП КАРА...



Күренекле тарихчы, Татарстан Фәннәр академиясенең Төркиядәге шәрәфле әгъзасы, профессор Надир Дәүләтнең (1944–2021) тууына – 80 ел.

Язмыш кушып, гомерен чит илләрдә үткәрсә дә, галим Татарстанны үзенең асыл Ватаны дип таныды, шуңа да аның төп хезмәтләре татар халкы тарихына, аерым алганда, 1917–1919 елларда барган иҗтимагый-сәяси процессларга кагылышлы.

Моннан төгәл ун ел элек, 2014 елның июнь аенда Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында галим белән истәлекле бер очрашу булып узган иде. Журнал укучылар игътибарына шул кичәдән фрагментлар тәкъдим ителә.

Ул вакытта язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев кунак белән болай дип таныштырган иде:

«Надир әфәнде татар дөньясында гына түгел, ә бәлки бөтен төрки дөньяда мәшһүр галимебез, әгәр дә Татарстаннан читтә, бигрәк тә чит илләрдә, дистәгә якын миллион татар яши икән, алар арасында иң мәшһүр татарның берсе дип мин Надир Дәүләтне әйтер идем. Әлбәттә, чит илләрдә безнең дөньякүләм танылган галимнәребез бар, әмма татар халкына хезмәт итү ягыннан, минемчә, беренче урында Надир Дәүләт тора. Моны академиклар Миркасыйм Госманов та, Индус Таһиров та, башкалар да әйтеп килде. Алар искиткеч зур галимнәребез, хәтта алар да Надир Дәүләтнең иҗатына зур бәя бирәләр иде. Миркасыйм ага Госманов турыдан-туры болай дип әйтте: «Мин үземне төшеп калган галим дип санамыйм, әмма Надир Дәүләт алдында башымны иям. Ул безнең тарихыбызга читтән карый, өстән карый, ул безгә караганда объективрак. Телибезме-теләмибезме, Совет чорының бикләре-йозаклары күңелебезнең түрендә утыра, ә анда күңел хөрлеге, күңел бәйсезлеге бар. Һәм аннан соң безнең чыганаклар Татарстандагы һәм күрше-тирә республикаларда гына. Алардан без татар, рус телләрендә генә файдалана алабыз. Надир Дәүләт исә Кытайда туып-үскән, димәк, андагы чыганакларга мөрәҗәгать итү мөмкинлеге дә бар, тагын әле татар телен, рус, немец, төрек, инглиз телләрен белә. Димәк, ул татарга кагылышлы чыганаклардан безгә караганда дистәләгән мәртәбә күбрәк файдалана...»

Язманың иң кадерле урыны – әлбәттә, Надир Дәүләтнең үз чыгышы. Ул биредә үзенең катлаулы тормыш юлын, фәнни карашларын бәян итә, тамашачыларның сорауларына җавап бирә. Әйдәгез, халкыбыз тарихын еракка китеп өйрәнгән галимнең якты рухын искә алып, шул язманы тыңлыйк.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## БРИКС СПОРТ УЕННАРЫ

Казанда БРИКС спорт уеннары үткәрелде. Анда 86 илдән спортчылар катнашты. Алар спортның 27 төре буенча көч сынашты. Уеннарны ачу тантанасы «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә урнашкан Илһам Шакиров исемендәге концерт залында узды. БРИКС спорт уеннарында катнашучыларны видео аша Россия Президенты Владимир Путин котлады. Тантанада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия спорт министры Михаил Дегтярёв чыгыш ясады.

БРИКС илләренең спорт уеннары зур уңыш белән барды. Россия җыелма командасы БРИКС уеннарында 507 медаль (264 алтын, 142 көмеш, 101 бронза) яулады. Россиянең җиңүенә Татарстан спортчылары да зур өлеш кертте. Аларга 38 алтын, 14 көмеш, 7 бронза медаль тапшырылды. Казан тагын бер кат илнең спорт башкаласы булуын раслады.

Казанның Тынычлык бистәсендәге Каенлыкта узган Сабантуйда БРИКС уеннарында катнашучылар да җыелды. Кунакларны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов сәламләде һәм тантаналы рәвештә БРИКС уеннарының тәмамлануын игълан итте, ярышларда катнашучыларга зур рәхмәтен җиткерде.

## БӨТЕНРОССИЯ АВЫЛ САБАН ТУЕ

Пермь крае Барда авылында XIV Бөтенроссия авыл Сабан туе булып узды. Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Пермь крае губернаторы Дмитрий Махонин халыкны бәйрәм белән котладылар. Зәйдән көрәшче Радик Сәлахов Сабантуйның абсолют батыры булды. Аңа төп бүләк ТР Рәисеннән «Лада Гранта» машинасы иде. Автомобиль ачкычын Рөстәм Миңнеханов тапшырды. Ат чабышында Пермь краеннан «Победная» кушаматлы атта Раил Шәйдуллин беренче килде. Аңа Пермь крае губернаторы призы – машина бирелде.

2025 елда Бөтенроссия авыл Сабан туе Киров өлкәсенең Нократ Аланында узачак. ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов Сабантуйның күчмә символы – Тулпар ат истәлекле бүләген Пермь өлкәсе губернаторы Александр Соколовка тапшырды.

Шул ук көнне ТР Рәисе Р.Миңнеханов һәм Пермь крае губернаторы Д.Махонин үзара хезмәттәшлек турында килешүне имзаладылар.

## МУСА ҖӘЛИЛГӘ ҺӘЙКӘЛ

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Пермь крае губернаторы Дмитрий Махонин Пермь крае Барда авылында Советлар Союзы Герое, шагыйрь Муса Җәлил бюстына чәчәкләр салдылар.

Бу бюст (авторы Санкт-Петербургтан Винера Абдуллина) һәм М.Җәлил исемендәге сквер Бардада Бөтенроссия авыл Сабан туе үткән көннәрдә ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Премьер-министры урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура Рәисе Васил Шәйхразыев, Барда районы башлыгы Хәлил Алапанов, Пермь крае губернаторы хакимияте җитәкчесенең беренче урынбасары Леонид Политов катнашты.

## А.С.ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА – 225 ЕЛ

Казанда Халыкара рус теле көнен һәм Александр Сергеевич Пушкинның тууына 225 ел тулуны М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында билгеләп үттеләр. Анда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, әдәбиятсәнгать әһелләре, укытучылар катнашты. Тантанада ТР Рәисе чыгыш ясады һәм республикабызның Дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Рөстәм Миңнеханов Халыкара рус теле көне һәм А.С.Пушкинның тууына 225 ел тулу уңаеннан Мөрәҗәгать белән чыкты. «Үзенең иҗатында Александр Пушкин кеше һәм гражданинга хас Ватанга тугрылык, намуслылык, фидакарьлек, гаделлек, белем-мәгърифәткә омтылу кебек һичкайчан әһәмиятен җуймас сыйфатларга дан җырлый. Александр Пушкинның бөек мирасы чиксез күпкырлылыгы белән аерылып тора. Ул – Рус дөньясының кодрәте, какшамас рухы, колач җитмәс мәһабәтлеге символы» диелә әлеге Мөрәҗәгатьтә.

Халыкара рус теле көне һәм Пушкинның тууына 225 ел тулу уңаеннан ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт

Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, шулай ук РФ Дәүләт Думасы, ТР Дәүләт Советы депутатлары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, иҗади интеллигенция һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре шагыйрьнең М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Казанлыларны һәм кунакларны бәйрәм белән ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тәбрикләде. Тантана шагыйрь әсәрләрен уку, әдәби-музыкаль композиция белән дәвам итте.

### МАЛАЙЗИЯДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Малайзиядә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре булып узды. Аның кысаларында ЮНЕСКО объекты буларак Казан Кремле, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Гөлназ Исмәгыйлеваның гарәп каллиграфиясе, дизайнер Элара Шәйхинең татар милли костюмнары, Куала-Лумпур һәм Джохор-Бару шәһәрләрендә XX «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестивале фильмнары («Ибн Фадлан», «Мулла», «Хәлимә», «Остазбикә» һ.б.) тәкъдим ителде, китапханәләрдә төрле чаралар үткәрелде. Татарстан делегациясе Селангор штатында дәүләт китапханәсе эшчәнлеге һәм фондлары белән танышты, Куала-Лумпур шәһәрендә Ислам сәнгате музеенда булды.

ТР мәдәният министры Ирада Әюпова белән Малайзиянең туризм, сәнгать һәм мәдәният министры урынбасары Кхайруло Фирдаус Акбар Кхан мәдәни хезмәттәшлекне үстерү турында сөйләштеләр.

### ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЬ

Кыргызстанда Кара-Кыргыз автономияле өлкәсенең 100 еллыгына багышланган Төрк дөньясының IX халыкара Чукурова әдәбият фестивале булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин катнашты.

### ТАТАР РУХЫ

Башкортстанның Туймазы районы Төмәнәк авылы янында урнашкан «Бабай утары»нда «Татар рухы» дип аталган әдәби-мәдәни фестиваль булды. Аның кысаларында очрашулар, түгәрәк өстәлләр, әдәби-музыкаль чаралар үткәрелде. Фестивальдә Татарстаннан, Башкортстаннан, Оренбург өлкәсеннән язучылар, рәссамнар, сәнгать осталары, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

### МӘКТӘП ЯЗУЧЫ ИСЕМЕН ЙӨРТӘ

Мамадыш районы Урта Кирмән мәктәбенә язучы, публицист Шаһинур Мостафин исемен бирүгә багышланган тантана булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов, язучылар Рафаил Газизов, Марат Закир, Вәрис Гали, Башкортстаннан җырчы Фән Вәлиәхмәтов, эшкуар, җәмәгать эшлеклесе Фәнир Галимов, районның мәгариф идарәсе вәкилләре, укытучылар, Ш.Мостафинның якташлары, туганнары катнашты.

### «ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ – 2024»

ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Театр эшлеклеләре берлеге, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры «Яңа татар пьесасы – 2024» конкурсын игълан иттеләр. Авторлар конкурска сәхнәдә куелмаган, матбугатта бастырылмаган пьесалар тәкъдим итә ала. Узган конкурсларда катнашкан әсәрләр кабул ителми. Конкурс ябык, тәхәллүс белән имзаланган әсәрләр 2 нөсхәдә кабул ителә. Автор турындагы белешмәләр ябыштырылган аерым конвертта тапшырыла. Җиңүче авторлар акчалата беренче, икенче һәм өченче премияләр белән бүләкләнә. Моннан тыш, ТР Мәдәният министрлыгыннан махсус премия билгеләнә. Текстларны почта белән түбәндәге адреска җибәрү сорала: Казан шәһәре, Татарстан урамы, 1 нче йорт. Г.Камал театры. Пьесалар 2024 елның 1 октябренә кадәр кабул ителә. Җиңүче әсәрләр 2024 елның 22 декабрендә игълан ителә. Мәгълүматлар Г.Камал театрының рәсми сайтында: www.kamalteatr.ru.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

29 июль – Татарстан Язучылар берлегенә 90 ел. Барлык каләмдәшләребезне олуг юбилей белән котлыйбыз!

2024 елның 19 июнендә 89 нчы яшендә актёр, режиссёр, язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Әхтәм Исмәгҗан улы Зарипов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Яшел Үзән районы Бузай авылында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман А.ГАЯЗОВА «С какой же стороны встаёт солнце?», повесть Н.ГИЛЬМУТДИНОВОЙ «Минбар наставника», рассказы Р.ЗАЙДУЛЛЫ; стихи З.МАНСУРОВА, Ч.ЗАРИФ, Э.ХУСАИНОВОЙ.*
*«Литература родственных народов»: стихи Р.УЗДЕНОВА, Ф.КАРАБАШЕВОЙ (УЗДЕНОВОЙ), Ш.УЗДЕНОВА.*
*«Новые имена»: рассказ А.НУРИЕВА «Куриное дело»; стихи А.БАХАВИЕВОЙ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома…»: рассказ Г.ГИЛЕМХАНОВОЙ «Парный танец».*
*Литературная критика: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА, посвящённая творчеству З.МАНСУРОВА.*
*Фотоархив: фотографии из архива журнала «Казан утлары».*
*«Память»: статьи Т.БИКТИМЕРОВОЙ, Л.ЯНСУАР; стихи Ч.МУСИНА.*
*«Грот Абугалисины»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА, посвящённая 200-летию К.Насыри.*
*«Памятные письма»: письма А.Атнабаева, Р.Валиева, С.Хакима, Н.Наджми, В.Исхакова Р.Гаташу.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 85-летию Ф.АХТЯМОВОЙ и 80-летию Н.ДАВЛЕТА. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: центр семьи «Казан». Фото И.АБРАМОВОЙ; переводчик, публицист, писатель Фатих Кутлу.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by A.GAYAZOV «Which side does the sun rise from?», story by N.GILMUTDINOVA «Minbar of the Mentor», stories by R.ZAIDULLA; poems by Z.MANSUROV, CH.ZARIF, E.KHUSAINOVA.*
*«Literature of kindred peoples»: poems by R.UZDENOV, F.KARABASHEVA (UZDENOVA), SH.UZDENOVA.*
*«New names»: story by A.NURIEV «Chicken Case»; poems by A.BAKHAVIEVA.*
*Literary contest «Morals of the Father's House…»: story by G.GILEMKHANOVA «Pair Dance».*
*Literary criticism: article by T.GALIULLIN dedicated to the creative work of Z.MANSUROV.*
*Photo archive: photographs from the archive of the «Kazan Utlary» magazine.*
*«Memory»: articles by T.BIKTIMEROVA, L.YANSUAR; poems by CH.MUSIN.*
*«Abugalisina Grotto»: article by I.ZAGIDULLIN dedicated to the 200th anniversary of K.Nasyri.*
*«Memorable letters»: letters from A.Atnabaev, R.Valiev, S.Khakim, N.Najmi, V.Iskhakov to R.Gatash.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLAH.*
*«Priceless voices»: articles for the 85th anniversary of F.AKHTYAMOVA and the 80th anniversary of N.DAVLET.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: the Kazan family center. Photo by I.ABRAMOVA; translator, publicist, writer Fatih Kutlu.*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Казан» гаилә үзәге. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* тәрҗемәче, публицист, язучы Фатиһ КУТЛУ.